# Казан утлары

10. 1986





Тукай-Кырлай, 1986 ел

РИФ ЯКУПОВ фотохикәясе

Фотохикәянең дәвамы 158—159 битләрдә

# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

10

1986

## Бу санда

Н. АРСЛАНОВ. **Робагыйлар** . . . . . . . 3

БӨЕК ОКТЯБРЬНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

А. ГЫЙЛӘҖЕВ, А. ЛИТВИН. **Августның алтысына кадәр...** *Роман-хроника* . . . . . . 12
З. МАНСУРОВ. **Ярымшарлар.** *Шигырьләр* . . 77
Ә. БАЯНОВ. **Мәңгелек бәхәс.** *Повесть* . . . . 83
М. ШӘЙХИ. **Иделләрем, илләрем...** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 125
И. ӘХСӘНОВ. **Яктырдың чорга, замандаш...** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 128

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Ю. В. КОЖЕВНИКОВ. **Вузның иртәгәге көне** . 131

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

З. Г. КӘРИМОВ. **Аксубайлыларның йөзе ак...** *(Аксубай районы)* . . . . . . . . . . 136

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

М. ӘМИРХАНОВ. **Беренче председатель** . . . 138

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Яңалык — тормышта һәм әдәбиятта.** *Яшь тәнкыйтьчеләр әңгәмәсе* . . . . . . . . 144
Г. АХУНОВ, Ф. КАЮМОВА. **Тәрҗемә турында сөйләшәбез** . . . . . . . . . . . . . 149

БИБЛИОГРАФИЯ

Х. МӘХМҮТОВ. **Эпосны өйрәнүдә яңа адым** . . 153

КОНКУРСКА

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. **Тормышны ярату** . . . . 155

Г. ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Р. ЯКУПОВ. **Тукай-Кырлай, 1986 ел.** *Фотохикәя* . . . . . 158

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

Б. ИСХАКОВ. Тукай һәм казах әдәбияты . . . 160
Ф. ШӘҢГӘРӘЕВ. Кымызга бару юлында . . . 164

САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Ә. МАЛИКОВ. Сәҗидәгә хатлар . . . . . . 165

СӘНГАТЬ

Ф. ӘҺЛИУЛЛИНА. Җанлы учак . . . . . . 177
Р. ХИСМӘТУЛЛИН. Бер сорауга бер җавап . . 181

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Л. АРСЛАНОВ. Кемнәр алар «Әстерхан каракалпаклары»? . . . . . . . . . . . . 182

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Гомәр Бәшировның «И язмыш, язмыш» повесте турында фикерләр . . . . . . . . . . 187

АЕК БУЛ, ЗАМАНГА ЛАЕК БУЛ!

М. САТТАРОВ. Әлкәш Ибрай бәете . . . . . 189

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

## *В нашем номере*

Окончание романа-хроники А. ГИЛЯЗОВА и А. ЛИТВИНА «До шестого августа...» Повесть А. БАЯНОВА «Вечный спор». Стихи Н. АРСЛАНОВА, З. МАНСУРОВА, М. ШАЙХИ, И. АХСАНОВА.
«Решения XXVII съезда КПСС — в жизнь!» — статья Ю. В. КОЖЕВНИКОВА «Завтрашний день вуза».
«Татарстан — родной мой край» — выступление первого секретаря Аксубаевского райкома КПСС З. Г. КАРИМОВА.
«Литературный пост — ТатАЭС» — очерк М. АМИРХАНОВА.
«Новое в жизни и в литературе» — «Круглый стол» молодых критиков. В журнале продолжается дискуссия о проблемах перевода. Рецензии на книги Ф. Урманчеева и Т. Миннуллина, отзывы о новой повести Г. Баширова.
К 100-летию Г. Тукая: статья Б. ИСХАКОВА «Тукай и казахская литература» и другие материалы.
К 60-летию со дня рождения С. Сулеймановой публикуются письма к поэтессе.
В рубрике «Искусство» очерк Ф. АГЛИУЛЛИНОЙ о народном артисте РСФСР, лауреате Государственных премий СССР и ТАССР Р. Тазетдинове.
К истории культуры: статья Л. АРСЛАНОВА «Кто такие астраханские каракалпаки?»
В рубрике «За трезвый образ жизни» — стихи М. САТТАРОВА.
«Дневник культурной жизни».
На наших обложках — творчество художника А. Тумашева.

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, А. Минһаҗева.*

Производствога бирелде 6.08.1986 ел. Басарга кул куелды 3.10.1986 ел. ПФ 05371. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8)
Тираж 62449. Заказ В-307. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

## Нури Арсланов

# РОБАГЫЙЛАР

Тукай бик яшь килеш мөнбәргә менде,
Халыкның аһ-зарын киң илдә күрде.
Шагыйрь булып бөтен төрки халыкка
Яши җирдә, бөек булганга күңле.

* * *

Нигә коллык богаулары кияргә,
Берәүгә бил бөгеп ник баш иярга?!
Җәяү калма, онытма кемлегеңне,
Егет булсаң, менеп атлан иярга!

* * *

Бабалар һәм аталар килде, китте...
Алар безне җиһанга варис итте,—
Варислар җир бүлә — гауга да шау-шу,
Иминлек язмышы һаман да шикле...

* * *

Сугышта илле миллионлап кырылды...
Кара язмыш ләкин бездән борылды;
Үлемнән туймаса туймый берәүләр,—
Дәшеп дауга тагын кычкырта быргы.

* * *

Мүлек йоткан чабакны йотты чуртан,
Ә чуртанны балыкчы тотты шуннан.
Хәятта күп язылмаган кануннар:
Үти һәр җан иясе... килсә кулдан.

* * *

Килеп кәрван, кичеп күп төрле җирләр,
Төнәргә дип учак яндырды ирләр:
Җылыткан, якты биргән шул учакның,
Китеп кәрван, көлен туздырды җилләр...

* * *

Багын алтынга манды патша Шәддат,
Кыядан су чыгарды көчле Фәрһад:
Бере — даннан, бере мәхрүм гыйшыктан,—
Әзәлдә[1] без дигәнчә булмый, һәйһат![2]

* * *

Ике төрле икән мәгънәсе «дәрт»нең,
Була бирсен, ике дәрткә дә мәндмен[3]:
Бере — кайгы, бере — рух омтылышлы,
Шуңадыр мин шәкерте Дәрдемәнднең.

* * *

Тимер Ләнк[4], урнашып алтын тәхеткә,
Талап илләр, ирешкән ди «бәхеткә».
Сыялмый тарсынып ярты җиһанны
Сыйган бит Гүр-Әмирдә[5] тар ләхеткә.

* * *

Казаныш килми ул тик дан яратып,
Юнәлдер йөзне хезмәткә каратып,
Бәхет, абруйга илтер тугры юлны
Табалмассың тырышлыктан да артык!

* * *

Караңгыны җиңә бер шәм генә дә;
Кояш син! Мин — кояштан бер күләгә.
Кая дәгъва кылу ул зур өметләр!
Бәхет миңа сине күрсәм генә дә...

* * *

Ачык тәрәзгә тын төн элде аен,
Уятты сандугач сайрап тугаен:
Уянды яктылык, хикмәт, мәхәббәт,
Ачылды ай кебек балкып чыраем.

* * *

Җиһанда күпме мескен бар өлешсез,
Кунар җай, эшле көн яуларга көчсез...
Шөкер кыл, илдәшем, үз хәлебезгә:
Я, кем бар બездә йортсыз, ач һәм эшсез?

---

[1] Әзәл — мәңгелек.
[2] Һәйһат — мөмкин булмаган әйбер турында өзгәләнеп әйту.
[3] Мәндмен — иямен, икесе дә миндә бар мәгънәсендә.
[4] Тимер Ләнк — Аксак Тимер.
[5] Гүр-Әмир — Тимер-Ләнкнең кабере.

* * *

Тагын да яхшырак яшәр идек тә,—
«Тынычлык!» — дип үзәкләр өзелә тиккә...
Арынса җир кирәкмәс борчулардан,
Йөзәр идек иминлектә, иректә!

* * *

Юлыксаң юлда җитди каршылыкка,
Егетлек күрсәт, ир, мәйданга чык та.
Чыгаргансың икән кыннан кылычны,
Чабып өзми торып һич кынга тыкма!

* * *

И башкорт көйләре шук тай шикелле,
Даладагы сихерле ай шикелле:
Бер уйнак, бер тирән моңлы-сагышлы,
Кереп ята йөрәккә май шикелле.

* * *

Төсен йөртәм фашист биргән «бүләкнең»,—
Таяк тотсам да юлда мин, кирәкмен.
Серен ачтың яшәүнең, изге халкым,
Кирәк булырга да үзең өйрәттең.

* * *

Минем сүз уйнатырга оста халкым:
«Сөйләү — көмеш,— дигән,— эндәшмәү — алтын.
Хәзер бу искерә төшкән төшүен,
Шулай да син чамалап сөйлә артын.

* * *

Миләш янды, кызарды... Җитте кышлар,
Җимеш чүпләп ботакка кунды кошлар.
Шәрә калган миләшкә охшый күрмә:
Берәм-берәм тарала башлый дуслар...

* * *

— Миңа буйсын! — диде, мин баш imәдем,
Рәхим-шәфкать сорап: «кызган!» — димәдем,
Якалашты җаным гомер-гомергә,
Ә язмыш пошмады — бирде кирәген...

* * *

Алай ит тә болай ит ди врачлар,
Киңәшләрдән тәмам әйләнде башлар...
Яшәп карыйм әле тагын үземчә:
Кая ширбәт, китер кыздырган ашлар!

* * *

Күзен сирпеп урамнан үтте берсе,
Йөзендә балкый тылсым, күрдегезме?!
Сөеп еллар акылдан язды Мәҗнүн,
Бу бер күз атты — Мәҗнүн итте безне...

* * *

«Үзем!» — димә, борын чөймә — масайма,
Бүтәннәрне алай түбәнгә сайма:
Эрелек һәм дә ваклык бертуганнар,
Кечелек шәп сыйфат, син шуны сайла.

* * *

Миңа: Эзлән,— диделәр,—үргә бар эз!
Чыгып киттем, арып та чүкмәдем тез:
Карасам әйләнеп — артымда кәрван,
Кая ару! Сынатмыйм, атлыймын төз.

* * *

Кояш хикмәтле уйлар төсле якты,
Тагын иртүк торып тапты, уятты.
Күгемдә — ул, күңелдә — бай хыялым,
Я нәрсә бар, хәят, синнән дә татлы!

* * *

Үлем хөкме язылган без тугач та,
Хисапсыз борчулар тулган бу башка...
Фанилеген хәятнең бик беләбез,
Ләкин мөмкин түгел дөнья кумаска.

* * *

Кеше акылы үсеп буйларга җитте,
Җиһанны тарсынып айларга китте:
Уңышлардан масаймасмы замана,
Чара бармы үлемгә куйса битне?!

* * *

Әзәл — фани, аның төрле чагы бар,
Язылмышның карасы бар, агы бар...
Табарга син тырыш әйбәт сыйфатын —
Һәр инсанның яман-яхшы ягы бар.

* * *

И дөньяның гүзәл яклары чиксез!
Шулардан файдаланмый кайбер ипсез:
Исән чакта яшәп кал дип өйрәткән
Гомәр Хәйям, ә без... хикмәткә җикбез.

* * *

Хәкарәтләү берәүгә берни тормый,
Аның тырнаклары һәр җанны тырный.
Сөрә дәуран адәм сынлы бу ерткыч,
Ничек шундый каһәрне каргыш ормый?!

* * *

Кырык елда кырык уй төште башка,
Шулай да кермәдек ызгыш-талашка,—
Акыл дәвере Җиһанда! Вәхшилеккә
Кире кайт ди имеш, күкләргә аш та!

* * *

Шулай, хаким, эшең уңмас бу көйгә,
Җиңеп булмый бит әверелеп бүкигә:
Сынап бактың: ысуллар төрле-төрле,—
Сиңа каршы бөтен дөнья ду килә!

* * *

Арыслан иснәгәндә, сантый чыпчык
Очып кергән ди уртка, дәүне борчып,
Арыслан чирканып шунда төкергән:
— Сөяк ни, ит ни синнән, әйдә бар, чык!

* * *

Юату, иркәләүләргә баемсың,
Караңгыда карап торган аемсың,—
Синең сулышың белән яшим җиһанда,
Аерса язмышым — җаннан аерсын!

* * *

Яшен атты — янып күкләргә аштым,
Томан сарды — болытларга тоташтым:
Рухым йолдыз булып балкып кабынды
Фәкать бер ымлавыннан серле кашның.

* * *

Килә язлар: күңелләр азмый булмас,
Килә илһам: шигырьләр язмый булмас:
Мәхәббәт моң чала тылсымлы сазда,
Булам Мәҗнүн, акылдан язмый булмас!

* * *

Шагыйрь Мәшрәб [6] руханиларга, ханга
Сүз атты ук итеп, куптарды гауга:

[6] Мәшрәб — *Дивана-и* Мәшрәб — үзбәк шагыйре.

«Дивана» дип кушамат алды башта,
Кара язмыш соңыннан асты дарга.

* * *

Чәчәкнең сандугачка аллары бар,
Тырыш кортларга җимгә баллары бар.
Син алымсың минем, татлы балымсың,
Телеңдә сандугач сайраулары бар.

* * *

Кирәкмәс борчулардан тынгы тапмыйм,
Җаным тетри, ишекле-түрле атлыйм.
Ничек әйтеп бирергә бу халәтне? —
Тимер читлектәге каплан да тап мин.

* * *

Шаярсам мин шаярмыйм мутлыгымнан,
Көлеп, уйнап яшим килгәнчә кулдан:
Тумыштан холкы шук булса берәүнең
Сөмәйми андый язмыш шуклыгыннан.

* * *

Меналсаң мен икән үргә дә үргә,
Офыкларны асат аннан күрергә:
Хәят манзарасын өстән тамаша
Кыла бөркет тә бит таулар түрендә!

* * *

Букефалдан[7] имеш шаһ Дарий [8] качкан.
Дөреслек беркадәр бар монда, баксаң:
Әл-Искәндәр җиһанда яулап илләр
Шул атта бит тәхет-таҗларны баскан.

* * *

Явызлыклар кылып әллә үкендең?
— Гаепле мин,— дидең, гафу үтендең.
Гафу иттем... шугалак бер балык син,
Белеп торам сытылганын үтеңнең.

* * *

Акан Актуктысын [9] алган да качкан,
Ике яр бер йөрәк булып тоташкан.
Аларны тик аерганнар кугыннар:
Ләкин аерып буламы күзне каштан!

---

[7] Букефал — Александр Македонияленең сугыш аты.
[8] Дарий — Иран шаһы.
[9] Акан — бөек казакъ акыны. Актукты (Акбәрән) — сөйгән кызы.

* * *

Алишларга, бөек Муса Җәлилгә
Боермады исән кайтырга илгә...
Тик акчарлак булып рухы аларның
Яши безнең белән бергә Иделдә.

* * *

Чыраеңны күреп таң калганым бар,
Бер өнсез күз атып ялварганым бар:
Дерелдәр дип синең керфекләрең дә
Өметләнеп, көтеп... алданганым бар.

* * *

Танышлардан берәү бар — иллә бәндә!
Теләндә: «Вәгъдә — иман!» ә гамәлдә:
Ышандыра, үтәми бер сүзен дә,—
Имансыз вәгъдәдә соң нинди мәгънә?!.

* * *

Иген акты көзен алтын улакка,
Өйләргә керде — әверелде коймакка:
Чәчеп-урганда ил хуҗа саналса,
Хәзер икмәк — хуҗа, ә без — кунакта.

* * *

Берәүләр күчмә дип йөргәндә таплап,
Игенчене Сараи [10] чыкты мактап:
Идел йорты — иген йорты икәнне
Шагыйрь шигърендә безгә бирде раслап.

* * *

Ни әйтсәң дә тамандыр бу АКШка,
Хуҗа мин ди Чыгышка һәм Батышка [11].
Яшәү кадерен тоеп илләр җиһанда
Бер әйтерме: «Җитәр сиңа, катышма!»

* * *

Хатом-Тай [12] булмасам да бит юмартмын,
Тырыш хезмәттә тик бәхтемне таптым,
Гөнаһым юк иде ул чаклы, язмыш,
Сизиф [13] ташы биреп ник аптыраттың?

---

[10] Сәйфи Сараи — XIV йөздә яшәгән татар шагыйре.
[11] Чыгыш, Батыш — Көнчыгыш, Көнбатыш.
[12] Хатом-Тай — Көнчыгыш дастаннарындагы юмарт кеше.
[13] Сизиф — саранлыгы өчен теге дөньяда тауга таш тәгәрәтеп мендерергә хөкем ителгән кеше. Менеп җитүгә таш тәгәрәп төшеп китә икән.

* * *

Суларда батмады ир, йөзде-чыкты.
Янып утта корыч төсле чыныкты.
Батырлыклар күренми калса-калды,
Ләкин дошманга ул кылды кылыкны!

* * *

Хисем дип һич лаф ормас хисле бәндә,
Хис ул көчсез халыктан иңмәгәндә:
Үзеңнең кайтавазсыз хисләреңне
Әҗәл даруы диеп белдеңме әллә!

* * *

Тыныч төн. Җиргә йолдызлар түгелгән,
Казан балкый, көмеш бәскә күмелгән:
Көмеш төндә, хәтерлим, яуга киттем,
Көмеш таңда исән кайттым үлемнән.

* * *

Көтәм... белмим үзем, кемне көтәмдер,
Килер төсле... нигә өмет итәмдер?
Яшим ялгыз, сагыштан сыкрый җаным,
Тыныч ял да гаҗәп борчу икән бер...

* * *

Асау ат төсле мин җилдән дә өркәм.
Бөтен рәнҗешләремне эчтә йөртәм,—
Ни файда зарланудан, аһ орудан?!
Шунадыр тынгы бирми бер дә теңкәм.

* * *

Күтәргән җилкәсенә җирне Атлант[14].
Галәм әйтә аңа: — Сак бар,— ди,— атлап!
Бөтен йолдызлы юлга газраилләр
Куя бомба, агяһ[15] бул, китмә шартлап!

* * *

Сабый чак бирде тай, алтын тояклы,
Менеп чаптым карамый алны-артны:
Хыяллардан юлымда үсте таулар,
Тәмам эштән чыгардым аргамакны...

* * *

Шөкер әле, ярыйсы хәлләрем дә,
Күзем, күңлем замана ямьнәрендә:

[14] Атлант — җирне җилкәсендә тотып торучы дәү.
[15] Агяһ бул — гафил булма, белеп тор.

Канәгать мин күреп уртак сыйфатлар
Үземдә һәм Туфан Әлмәндәрендә[16].

* * *

Мисырга чапты яу җитмеш мең атлы,
Һәлак булды сәмумда, комга батты...
Ә мин, бөртек кенә булсам да, комнан
Давыллардан сөйрәп чыктым хәятны.

* * *

Ирек, ирек дияргә без күнеккән!
Шөкер, иске йолалар бетте күптән:
Яңа дип бик алай тезген бушатма,
Тәмам маймыллашып китмик иректән.

* * *

Төн. Ай балкый көмеш балдак кигән дә,
Тәрәздән яктысы төшкән идәнгә.
Менә шат Кар кызы кергән яныма,
Мөгаен, «Кыш бабай шулдыр», дигән дә.

* * *

Бала чактан күңел сәнгатькә тартты,
Зәвыкне сәхнәдә, җырлауда тапты,
Рәсемнәр дә төшерде... Әмма шигърем
Гомергә тынгы бирми аптыратты.

..........

16 Әлмәндәр — драматург Туфан Миңнуллин пьесасындагы үлемсез кеше.

**Аяз Гыйләҗев,**
**Алексей Литвин**

# АВГУСТНЫҢ АЛТЫСЫНА КАДӘР...

**РОМАН-ХРОНИКА**

Унсигезенче елның соңгы көне минем өчен әнә шулай тәмамланды — нидер югалттык, нидер табылды; йомшак якларыбыз да ачылды, көчле якларыбыз да...

Ольканицкийны үтерүчеләр килеп капты.

Таняны чактан гына югалтмадым. Әйтергә ансат! Леонид Заковский 1 июльдә Мәскәүгә кайтып китте, мине әлегә Казанда калдырдылар. Үзем дә бик атлыгып тормый идем, күнектем, шәһәрне яраттым. Җәйнең иң эссе ае Казан чекистлары өчен моңарчы булмаганча тагын да кайнаррак булып чыкты, эштән аерыла алмадым. Таня яныннан болай җиңел генә китә дә алмый идем, ул үзе беләдерме-юктырмы, соңгы көннәрдә ул миңа үтә кадерле, чамасыз кыйммәтле бер затка әйләнеп бара. Рухи таянычым дип атасам да дөрес булыр. Аны югалтырга курка идем мин хәзер. Ташлап китсәм бу матавык заманда ни булмас та, нинди хәлләр очрамас дисең...

Университет тәмамлап югары белем алырга өлгермәсәм дә, иске китапларны, борынгы кулъязмаларны актарырга гомер-гомергә яраттым. Аларда адәм баласының зирәклеге дә, тинтәклеге дә берегеп калган. Кеше артык картаймастан да элек, билгеле бер яшенә җиткәч, үзеннән соң ни каласы турында уйлана башлый. Әйе, кеше гомере гаҗәп кыска һәм ул тиешле, мәгънәле чорларга искиткеч тапкыр бүленгән — үзеннән соң ни каласын уйлый башлавы аның картлыкка күчү чоры. Көн саен кайнар иҗат дәрте белән янып яшәгән даһи гына гомер агышы турында уйланмый! Шуңамы, аның кайнар дәрт, сүнмәс җан учагында туган әсәрләрендә заманның үлемсезлек билгеләре чагылыш таба. Даһи эчке сиземләү белән заманның бар булган төсмерләрен тоя ала. Пушкин белән Лермонтов, Бетховен белән Моцарт әнә шундыйлардан. Үз заманнарында аларга мөнәсәбәт төрлечә булып, алар якты дөньядан гадәттә иртәрәк, күп очракта үз ихтыярларыннан башка китеп барганнар. Вакытлар узу белән алар исеменә нисбәтле һәр нәрсә изгегә әверелгән, бөтен тормышлары илаһи итеп сурәтләнгән, кимчелекләре исә язмыш иркәләгән җаннарның гөнаһсыз шуклыгы булып кына телләрдә калган. Без, яшьтән үк Лермонтовның гүзәл шигырен укып, Пушкин күкрәгенә кургаш ядрә кереп гомерен чикләгәнен беләбез... Гәрчә бик күпләр аның күкрәге түгел, корсагы яраланып, перитониттан үлүен

---

Ахыры. Башы журналның 9 нчы санында.

дә beләләр булыр. Медицина раслаган шушы хакыйкатьнең бозылуына берәүнең дә исе китми: чөнки Пушкин белән Лермонтов дөньяга гүзәллекне шулкадәр мул бүләк итteләр ки, алар безнең инануыбызча, күкрәккә күкрәк килеп, бары тик ирләрчә горур үлә алалар да! Даһи кеше ямьсез яки куркак була алмый ди безнең аңыбыз һәм чыннан да, хакыйкатьнең һәр хәрефенә ябышып ятуның кирәге бармы икән?! Бу очракта да шулай: кургаш ядрә бөек Пушкинның күкрәгенә генә кадала ала!

Фән һәм тикшерүләр исә хакыйкатькә таянмыйча яши алмыйлар, чөнки ансыз дөрес нәтиҗәгә ирешеп булмый. Вакыйгаларның характеры да, бер-берсен тулыландырып үсеп баруы да нәкъ заманындагыча ачылырга тиеш. Буыннар алмашынып, җиргә һәм фәнгә яңа кешеләр килгәч, без яшәгән чорда булып узганнарны үзгәртеп язасыларын чамалый идем мин. Алар без белгәннән күбрәк беләчәк, вакыйгаларны нәтиҗәләр югарылыгыннан калкурак күрә алачак. Алар, Маркс тәгълиматына таянып, «яңа җәмгыятьнең элгәреп капитализм әзерләде» дип төпле сүз әйтеп нокта да куячаклар.

Болары әле алда булыр, ә без, интегеп-тилмереп, бик күп сорауларга җавап эзләдек. Тормышның һәр очрагына яраклы рецептның булмавын, була алмасын белгән хәлдә тырмашып-тырмашып эзләдек. Без өлкәннәр, ил аксакаллары белән киңәшеп-аңлашып, революцияләр тарихын яктырткан китапларны кат-кат актарып хакыйкатьне табарга, белергә тырыштык. Безнең арага килеп кергән очраклы бушбугазлар, «күпбеләмлек» чиренә чорналган сул эсерлар белән бәхәсләрдә безгә Англия, Франция, Париж коммунасы һәм Россия тарихы ярдәм итте. Россия тарихы — күп тармаклы зур тарих, аның дәвамында буыннар гына түгел, халыклар алышынган, берәүләр килгән — эз калдырган, берәүләр килгән — эзсез-нисез югалганнар. Нигә? Нилектән алай?

Кайберәүләр: «Буталчык заманда яшәгәнсез, рәхәт күрмәгәнсез»,— дип, безне ышандырырга азапланса да, без үзебез яшәгән заман белән горурланабыз. Безне барыннан да бигрәк яңа җәмгыятьтә — көчебезне,вакытыбызны, кирәк чакта гомеребезне дә биреп корган яңа җәмгыятьтә яшәргә тиешле кешеләр тормышы кызыксындыра иде. Без барыбыз да бер нәрсәгә инанабыз, бер җәһәттән иманыбыз камил: авырлыклар узар, дошманны тар-мар итәрбез, җимерекләрне торгызырбыз, аннан соң ни булыр? Барыбызның да ул якты көннәргә барып җитә алмаслыгын белә идек, әмма барып җиткәннәрнең бик бәхетле булуын тели идек. «Корбаннар юкка булмады!» — дип әйтерлек заман килсен иде!

Еллар үткәч, безнең хакта да китаплар язылыр. Китапларның үз укучысы булыр. Кем язар икән дә ничек язар? Ул язганнарны яңа заман кешеләре ничек кабул итәр?

Күптән түгел генә тагын бер «ачыш» ясадым... Уртакул язучы, даһига караганда, үз чорын яхшырак һәм төгәлрәк ачып сала. «Уртакул» үзе яшәгән заманның стандарт фикерләреннән узып китә алмый, ул алга ыргылмый, хәленнән дә килми. Даһи исә заманның гади генә бер вакыйгасында гомумкешелек орлыкларын яки сирәк очрый торган, башкалар әле танып-белергә өлгермәгән күренешләрне дә абайлап ала... Мәгәр мин безнең хакта тегеләренең дә, боларының да күбрәк язуын теләр идем.

Сизенмәстән хыялга бирелдем, ә тормыш чынлыгыннан ычкынып китеп булмый, ул хыялга караганда да аяусызрак һәм фаҗигалерәк. «Без дөньяда иң гадел көрәш алып барабыз»,— дидек. Ә менә кичә спекулянтлар эшен карадык. Шуларның байлыгын конфискацияләгән, шул мөлкәтнең бер өлешен бүтәннәр аша базарда саттырган, чекистлар арасына үрмәләгән бер бәндәне атарга туры килде. Нәсел-нәсәбе таза, эшче арасыннан чыккан, җыелышларда кулын иң элек күтәргән, күрер

күзгә гап-гади кеше... Вакыйгаларны гына түгел, кешеләрне дә аңлау кыен кайчакта.

Я, ни этәргән аны бу җинаятькә? Ул да безнең белән бергә якты киләчәккә омтыла иде бит?!

Сул эсерлар һаман канга тоз сала. Мин Вера Петровна Брауденың шулар арасында әгъза булып торуын аңламыйм, бу турыда әйтергә дә йөрим, җае гына чыкмый. Мин болай, узып барышлый гына, тиктомалдан кешенең иманына кагылырга базмыйм. Ярамый да.

Эсерлар комитеты Казанның Большой Проломный һәм Университет урамнары чатындагы бинада. Шейнкман берзаман аларны, усал шаяртып, «җимерүче большевиклар» дип атаган иде. Күп нәрсәләрдән риза булмасак та әлегә Вера Петровнага бәйләнер урын юк, без бергә. Мәгәр нәразыйлык һаман арта тора. Июнь азагында сул эсерлар партиясе Үзәк комитетының Брест солыхын көчләп өзү турында карар кабул итүе безгә көне-сәгате белән килеп иреште. Мәскәүдә Германия илчелеге хезмәткәрләренә һөҗүм — бу карарны тормышка ашыруның башы булды дисәк тә ярый. Шул чакта ук Мәскәү консерваториясенең кечё залында сул эсерлар партиясенең 3 нче съезды җыелды. Партияләрендә ул чакта сиксән меңгә якын әгъза исәпләнә иде. Съезд материаллары матбугатта игълан ителмәсә дә, белдек: сул эсерлар, Совет властена шелтә белдереп, тәнкыйтьләп кенә калмаганнар, алар власть өчен большевиклар белән көрәшергә, дәүләт башына менеп утырырга ниятләгәннәр.

Партия лидеры Мария Спиридонова болай дип чыгыш ясый:

«Безнең партия массаларны күтәрелешкә өндәп, восстание барышында ут төртергә, котыртырга, кирегә сукаларга, кыскасы, бар җаваплылыкны үз өстенә алырга тиеш. Бары тик күтәрелеш аша гына без үз өстебезгә ябырылган афәттән котыла алачакбыз».

Съездда Казан делегатлары Андрей Колегаев, Илья Майоров һәм Казимир Шнуровскийлар да авыз йомып утырмый, алар губернада өч меңгә якын эсер барлыгын, губбашкармада сул эсерларның күпчелекне тотуын мактанып белдерәләр. Колегаев алай да крестьяннарның немецлар белән яңа сугышны теләмәүләрен, совет власте сәясәтенең байтак пунктлары, җөмләдән, азык-төлек программасы белән килешмәсәләр дә, властька каршы күтәрелергә риза түгеллекләрен икърар итә.

Әмма партия житәкчелеге съездда кораллы күтәрелешкә чакыруны уздыра: «3 нче съезд,— диелә аның резолюциясендә,— үзенең тәэсир итә алу көче һәм партия аппараты катнашы белән совет сәясәтен хак юлга төшерергә тиеш».

Ни дигән сүз иде бу?

Байтактан бирле сүздән коралга күчәргә кызышып яткан сул эсерларның ачыктан-ачык көрәшкә чыгулары идеме?

1918 елның 4 июлендә Советларның 5 нче Бөтенроссия съезды ачылырга тиеш. Сул эсерларның бу көнне фетнә белән билгеләп узарга ниятләвен безгә Дзержинский һәм Петерс хәбәр итеп кисәттеләр. Шул уңайдан сул эсер житәкчеләренә күз-колак булырга тәкъдим ителде, чекада эшләүче сул эсерларга тулысынча ышанмаска кушылды. Казанда урнашкан Көнчыгыш фронтның командующие сул эсер Муравьевка һәм өлкәдәге кулакларның баш күтәрүләренә аерым игътибар итәргә боерылды. Сул эсерлар ничаклы нык әзерләнсәләр дә, Казан чекистлары бу ф е т н ә н е дә булдырмый калырга тиешләр!

Без соңгы вакытта бишәү — бер-беребезгә тулысынча ышана торган биш большевик кына җыелып сөйләшә идек: Кин, Таһиров, Аристов, Вәлиуллин һәм мин. Саклык чараларын көннән-көн арттырабыз, чөнки бергә эшләүче башка иптәшләрнең язмышы хәзер тулысынча безгә бәйләнгән. Яңа шартлар туса, алар үзләрен ничек тотарлар? Революцион намуслылык, партия дисциплинасы гамәлдә калып, халык алдындагы бурычларын башкарып чыга алырлармы?

Казандагы гомуми хәл болайрак иде: Советларның 5 нче съездына сайлау исемлекләреннән 8 большевик, 18 сул эсер һәм бер партиясез бара. Тагын ике коммунист — Измайлов белән Шейнкман, бер сул эсер — Шляпников исемлектән тыш барачаклар. Алардан алдарак үз съездларына киткән сул эсер делегациягә Мәскәүдә кушылачак.

— Сигез большевик... азрак шул! — дидем мин Межлаукка. Колегаев турында фикер алышырга Межлаук янына кергән идем. Межлаук минем һушымны ала язды...

— Китәр алдыннан Колегаев минем янга кергән иде,— диде военком Межлаук.— Мәскәүдән җаваплы кешеләрнең берсе сорады дип, миннән биш пот динамит бирүне үтенде.

Бу хәбәрне иптәшләргә җиткердем.

— Межлаук биргәнме соң? — дип сорады Таһиров.

— Бирүен бирмәгән, әмма ул да бик гаҗәпләнеп калган. Каян чыккан андый үтенеч? Мәскәүдән кем сораткан? Кемгә кирәк булган шулкадәр динамит? Нигә?.. Съезд алдыннан бит! Димәк, алар нидер маташтыралар!

Бу хәбәрне телефоннан Петерска җиткердек: «Съезд алдыннан мәскәүле сул эсерлар биш пот динамит сораткannар!»

Бу сәер һәм бик күңелсез хәбәрдән соң без сул эсерларга башка күз беләнрәк карый башладык. Казанда сул эсерлар комитетын Зубарев җитәкли. Комитет членнары Колегаев, Майоров, Пономарев, Попов — безгә бик билгеле кешеләр. Губернада сул эсерлар газетасы «Җир һәм ирек өчен»нең башында да сул эсер — Шнуровский. Хәтта губерна газетасы «Революция байрагы»н да сул эсер Ионов чыгара! Әгәр алар партиясе җитәкчеләре безгә каршы күтәрелсә — газеталар нишләр? Колегаев, Ионов, Шнуровскийлар — акылсыз егетләр түгел, әмма алар артында торган өч мең кеше кая таба карар? Кул кушырып утырырлармы? Шәһәрдә эсерларның кораллы ике дружинасы, ике йөзгә якын кораллы сугышчылары, пулеметлары, винтовкалары, гранаталары бар!

Көнчыгыш фронтының башкомандующие сул эсер Муравьев карамагындагы кораллы гаскәрне дә саный китсәң... Алар нишләр дә кайсы якка борылыр?

Һәр революция, француз революциясе кебек үк, үз Наполеонын тудыра. Михаил Артемьевич Муравьев — иске армиянең подполковнигы, сәяси яктан тотрыклы кеше түгел, тәкәббер, данга һәм мактауга сусаган, үзен бик зурга куя торган чуар җан иде. Россия революциясендә Наполеон булу бәхете аңа, Муравьевка язган дип ышана торган буш куык иде.

1917 елның ноябрендә Смольныйга килә ул һәм Совет властена хезмәт итәргә әзер икәнлеген белдерә. Керенский-Красновның революцион Петроградка һөҗүме вакытында шәһәр оборонасын җитәкли, соңрак Петроград оборонасының командующие була. Сәләтле һәм батыр офицер буларак таныла. 1917 елның декабрендә Антонов-Овсеенко җитәкләгән совет гаскәрләренең штаб начальнигы итеп билгеләнә. Калединның ак казаклары һәм Үзәк украин радасының гайдамаклары белән сугышларда катнаша. Аннары аны совет гаскәрләренең командующие итеп күтәрәләр. Монда инде аның сәләте, сәләтеннән дә бигрәк тотнаксызлыгы ачыла башлый. 1918 елның апрелендә яңа назначение алырга дип Муравьев Мәскәүгә чакырыла. Дзержинский ревтрибуналның тикшерү комиссиясеннән Муравьевны кулга алып гаепләүне таләп итә. «Комиссия Муравьевның совет властена яраксыз командующий булуы турында хәбәрләр алды. Гаепләүләр төп бер юнәлешкә кайтып калалар: иң әшәке дошман да мондый кот очарлык үч алуларга маһир түгел... Атулар, бозыклыклар, талаулар, җиңүдән соң солдатларга шәһәр-авылларны таларга тапшыру... Болары белән ул безгә чиксез зыян салды. Халыкны безгә каршы аякландырып, ул бөтен башбаштаклыкны совет власте исеменнән башкара».

Муравьевны шунда ук кулга алалар, әмма кайбер хәрбиләрнең үтенеченнән соң азат та итәләр. Алай гына да түгел, озакламыйча аны республиканың төп фронтына әйләнгән Көнчыгыш фронтының командующие итеп билгеләләр...

20 июньдә ул штабы белән Казанга килеп төшә һәм Щетинкин номерларына урнаша.

Чекага хәбәрләр ява башлады: Муравьев бөтен митингларда катнашырга тырыша, сул эсерларның барлык җыелышларына бара, кемгәдер тәлинкә тота, кемнәргәдер койрык болгый, котырта, астыртын яный, куркыта, чакыра — кыскасы, тик торганы юк!

Хәбибулла Вәлиуллин ике хәбәр китерде. Берсе — Муравьевның Казаннан фронтка китүче кызылармеецлар алдында ясаган чыгышы. Ул үзе җитәкләгән ставка исеменнән мөрәҗәгать итә. «Без сезнең белән бөек эшләр башкарырбыз! Кулга төшкән һәр шәһәрне мин сезнең ихтыярга тапшырам. Җиңел яраланганнар 500 сум алачак, һәлак булганнарның гаиләләренә миннән меңәр сум! Сүземдә торуымны минем белән Украинада булганнар расласын! Безне бөек эшләр көтә!» — дип кабатлый командующий.

— Моны ничек аңларга? — диде аптырап Хәбибулла.

— Аңлау кыен түгел түгелен, хәбәре бик начар! Ул Наполеон булып кылана, кызылармеецларны ялланган солдатлар урынына күрә. Революция өчен көрәш юлындагыларны олы юлдагы талаучыларга тиңли.

Вәлиуллинның икенче хәбәре тагын да аянычлырак иде.

— Бусына үзем шаһит,— диде ул.— Мин дә Муравьев бүлмәсендә идем. Хәрби контроль башлыгы Файерман да шунда. Берзаман 1 нче Казан совет ирекләләре полкының командиры белән комиссары килеп керде. «Полк фронтка чыгып китүдән баш тарта, бүгенгәчә солдатларга июнь ае өчен хезмәт хакы түләнмәгән, бүген егерме алтысы!» — диде командир. «Ах, әле сез революциягә хыянәт итәсезме? — дип акырды Муравьев.— Хәзер үк икесен дә атарга приказ бирәм!» Файерман, куян җан, револьверын чыгарып командирга төзәде, чакмасына да басты, револьверы гына атмады. Муравьев: «Тукта!» — дип боерды. «Командир да, комиссар да иртәгә полкны походка тулы әзерлек белән пристань мәйданында тезәләр, китәр алдыннан мин алар белән сөйләшә белермен!» — диде. Икенче көнне мин анда төштем, Муравьевның сөйләгәнен үз колагым белән ишеттем. «Сез, солдатлар, буржуйлар кесәсен калынайтыр өчен түгел, Октябрь революциясе казанышларын яклар өчен барасыз»,— диде. Полк пароходка төялә башлаганчы, шунда торды. Аннары: «Ярый, төялмәсәгез, мин сезгә күрсәтә идем!» — дип китеп барды. Иртәгәсен аңа, полкның күп өлеше пристаньда калды, дип хәбәр иткәннәр. Ул шунда ук ике броневик җибәреп, китми калган солдатларның һәммәсен юк итәргә боерган. Броневиклар барган, ата башлаганнар, кызылармеецлар патруле килеп чыгып кына чуалышны туктаткан.

Мин Вәлиуллин алдында ук Межлаукка шалтыраттым.

— Шашкан кеше ул, тинтәк! — диде военком.— Миңа әллә нинди тузга язмаган приказлар биреп ята. Бер сүзе икенчесенә капма-каршы килә. Бүген әйткәннәрен иртәгә тәмам оныткан була... Хыянәтче ул, болгаткыч таяк! Фронтта подполковник булмаган ул, капитан килеш йөргән, подполковник дәрәҗәсен аңа Керенский — мөгезсез кәҗә биргән!

— Нигә кулга алмыйбыз соң аны?

— Ашык-пошык кына кулга алып кара! Командующий, җитмәсә сул эсер...

Тагын киңәшмәгә җыелдык, белгәннәремне Кинга җиткердем.

— Муравьев кылган гамәлләре белән, чыннан да, зур шик тудыра,— диде Кин.— Тик ул кадәр холыксызланырга да урын юк. Аның адьютанты Александр Логинов — безнең кеше. Моны истән чыгарырга ярамый. Дөрес, ул артык яшь. Муравьев аның кем икәнен сизенәдер, бәлки, әлегә аны-моны белдерми. Логинов мине соңгы көннәрдә Муравьев төрле

адресларга суккан берничә телеграмма копиясе белән таныштырды. Мәсәлән, нарвоенкомның оператив бүлегенә егерме алтынчы июньдә киткән телеграмма. «Без армый-талмый әзерләнәбез һәм тиздән гаҗәеп хәлләр җанланачак. Башлаган эш тиз тәмамланачак. Гаскәрләр мине һәр җирдә алкышлап каршылый, фронтта да эшләр яхшыга бара». Яки менә хәрби ведомствода эшләүче берәүгә ул болай дип хәбәр итүне кирәк таба: «Гаскәрләр мине алкышларга күмгән саен, комиссарларның карасы коела. Миңа үпкәлиләр, өнәмиләр, гаскәрләргә мөрәҗәгать итсәм, үз имзаларын янәшә куймыйлар, сүзләремне ирештермиләр, тоткарлыйлар. Доносларыдан бик куркам. Төп эшемә ачыктан-ачык тыгылмасалар да, акрын-акрын аяк чалырга маташалар. Һәркөнне үз җанын куркыныч астына куйган кешегә ышанмауны ул болай бәяли: «Мехонишин командировкасы мине куркыта. Бу яңа революцион штабларга өмет бик аз. Шундый штабка килеп каптым, бөтенесен рәттән асып куяр идем!»

Кин, «танышыгыз» дигән сыман, безнең алга кәгазьләрне чәчеп ташлады. Димәк, Муравьевтан шикләнүләребез юкка гына түгел икән, чека председателендә шактый кыйммәтле информация тупланган. Кемнәр белән генә эш йөртә диген син аны: оператив бүлеккә хәбәр сала да, хәрби ведомствода эшләүчегә ачыла. Иш ишен таба...

— Бер нәрсә ачык — ул комиссарлардан курка. Бу гади тәкәбберлек кенә түгел инде... Курка икән — сәбәбе бар. Сәбәп нәрсәдә? Үзенең астыртын уе бармы, әллә башка берәүнең ихтыярына буйсынамы? Реввоенсовет председателе Кобозевның хәбәре дә игътибарга лаек, иптәшләр. Кобозев фронтта чактан файдаланып, Муравьев политкомиссар Благонравовның урынбасары итеп сул эсерны билгеләгән. Кобозевның кая булса да киткәнен көтеп кенә тора, губбашкармадагы җаваплы урыннарга тизрәк сул эсерны китереп тыга икән!.. Хәбәрләргә караганда, Муравьев штабында, ничә карама, элекке офицерлар айкала, черкеска кигән купшы кешеләр кереп-чыгып йөри, эсер-максималистлар отряды командиры Трофимовский көне-төне шунда. Әшнәсе! Аның кешеләре, эчеп, шәһәрдә шау-шу кубаралар. Игътибар итегез: крепостьтагы серблар отряды командиры майор Благотович та аңа әшнә! Бу батальон офицерлары совет властен өнәмиләр. Аристовның хәбәр итүенә караганда, Благотович Сербиянең король хәрби миссиясе белән бәйләнештә тора, Казан халләрен чит дәүләт илчелекләренә шул хәбәр итә! — Кин боерык биргән тонга күчте.— Шулардан чыгып, минем тәкъдимем: безнең чека составында өч оператив группа булдырырга. Николай Семенович Дунаев җитәкләгән группа «Ватанны һәм ирекне саклау союзы» кешеләрен — Савинков койрыкларын эзләүне дәвам итсен. Муравьевны күзәтеп, аның яраннарының хәрәкәтен билгеләп, кирәк чакта ашыгыч чаралар күрүне Евгений Антонов группасына йөклибез. Антонов Донбасстан килде, шахтер, большевик, Донецк чекасында эшләгән. Инде сул эсерлар артыннан күзәтү кебек катлаулы бурычны Вера Петровна Браудега тапшырыйк. Дөрес, ул үзе дә сул эсер, әмма күп җәһәттән коммунистларга якын тора. Минемчә, аңа ышанырга ярый. Җитәкчеләр үз карамакларына бишалты кеше сайлап алсыннар. Планнарыгыз, нинди чаралар билгеләвегез турында миңа ашыгыч хәбәр итегез. Куркыныч бөтен яктан да яный, шуны онытмыйк!

Киңәшмә бетте, таралдык, әмма эш кимемәде, артты гына.

Хәзер уйлап баш ватам: «Нигә әле без барысын да алдан күреп бетерә алмадык та, Казандагы контрреволюцион подпольены кырып-себереп ташламадык?» дигән сорау туа. Хаклы сорау. Аңа җавап бирү дә ул кадәрле үк кыен түгел. Әйе, без бик аз идек, булганнарыбызның да эш тәҗрибәсе кечкенә, вакыйгалар исә ашыгыч туа торды, үсеп, алга ыргылды, җәелде, киңәйде; бер урында эш бетте дип исәплисең, ә ул әрсез сарут кебек әллә кайларга тармакланып тамырланган була. Утап ыргыттык, бетте дип уйлаган җирдә өр-яңадан шытып чыга. Илне дошманнар камаган, илне эчтән дә дошманнар урап-чурап алган иде.

Күз алдына китереп карагыз: ярый, өч группа төзедек ди, аларга никадәрле катлаулы бурыч йөкләдек ди. Безнең әле спекулянтлар, урыннарыннан явыз ният белән файдаланучылар белән дә көрәшү бурычыбыз бар иде, онытмадыгызмы? Контрреволюцион ташкынга бер түгел, ун группа каршы куйсаң да, аз булыр иде ул чакта! Совет властен, революция казанышларын саклап калу өчен Көнчыгыш фронты төзелә, аңа искиткеч зур бурычлар куела, аның штабы Казанда... Ә армия башында сул эсер Муравьев! Алып кына ыргытыр идең, куллар бәйле. Чөнки көне-сәгате килеп җитмәгән, әйткәнемчә, губернада өч меңнән артык эсер бар! Алар һәммәсе дә диярлек көрәшкә әзер, әзерлекле һәм җаваплы урыннарда утыра торган кешеләр.

Шуның өстенә без бик күп милләтләр яшәгән төбәктә эшлибез, якында гына фронт, фронттагы хәлләрне катлауландырып, ак чехлар кузгалды. Алары алтмыш мең! Алар алга шуышкан саен, совет дошманнары терелеп туа тора, туганнары тернәкләнә, тернәкләнгәннәре канатланып коралга тотына. Ә корал агыла гына!.. Кем санап, чутын алган аларның? Боларның һәммәсе белән әнә шул өч оператив группа көрәшергә тиеш!

1918 елның июне милләтчеләр, сепаратистлар арасында зур җанлылык тудырды. Килгән шаптә, моңарчы милли төбәкләрдә эшләгәнем булмаганга, милли хәрәкәтләр турында авыз тутырып әйтергә базмыйчарак тордым, яши-яши, ул яктан да тәҗрибә тупланды... Әйткәнемчә, июнь көннәрендә милләтчеләр яңадан аякка басты. Таһиров шәһәрдә «Болак арты республикасы»ның юлбашчыларыннан берсе Ильяс Алкинны күргән. Элекке Хәрби шура комиссары, элекке подпоручик, хәзерендә 1 нче мөселман полкының рота командиры, ялагай һәм төче телле Хәлил Чамаев артына нашатырь кыстырган кебек чабып йөри башлады, кая барып кермә — ул шунда, сикереп торып урын тәкъдим итә, елмая, төче сүзләр сибә, ә күзендә нәфрәт уты... Йөри, өлгерә, «болак арты» калдыклары белән чышын-пышын сөйләшә, нидер кыймылдыйлар, нидер маташтыралар... Әле ярый революция тудырган татар чекистлары ныгып, өйрәнеп киләләр!

Бераз артка китеп булса да, кайбер конкрет эшләргә тукталып китәргә кирәк булыр. Әгәр без Казан турында сөйләп, татар буржуасына, милләтчеләренең ул чактагы хәленә күз ташламасак, язмаларыбыз тарихи хакыйкатьне тулысынча ача алмас...

10 июньдә Казанда мөселман социалистик комитетлар вәкилләре — мөселман коммунистларының киңәшмәсе булып узды. Большевиклар Үзәк комитетыннан һәм җирле партия оешмаларыннан кешеләр катнашмаса да, җыелыш социалистик комитетларны «Мөселман коммунистик комитетлар» итеп үзгәртергә диган мөһим карарга килде. Димәк, аерым Бөтенроссия коммунистлар партиясе төзелде. Бу моментны хәтерегездә калдырыгыз әле...

Без, коммунистлар, милли коммунистик партияләр төзүне революциягә кадәр үк кире кактык. Без һәрвакыт пролетариатның һәм аның авангардының бердәмлегенә омтылдык, аны милли кисәкләргә бүлергә ярамавын аңлый идек. Бу милли тайпылышны нәкъ менә Мирсәет Солтангалиев җитәкләве, Россия мөселманнарының коммунистик партия рәисе булып китүе аңлашылып та бетмәде, ачуны да китерде.

Менә хәзер шулай дип яздым да, карам кипкәнче, уйга калдым: ялгыш язмадыммы, бәям хакмы?

Милләтчелек — каннан озак таралмый торган чир. Милли хис кешедә гомере буе саклана. Революционер — гел алга омтылып яши торган кеше — милләтләрне уртак итә торган сыйфатларны табарга тиеш булса, милләтче — әнә шул уртаклыкны юк итә торганнарын эзли. Карьерист һәр җирдә беренче булырга тырыша, урын алырга омтыла, омтылышы янында ул акыллы да булып чыкса, нәтиҗәдә югары урын өчен ул бишкә төрләнергә әзер, бусы гадәти хәл, ул үз юлын акларлык теория



*А. Тимергалина рәсеме*

дә эзләп таба! Сәяси яктан томаналарны, аз белемлеләрне ияртә! Әмма намуслы һәм чын хезмәт кешеләренә аның теше үтми...

Солтангалиев бу юлга очраклы гына кереп китмәде, аңламаслык һәм үпкәләрлек ни бар монда? Бергәләп уйлашыйк...

Ул РКП(б) сафларына 1918 елның башларында кергән. Февраль-мартта мөселманнарның «Идел-Урал штатлары» барып чыкмаслыгына ышангач, «болакчылар»га каршы чыкты. Чыгуын чыкты, «болакчылар»-ның кулга алынган лидерлары бертуган Ильяс һәм Җангир Алкин-нарны, Йосыф Мозаффаровны, Усман Токумбетовны порукага алды... Шул чакта ук Солтангалиев «милли коммунизм» теориясен алга сөрә башлады. Һәм, әйтергә кирәк, һәммәсен үлчәп, җаен белеп, алга-артка карап эшләде. Контрреволюционерларны аклады, яклады — сугыш барышында, бигрәк тә гражданнар сугышында җилнең теләсә кайсы якка борылуы мөмкин! Милли бердәмлек өчен көрәшкәндә сыйнфый таләпләрдән чыгып түгел, бары тик милләт өчен генә тырышты! Милләт бердәмлеге!

Бер караганда, аның теориясе кызыгырлык та иде! Милләт бердәмлеген ул сәнәк белән суга язмады, аны заманында бик нык таралган «бөтендөнья революциясе» идеясенә нигезләде. Ә «бөтендөнья революциясе», һичшиксез, Россиядәге социалистик революция нәтиҗәсендә туачак. Бер караганда, һәммәсе тәртиптә, дөрес һәм какшамаслык та кебек иде...

«Бөтендөнья революциясе» фикере илне гөр китерде, без ул фикергә тулысынча ышана идек, бер кузгалган боз тукталмас, аңлы, үз халкының бәхете өчен көрәшләрдә чыныккан эшче сыйныфы булган алдынгы капиталистик илләр берсүзсез бездән, безнең илдән үрнәк алырлар дип инана идек.

— Юк! — дип чыкты Солтангалиев. — Дөньяны капитал изүеннән бары тик милли азатлык хәрәкәте генә коткарып кала ала. Көнчыгыш кулдан ычкынгач, Һиндстан, Әфганстан, Иран һәм башка шуның кебек Азия-Африка колонияләреннән коры калгач, көнбатыш империализмы үзеннән-үзе, тамырында саргаеп корыячак. Бу милли-азатлык хәрәкәте белән кем җитәкчелек итәчәк дип сорый да үзе үк җавабын да таба: Көнчыгышта, бигрәк тә мөселманнар күп булган илләрдә, эшчеләр аз санлы, халкының күпчелеге крестьяннар икәнен истә тотсак, ул илләр белән сәяси һәм мәдәни яктан иң нык алга киткән халык җитәкчелек итәргә тиеш. Россиядә төрки халыклардан иң алдынгысы — татарлар. Димәк, дип йомгак ясый ул, марксизм-ленинизмнан бик ерак киткән сәер фикерләренә, Казанда төзелгән Россия мөселман коммунистлар партиясе Көнчыгыш мөселманнарының азатлык хәрәкәтенең башында барачак.

Әлбәттә, бу хәрәкәттә ул үз урынын да билгеләде: үзен җитәкче, юлбашчы итеп кенә күрде.

Гәрчә ул төзегән партия берничә ай яшәп маташса да, күпчелек «аерылып чыгу»ны якламады. Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар ди татарлар. Россия туфрагында ул чакта «аюлар» да җитәрлек, «бүреләр» дә күп иде. Сарык тиресе ябынган бүреләр тагын да ишлерәк иде. Бер Муравьев үзе генә ни тора! Ул да юлбашчы булу турында хыяллана. Әле Савинков та исән, аның төшенә дә бөек миссия, «Россияне һәм ирекне» коткарып калу бурычы керә...

Аннары, шул турыда да уйладым. «Идел-Урал» атамасын телгә Галимҗан Шәрәф кертте... Соңыннан ул танылган совет тюркологы булып китте. Берничә елдан соң партиягә һәм революциягә каршы эшчәнлеге өчен партия сафларыннан куылган Солтангалиев заманында бу атамага каршы чыккан иде. Шулай да була, дошман дип санаганың дуска әйләнә, дус булып, ал битлек киеп йөргәнең чамасыз әшәкелек эшләп ташлый...

Әле болар соңрак билгеле булачак, күп вакытлар узгач! Ул чакта мин Таһировтан гади генә:

— Аерылу турында ни уйлыйсың? — дип сорадым.

— Алда күз күрер,— диде ул хәйләкәр генә елмаеп. Шунда ук житдиләнде.— Ошамый миңа андый кыланышлар! Мин сезнең белән бергә булырга телим, бер партиядә. Эш исемдә түгел — жисемдә. Алар партиясенә иярмәячәкмен! Гәрчә анда яхшы иптәшләр дә байтак, саташканнар гына алар! Кылган эшләренә караганда, аларның гомерләре озын булмас...

Сүзне шулай тыныч тәмамласак та, безнең көнкүрештә, яшәештә, көндәлегебездә тагын бер авыр мәшәкать артты, бурычлар өстәлде — мәйданда Солтангалиев пәйда булды. Аның артыннан ияреп адашканнарны туры юлга кертәсе бар, аның идеяләрен Совет властеның дошманнары күтәреп алган очракта, аларның уйларын да, юлларын да кисәргә кирәк. Болар һәммәсе безнең өстә... Вакытны кулдан ычкындырырга да, акрынайтырга да мөмкин түгел. Вакыт ага, тик кайвакыт аның кая таба акканын гына белеп бетереп булмый. Сулар үргә акмый диләр, вакыт исә үргә дә ага ала...

Төзелгән оператив группалар жиң сызганып эшкә кереште.

Киңәшмәдән соң берничә көн үтүгә, Михаил Антонов минем янга керде.

— Сергей Сергеевич,— диде ул.— Әлегә хәл менә болайрак: Муравьев чыннан да нидер маташтыра! Аның «гөнаһлы җепләре» бер сул эсерлар ягына гына тартылмаган икән әле! Катлаулы кеше! Монда, Казанда, юнкерлыкка укыган ул, 1901 елда тәмамлаган. Сабакташлары белән элемтәдә! Әйтик, подполковник Колесников аның фикердәше, элекке сабакташы. Шундыйларны гел үзенә тарта, жыя. Колесниковка нинди хокук биргән диген син: «Махсус армия» төзү хокукы.

— Нинди армия була инде ул?

— Муравьев белән Колесников парлашып төзегәч, аның төсен тану читен түгел! Армиядә дүрт жәяүле һәм бер кавалерия дивизияләре булачак. РВС исеменнән бу приказга Муравьев, Колегаев һәм Миронов кул куйган.

— Өчесе тиң сул эсерлар!

— Нәкъ! Колесников эшне кыздыра гына: элекке офицерларны жыеп штаб укмаштырган. Аристов белән Таһиров ачыкладылар: штабистларның күбесе безнең картотекада «контрреволюция яклы» булып саналалар. Офицерлары алдында чыгыш ясап, Колесников: «Минем «махсус армия»дәге офицерлар барлык хокуклар белән файдаланачак!» — дип сөйләгән... Шул чагында Муравьев залга килеп керә. Колесников: «Встать! Смирно, господа офицеры!» — дип команда биргән. Болай каршылау Муравьевка ифрат ошаган...

— Алай,— дидем мин.

— Колесников шул киңәшмәдә, Муравьев алдында: «Безнең «махсус армия» тышкы фронт өчен төзелә!» — дип белдергән.

— Димәк, Германия белән сугышны күздә тоталар? — дип ачыкладым мин.

— Шул инде, чехлар белән сугышырга жыенмыйлар, күренеп тора. «Комиссарлар командирлар эшендә гади ярдәмчеләр генә булачак»,— дип тә ачыклаган Колесников. Шуннан мин реввоенсовет председателе Кобозев янына бардым. Ул да белә икән! «Әйе,— ди,—«махсус армия» дигәннәре сул эсерлар укмаштырган нәмәрсә, алар шуны төзеп, Брест солыхын өзәргә тырышалар, ниятләрен тормышка ашырып өчен гаскәр житәкчелегеннән коммунистларны куарга жыеналар...» Кобозев мин барында реввоенсовет утырышын жыйды.

— Нинди карарга килделәр?

— Кобозев «махсус армия» хакындагы приказны юкка чыгарды. Ну чинадылар инде сул эсерлар! Үкчә белән идәнгә тибәләр! Кобозев нык торды — мобилизацияләнгән офицерларны хәрби комиссариатлар аркылы фронт частьләренә таратырга кушты... Алай да Колесников, офицерлардан иң якыннарын алып, Муравьев штабында оялап калды. Командующийның боерыгы шундый, имеш...

Антонов миңа нидер язылган кәгазьләр сузды.

— Болары Муравьев узган юллар турында белешмәләр. Кем булуы, характеры, бәйләнешләре, көчле һәм йомшак яклары турында, таба алганнарның барын да теркәдек.— Мин кәгазьләрне кулга алуга, Антонов арадан берсен аерып күрсәтте.— Бусы минем үз «хатирәләрем». Күптәннән беләм мин ул «Наполеонны»!..

«Украинада чакта Муравьевның начальнигы булган Антонов-Овсеенко белән очрашканым бар. Муравьев турында да сүзләр булгалады. Хәтеремдә, Антонов-Овсеенко аны болайрак бәяли иде: «Муравьев төп эшен онытып, үз-үзенә соклану сөременә уралып яшәде. Кайнарлыгы белән башкаларны да үзенә тартучан. Аның характерының асылы — үз шәхесе белән артык дәрәҗәдә мавыгу, соң чиккә җиткән соклану. Ул үзен табигатьтән дә өстен көчкә ия булган зат дип исәпли, тирәягындагыларга да шушы фикерне сеңдерергә омтыла, башкаларны ышандыра ала. Башкаларның ышануында булса кирәк аның көче...»

Арага Муравьевның биографиясе да теркәлгән. Молодцы, егетләр, тапканнар...

«Ярлы крестьян баласы. Җирле байгуралардан берәвесе аны үз тәрбиясенә ала, укытучылар семинариясенә җибәрә. Аннан юнкерлар училищесы, аны тәмамлап, Беренче Невский укчы полкта хезмәт итә. Балда бер офицер белән ызгышып, аны үтерә. Ристаннар ротасына озатыла, батырлык күрсәтеп офицер дәрәҗәсен кире кайтара. Рус-япон һәм Беренче бөтендөнья сугышларында катнаша. 1917 елда Керенскийга удар батальоннар төзергә киңәш итә. Корниловка каршы сугыша, Керенскийдан өметен өзгәч, сул эсерлар ягына тайпыла. Украинада совет власте ягыннан Керенский-Красновка каршы сугыша...»

Боларын якынча мин белә идем инде. Антонов-Овсеенко белешмәсендәге бер фикергә игътибар иттем. Җитди искәрмә иде бу! Штаб начальнигы итеп Муравьев билгеләнгән армия Украинага юнәлгәч, Ленин Антонов-Овсеенконы: «Уяу булыгыз, сезнең карамакка тапшырам!» — дип кисәткән.

Димәк, Ленин башта ук Муравьевка ышанып бетмәгән!

Ниһаять, Муравьевны Казан җирлегендә күргән чекистларның җыелма фикерләре: «Үз-үзенә гашыйк бушбугаз, җилкуар...» Һм-м, өстән караганда шулай күренәдер дә, эчендә ни? Эчендә?!

Тышкы яктан мин дә аны беләм: арык төз гәүдәсен, кечкенәрәк баш өстендә кыска калдырып алдырган көмешсыман чәчләрен, чыңгылдап торган тәэсирле тавышын, чыңлап торган шпорларын, гап-гади фикерне дә митингларда күнеккәнчә күпертеп, тантана белән сөйләргә яратуын белеп бетердем... Чекистлар тагын бер кыйммәтле фикер өстәгәннәр: «Сәяси яктан тотрыксыз, фикере чикләнгән, тар».

Тар диләр. Хәнҗәр дә тар — үзенә юл яра... Күпме җаннарны харап итә...

Әһә, тагын бер белешмә: «Немецлар Одессага һөҗүм итә башлагач, Муравьев Мәскәүгә китә, анархистлар ягыннан йөргәнгә күрә аны кулга алганнар. Партия һәм хәрби җитәкчеләреннән унөч кеше — шул җөмләдән Антонов-Овсеенко һәм Муралов үтенече буенча азат ителгән. Көнчыгыш фронт оешкач, аның командующие итеп Антонов-Овсеенконы җибәрергә уйлыйлар, әмма ул бер шарт куя: «Бөтен властьны һәм җаваплылыкны үземә тапшырсагыз — барам, юк икән — башка кандидат эзләгез!» — ди. Муравьев кандидатурасын шул чакта Троцкий тәкъдим итә, «Украинадан соң җитәрлек ял итте, тумыштан хәрби кеше, хәзер сугышка ыргылып тора»,— дип мактый. Шулай итеп, Муравьев Казанда пәйда була...

«Безнең башка бәла!» — дип әйтер идем, Муравьевны кая куясың? Бездә булмаса, башка бер урында совет властена мәшәкать тудырып, комачау итеп йөрер иде. Бездә тек бездә...

Бар булган кәгазьләрне җентекләп укып чыккач, түземсезлек белән

көтеп утырган Антоновка карадым... Шахтер егет, яңа пешеп өлгереп килгән чекист, ә ни арада күпме материал туплаган! Ольkenицкий искә төште: «Егетләр көнләп түгел, сәгатьләп үсә». Антонов, Таһиров кебекләргә ышанырга була, революциядә үзең чын-чынлап таянырлык көрәштәшләрең булганда, көрәшнең мәгънәсен тирәнрәк аңлыйсың. Мин Антоновка рәхмәт әйттем:

— Рәхмәт, Михаил. Муравьевтан күзеңне ычкындырма. Яңа нәрсә сизелә калса, шунда ук хәбәр иттер. Ул нидер маташтыра дисең, аның маташулары элегрәк башланган инде! Гади генә биография дә кайчагында күп нәрсә сөйли. Гаугалы бәндә, авантюрист. Революцион кузгалышларда авантюристлар суны болгатырга, болганчык суда бөтен балыкларга хуҗа булып калырга омтыла! Группаңа рәхмәт әйт, саклыкны икеләтә, өчләтә арттырсыннар.

Антонов китүгә, бүгенге газеталарны керттеләр. Кичәгеләр дә укылмаган килеш ята, өченче көнгеләрен дә аннан-моннан гына караштырган идем. Өч көнлекне бергә җыеп укыштырып чыктым...

Газеталар сугыш эшенә, тизрәк коралланырга чакырулар белән тулы. Казан советы эшчеләре ачыктан-ачык язалар: «Без Петроград, Мәскәү, Кубань эшчеләреннән кимме әллә? Алар революция алдында үз бурычларын аңлап, беренче чакыру ишетелүгә, көрәш сафларына басачак. Без, Казан завод-фабрикаларының эшчеләре дә, үз сәяси органнарыбызның чакыруын чын күңелдән кабул итеп, көрәшнең алгы сызыгында булачакбыз!»

Әйе, май башларында дошманның фетнә әзерләве ачык иде, июль башында да бу хәл үзгәрмәде: дошманның күтәрелешкә омтылышы тагын да ачыкланды, дәлилләр белән ныгытылды. Бер нәрсә хәзер безнең өчен сер түгел иде: кичә безнең белән янәшә барганнар бүген безгә каршы күтәрелеп чыккан дошман ягына авышып бетте диярлек.

Чишелеш без көткәнгә караганда да тизрәк килде...

1918 елның 4 июлендә Зур театр бинасында Советларның 5 нче Бөтенроссия съезды ачылды. Күп еллар узгач инглиз дипломаты атаклы шпион Роберт Локкартның съездан алган тәэсоратын укырга туры килде. «Свердловтан уң кул якта һәйбәт киемнәрдән, кырынган, мөгаен, тәрбияле сыйныф вәкилләредер, сул эсерлар утырган: Камков, Карелин, янәшәдә Черепанов, иң кырыйда партиянең җитәкчесе утыз ике яшьлек Мария Спиридонова. Ул тыйнак кына киенгән, чәчен артка кайтарып тараган, пенснесы белән өзлексез уйнап утыра, Чеховның «Өч бертуган кыз» пьесасыннан укытучы Ольга диярсең! Ә бер ноктага төбәлгән карашы — кичергән газапларының эзсез үтмәвен сөйли. Сәяси җитәкче буларак ул эшлексез, дуамал, алай булса да даны ифрат киң таралган. Партия члены өчен ул үрнәк, иярергә лаек ханым!»

Мин Спиридонованы ВЦИКның крестьян секциясен җитәкләгән чагыннан ук беләм, ул анда үзен тиз арада тискәре, дуамал, күкерт булып кабынучан итеп танытты, шушы сыйфатлары аша гомерендә байтак газап ашады. Күпләр шул сәбәпле аның чиксез гөнаһларын кичерә килгәндер дә...

Уналты яшеннән Тамбов эсер дружинасына кереп, крестьяннарга китергән авыр газаплары белән дан алган явыз вице-губернаторны атып үтерә. Үлем җәзасына хөкем ителеп, бераздан бу хөкем гомерлек каторга белән алыштырыла. Жандармнар һәм төрмә хадимнәре тарафыннан чамасыз күп тукмалган, сансыз-исәпсез көчләнгән хатын. Аның сабырсызлыгы, тәвәккәллеге мәгълүм, аның хакындагы риваятьләр телдән телгә күчеп ил гизә иде.

Спиридонованың бу сыйфатлары кайнар июль көннәрендә тулы чагылыш тапты.

Съезд делегатларының өчтән берен сул эсерлар алып тора. Моңарчы аларның болай хәтәр тузынганын күргән юк иде. Чыгыш ясаучы больше-

викларны алар туктаусыз бүлдерәләр, «Брест солыхын өзәргә!» — дип котырынып акыралар, «Комбедларны куабыз, крестьян восстаниеләре күтәреп большевикларсыз гына Советлар төзибез»,— дип кычкыралар.

Без ул көннәрдә делегатларның чыгышы басылган газеталарны тетkәләнеп беткәнче укып, бәхәсләшә башладык. Иң нык ачу куптарганы әлеге дә баягы Спиридонова чыгышы булды.

— Мин,— дип башлаган ул сүзен,— хәзер большевиклар партиясенең аяусыз дошманы рәвешендә чыгыш ясыйм. Мин, төрмәдән чыкканнан бирле, алар белән бергә көрәштем, социал-революционерлар партиясендә даими әгъза булып торып, аларга бик күп ярдәм күрсәттем. (Залда көлү). Социал-революционерлар партиясен урталай бүлеп, уңнар бездән аерылгач, безнең төркем, сул социал-революционерларның нәни генә төркеме исән-аман яшәсен өчен бик күп көч куйдым. Мин крестьяннар белән береккән, сез, залда утыручы крестьян большевик иптәшләр, шикләнмәгез. (Залда тавышлар: «Оятсыз!») искиткеч нык береккән...

Шул көннәр газетасыннан күчереп алган бу өзек съездда булган хисләр киеренкелеген генә түгел, бәлки ике сәяси партиянең ил киләчәге турындагы бәхәстә фикерләр сугышы турында да ачык сөйли. Бу гади талаш, каприз гына түгел, бу кушылмаска аерылышу иде.

Спиридонованың истерикалы өндәүләре, сул эсерлардан башка житәкчеләрнең әле карга булып каркылдап, әле сандугач булып сайрап маташулары съездда хәтта үз партия әгъзаларын да артларыннан ияртә алмадылар. Аларның мәгънәсез өндәмәләренә Ленин кискен отпор бирде.

Шул ук Локкарт Ленин чыгышының съездның башка делегатларына тәэсире турында да язмый булдыра алмаган: «Бара-бара бөтен зал бу корыч кешенең какшамас тәэсиренә бирелә һәм сихерләнеп тыңлый. Речь алкышлар давылына күмелеп тәмамлана, большевиклардан бүтәннәр дә кул чаба, социал-революционерлар алдагы көн үзләренә ни китерәчәген чамалыйлар».

Сул эсерлар фетнәсе безнең өчен бөтенләй көтелмәгән булды дип раслый алмыйм. Әмма ул Мәскәүдә Германия илчесе Мирбахны үтерүдән башланыр дип берәү дә көтмәгән иде. Спиридонова оятсызларча съездда үгет-нәсихәт чәчеп маташканда, сул эсер Попов әнчекләре Мәскәүдә коммунист хезмәткәрләрне, шул җөмләдән Дзержинскийны, Лацисны, Смидовичны һәм башкаларны кулга алырлар дип башыбызга да килмәде. Күбесе без көтмәгәнчә булды...

Чөнки без моңарчы бергә эшләдек, янәшәдәгеләргә хөрмәт һәм ышаныч белән карадык, аларның башка партия кешеләре — сул эсерлар икәнен онытып торып, бергә ут астына кердек.

Күп нәрсәләрдә ялгышмавыбыз да расланды. Вера Брауде һәм башкалар сул эсерлар партиясе җитәкчелегенең хыянәтчел эшчәнлеген кискен хөкем иттеләр һәм чекада эштә калдылар. Байтак намуслы иптәшләр шушы дөрес юлны сайлады. Ә кайберәүләр бүтән юлга басты.

Съездда барган көрәш Казан чекистларын да киеренкелектә тотты. Без хәзер, Мәскәү белән Казан арасы шактый булса да, кирәк чагында тиз якыная алганын бик яхшы искәргән идек. Бүген Мәскәүдә ут кабынса, көне-сәгате белән аның Казанга да, Самарага да килеп бәреләчәген аңлыйбыз. Мәскәүдә яшен уйнаса, тавышы безгә килеп күкри. Шуның өчен мин көне-төне үз кабинетымнан чыкмадым дисәм дә ярый, күп вакыт ашханәгә йөрергә дә ара калмады... Ике көнгә бер мәртәбә Сәҗидә апа кереп чыккалый, эремчек пилмәне, бәрәңге дучмагы һәм шешә белән кайнар чәй кертә. «Тәмле ризыкларымның суынып, рәте калмагандыр инде»,— дип бик хафалана. Бер көнне ул кергәндә янымда кулга алынганнардан берәү бар иде... Икенче килүендә ул сүз арасында гына:

— Сергей улым, синең янда утырган сөйкемле кеше кем ул? — дип сорады. Дәшмәдем, җавап бирмәдем, каршымда утырган кешенең биш-алты совет хезмәткәренең җанын кыйганлыгын әйтергә базмадыммы, белмим...

Ничә көнгә бер мәртәбә Таняларга барып кайттым. Алар өчәүләшеп мине көтәләр иде бу юлы. Әтисе дә, әнисе дә хөрмәт белән сәламемне алдылар, чәй эчәргә кыстадылар. Таня банк каршысында булганнарны аларга түкми-чәчми сөйләп тә биргән икән. Әлбәттә, әтиәниләре һаман Казаннан китү ягында булсалар да, Таня аяк терәп каршы торган, инде өметләнгән дәлилләрен санап бетергәч:

— Мин Сергей Сергеевич яныннан беркая да китмим! — дип әйтеп салган. Ата белән ана «аһ!» итеп телсез калганнар...

Мин бу сөйләшүне һәм сүзнең кая кадәр җиткәнен белми идем әле, алай да ата белән ананың миңа булган мөнәсәбәтләре үзгәрүеннән, аның яхшы якка нык ук алмашынуын сизеп, Таня сүзенең өстен чыкканлыгын искәргән идем. Без ишегалдына түгел, бакчага чыгып утырдык.

— Газеталарны караштырам, әти эштән алып кайтып йөри,— диде Таня.— Син бу арада гел күренмәдең... Мин өч көн урын өстендә яттым...

— Ничек?

— Шулкадәр курыкканмын, һушыма килә алмадым. Син миннән артык куркак дип көлмә.

— Юк, Таня, син искиткеч батыр кыз!

— Батыр ук түгелдер инде түгелен... Алай да бандитлар мине ияртеп киткәч башта бик курыктым. Алар мине бер ишегалдына алып кергәч күзләремне бәйләделәр. Сукыр килеш ниндидер йортка барып кердем. Кичкә кадәр тавыш-тының чыкмасын диделәр. Әти синең янга бармый калмагандыр дип уйладым. Син белгәч, мине йолып алырсың дип тә уйладым...

— Һәммәсе ахырда әйбәт булыр дип үзең юрадың, Таня.

— Син шуңа ышандыңмы?

— Алда әйбәт булачагын юрамыйча да беләм.

— Мин синең эшең хакында сораша, белешә алмыйм. Кыймыйм да. Синең бик авыр, хәвефле эшкә тарыганыңны гына беләм. Минем яндагы бандит атып җибәргәч, синең «ят!» дигән тавышыңны ишетеп җиргә егылдым... Тез башларым канаган...— Ул уңайсызланып кына, озын күлмәк итәген күтәреп, марля белән бәйләнгән тез башларын күрсәтте.— Ә син сизгер түгел икән, Сергей Сергеевич.

— Нигә?

— Мин бүген Зоря күлмәген кигән идем бит. Шушы күлмәктән ул сине каршыларга вокзалга төште...

Таняны үземәрәк тартып китереп, аның күзләренә карадым.

— Димәк, син дә апаң кебек үк зуп-зур кыз булып барасың...

Күлмәкнең яшь тәнгә киңрәк икәнен, аннан-моннан бераз салынып торганын мин күрмәгән дә идем, әллә сизгерлегем азаеп калдымы?

— Бая башлаганымны әйтеп бетерим инде... Эшең турында әйткән идем — сораша, белешә алмыйм дидем. Ни булса да мин синең тормышың белән генә яшим, Сережа... Берүк үзеңне сакла... Мин сиңа апамны, Зоряны алыштырырга телим...

Зоря күлмәге кигән кызның кайнар тәнен кысып кочакладым.

Хатын-кыз җанын берчакта да аңлап бетереп булмый, хатын-кыз җанының гүзәллегенә, сизгерлегенә һәм нечкәлегенә сокланырга гына кала. Вакыт ни тар булса да, икенче көнне кыска гына арага зиратка барып без Зоряның каберенә баш орып килдек...

Әйткәнемчә, кайбер сул эсерлар башка юл сайладылар... Белеп торсын өчен мин боларны кыскача гына Таняга да сөйләгән идем. Минем белән янәшә бара икән, әйдә, белеп торсын...

Тарих тәгәрмәче бер мизгелгә генә тыелып торды, аны сул эсерлар бөтенләйгә туктатырга тырышты. «Эш восстаниегә барып җитәр дә, башкомандующий сул эсер Муравьев хыянәт итәр дип мин һич тә көтмәгән идем!» — дип язды соңыннан Ленин...

6 июльдә фетнә күтәреп, сул эсерлар үзләрен үлемгә дучар иттеләр. Әлбәттә, аларның лидерлары бик күпләргә, шул исәптән күпсанлы Казан оешмасына да, главком Муравьевка да исәп тоттылар. Соңыннан билгеле булганча, Казанга килер алдыннан Муравьев сул эсерлар Үзәк комитеты җитәкчеләреннән: «Армияне сул эсерлар кулында булырлык итеп оештырырга!» — дигән анык күрсәтмә алган була.

6 июльдә, фетнә купкан көнне, Мәскәүдә ВЧК бинасы фетнәчеләр кулында була, Петерс безгә сигезендә генә шалтырата алды. Мәскәү вакыйгаларын Казанда иң элек Реввоенсовет членнары ишетеп беләләр. Безгә бу хәбәр Реввоенсовет председателе Кобозев аша килеп иреште. Ул болай сөйләде:

— Җиденче июльдә, якшәмбе көн, фронт Реввоенсоветы үзенең чираттагы утырышына җыйналды. Генеральный һөҗүм планын Муравьев игълан итте. «Эшләр шуңа бара ки, тиздән фронт Иделдән Уралга күчәчәк!» — дип шапырынды. Аерата мактанчык, сүзләре томанлы һәм нигезсез иде аның... Ул арада булмады, рөхсәтсез-нисез дежурный килеп керде һәм мине турыдан-туры Мәскәү чакыруын белдерде... Туры чыбыкка чыгып киттем... Совнарком секретаре Горбунов шалтыратты, 6 июльдә эсерларның Германия илчесен үтерүләрен, восстание күтәреп совет властена каршы чыгып, шәһәрдәге кайбер биналарны яулап алуларын, байтак совет-партия хезмәткәрләренең һәлак булуын хәбәр итте. «Иптәш Ленин сезгә шуны да тапшыруымны үтенде,— дип дәвам итте иптәш Горбунов.— Сул эсерлар Муравьевка исәп тотулары белән мактанганнар! Мин моны буш куык очыру дип беләм, алай да Муравьев өстеннән күзәтүне өчләтә арттырыгыз. Сез яки Мехонишин белән Благонравов алмаштилмәш аның катында булыгыз, бер минутка да ялгызын калдырмагыз. Муравьев бу ахмак эшләргә катнашамы-юкмы икәнен һәм аны саклау эшен тәэмин итә алуыгызны хәзер үк хәбәр итегез!» Телефоннан соң туры реввоенсовет утырышына барып кердем. Зарыгып көтеп утырган иптәшләргә эсерларның фетнәсе турында әйттем һәм Муравьевтан: «Ә сез моңа ничек карыйсыз?» — дип сорадым. Муравьев торды, кәпәренеп кенә болай диде: «Партиядәш иптәшләрем революциягә хыянәт итеп, мин унҗиденче елның Октябреннән бирле кан койган һәм соңгы тамчы каныма кадәр бирәчәк Совет властена каршы чыкканнар, янә дә эсер партиясе әгъзасы исемен пычратканнар икән — моны беркетмәгә язып куюыгызны үтенәм — мин ул партиядән чыгам!»

Утырыш агымдагы эшләрне карауны дәвам итте, әмма хәзер уй җебе моннан киткән, барыбызның да күңелендә Мәскәүдәге хәлләрнең агышы иде. Торабыз да ишеккә карыйбыз, калкынабыз да тәмәке кабызабыз. Аппаратныйдан дежурный керер дә тагын нидер хәбәр итәр төсле. Бер Муравьев кына тып-тыныч. Булса да булыр икән артист! Һичнәрсәгә исе китмәгән булып кылана. Үз белдерүе теркәлгән беркетмәне кат-кат укып чыкты, күрсенеп куйды...

Түзмәдек, Мехонишин аппаратныйдан туп-туры Ленинга шалтыратты, фетнә хәлләрен һәм Казан губбашкармасы председателе Колегаевның андагы вакыйгаларга мөнәсәбәтен сорады. Көнчыгыш фронты гаскәрләренең башкомандующие Муравьевның эсерлар партиясеннән чыгуы искиткеч зур әһәмияткә ия иде, аны да Владимир Ильичка җиткерде.

«Колегаев үземә дә, башка иптәшләргә дә сул эсерлар партиясенең бүгенге сәясәте белән килешмәвен белдерде... Фетнә бер көн эчендә тулысынча бастырылды... Йөзәрләгән дошман кулга алынды... Муравьевның сул эсерлар партиясеннән чыгуын протоколда беркетеп куегыз, әмма күзәтүне киметмәгез... Ышанам, әгәр шушы шартларны үтәсәк, без аның гаскәри талантын тулысынча файдалана алырбыз. Чехословаклар һәм казаклар белән көрәшне өчләтә көчәйтеп дәвам итегез».

Ильичның бу сүзләре — кешегә ышануның якты мисалы. Владимир Ильич Муравьевка ышана, аның сәләтен буталышлардан арындырып

революция эшенә жигәргә куша. Ә ул үзе? Ни уйлый? Шушы олы ышанычны бәяли аламы? Болай да арык, туп-туры гәүдәсен төп-төз тотып кәкре-кыек эшләренә кире кайтмасмы?!

Реввоенсовет утырышы дәвам итте.

— Иптәшләр! — дип өр-яңадан сүз алды Муравьев. Сүз әзерләп өлгердеме? — Хәзерендә без билгеләгән һөҗүмдә төп авырлыкны Сембер шәһәренә урнашкан 1 нче Армия тартырга тиеш. Белгәнегезчә, Армиянең командиры яшь, тәҗрибәсез Тухачевский. Сез миңа китәргә рөхсәт итегез: Сембергә барып һөҗүмне үзем җитәкләргә телим! Бу минем элеккеге партиямнән аерылуым билгесе булсын.

Ну артист! Без бер-беребезгә караштык.

Кобозев маңгаен җыерды:

— Моның хаҗәте бармы икән? Яшь Тухачевский да үзенең яшь үк түгеллеген расласын инде. Сезнең карамакта армияләр әнә ничәү, һәммәсенә дә йөри алмассыз. Штабтан торып гомуми җитәкчелекне яхшы башкарып чыксагыз файдалырак булмасмы?

Без, чекистлар, Кобозев белән килешүебезне белдердек.

Муравьевның әтлегән белә идек ич һәм аның бу юлы да ялганнары тиз ачылды. Без капчыкта ятамы соң?! Фетнә бастырылып, сул эсер җитәкчеләре таш капчыкка кереп утыргач, документлар кулга төшеп, сорау алулар башлангач, үз исеменең дә өскә калкып чыгасын белмәгәнме Муравьев? Соңгы айларда бар көчен, энергиясен биреп әзерләгән заговорда нинди урын биләгәнен чекистлар төбе-тамыры белән ачыклыйсын сизенмәгәнме? Белү генәме сиңа, нәтиҗәдә үзен ни көткәнен, стенага терәп атачакларын шунда, реввоенсовет утырышында ук аңлаган. Аңа ашыгыч рәвештә реввоенсовет членнары һәм чекистлар күзеннән ычкынып торырга кирәк булган! Ары-бире ак-каралар ачылганчы моннан эзне суытырга! Качып китүен дә шәп спектакль итеп оештырырга теләгән: янәсе, яшь командармга ярдәмгә ашыга! Чамалый — бердәнбер юл шул, Сембергә. Китәргә сәбәп табу да җиңел: анда да аны дан көтә! Ак чехлар якынлашкан саен канатлана барган тугрылыклы гаскәр, офицерлар көтә... Муравьевның Брест солыхын өзүне яклаганын да, Германиягә сугыш ачу коткысын иң нык таратучы икәнен дә гаскәр һәм офицерлар белә, онытмаганнар! Шушы ялган патриотизм дулкыны аны тагын өскә чөячәк, ул анда, эсер-меньшевик калдыклары белән берләшеп, кичәге дошманнары армиясенең дә башына менеп утыра алмасмыни?..

Шулай уйлап өлгергән Муравьев, шулай уйларга бөтен гомере белән әзерләнгән булган. Нинди хыянәткә дә әзер булган аның җаны. Кобозев аның ашыгыч адымнарын беразга туктатып тыеп торды...

Мин боларның һәммәсен дә шул чакта ук дөп-дөрес белдем дип язар идем — ялган була, хакыйкатькә хыянәт була. Муравьевка шикләнеп карадык, шикләнсәк тә ышандык, ышанасы килде. Кешеләрдән яхшылык эзләү, яхшылык көтү күңелгә рәхәтлек бирә. Шулай түгелмени? Яхшылык эшләгәндә яхшылыкны алучы гына түгел, яхшылыкны бирүче, таратучы ныграк баеый...

Сул эсерлар бер Муравьев кына түгел иде һәм алар фетнә хәбәрен төрлесе төрлечә каршылады...

Кобозев янынннан кайтып әл-хәл алырга да өлгермәдем, яныма Вера Петровна Брауде килеп керде. Күрештек. Мин аннан ашыгыч хәбәрләр көтәм, ул да мин көткәнне белә. Вера Петровна сүзне уртак мәсьәләдән башлады.

— Комитеттан килешем...

— Ничек анда?

— Бәхәс бара! Сул эсерлар Үзәк комитетының гамәлләрен яклаучылар да бар, каршылар да җитәрлек.

— Күпчелек кайсы якта?

— Кыямәт әле! Газета редакторы Петр Ионов «аңлап кайтырга» дип Мәскәүгә үк чыгып киткән! Имеш, информация җитәрлек түгел.

Шнуровский бикләнгән дә Казан эсерларының фикерен язмача әзерләп ята. Монда Казанда крестьян секциясендә раслатып, аны өяз советларына таратырга ниятли икән. Анысы алай, иртәгә,ягъни сигезенче июльдә, Мәскәүдән безгә сул эсерлар Үзәк Комитеты члены Вячеслав Трутовский килә.

— Ни калган аңа монда?

— Инструктаж алып килә дип беләм. Башкача ни өчен килеп йөрер?

Төштән соң миңа Петерс шалтыратты:

— Сергей Сергеевич, сездә ни хәлләр?

— Бездә бер килеш, менә сездә эшләр ничек?

— Мәскәүдә фетнәчеләрне ачыклау һәм кулга алулар дәвам итә. Совнарком Германия илчесе граф Мирбахны үтерүчеләрнең эшен тикшерергә махсус комиссия төзеде. Комиссия составына партиянең Казан губкомы председателе, Советларның 5 нче съезд делегаты Шейнкман кертелде. Комиссия җитәкчесе — юстиция халык комиссары Стучка. Икенче бер казанлы делегат — сул эсер Шляпников кулга алынды. Майтарган ул эшләрне! 6 июльдә Ярославльдә, 7 сендә Рыбинскида советка каршы фетнәләр кузгалды. Муравьев артыннан күзәтүне туктатмагыз, киметмәгез дә! Уяу булыгыз, Казанда да сул эсерлар һәм савинковчылар җитәрлек! Аларның баш күтәрүе бик мөмкин! Иделнең югары ягында нәкъ әнә шулар котырына да — савинковчылар!

Мин үз чиратымда Яков Христофоровичка Казан хәлләрен сөйләдем:

— Шалтыратуыгызга рәхмәт, сөендердегез! Җидесендә иртән, сәгать дүрттә Мәскәүгә шалтыраткан идем, телефоннан: «Власть сул эсерлар кулына күчте, аппарат яныннан сыпырыгыз!» — диделәр.

Петерс тыенкы гына көлеп куйды:

— Әйе, почта белән телеграф азга гына алар кулында булып алды. Азга гына! Аларның көне тиз үтте, кояшлары тиз баеды, тар-мар иттек үзләрен!

Бер-беребезне юатырлык, өмет өстәрлек хәбәрләр алышсак та июль аеның ил язмышында хәвеф-хәтәр белән узасын икебез дә белә идек...

Әҗәл барын да тигезли, ә хәтер яңадан үз урынына куя диләр. Дөрестер, әй! Кеше сау чакта аның эшчәнлеге бер төрле бәяләнсә, үлеп, бераз вакытлар узгач, бу бәянең капма-каршыга үзгәрүе ихтимал. Кеше гомеренең бер мөһим гамәле генә дә аның яшәешенең бөтен юлларын үзгәртеп җибәрә. Әгәр язмыш берәүнең кулына бик күпләрнең үткәнен тапшырып калдырган икән, чынлап әйтәм, андый кешенең тормышы жиңел түгел! Кинәт андый шәхес үз урынын бозып аңлый башлар да «ни кылансам шул килешә!» дип, үзен язмыш иркәсе, сайланмыш зат дип таныр, башкаларның тормышына гына түгел, үлеменә дә бармак аша гына карар... Үткәннәр белән эш итәргә алынган кешенең дә үз киләчәге бар...

Муравьев катлаулы затлардан иде дип килештек. Фетнә куптарырга йөрсә дә аны ахмак дип атап булмый, һич! Үз партиясе кешеләре белән аңлашып, сөйләшеп, бөтен җаваплы урыннарга үз кешеләрен куеп, һаваланып, шпор чыңлатып кына йөрмәгән икән ул!

Хәбибулла Вәлиуллин миңа Вологдадан килгән ашыгыч хәбәрне алып керде:

— Сергей Сергеевич, көтелмәгән яңалыклар!

— Көткән яңалыклар заманы кайчан килер соң, Хәбибулла?

— Вологдадан!

Чит ил миссияләренең дипломатик хадимнәре вакытлыча шул шәһәрдә урнашкан иде. Дипломатларның эшчәнлеге һәм элемтәләре белән кызыксынып яшәүче Хәрби контроль хезмәткәрләре элеккеге офицер Валерий Кудрявцев исеменә барып юлыгалар. Кудрявцев, инглиз һәм француз миссияләре белән элемтәгә кереп, Вологдада контрразведка бүлеге сыман нәрсә оештырган икән. Сорау алу вакытында ул: «Муравьев боерыгы белән эшләнде», — дип җавап биргән.

Хәбибулла алып кергән кәгазьдә Вологда чекистлары: «Кудрявцевны нишләтергә?» — дип сораганнар.

— Телеграмма сугыгыз, сак астында тизрәк Казанга озатсыннар. Муравьев турында безгә мөмкин кадәр тизрәк һәм күбрәк белергә кирәк.

Хәбибулла чыгып киткәч уем һаман бер тирәдә тулганды: «Кудрявцев, Кудрявцев... Нигә бу фамилия миңа бик таныш соң әле?» Таһировны дәшеп алдым.

— Гайнулла, Кудрявцев фамилиясе сиңа танышмы? — дип сорадым.

— Таныш. Бездә, чекада эшли Николай Кудрявцев.

— Кайчандыр Муравьевта махсус йомышчы булып хезмәт иткән, аннары каядыр югалган офицер Кудрявцевка бер-бер мөнәсәбәте бармы аның?

— Бертуганы, — диде барын да белә башлаган Таһиров. — Мин аларны бик күптән беләм, бер урамда, күрше дип әйтерлек яшәдек. Әтисе без азык-төлек ала торган кибеттә эшли иде. Хәзер дә шунда кайнаша, сәясәткә катышмый, бала-чагага кәнфит бирә торган юмарт абый. Ә нәрсә булган? — дип сорады Таһиров үз чиратында.

— Күзәт әле шул кешене. Бертуган абыйсы югалды дисәк, аны Вологдада кулга алганнар. Муравьев ихтыярын үтәп, чит ил дипломатлары белән арадашлык оештырып йөргән. Шуннан артыгы мәгълүм түгел. Мондагы Кудрявцевның чит ил контрасы белән якын булу ихтималы бар!

— Кул озын Муравьевның! — диде чыраен сытып Таһиров.

— Озын гынамы сиңа!..

— Яхшы, — диде Гайнулла. — Үтәрбез.

Хәбәр асылда Муравьев турында булганга, мин аны ашыгыч рәвештә Кин белән Кобозевка житкердем.

Төштән соң Кобозев мине чакырып алды, барсам, аның кабинетында Кин да утыра. Нидер сөйләшәләр иде, мин кергәч сүз бүленмәде. Кобозев кулындагы газетасын селки-селки миңа эндәште:

— Күрегез инде, Сергей Сергеевич! «Рабочий» газетасы, 9 июльдә чыккан... Менә ни дип язалар! «Граф Мирбахка бомбаны сул эсерлар ташлаган. Совет власте вәкилләре үтерүчеләрне эзли башлагач, сул эсерлар кораллы фетнә күтәргәннәр. Мескен партиянең мескен бунтын биш минутта бастырганнар».

Алар бу хакта сөйләшкәннәр иде ахрысы, Кин, башын чайкап йомгаклап куйды:

— Һәммәсе дөрес! Тик менә «бунтны биш минутта бастырганнар!» дип шапырыну уяулыкны киметә. Газета, яхшылык эшлим дип, укучыны йоклата!

Өчебезнең дә фикере бер иде: әйе, тәүлек кенә дәвам иткән фетнәдә кичә «совет партиясе» дип саналган партия, бүген үз исемен «революция дошманы» дип үзгәртте... Анысы хак!

— Тик менә бу партиянең членнары Казанда ни кылырлар?

— Муравьев кайсы якка үзгәрер?

— Газетада шулай язарга яраса да, безнең бүгенге хәлебез ифрат авыр...

— Кораллы бәрелеш буласы көн кебек ачык!

Кобозев белән Кин көндәлек вакыйгаларга шундый бәя биреп бетергәч, мин дә сүз кыстырдым:

— Бәлки, газеталарда тагын да ачыграк һәм кыюрак язаргадыр? Әгәр заговорчыларга «сезнең планнарны беләбез, һәр адымыгыз күз алдында!» дип белдерсәк, кораллы бәрелеш булмый да калыр? — дидем.

— Хәзерге халдә иң яхшысы шул булыр иде, — диде Кин. — Савинковчыларны туктаусыз эзәрлекләп, тотып алып, ачыктан-ачык бәрелешне моңарчы булдырмый килдек ләбаса! Хәзер дә әллә ни канат жәя алмас алар.

Кобозев аңа каршы төште:

— Эсерлар савинковчылар гына түгел! Савинковчыларның халык

арасында авторитеты юк иде, ә эсерлар крестьяннарга да таяна, теләктәшлек таба.

Крестьяннар, крестьяннар... Алардан кала сул эсерлар тагын кемгә таяна да, кемгә аркалана ала?

Кобозевны асылда шул сорау борчый икән. Кин белән мине шуңа күрә чакыртып алган. Икенче мәсьәлә: Муравьевны ничек кенә булса да хыянәттән саклап, аралап калырга!

— Шәһәрдә «Большевиклар тиздән бетә икән!» — дигән имеш-мимеш хәбәрләр таралган, — диде Кин. — Обсерватория станциясеннән «Ирекле Россия» бронепоезды кузгалырга җыена... Кузгалырга кем кушкан аңа? «Главком Муравьев боерыгы», — диләр. Дөресен бераү дә әйтми. Уйлашыйк әле, Казанда Муравьев кемнәргә таяна ала?

Уйга калдык. Мин, Кобозев үз фикерен әйтмәсме дип бераз көттем дә, белгәннәремне уртага салдым:

— Беренче чиратта Трофимовскийның эсер-максималистларына. Благотовичның серб батальонына. «Ирекле Россия» бронепоезды да аның яклы! Тагын элеккеге офицерлар тупланып, «Бетсен Брест солыхы! Рус офицерларының намусын һәм ватандарлыгын саклап калыйк!» дип бер чыгып кычкырса, өерләре белән Муравьев артыннан китәчәкләр.

— Алар шәһәрдә күпме? — дип сорады Кобозев.

— Житәрлек! — дидек без Кин белән бер авыздан.

— Байтак җыелалар икән, — дип килеште Кобозев. — Муравьев, сул эсерлардан Камков белән Спиридонованы дәүләт башлыклары итеп күтәреп, Идел буе Совет Республикасы төзергә җыена дигән хәбәр дә бар. Әлбәттә, сул эсерлар партиясенә таянып! Ниятләре һаман бер балык башы: чехлар белән берләшеп Германиягә сугыш игълан итү. Тик болары расланган фактлар түгел әлегә. Ә булуы ихтимал. Муравьевның характерына туры килә. Барыбызга да аерата сак булырга кирәк, сезгә чекада, безгә Реввоенсоветта. Без Мехонишинга фронт штабының эшен күзәтүне йөкләдек, сезнең чекистлар Трофимовский белән Благотовичны күздән ычкындырмасын. Тагын бер четерекле хәл: һич көтмәгәндә Казанга Беренче Уфа полкы кайтарылган. Ялга дигән булалар. Нигә? Юлда алар, кайтып киләләр, аларның командирларын да бераз чеметкәләп аласы иде. Кыскасы, безгә һәр адымны үлчәп, бер-беребезгә беледереп атларга кирәк булыр.

Шулай килешеп чека машинасында үзебезгә кайттык. Озак та үтмәде, Кин мине үзенә чакырып алды. Мин кергәндә ул терсәкләрен кочаклап, хафаланып тәрәзә каршысына баскан иде.

— Ни булды, Павел Андреевич? — дип сорадым.

— Эш мөшкел, — диде ул миңа борылып. — Кремль арсеналыннан туктаусыз корал югалуы турында хәбәрләр бар иде. Кая китүен генә моңарчы ачыклый алмадык. Хәзер хәбәр иттеләр: Муравьевның якын эшнәсе полковник Колесников бүген кич элекке дворяннар собраниесе бинасына офицерларны җыя. Һәммәсе коралланып килергә тиеш. Мәскәүдән өстәмә хәбәр алынды: Муравьев сул эсерлар фетнәсенең катнашучысы гына түгел, аны рухландыручы да! Муравьевны бер минут тормый кулга алырга кирәк. Югыйсә соң булыр.

— Әйе, җибәп торырга ярамый, — дидем мин Павел Андреевич Кинның тәвәккәллеген күреп. — Вакыт!

— Кобозевны да үзебез белән алыйк!

— Дөрес!

Кобозевны чакыртып алдык та, берничә чекистны ияртеп, главкомны эзләп киттек. Штаб урнашкан вагонда тапмадык, фронт штабында да юк иде ул, кичкырын без аны дворяннар собраниесе бинасында, мыжлап торган офицерлар арасында очраттык. Очрашу урыны безнең өчен бер дә кулай түгел иде... Кичектерергә дә ярамый. Безне күрүгә ул сискәнеп китте һәм тиз-тиз:

— Кулга алырга килдегезме? — дип сорады. — Мин эсерлар партиясеннән чыктым, кыек-мыек эшләргә катнашканым юк...

Аның юри кычкырып әйткән сүзләре тирә-яктагыларга ап-ачык ишетелде, безне уртага алып, яныбызга офицерлар тартылды. Кобозев безгә ым кагып өлгерде һәм бер дә исе китмәгән кыяфәт белән:

— Юкны юрыйсыз... Фронттан ашыгыч хәбәрләр алынды. Шуларны тизрәк карап хәл итәр өчен сезне фронт штабына чакырырга кердек.

— Яхшы! — диде Муравьев бер секунд икеләнеп тормастан. — Конвой, минем арттан!

Безнең арттан ук яхшы коралланган, черкеска кигән унлап кеше иярде, алар мыштым гына тыңланып баралар.

Большой Проломный урамындагы Щетинкин номерларына урнашкан фронт штабына барып кердек. Муравьев нидәндер шикләнеп якягына каранып алды, «кулга алулары ихтимал!» дигән шик килде ахрысы, мөгаен, ул моны ук көтмәгән иде бугай, юк-бар сөйләп вакытны сузарга, шул арада уйлап алырга, әзерләнергә тырышты.

— Штаб хезмәткәрләренә нинди уңайлы шартлар тудырдым! — диде ул кулларын җәеп күрсәтеп. — Җиһазларга гына игътибар итегез...

Чыннан да, кунакханәнең иң зур ике бүлмәсе, штабтан бигрәк, купшы ханымнар җыелып утыра торган зиннәтле залларны хәтерләтә иде. Тәрәзәләргә ука чуклы калын-калын пәрдәләр эленгән. Муравьев мактанырга теләп келәм калынлыгы пәрдәләрнең берсен күтәргән иде, аннан иңбашлары шәрә, чәчләре чүмәлә хәтле өелгән бер ханым йомылып кына чыкты да ишеккә ташланды. Ихтыярсыздан көлешеп алдык. Муравьев бик тәмләп кәкре аяклы, зиннәтле өсталләрне, язу машинкасын, йомшак кәнәфиләрне күрсәтә-күрсәтә бераз очынып йөрде дә туктады. Сизәбез, ул безнең тиккә килмәгәнне аңлады, хәзер шуны — тәбенең төшәргә әзер булуын заговорчы яраннарына хәбәр итүнең җаен эзли иде. Гәрчә үзенең хәле бик мөшкел икәнне аңласа да каушамады, артистларча лаеклы тотты, оста уйнады, кәмитләнде.

— Башта фронт хәбәрләре белән якыннанрак танышыйм инде мин, — диде ниһаять Муравьев. Аны киеренкелектән коткарырга теләгән кебек, штаб офицерларыннан берәү кочагы белән телеграммалар китереп тоттырды. — Аннан Реввоенсоветка үз фикеремне җиткерермен. Миңа сәгать ярым вакыт җитә.

— Риза! — диде Кобозев ашыгып. — Штабтан чыгып китмәвегезне генә үтенәм.

— Әлбәттә! Мин аңлыйм! — дип көлемсерәп Муравьев үз кабинетына кереп китте. Без ияртән чекистлардан икәвесе, Муравьев сакчылары белән аралашып, ишек төбендә басып калдылар.

Без Кобозев белән янәшә бүлмәләргә урнашкан реввоенсоветка кердек, ул секретарен чакырып, хәзер үк реввоенсовет членнарын җыярга кушты, губвоенком Межлаукка да хәбәр итүләрен үтенде.

— Муравьев сәгать ярым вакыт сорады, аңа кадәр безгә тупланып өлгерергә кирәк, — диде ул.

Чакырылганнар ун-унбиш минут эчендә килеп тә җиттеләр.

Утырышны Петр Алексеевич үзе ачты.

Гомердә истә калырлык утырыш иде бу...

— Казанда контрреволюцион заговор өлгереп житте. Моңа хәзер шик юк. Корбаннар бирмичә, ахыр чиктә, аз корбаннар бәрабәренә ничек шуны булдырмый калырга?.. Нинди мөмкинлекләр бар? Берәмберәм һәркем үз фикерен әйтсен. Фетнә якынлашуы безнең өчен яңалык түгел, һәркемнең үз акылы бардыр дип беләм. Губвоенкомнан һәм чекистлардан башлыйбыз. Кайсы гаскәри частьләргә таяныч була да, кайсыларын читләтеп, кемнәрнең юлын кисәргә кирәк. Кемнедер коралсызландырырга туры килер. Кемне? Сөйләгез, иптәш Межлаук.

Межлаук торып басты, барыбызны карап, барлагандай күзәтеп чыкты.

— Шәһәр коммунистларында төп өмет, иптәшләр, — диде ул. — Коммунистик батальонга таянырга була. Тимер юлчылар безне яклый. Карл Маркс исемендәге интернациональ батальон һәм фронтка әзерлә-

неп, китәргә өлгермәгән татар-башкорт ротасы. Чекистлар, милиция... — Межлаук бераз гына уйлап алды. — Кичә генә килеп төшкән Беренче азык-төлек полкы да безнең якта булыр дип ышаныйк. Полк Петроград, Мәскәү, Серпухов эшчеләреннән төзелгән. Мин аларны каршыларга бардым, очрашуда чыгыш та ясадым, хәлнең кискенлеген сөйләп, авылларга чыгардан элек беразга шәһәрдә калуларын үтендем. Алар резолюция кабул иттеләр. Менә ул. «Революция байрагы астына ышыкланган авантюристларның акылсыз чыгышларына протест белдерәбез. Андый чыгышларны барлык пролетариатка — беренче нәүбәттә Казан эшчеләренә дошманлык дип кабул итәбез. Контрреволюционерларның соңгы талпынулары безнең полкны әлегә шәһәрдә тоткарлады. Без Совет власте казанышларына кул тидертмәбез!»

— Барлыгы күпме җыела? — дип сорады арадан кемдер.

— Димәк, барлыгы өч меңгә якын аңлы сугышчыга исәп тота алабыз.

Бу сан барыбызны да уйландырды. Аз да түгел, дошман көчләре белән янәшә куеп караганда, күп тә түгел иде безнең көчләр...

— Иптәш Кобозев, сезнең чакыруны алуга, мин заводларга тревога сигналы тапшырттым. Хәзер эшчеләр ашыгып коралланa. Бүген төнлә, иртәгә көне буе урамнарда эшче патрульләр йөреп торачак. Почта-телеграф, банк, партия комитеты бинасы, коммунистлар клубы, чека бинaлары тиешенчә саклана. Хәзер бирегә, фронт штабына, Грузинский урамы аша коммунистик рота батальоны һәм броневик килә.

Муравьев ягында хәзергә Трофимовский отряды — ун пулемет белән коралланган мең ярым солдат һәм матрослар. Курск бронедивизионының бер өлеше. Сул эсерлардан ике дружина һәм советка каршы офицерлар. Сан ягыннан да дошман күбрәк, алар яхшырак коралланган да, арада сугыш тәҗрибәсе алганнар байтак. Безнең якта исә оешканлык, эшчеләрнең үз казанышларын яклап калырга чын омтылышы.

Межлаукның чыгышын Кин дәвам итте.

— Фетнә үзәгендә бүгенгә Муравьев фигурасы. Без аның белән Украинада бергә эшләдек, моңарчы ул миңа ышанып килә... Чека юнәлешеннән кыска гына арада без байтак эш башкардык. Кичәге газеталарда безнең махсус боерык басылды. Социал-революционерларның барлык хәрби дружиналары бар булган коралларын утыз беренче июльгә кадәр Гоголь урамындагы егерме сигезенче йортка урнашкан чекага китереп тапшырырга тиешләр. Боерыкка буйсынмыйча, рөхсәт язуыннан тыш корал асраган кешеләр атылачак... Әлегә китерүче юк, алай да боерык аларны сискәндергән булырга тиеш. Эсерлар Үзәк комитеты члены Трутовский монда бутала. Алар Спиридонованың кулга алынуына каршы чыкмакчы булалар һәм җирле эсерларны шуңа тартырга азапланалар. Мәгәр шушы шау-шуга нигезләнеп кенә әллә ни кыра алмаслар дип ышанам. Урындагы хәлләрне төрле яктан исәпләп, Муравьевны Казанда кулга алмаска дигән тәкъдим кертәм. Көтелмәгән һәм зур ыгы-зыгы тууы ихтимал. Бүгенге шартларда аның азагы безнең файдага булырмы яки киресенчәме? Без болай итик: барсын фронтка! Озатырга ышанычлы иптәшләрне җибәрик. Антонов аны күптән белә, ул үзе теләгәннәрдән бер төркем чекистны алсын, барсын! Юлда алар Муравьевны кулга алалар да туп-туры Мәскәүгә, Лубянкага озаталар. Анда инде һәммәсе энәсеннән җебенә кадәр ачыкланыр.

Безнең киңәшмәнең агышын бозып, усалланып телефон шалтырады. Трубканы Кобозев алды да бер-ике сүздән Кинга бирде.

— Крепостьтан безнең кеше шалтырата, — диде Кин бер минуттан. — Анда Муравьевны яклап митинглар башланган. Хәзер монда килеп аны коткарабыз дип яныйлар. Сул эсерлар белән анархистлар аерата шашыналар икән. Благотович серблары коралланa, корал төягән ике машинаны шәһәргә дә озатканнар.

Кин сөйләп тә бетермәде, телефон икенче тапкыр шалтырады. Трубканы телефон яныннан китәргә дә өлгермәгән Кин алды, ул, вакытны сузмас өчен, ишеткәннәрен кыска-кыска безгә дә әйтә барды:

— Трофимовский отряды поход тәртибендә шәһәр үзәгенә һәм вокзалга таба кузгалган... «Муравьевны бирмибез!» — дип бертуктаусыз акыралар.

— Тора-бара һәммәсе ачыкланды, — диде Кобозев. — Контрреволюция кузгалды. Бурыч элеккечә кала: фетнәне булдырмаска! Кин тәкъдимен кабул итәбез.

Ул арада ишек ачылды, шпорларын чыңлатып, башын югары чөеп Муравьев килеп керде. Кобозев, берни дә булмаган төсле эшлекле кыяфәт белән, өстәлдәге кәгазьләрен кузгатып алды һәм сүзен дәвам иттерде.

— Иптәшләр, барыбыз да җыйналдык. Реввоенсовет утырышын башлыйбыз. Сезнең фикерләрне тыңлап карыйк, Михаил Артемьевич.

— Оператив хәлләр бүгенгә шундый, — дип башлап китте Муравьев. — Инза дивизиясе һөҗүмгә күчеп Сызраньны азат итте. Гай отрядлары Жигули итәгенә чыктылар. Пугачевск отряды Ставрополь тирәсендә. Болар һәммәсе дә безнең уңышларны күрсәтә. Ләкин һәркайда да алай түгел. Соңгы сводкалардан күренгәнчә, безнең һөҗүм бер урында сөрлегеп тукталды — дошманның тиз арада Сембергә килеп җитүе ихтимал. Сембергә үземә бару кирәк дип исәплим. Һөҗүмне дәвам итәрлек чараларны үземә эзләп карарга булыр.

— Риза. Кушылам. — диде Кобозев, ашыгып. — Комиссар Благонравов белән иртә-таңнан кузгалыгыз...

Муравьев бер дә моны көтмәгән иде, теләсә нинди каршылыкка җавап әзерләп өлгергән бу елгыр кеше, Кобозевның ризалыгын карышусыз-нисез алгач, бер мизгелгә аптырап, сүзсез калды. Кобозев киңәшмәне үз кулыннан ычкындырмады.

— Хәзер Казандагы хәл турында сөйләшик. Аерым кешеләрнең генә түгел, гаскәри частьларның да совет властена каршы чыгарга әзерлеге мәгълүм. Күтәрелеп килгән фетнәне басар өчен без өч меңнән артык кораллы гаскәр тупладык. Главком бу хакта ни уйлый?

Муравьевның шпорлары чыңлап алды.

— Аерым частьларның тәртипсезлеге ачуны чыгара! Әгәр андыйлар башбаштаклыкны һаман дәвам иттерә икән, миңа буйсынмаучыларны каты җәза көтә!

Аның шушы сүзен генә көткән сыман, телефон өченче тапкыр шалтырады, трубканы Кобозев алды, агарынды һәм сүзен көчкә-көчкә ишеттереп әйтеп куйды.

— Син, Алевтина, боларны главкомның үзенә сөйлә! Вакытның аз икәнен әйтермен, үзе дә чамалар! — Ул безгә борылмыйча гына туп-туры Муравьевка карады. — Михаил Артемьевич! Трофимовский отряды солдатлары вокзалда гауга чыгарганнар, юлда граната шартлатканнар. Реввоенсовет поездын урап алып, председатель вагонына пулемет төбәгәннәр. Трофимовский минем хатынга янаган, «Әгәр Кобозев Муравьевны юк итсә, ачудан башта аның гаиләсен кырып эчәм, аннары үзенең җанын алам!» — дигән. Моны ничек аңларга, иптәш главком? Сезнең кешеләр хатыннар һәм балалар белән сугыша башладымыни инде? Балалар җылаша!

Муравьев дәшмичә генә телефонга килде, коры, ягьел тавыш белән Трофимовскийны чакырырга кушты.

— Нәрсә анда җәнҗал кубарасың? Кобозев хатынына янарга ни хакың бар? Мин исән-сау, иртәгә таңнан пароход белән Сембергә юнәләм. Вокзалда күз ачып йомганчы тәртип урнаштыр! Тәртип өчен башың белән җавап бирерсең!

Утырыш тып-тын булып калды.

Алевтина реввоенсовет утырышы узуын ничек тиз белгәндер! Азга гына соңга калса да, бик зур бәхетсезлек булуы ихтимал иде бит. Мин

Кинга авышып: «Әллә миңа шунда барып кайтыргамы?» — дип сорадым. Ул ашыкмаска кушты...

Кобозев биш минутка тәнәфес игълан итте.

Муравьев торды, кырт борылып үз кабинетына кереп бикләнде, ике чекист аның ишек катына бастылар.

Күзләр телефонда. Ул көттереп кенә тагын шалтырады. Вокзалда дежур булган чекист Кинга Трофимовский кешеләреннең юллардан чыгып, вокзал алдына тезелүләрен, каяндыр ике орудие тәгәрәтеп китереп, шәһәр ягына, дөресрәге Большой Проломный урамы Фронт штабы бинасына турылап куюларын хәбәр итте. Димәк, андагы ыгы-зыгы туктамаган. Каушап калмасак та, барыбыз да дулкынланган идек. Ниһаять, Муравьев күренде, черкеска кигән купшы офицерлар коридорда юл биреп аны хөрмәтләп озатып калдылар. Кин аңа мөрәҗәгать итте:

— Михаил Артемьевич, шәһәрдә комендант мин. Ә Иванов, крепость коменданты, минем рөхсәттән башка арсеналдан корал өләшә. Бронедивизион взводы да, серблар отряды да сугышка әзерлек хәленә китерелгән. Ярамаган куркынычлы хәл тумасын дисәк, Ивановка боерыгыз, законсыз эшләрен туктатсын! Солдатлар казармаларына кайтсыннар.

— Яхшы, — дип килеште Муравьев.

Кин, берничә минуттан, коммунистик батальон сугышчыларын алып, крепостька ашыкты. Мандатта Муравьев имзасын күргәч, Иванов белән Благотович Киннан: «Муравьев чыннан да иректәме?» — дип сорадылар, җавапның дөреслеген ачыклар өчен, өч кешене чаптырып җибәрделәр.

— Әгәр дөрес икән, главком боерыгына сүзсез буйсынабыз!

Крепостьтан Щетинкин номерларына еракмыни, китүчеләр тиз үк әйләнеп тә кайтты.

— Главком белән сөйләшә алмадык, реввоенсовет утырышы бара, мәгәр аның тыныч кына түрдә, киңәшмәдә утыруын үз күзләребез белән күрдек, — диделәр алар.

— Буйсынабыз! — диде Благотович һәм солдатларына таралырга боерды.

Кин коммунистик батальон сугышчыларын арсенал янына каравылга куйган, Ивановны Черек күл урамындагы комендатурага алып барып тапшырган. Тегене утырткannar.

Без боларны бераз соңрак, күңеле күтәрелгән Кин реввоенсовет утырышына әйләнеп кайтып, күргән чаралары турында сөйләп биргәч кенә белдек.

Мин Муравьевтан күземне алмадым.

Крепостьтагы солдатларның аның исәнлеген һәм иминлеген кайгыртып килеп китүләрен ишеткәч, ул канәгатьләнеп елмайды. Арсенал каравылына коммунистик батальон сугышчылары басканын ишеткәч, елмаеп торган күзләр усал елтырадылар. Кин шуларны сөйләгәч, кыска гына кәгазь язып Кобозевка тапшырды һәм китәргә рөхсәт сорады. Кобозев кәгазьне укыгач, баш кагып, китәргә рөхсәт бирде.

Павел Андреевич бик вакытлы чыгып киткән икән! Ул янәдән туптуры крепостька юнәлә, бронедивизион коммунистларын җыеп, ике броневикка утыртып, атлы взводны ияртеп, дворяннар собраниесе бинасына алып бара. Анда җыелган офицерларның Муравьевны яклау хәрәкәтен кисәргә кирәк. Хәзергә иң ашыгыч эш шул! Барып җитсәләр, йөзәрләгән кораллы офицерлар кызып-кызып Муравьевны коткарырга җыенып яталар. Шау-шу, ачыктан-ачык янау тавышлары. Броневиклар, атлылар һәм Кинның сүзләре аларны айнытып җибәрә, офицерларның күпчелеге өйләренә тарала, бер өлеше, ышанмыйча, Щетинкин номерларына таба кузгала. Броневиклар һәм атлылар аларны уртага алып өлгерә. Бусы да бик вакытлы эшләнә!

Без реввоенсоветта Муравьев һәм комиссар Благонравовның фронтка маршрутын билгеләп утырганда, тагын телефон шалтырады. Ничәнче

мәртәбә барыбыз да шик һәм шөбһә, өмет һәм нәфрәт белән тагын телефонга текәлдек. Вокзал янындагы чекист тагын шалтырата икән.

— Инде хәл тынычлана дип торганда, Трофимовский вокзал мәйданында җыелган гаскәренә: «Безнең главкомны революция хыянәтчеләре кулга алган, барыйк та аны коткарыйк!» — дип команда бирде...

Балконның ачык ишеге аша без гостиницага таба чапкан ишле атлыларны күрдек. «Трофимовский безнең планнарны сиздеме, әллә аларның башка бер максатлары бармы?» — дип тә уйлап өлгермәдем, Кобозев, әче тавыш белән Муравьевка эндәште:

— Үзегез чәчкәнне урыгыз әнә! — диде. — Әгәр сез фетнәче түгел, главком икәнсез, балконга чыгыгыз да Трофимовскийдан сорагыз: ни кирәк аңа? Эскадронын ни максат белән монда чаптырган? Әлегә тирәякта дошманнар юк шикелле.

Муравьев безнең ачулы, ярсыган чырайларга бер генә карап алды, минем һәм кайбер башка иптәшләрнең кулларында ялтыраган пистолетларны да күрмәде түгел, артык сөйләшеп торуның файдасы юк икәнен төшенде. Шпорларын тагын да ныграк чыңлатып калкынды, чәчләрен артка сыпырды, киң-киң атлап балконга чыкты. Гостиница турына килеп бөялгән атлыларга карап, урамны яңгыратып:

— Смирно! — дип акырды. Җайдаклар атларының авызлыкларын тартып сафка тезелделәр. — Кем сезне чакырды? — Ул карашын Трофимовскийга төбәде. — Кем? Башбаштаклык өчен кирәгеңне алырсың! Кайда булырга куштым мин сезгә? Эскадрон, кругом марш!

Отряд вокзалга карап юртты, аннан пристаньгә — Аргы Үсиягә таба юнәлде. Ат тояклары куптарган тузан басылып та өлгермәгән иде, мин балконга чыктым. Бер яктан атлы отряд китеп тә өлгермәде, Балык мәйданы ягыннан, Проломный урамын иңләп тагын гаскәр килә! Бер төркем офицерлар кызып нидер сөйләшә-сөйләшә ашыгалар, аларга ике броневик һәм атлылар ияргән иде. Арада Кинны һәм башка чекистларны күргәч, мин җиңел суладым. Ярый әле Трофимовский атлылары китеп өлгерде, әгәр алар монда очрашкан булса, кем белгән...

— Реввоенсовет утырышын ябып таралышканчы, — диде бераз тынычланган Кобозев. — Без сул эсер фетнәсен хөкем итүебезне белдерергә бурычлы. Көнчыгыш фронт армияләренә приказ язгыз! — Ул Муравьевка борылды. — Языгыз, Михаил Артемьевич.

Утырды Муравьев, яза да башлады. Кобозев һәм башка комиссарлар әйтә тордылар.

«Көнчыгыш фронтында сугышучы кызылармеецлар һәм командирлар! Мәскәүдә сул эсерларның революциягә каршы чыгышы тар-мар ителүен сезгә җиткерәбез. Социалистик Ватан дошманнарына каршы көрәштә бар көчебезне туплыйк. Һәлак булачагы алдан ук билгеле булган авантюристик чыгышларны һәрчак тар-мар итү — безнең төп бурыч».

Приказга кул куяр алдыннан Муравьев каләмен соңгы кабат зәңгәр карага манды да кәгазьгә карап уйланып торды. Нинди кичерешләр биләде икән аның дуамал башын? Тезен-тезгә күчерде ахры, яшел сукно ябылган өстәл астыннан тоньк кына чыңлап шпорлары тавыш биреп алды...

Главкомны фронтка озатып йөрү реввоенсовет члены Благонравовка һәм Хәрби контроль начальнигы Файерманга йөкләнде. «Межень» пароходына алдан ук бер төркем чекистлар кереп утырды, алар билгеләнгән «эш»не юлда башкарырга тиешләр. Муравьев 10 июльдә иртәнге тугызда Казаннан йөзеп кузгалырга тиеш.

Главком ниятләгән фетнә әлегә сүнде, урам-мәйданнарда көчәйтелгән патрульләр йөреп тора, шикле кешеләрнең документларын тикшерәләр, бергә җыелганнарны иңләп кенә тарата торалар. Хәзер операциянең

икенче өлеше гамәлгә керәчәк: тавышсыз-тынсыз гына Муравьевны кулга алырга һәм Мәскәүгә озатырга кирәк. Казанлы сул эсерлар бу хәлне белми калырга тиешләр. Без шулай дип планлаштырган идек. Әмма уйлаганнарыбызны ансат кына эшкә ашыра алмадык, көтелмәгән хәлләр туды, тәҗрибәле һәм хыянәтләргә остарган Муравьевның елгырлыгы тагын өстен чыкты.

Нишлисең, тормышта алай да була...

Вокзалда, иң аулак юлда, реввоенсовет поезды тора иде.

Фронт штабыннан, Щетинкин номерларыннан бергә чыгып, шунда кадәр Муравьев белән бергә Благонравов һәм Файерман икесе баралар. Поезд составындагы главком вагонына да өчәү керәләр. Вагонга кергәч, Благонравов Муравьевка:

— Михаил Артемьевич, комиссарларның тулысы белән сезгә ышанып бетмәскә нигезе бар, гафу итегез, шул сәбәпле без гел сезнең тирәдә булырбыз инде, — дип кисәтүне тиеш таба. — Бу — приказ, сезгә аңа буйсынырга гына кала!

— Ачык әйтүегез өчен рәхмәт, — ди Муравьев һаваланып. — Мин үз вагонымда булам, юл кирәк-яракларын әзерләп, чак кына черем итеп алам.

— Яхшы, — дип күнә Благонравов. — Ике сәгать дәвамында сезнең янда Файерман торып торыр, аннары мин аны алыштырырмын. Сез безгә карамагыз, эшегезне эшләгез, әзерләнегез. Китеп кенә йөрмәгез!

Благонравовның бу сүзләренә дә күтәрелеп бәрелми Муравьев, бу кыланышы белән комиссарны бераз шиккә дә төшерә, әмма сүз бик тыныч дәвам итә. Благонравов чыгып киткәндә Файерманга мәгънәле карап ала: уяу бул, янәсе! Сак бул!

Благонравовның аяк эзләре дә басылып өлгерми, Файерман түш кесәсеннән ниндидер кәгазьләр чыгара, тотлыга-тотлыга:

— Михаил Артемьевич, бу документларга күз салыгыз әле, — ди. — Шуннан барын да аңларсыз.

Муравьев кәгазьләргә карап кына ала.

— Сез кем? Сул эсермы, коммунистмы? Ике партиядә дә торуыгыз турындагы карточкаларны нигә миңа күрсәтәсез?

— Миңа ышануыгызны телим.

— Шуннан ни үзгәрә?

— Михаил Артемьевич! Пароход Казаннан кузгалып китүгә үк чекистлар сезне кулга алырга телиләр. Аларның күпчелеге пароходта инде. Тик алар — чекистлар һәм коммунистлар — егермедән артык түгел. Сезгә иртәгә түгел, бүген, хәзер үк, ашыгыч рәвештә качарга кирәк. Мин ярты сәгатькә генә югалып торам, шуннан артыгы ярамый... Форсаттан ничек файдаланырга кирәген үзегез уйлагыз.

Муравьевның ризалыгын көтеп тә тормасын, Файерман китеп бара. Главкомның, тәкәббер һәм һавалы бөек затның, ул тәкъдим иткәннән башка юлы юклыгын Файерман чамалый. Берәүгә дә баш бирмәгән, дәһшәтле совет властена да буйсынмаган, хәйләкәр чекага да тоттырмаган башкомандующийның язмышы әлегә аның — Файерманның кулында! Мондый минутлар — бөеклеккә ашкынып омтылган, әмма бер чакта үз кендегеннән биеккә күтәрелә алмаган, күтәрелә алмаслыгын тормыш тәҗрибәсе өйрәткән кеше өчен үтә кадерле минутлар. Файерманның көткән сәгате сукты: ул тарихи затлар арасында. Тарихи шәхеснең язмышы аның кулында. Кем моннан болай аны, Хәрби контрольдә шыпырт кына имеп яткан бәндәне, вак кеше дип әйтә алыр? Әгәр бүген ул аны коткарып калмаса — чекистлар Муравьевны иртәгә көл итәчәк. Ул — Файерман, моңарчы тарихка керә алмаган кечкенә кеше — аны коткарып кала! Комиссарларның, чекистларның тырышып-тырышып корган планнары сүтеләчәк, черек җеп кебек өзеләчәк! Алар, үз планнарына үзләре гашыйк булып, адәм көлкесенә калачаклар... Главком вагоныннан чыкканда Файерман бөркеткә әйләнә, кашлары югары менеп кит-

кән, нәзек муены турыга каткан, тыпыр-тыпыр бара, сакта торган эчкерсез кызылармеецлар хәтта аңа честь биреп озаталар...

Соңыннан ул: «Эч бөтереп алды, туалет эзләп, чиратка басып, ярты сәгатькә генә югалып тордым», — диячәк. Сүзенең дөреслеген честь биреп поезд сакчылары раслаячак. «Әйе, ярты сәгатьтән әйләнеп кайтты»...

Файерман чыгып китүгә үк Муравьевның хәрәкәтләре үзгәрә, бүгенге тыгыз вакыйгалар өермәсеннән томаланган зиһене яп-якты ачылып китә, ул, хәрбиләрчә тиз һәм туры уйларга күнеккән кеше, күз ачып йомганчы, Трофимовскийны һәм өч адъютантын дәшеп ала. Чакырганнар көттермиләр, лапыр-лопыр атлап килеп тә керәләр. Муравьев алар белән колактан-колакка чыш-пыш сөйләшеп ала, аларның ни кинәшкәнен тәрәзә астында торган чекистлар да ишетә алмый. Адъютантларның өчесенең өч якка ашыгып чабып китүе дә аларны хәвефкә төшерми, главком Сембергә барырга әзерләнә, йомыш-каралары булуы ихтимал! Андый кабалануны алар һәркөн, һәркемдә күреп торалар лабаса.

Муравьевның чыгып китүен алар абайламый да кала диярлек. Муравьев песи булып кына чыга да, үзен көтеп торган автомобильгә утырып, Трофимовский белән пристаньгә элдертә. Үзен көтеп аулактарак торган пароходка кереп тә урнаша. Кай арада килеп өлгергән Трофимовский отрядыннан ике йөзләп офицер белән солдатлар да дулкыннарда матур тирбәлеп утырган пароходка кереп тула. Муравьевка сукырларча ияргән, аның өчен жаннарын бирергә әзер торган ышанычлы кешеләр була алары. Янәшәдә генә торган «Миссури» пароходына Трофимовский урнаша. Алар кузгалалар да, Свияжск ягына йөзеп тә китәләр.

Озакламый пристань янына выжылдап икенче автомобиль килеп туктый, аннан Муравьевның тугры адъютанты Чудиношвили һәм черкеска кигән ике офицер сургуч белән пичәтләнгән авыр тартманы бөгелә-сыгыла күтәреп пароходка кертеп тә куялар. Тартмада бер миллионга якын акча — Сембер армияләренә бер айлык жалуния! Акчалы тартманы офицерлар күз белән каршылыйлар, күз белән капитан каютасына озатып калалар. Эчләренә жылы йөгерә: акча алар белән! Алар пароходында андый-мондый хәл булса да акчалы булып калачаклар...

Төнге икеләрдә «Межень» якорьләрен күтәрә дә туп-туры Сембер ягына юл ала. Пароходта Муравьев, янында бер тартма акча. Азыктөлек мул, тырыш адъютантлар ул якны да, эчемлек мәсьәләсен дә хәстәрләп куйганнар. Кайберәүләргә бу сәфәр күңел ачу, сәйранга чыгу кебегрәк тоела... «Тотыгыз Муравьевның койрыгын, сизгер чекистлар!»

Шул чамада Файерман арып-талып йоклаган Благонравовны төрткәләп уята, ирен читләре күбекләнгән, сүзен әйтә алмый... Алар ап-ак агарынып, телсез калып Кобозев вагонына барып керәләр. Алевтина, Кобозевның хатыны, аларны кертми тора: «Әлерәк кенә кайтып ятты, түзегез, чак кына ял итсен инде!» — дип ялвара. Кая ул, түзәрлекме соң! Күпме көннәр күздән югалтмаган явыз дошман борын төбеннән исән-аман ычкынсын әле!

— Муравьев качты!

Кобозев тревога күтәрә...

Чекада э л е к хезмәт иткән Александр Логинов күрсәтмәләре. Хәтерлисезме, аны «безнең кеше» дип Кобозев атаган иде...

«Пароход командасы белән гаскәриләр төне буе эчтеләр. Минем к е м икәнлегемне, каргалар арасына килеп эләккән үрдәк бәбкәсе булуымны беләләр иде ахрысы, кузгала башласам, «утыр!» дип бер генә жикеренәләр. Иртәнгә кадәр беркая чыга алмадым. Янымдагыларның телендә элә-тотанак юк иде, ике сүзнең берендә Муравьевка мәдхия укыйлар да коммунистларны сүгәләр. 10 июльдә палубага чыккач, безнең белән янәшәдә, ерак та түгел катер барганын күрдем. Бөтен урыннарында кораллы солдатлар тәялгән. Безне күрүгә сөенешеп һавага ата башладылар. Тиздән аның «разведка» икәне беленде. Ул арада палуба-

да Муравьев та күренде. Кырынган, чистарынган, өстендә өр-яңа киемнәр. Аны «ур-ра!» кычкырып каршыладылар, пароход гудок белән сәламләде. Бераздан ул минем янга килде, бөеренә таянып: «Кем син? Һаман коммунистмы, түгелме?» — дип сорады. «Коммунист!» — дип җавап бирдем. Муравьев артык төпченеп тә, бәйләнеп тә тормады, китеп барды. Озакламый палубага Муравьевның барлык штабы бүселеп чыкты, ул башкаларны да чакырырга боерды. Халык палубаны тутырып җыелса да, әлегә ул бер сүз дә эндәшмәде, тарафдарларын кул болгап сәламләде дә шуның белән очрашу тәмамланды.

Сембергә җитәрәк ун-унбиш чакрымнар булыр, ул пароходны туктатырга боерды. Якорь төшерделәр. Бездән күрмәкче янәшәдәге катер да туктап калды. Пароходтагылар барысы җыйналып беткәч, катер да швартовыйлар белән безгә бәйләнгәч, Муравьев гаскәрләргә мөрәҗәгать итте.

Адъютантлары ул сүз әйткән саен «ур-ра!» кычкырдылар...

— Мин, чехлар белән бәрелешне туктатып, Германиягә сугыш игълан итәм. Без ач, ә миллион потлап икмәк Германиягә озатыла. Без ялангач, ә бөтен манафактура немецларга китеп бара. Мин моңа чыдап тора алмыйм. Брест солыхын моңарчы да танымаган бар халык — сул эсерлар, максималистлар, анархистлар, большевик-бухаринчылар безгә иярәчәк!

Үземне Верховный башкомандующий дип игълан итәм. Кем миңа каршы — аны тар-мар итәчәкмен. Гаскәрләр кайда да минем арттан барыр дип ышанам! Сембердә мине тугрылыклы частьларым көтә. Мин үземне Россияне коткаручы Гарибальди дип белдерәм. Хурлыклы Брест солыхы бетсен! Германиягә каршы баррикадаларга! Яшәсен немецларга каршы восстание!

Бу — аның сүзләре. «Җыелганнар тагын бер тапкыр «ур-ра!» кычкырдылар. Тик кенә басып торып, мин аны-моны сиздермәдем. Алар кызган чакта каршы бер сүз әйтсәм дә суга тотып атачакларын күреп тордым. Шунда ук Муравьевның секретаре солдат башына иллешәр сум өләшеп чыкты, офицерларга күпмедән эләккәндер, аларга акчаны безнең күз алдында бирмәделәр...»

Муравьевны армиядән аеру, хыянәттән аралап калу планнарыбыз өзелде... Төн урталарында «Межень» пароходын куа чыккан безнең катерлар, Трофимовский утырган «Миссури» пароходына алданып, Свияжск ягына киткән булып чыктылар...

«Межень» пароходындагы чекистларны һәм коммунистларны берәм-берәм кулга алып, кыйный-кыйный пароход трюмына төшереп ябалар. Мәскәүдән бергә килгән кеше буларак бер Логиновны гына иректә калдыралар. Ләкин ул да чарасыз: бер башы шул кадәр дошман арасында ни дә кыла алмый, ирексез шаһит булып кына кала...

Александр Логинов сүзләренең дәвамы:

«Пароходта көне буе бәйрәм ясадылар. Исерекләр кочаклашып палубада йөриләр, Муравьев күренсә, аны кочаклап җырлыйлар, җылаучылар да булды. Пистолетымны тартып алмаган булсалар атып үтерә идем явызны. Исерек тавышлар арасында трюмнан яралы иптәшләремнең су сорап ялварган тавышлары ишетелеп кала. Нишләргә белмим... Төштән соң Муравьев тагын минем янга килде:

— Син һаман коммунистмы әле?— дип кат-кат сорады.

— Коммунист! — дип җавап бирдем.

Аның күзләре ялтырап китте. Берзаман кичкырын трюмны ачтылар, исерек офицерлар, солдатлар чекистларны, коммунистларны сөйрәп меңгерделәр. Ату тавышлары яңгырады, иптәшләрне берәм-берәм Иделгә ташладылар. Сембергә җитәрәк Муравьевның ике адъютанты мине эләктереп алдылар да чайкый-чайкый суга ыргыттылар. Көләләр үзләре, шаркылдыйлар...

Көне буе ашамаган, хәлем юк, пароход дулкыннары бөтереп алып төшеп киткәч: «Беттем!» — дип уйладым. Әмма күз алдымнан иптәшләремнең кыйналган, тапталган, атылган канлы гәүдәләре узып китте: дөреслекне кем дә булса кайтып ирештерергә тиештер бит! Яшь чактан ук бик яхшы йөзә идем мин, җайлап кына иң әүвәл күн итекләремне салдым, су өстендә чалкан ятып чалбар-гимнастеркамнан котылдым, әле ярый, көн тыныч, җилсез иде, су өсте вак кына шадраланып тора. Әмма агым бик көчле, һич кенә дә ярга чыга алмыйм, йөзә-ага бер маякка барып җиттем, хәлем китеп шуңа ябыштым. Күпме торганмындыр, кич күз бәйләнә башлаганда, мине маякчы агай йолкып алды. Көймәгә утырып аның йортына кайттым. Әл-хәл алып, чәй эчеп, аның иске-москы киемнәрен киеп төн уртасында Сембергә барып кердем...

Пароход Сембергә кичке җиделәрдә килеп җиткән икән...»

Файерманның хыянәте безгә бик кыйммәткә төште!

Пароход телеграфы бертуктаусыз эшли. Муравьев аны үзенең штабы иткән. Муравьев кушуы буенча 1 нче Армия командующие Тухачевскийны Сембергә чакыртып алалар. Армия житәкчесез кала. Фронттагы частьлар главкомның коткысына ышанып ялгыш юлга кереп китәләр.

«Немец гаскәрләре демаркацион сызыкны үтеп чыгып, бөтен фронтларда һөҗүм башладылар: Мәскәү һәм Петроград юнәлешендә хәрәкәт итәләр. Шул сәбәпле Көнчыгыш фронт Кайзерга сугыш игълан итә һәм барлык гаскәрләрен көнбатышка таба юнәлтә».

Муравьевның беренче приказы шул була.

Ул чехословак корпусы легионерларына да тиешле сүзне таба: «Самарадан алып Владивостокка кадәрге чехословак командирларына!» дип тукылдый телеграф, «Германиягә сугыш игълан ителүен истә тотып, Көнчыгышка баручы барлык эшелоннарны Көнбатышка борырга, Иделдә тупланырга, аннары Көнбатыш чиккә һөҗүмгә күчәргә. Иделдә Сембер-Саратов-Балашов-Царицын сызыгын тулысынча яулап алып, төньяк Уралда Екатеринбург һәм Пермьне кулга төшерергә. Күрсәтмәләр өстәмә рәвештә махсус биреләчәк». Бу приказларга ул «Германиягә каршы сугышучы Армиянең башкомандующие» дип кул куя...

— Сез ни майтарганыгызны аңлыйсызмы? Бөтенесе җайга салынганда, Казанда фетнәне булдырмый калдырдык дип исәпләгәндә төп хыянәтчене чыгарып җибәреп, Семберне һәлакәт алдында калдырырга, Көнчыгыш фронты гаскәрләрен бутап бетерергә... — Вагон буйлап гасабиланып йөргән Кобозев Благонравов белән Файерманның тетмәсен тетә иде.

Үкенеп ни файда, моны яхшы аңлаган Кобозев телефон аша безне чакырып алды. Без Кин белән чекада идек.

Кобозев вагонына барып кергәндә, реввоенсовет членнары анда җыелып өлгергән иде инде. Алар курач гәүдәле, йомыкый гына Файерманны урап алганнар да, кабып йотардай булып, аңа карап торалар. Куркуы йөзенә чыкса да, Файерман, телгә беткән бәндә, аксак саескан кебек тәтелдәпме-тәтелди... Кин белән минем кергәнне күргәч шым булды, агарынды. Без Кобозев янына аппаратныйга уздык. Ул Мәскәүгә хәбәр тапшыра иде.

«Мәскәү, Кремль, Ленинга. Оператив штаб Араловка. Бөгелмә, Мәләкәс, Пермь... Барчагызга, барчагызга, барчагызга! Халык акчасын алып Казаннан Сембергә качкан элекке главком Муравьевны революция хыянәтчесе, шашкан провокатор итеп игълан итәбез. Ул бөтен җирдә таратып йөргән хәбәр — ялган! Советларның Германиягә каршы сугыш белдергәне юк. Очрата калсагыз, Советлар Россиясенең дош-

маны буларак, аны котырган этне аткан кебек атып үтерү бурычы йөкләнә».

Аппарат тынды. Без өчәү тик кенә утырабыз. Кыен хәлдә калдык, сынаттык, республика тормышына буталыш керттек.

— Нишләргә? — диде Кин.

— Барыннан да элек Файерманны ябып куегыз. Иң житез катерны эзләп табып, берничә чекист белән Антоновны утыртыгыз. Куып карасыннар. Жае чыкса — кулга алырга, жай юк икән — үтерергә! Башка чара калмады.

Антонов экспедициясен әзерләү өчен без ашыгыч рәвештә чекага кайттык, якындарак булган иптәшләрдән отряд оештырып, аларга гадәттән тыш авыр бурыч йөкләдек:

— Сез хәзер Муравьев эзе белән китәсез. Жирдәме ул, күктәме, сез аны эзләп табарга тиеш. Аның качып китү хурлыгы Казан чекистлары намусында.

Эш бүлешеп, коралландырып Антонов отрядын пристаньга озаткач, яңадан Кобозев янына кайттык. Реввоенсовет председателе беркая да китмәгән, ул тирләп-пешеп аппаратныйда басып тора иде. Кобозев хәбәренә Совнаркомнан жавап та килеп житте: «Барчагызга, барчагызга, барчагызга! Чехословакларга каршы оештырылган Көнчыгыш фронтның элекке башкомандующие Муравьевны инглиз-француз империалистлары сатып алган. Муравьев революцион совет штабыннан Сембергә качып, барлык гаскәрләргә: «Немецлар Оршаны алган, Германиягә каршы сугышка чыгыгыз!» — дип боерык биргән. Бу хыянәтчел приказның максаты бер: Петроград белән Мәскәүгә, аннары бөтен Россиягә чехословаклар һәм акгвардиячеләр һөжүм итә алсын өчен эшләнә. Муравьевның хыянәте Революцион Хәрби Совет тарафыннан ачылды. Чехословакларга каршы көрәшкән барлык гаскәр Совет властена тугры калды. Советларга, гаскәрләргә, совет республикасының барлык гражданнарына белдерәбез: немецлар беркайда да һөжүмгә күчмәделәр, герман фронтында тынлык. Икенчедән, немец фронтында һөжүмгә өндәүләр провокация саналып, өндәүчеләр үлемгә хөкем ителәчәк. Өченчедән, элекке башкомандующий Муравьев халык дошманы дип игълан ителә. Дүртенчедән, Көнчыгыш фронты гаскәрләренә приказларга бары тик Мехоношин белән Благонравов кына кул куячак».

— Бүгенгә программа әнә шул, — диде Кобозев, кулындагы ленталарны безгә күрсәтеп. — Сездә ни хәлләр?

Эшләрнең башкарылган кадәресе белән реввоенсовет председателен таныштырдык.

— Революцион частьларда уяулыкны арттырыйк дип сөйләшәбез, приказлар язабыз. Уяу булырга гына өйрәнеп бетә алганыбыз юк. Савинковчылар йокламый дип хәбәр итәсез, сул эсерлар нәрсәгәдер өметләнә дип нәтижә ясыйсыз. Нинди чаралар күрдегез соң? Мин әлерәк кенә большевиклар комитеты белән сөйләштем. Алар эшчеләр һәм кызылармеецлар арасында аңлату эшләрен көчәйтергә керештеләр. Болар гына аз. Файерманнан сорау алдыгызмы әле?

Файерманнан сорау алдык та чыгарып жибәрдек.

Хәзерге көнгәчә баш ватам: нигә чыгарып жибәрдек без аны? Аның тезләнеп, түше белән шуышып дигәндәй ялваруы һаман күз алдымда. Жирәндекме без аннан, әллә: «Яшәсен әйдә, тагын ни кырырлыгы калган инде бу хәшәрәтнең?» — дип уйладыкмы?.. Бер караганда, шулай да иде бит! Кесәсеннән чыккан ике билет — ике партиядә дә әгъза булып торуын күрсәткән документлар Хәрби контроль начальнигының ике яклы пычак булуын раслады. Аның кем булуы, теләсә нинди хыянәткә әзер булуы хәзер тулысы белән ачык иде. Үзе кылган жинаятьләрдән моннан ары ул котылачак түгел. «Кара сакалың кайда да артыңнан калмас!» — диләр бит, мин бу очракта халык мәкален чак кына үзгәртер идем: «Кара сакалың үзеңнән алда йөрер!» Файерман-

ның яманаты, кем булуы үзеннән алда йөриячәк. Кайда да аның кемлеген беләчәкләр... Әллә шуны уйлап, без аның хыянәтенә тагын да авыррак хөкем чыгардыкмы? Ансат үлем бүләк итәсебез килмәдеме?

Боларын мин гомерем буе уйладым, мәгәр җавап таба алмадым.

Антонов отряды мең бәлаләр белән Сембергә барып җиткәндә, Муравьевны үтергәннәр иде инде...

10 июльдә, Сембердә, Муравьев үзенә тугры отрядлар белән совдепны камап ала, совет хезмәткәрләренең байтагын кулга төшерә. Почта белән телеграфка да хуҗа булып өлгерә — Сембер Казан белән Мәскәү элемтәсеннән мәхрүм кала. Варейкис җитәкчелегендәге Сембер большевиклары һәм чека председателе Левин кул астындагы чекистлар хыянәтчене юк итәргә тырышалар. Совнарком карарын ишетә алмасалар да, Сембер коммунистлары Муравьевның хыянәт юлына аяк басканын баштан ук белеп алалар. Гаскәри частьларда аңлату эшләре җәелә, Мәскәүдән Көнчыгыш фронтка килгән эшчеләр отрядында, бронедивизионда, матрослар һәм латыш укчылары арасында алар теләктәшлек табалар. Губисполкомны хыянәтчеләрдән тартып алуны планлаштыралар. Йөз-йөз егерме сугышчыдан торган отряд губисполком бинасын камый, икенче бер отряд бинаның эченә үтеп керә... Отряд командиры итеп Мәскәү чекисты Александр Медведь билгеләнә. Алар һәммәсе дә партиянең Сембер губкомы председателе Варейкиска буйсыналар.

11 июльдә, төнге сәгать өчтә, яктырыр-яктырмас бер мәлдә, Советның ике фракциясе членнары — большевиклар һәм сул эсерлар утырышка җыйналалар. Утырышка тән сакчыларын ияртеп Муравьев килеп керә. Килеп тә керә, сүз җаен, утырышның агышын үз кулына алырга тели. Башта беркемгә дә сүз әйттерми.

— Сембер советы депутатлары! — дип башлый ул сүзен. — Сезне җирле сәяси эшлеклеләр исәпләп мин сезгә мөрәҗәгать итәм! Сез — акыл ияләре, кая кусаң — шунда борыла торган солдатлар түгел. Мин дә уен уйнарга җыенмыйм, мин зур һәм тарихи эш башладым: бүгеннән Идел буе республикасы төзелүен игълан итәм һәм аны 1919 елның январендә ачылачак Учредительное собрание утырышына кадәр җитәклим. Сембер советы мине яклап чыгар дип ышанам. Шуңа чакырам сезне, депутат иптәшләр. Миңа сезнең совдепның авторитеты үтә кадерле һәм бик кирәк. Турысын әйткәндә, сезнең бүтән юлыгыз юк. Көчнең минем якта икәнен исәпкә алырсыз. Туп көпшәләренең, броневиклардагы пулемет борыннарының сезгә төбәлгәнен күрәсездер? Иделдә мин коралландырган пароходлар йөзә. Тимер юлларда мин көнбатышка борган хәрби эшелоннар чаба. Сайлагыз! Безнең Идел икмәге тулысынча безнең кулда — ышаныгыз, безнең республика көчле булачак. Үзәк Идел икмәгеннән башка яши алмый. Димәк, көч һәм хокук безнең кулда. Ни кушсак, Мәскәү шуны эшләр. Ачка дөмегәселәре килмәсә, безгә тез чүгеп килерләр. Безнең беренче таләп: илнең барлык ватандар көчләре берләшеп, Германиягә каршы сугыш!

Тагын нидер әйтергә омтылган Муравьевны Варейкис бүлдерә:

— Революциягә хыянәт итүгә караганда үлем яхшырак безгә!

Муравьевның йөзе тартышып ала, тавышы салкын тидергән әтәчнеке сыман сыегаеп чыга:

— Алайса, җырыгыз җырланган санагыз!

Варейкис һаман бирешми:

— Җыры шәп иде бит! Без аны чын йөрәктән матур итеп җырладык. Үзебез башлаган эшкә хыянәт итмичә ахырынача җырлап барырбыз. Бу сез, Муравьев, революцияне саттыгыз, хәзерендә юк-бар өркетүләр, ялган, яла чәчәсез! Хәзерге көндә Германия белән бернинди сугыш юклыгын сез бик шәп беләсез! Безнең Революциянең Бонапарты булырга сезгә ирек бирмәбез! Кая инде сезгә намусы саф, йөзе ак Гарибальди булырга! Сез куркак, хыянәтче бәндә! Хыянәтчене куркаклык тудыра. Безне өркетә алмассыз!...

Нәкъ шул чагында киңәшмә залына Александр Логинов килеп керә, трибунага кадәр уза һәм Муравьевның пароходта кылганнарын кыска-кыска гына сөйләп бирә. Муравьевны хуплап кул чабып утырган сул эсерлар сагаялар, хуплау авазлары азая.

Киңәшмә барган бүлмә ишеге артында шау-шу ишетелә башлый. Нидер сизенгән Муравьев артка чигеп куя, чырае агара. Ул Варейкиска нәфрәт белән карап ишеккә юнәлә.

— Сез кая, Михаил Артемьевич? — дип сорый Логинов. — Мин сөйләп бетермәдем әле.

— Чыгып кешеләрне тынычландырам. Берни ишетеп булмый.

Ишек артында чекистлар һәм Советка тугры кызылармеецлар тупланганын бары Варейкис кына белә! Муравьевның утырышларны, тантаналарны яратканын, сүз сиптерергә омтылганын яхшы белгән Варейкис бүгенге утырышны юри оештыра...

Калганнар катып калалар: ишек артындыгы ыгы-зыгы, шау-шу көчәя, әгәр аннан Муравьев яклылар, әле генә Логинов сөйләгән «пароход батырлары — җан кыючылар» килеп керсә, чыннан да, «соңгы җырны җырларга туры килмәгәе» дип шигәяләр... Алардан хәзер яхшылык көтәргә ярамый, имансыз халык, сүзне ярып әйттеләр — эше дә шулай булачак.

Муравьев гадәтенчә аякларын җәеп, башын чөеп баса да ике куллап ишекне этеп җибәрә... ишек катында үзенә төбәлгән коралларны һәм кырыс йөзләрне күреп бер секундка гына каушап кала.

— Сезне кулга алабыз! — дип кычкыра Медведь.

— Минеме? Кулга? Минем кем икәнне беләсезме?

— Беләбез. Белгәнгә күрә кулга алабыз!

Муравьев маузерына ябыша, Медведь аның кулына килеп асылына, пуля идәнгә барып керә. Муравьев сул кулы белән кесәсеннән браунинг чыгарып өч мәртәбә атарга өлгерә, яраланган өч кызылармеец ыңгырашып идәнгә ава. Шул чагында Медведь аның уң кулын каерып атып җибәрә. Берничә винтовка да гөрселдәп тавыш бирә, адъютантлары чинап куя...

Идәнгә чалкан барып төшкән Муравьев үлгән була иде инде.

Илдә күпме тавыш-гауга чыгарган, ничаклы бәла-каза китергән, властьны үз кулына алырга омтылган авантюрист җансыз бер гәүдәгә әйләнә. Чекистлар яралы кызылармеецларны тизрәк аның яныннан алып чыгып китәләр...

Бу хәлләрне миңа Сембердән кайткач Антонов сөйләде.

— Безнең барып җитү ярады! — диде ул.— Муравьев үзе үлсә дә, ул урнаштырырга маташкан тәртип исән иде бит. Аның тарафдарларын тиз-тиз кулга ала башладык. Варейкис белән Левин чыннан да эшне коры тоттылар. Муравьев төрмәгә яптырган Тухачевский аларга бик зур ярдәм итте! Мәскәү-Казан белән элемтә юк чакта дип, алар, үз инициативалары белән, Тухачевскийны башкомандующий итеп билгеләделәр. Казан крепостенда торган унике бронемашинаны хәтерлисез булыр? Курскидан китерелгәннәр иде алар. Өчесе хәзер дә урынында тора! Калганнарын Муравьевның ахирәт дусты, иң ышанычлы ярany әлекке поручик Беретти Сембергә озаткан булган икән! Бронедивизион командиры, патша генералының улы Беретти дә Сембердә чека кулына килеп төште. Левин түкми-чәчми сезгә шуны тапшырырга кушты, Сергей Сергеевич, допрос вакытында Беретти: «Фетнәне Муравьев житәкчелегендә әзерләдек, дивизион тулысынча аның яклы иде, безгә буйсынмаганнарны тараттык, эчтән таркаттык»,— дигән.

Казанда фетнә күтәрергә җирлек бетә барганын аңлагач, Муравьев иң ышанычлы, өметле гаскәрләрен берәмләп-берәмләп Сембергә күчерергә боерган... Июнь башында дивизионга ярдәм сорап килгән алафузовчы эшчеләре Муравьев приказы нигезендә атып үтерелгән икән. Шул юл белән ул дивизионны хыянәткә бәйләгән, Казан фетнәсе вакытында

икеләнерлек булмасыннар дип, солдатларны җинаять артыннан җинаятькә тарткан.

Казанда Муравьев штабы калды. Алар һаман Щетинкин номерларында тыз-быз киләләр, ука чуклы пәрдәләр артында хатын-кызлар чинаганы ишетелеп кала. Аны бик нык күзәтергә кирәк безгә. Файерман барын да ачып салдымы икән? Бәлки, беренче караштагы куркак ук түгелдер дә?

— Куркак ул, куркак! — дидем мин Кингә.

— Саескан да куркак, мәгәр такылдап бөтен тирә-юньнең серен ачып утыра,— диде Кин.

Мин Муравьев маҗаралары белән артыграк мавыктым шикелле. Бу беренче карашка гына шулай тоела.

Казан язмышы гына түгел, ил, Мәскәү язмышы да бер очы белән шушы кешегә килеп тоташа иде.

Аның бетүе — фетнә чиренең башын кисеп ташлау дигән сүз. Муравьевның хыянәте баш җитмәслек буталыш, кырылыш тудыра ала иде. Аның тинтәк боерыгына буйсынып, фронт ачылмыйча калды. Әгәр сугыш кузгалып киткән булса, без никадәрле авырлыкларга, өстәмә корбаннарга дучар ителер идек...

Муравьев һәм аның тарафдарлары Сембердә юк ителгәннән соң, әйткәнемчә, фронт белән җитәкчелек итү Тухачевскийга йөкләнә. Ә Казанда бу вазифаны реввоенсовет үз кулына алды. Ленин телеграммасында бу турыда ап-ачык әйтелә: «Җитәкче итеп тәҗрибәле, чын-чыннан хәрби белгечне билгеләргә кирәк!»

Көнчыгыш фронтның реввоенсоветының яңа составы 12 июльдә расланып, аның командующие итеп иске армиянең полковнигы, латыш совет дивизиясенең командиры Вацетис билгеләнә. Кобозев, Мехоношин, Данишевский һәм Раскольниковлар комиссар итеп сайланалар.

Идел ул чакта илнең Көнчыгыш чиге иде, ул бер мәлгә революциянең язмышын хәл итүче төп төбәккә әйләнде, сугыш көннән-көн кызды, яңа формалар ала торды. Әле анда, әле монда контрреволюция баш калкытты, димәк, бу мөһим фронтны яңадан-яңа ышанычлы большевистик частьлар белән ныгытырга кирәк иде. Иң әүвәл, күргәнегезчә, фронт җитәкчелеге ныгытылды. Иаким Вацетис латыш укчылары белән Казанга 16 июльдә килеп төште. Аның белән яңа билгеләнгән штаб начальнигы элекке капитан Майгур һәм политбүлек начальнигы, ВЦИК члены большевик Захаров килде.

Шул ук уналтынчы июльдә Көнчыгыш фронтта контрреволюция белән көрәшү буенча ЧК — Гадәттән тыш комиссия оештыру турындагы Совнарком карарына Ленин кул куйды. Аны җитәкләү 1905 елдан партия члены Мартин Лациска йөкләнде. Ленин аңа Идел буе контрреволюционерлары белән көрәшне бермә-бер кискенләштерергә кушты һәм үзәк ВЧК белән яңа төзелгән комиссиянең арадашлыгы ни дәрәҗәдә булырга тиешлеген аңлатты. Көнчыгыш фронтта контрреволюция белән көрәшүче Гадәттән тыш комиссия, табигый буларак, Казанда урнашты һәм Казан чекистлары аның составына керде.

Төп бурыч — Муравьев фетнәсенең калдыклары белән көрәш иде. Елан үзе үлсә дә, агуы кала, ди халык. Ул үз вактындагы чиксез зур властьтан файдаланып, фронтның күп тармакларына үз кешеләрен — хәрби белгечләрне, сул эсерларны урнаштырып өлгергән иде. Әйтик, Уфа штабында хәрби җитәкче булып элекке подполковник Махин утыра. Хәрби яктан тәҗрибәле, әмма искиткеч аумакай җан! Муравьевны алла итеп табынганнардан берәвесе. Халык мәнфәгатен Советлар түгел, әмма Учредительное собрание яклый дип ининып яшәгән сөрсегән кеше. Штабының бер өлешен ияртеп, Самарага, учредительканы яклаучылар арасына кача...

Мондый хурлыклы хәлләр кабатланмасын өчен, большевиклар Үзәк Комитеты тиешле карар кабул итә. Анда хәрби комиссарларның җаваплылыгын арттыру турында сүз бара: «Хәрби комиссарлар комсоставны җентекләп күзәтеп бетерә алмыйлар. Махинның качуы, Муравьевның мең күз алдында Казаннан Сембергә күчүе шуны дәлилли, боларның авырлыгы комиссарлар җилкәсенә дә төшә. Артык ышанычлы булмаган элекке хәрбиләрне, хәзерге командирларны даими күзәтү астында тотарга. Әгәр командующий кача яки хыянәт итә икән, моның өчен комиссар җавап бирә, ату белән җәзалана».

Көнчыгыш фронтка командарм Вацетисның һәм дүрт комиссарның җибәрелүе, илдә беренче тапкыр буларак фронтның Гадәттән тыш һәм киң вәкаләтле комиссиясе төзелүе — эшнең никадәрле катлаулы, соң дәрәҗәдә җитди икәнен раслаучы дәлил иде. Армия командованиесенең һәм Гадәттән тыш комиссиянең Казанда булуы да очраклы хәл түгел, бу фактны фронтның Казанга якынаюы белән генә дә аңлатырга ярамый. Казанда ул чорда советка каршы чыгышлар белән көрәшүнең мәгълүм дәрәҗәдә тәҗрибәсе дә тупланган иде. Без моны шулай дип аңладык, шулай дип кабул иттек.

Муравьевның сул эсерлар һәм башка контрлар белән тыгыз элемтәдә булуын беренче булып без ачтык. Муравьев яклы сул эсерларның кузгалышы белән Ярославль һәм Югары Иделнең башка шәһәрләрендә савинковчыларның күтәрелеше бер вакытка туры килгән икән, моның да очраклы булмавын без ачып салдык.

(Муравьевка бәйләнешле хәлләрнең җебе өзелмәсен өчен, мин үз тормышыбызда булган байтак әһәмиятле вакыйгаларны төшереп калдыра бардым. Алар, бер-берсенә тыгыз бәйләнгән булсалар да, беренче дәрәҗәдәге вакыйгалар түгел иде. Кичерерсез!)

Кулларында мөмкинлекләр киң булып та, алардан бар булганча файдаланган эсерлар Казанда фетнә күтәрә алмадылар. Ниятләре барып чыкмады. Ул көннәрнең иң әһәмиятле йомгагы шул...

Эзләп табып яки хәтердә яңартып, без үткәндә билгесез булганнарны да дөньяга чыгарабыз. Әмма бу ифрат җаваплы адым... Бигрәк тә кешеләр турында язып чыгару — катлаулы эш. Хәтердә ничек саклансалар, без аларны шул хәлдә искә алабыз; яки документларга таянып күз алдына бастырырга омтылабыз. Төрле чорларда төрле халыклар: «Үлгәннәр турында я гел сөйләмә, сөйләсәң, яхшыны гына сөйлә»,— дип әйтеп калдырганнар. Бу уңайдан: «Аның талантына чын бәһа бирелер өчен дөньядан китүе дә кирәк!» — дип өстиләр.

Көндәлек тормышта бәлки шулайдыр, әмма тарих язганда, болай эш итәргә ярамый.

Хуш, син исән, зиһенең ачык, син утырып уйлыйсың да хатирәләр язасың... Синнән талантлырак, синнән булдыклырак, яшәү хакы синекеннән дә күбрәк булган кеше инде юк, ул күптән киткән... Менә син шул кеше турында язарга тиеш. Исән чакта син аннан гомерең буе көнләшеп яшәдең ди. Хәзер синең үзеңнән дә талантлырак, булдыклырак кеше юк иде дип язасың килә! Көнчелек корты сине кимерә, көнчелек корты сине котырта, аздыра... Ә син язасы хәлләрне ике генә кеше белә: син дә, синең замандашың — талантлы һәм булдыклы зат... Ләкин ул бүген юк...

Наданлык һәм көнчелек дигән ике бозыклык нәтиҗәсендә күпме аңлашылмаучылык, буталыш туа. Наданлык бик күп фаҗигаларның эти-әнисе булган, ул аларны тудырган. Бу — мәгълүм нәрсә. Үзеңдә булмаган яхшылыкка көнләшү кешене әллә нинди яман юлларга этәрә, күңеленә әллә нинди кара уйлар иңдерә. Әгәр көнчелек политик партия җитәкчеләренең башка замандаш партияләргә мөнәсәбәттән туса һәм власть, ил язмышын, халык һәм дәүләт язмышын хәл иткәндә өстенлек алса?

Шулай булмадымыни?

Сул эсерлар шул тайгак юлга төшмәдемени?
Башта берәүне дә санга сукмадылар, буш сүз куерттылар. Соңра куркыту, шантаж өскә калкып чыкты. Болай да җиңә алмаган сул эсер житәкчеләренең нерв җепселләре чыдамады: алар ачыктан-ачык мөртәткә әйләнделәр, фетнә күтәреп, кичәге иптәшләрен аттылар, чиксез томаналык күрсәтеп, тарихи вакыйгаларга хата бәя бирделәр, җәмгыять үсешен күз алларына китерә алмадылар, ялгыштылар.
Үз-үзенә гашыйк булганның көндәше юк диләр.
Көндәше юк — ә көнчелек кала! Бар ул көнчелек! Көнче кешенең уенда гел шул: кемнедер күбрәк яратып, аны кимрәк яраталар төсле.
Сул эсер партиясенең лидерлары үзләрен гөнаһсыз ватандарлар дип бәһаләделәр, гәрчә бөек Толстой нәкъ әнә шундый ялган ватандарлыкны «кабахәтләр качып ята торган өн» дип атады...
Башка юллары да калмагандыр аларның, мөгаен, алар Ленинның абруе үсүен, ныгуын күреп, белеп тордылар. Элгәрге эшем иясенең акгвардиячеләр газеталарында язганнарын да укыдылар ич алар. Алар, эшем ияләре, фабрика-завод хуҗалары: «Россиядә, монархия кайтып, Министрлар советы башында Ленин торса, ничек әйбәт булыр иде!» — дип юкка гына язып чыкмадылар ич! Заводларын, фабрикаларын югалткан, эш кешесен күреп ала белгән хуҗалар шулай язды ич!

Кобозев миңа: «Сул эсерлар арасына кагылып чык әле бер!» — дигән иде. Вера Петровна Брауде белән сөйләшү аның сүзләренә куәт булды.
— Сул эсерлар комитетында көне-төне өзмәс талаш, бәхәс бара,— дип борчылып сөйләде ул. Әйтерсең лә алтынчы июль вакыйгалары булып узмаган! Әйтерсең лә Муравьевның хыянәте сул эсерлар җирлегендә шытып, үсеп ныгымаган! Әйтерсең лә тарих сул эсерларга үз мөнәсәбәтен белдермәгән! Һаман бәхәсләшәләр, һаман нидер мыштырдыйлар, һаман нәрсәгәдер өметләнәләр!
Мәскәүдән Трутовскийның килүе дә эзсез үтми: Казанның аерата әтәчләнгән сул эсерлары Совет властена һәм большевиклар партиясенә пычрак аталар, чекистларның эшчәнлеген каралтып, өметсез итеп күрсәтәләр. Үзәк комитетларын яклап, сугышка чыгарга өндиләр.
Бардым, кердем, утырдым...
Минем Вера Петровна белән килүемне күрделәр, күрмәмешкә салыштылар. Губисполкомның секретаре Зубарев комитетны миңа кай якка котырта:
— Мирбахны үтермичә ярамый иде! Аның куенына провокаторлар һәм шпионнар оялады. Берлиннан махсус килгән Азеф та шунда иде.
Мирбах алдында совет власте бөтенләй көчсез булып калды, шул сәбәпле безнең Үзәк Комитет империализм агенты һәм контрреволюционер Мирбахны юлдан алып чөйде. Брест солыхы бетсен! Мария Спиридоновага ирек!
Һаман шул җыр икән, иске җыр, әмма артык тузган, күгәргән җыр. Яңа сүз юк икән эсерлар комитетында...
Дөньяда Казимир Шнуровский да бар ич әле! Ольконицкий җеназасында күз яшьләрен яшермәгән, чын күңелдән кайгыра алган бу кеше һаман тынмый, һаман нидер чокчына, нидер эзли, нидер раслый. 10 июльдә (көнен карагыз сез, көнен!) аның тәкъдиме белән Казан губбашкармасының Крестьяннар секциясе мондый декларация кабул итә: «Сул эсерлар, моментның мөһимлеген искә алып, Мирбахны үтерү фактын житди тикшерү сорыйлар. Мирбахның үлеменнән соң кулы чишелгән юнкерлар Германиясе Совет властена яңадан-яңа ударлар белән янаганда, барлык көчебез белән революцияне якларга кирәк!»
Ах, Казимир, Казимир! Күп еллар үткәч, Григорий Шмулевичның үлеме уңае белән әниенә, Уфага язган хатларыңны укырга туры килде. (Тарих өчен шәхси хатлар да ярап куя!) Син бит житди уйлый да беләсең, ә уныничы июльдә Сембердә Муравьев советка каршы чыгышын

ачыктан-ачык башлап җибәрде, совдеп бинасын камап алды, почта-телеграфны кулына төшерде... Ә син «кискен момент, революция!» дип суган сатып утыргансың. Нинди революцияне яклыйсың син, кем революциясен?!

Алай гынамы әле, шушы декларация нигезендә Казаннан өязләргә хатлар китә, анда аз да түгел, ким дә түгел, Советларның 5 нче съездына катнашкан, совет хөкүмәте тарафыннан кулга алынган сул-эсер фракциясе членнарын азат итү сорала. Шуның өстенә алар Мирбахны үтерүне тагын бер мәртәбә тикшерүне таләп итәләр...

12 июльдә Вера Брауде белән губбашкарманың утырышында тагын катнаштым.

Зубарев белән Пономарев һаман тынмыйлар, яныйлар.

— Сул эсерларны төрмәләрдән чыгарырга! Комбедлар оештыруны туктатырга. Икмәккә куелган нык бәяне алыштырырга!

— Мужик Россиясенә Спиридонованы кайтарыгыз! — дип улады Пономарев. Большевикларның нык каршылык күрсәтүенә дә карамастан, бу утырышта күпчелек тавыш белән сул эсерлар резолюциясе үтте. Тавыш бирү тәмамлануга ук большевиклар фракциясе губбашкарма составын ташлап чыкты. Анда сул эсерлар гына бөялеп калды. Шатландыларммы, кайгырдылармы — әйтүе кыен, бермәлгә алар шашынып калган иде. Чөнки арадан иң авторитетлы ике кеше Казимир Шнуровский белән Вера Петровна Брауде сул эсерлар партиясеннән чыгулары турында рәсми белдерү ясадылар. «Җир һәм ирек өчен» газетасының редакторы Слесаревны, Шнуровскийның резолюциясен газетада бастырганы өчен, сул эсерлар үзләре партиядән куалар...

Вера Петровнаның кайсы якка каерылганын белә идем диярлек, Шнуровскийның адымы көтелмәгәнрәк булды.

Сул эсерлар ашкынып коралланa башладылар һәм, губерна кулакларын үз якларына тарту өчен, байтак чаралар күрделәр. Кулакларны сөендереп, азык-төлек комиссары сул эсер Штуцер икмәк сату бәяләрен өчләтә арттырырга боерык бирде. Бу — икмәкле урта хәллене турыдан-туры сул эсерлар ягына аудару, кулакларның болай да шәп әйләнгән тегермененә су кою иде. Июнь ахырында Мәскәүдән Малюгин җитәкчелегендә килгән азык-төлек комиссиясе икмәкне югары бәяләр белән сатуны туктатуны таләп итте. Сул эсерлар аңа буйсынмадылар.

Казаннан үтенү буенча Азык-төлек комиссариаты, махсус белдерү ясавын сорап, Ленинга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды.

«1. Казан губернасы Азык-төлек коллегиясен таратып, судка бирергә, 2. Коллегия рәисе Штуцерны кулга алырга дигән махсус күрсәтмәне Казан губбашкармасына бирүегезне үтенәбез»,— диелгән иде ул мөрәҗәгатьтә.

Шул ук көнне, ягъни унҗиденче июльдә, Ленин имзасы белән Казанга телеграмма килеп тә төшә.

«Казан губпродколлегиясен эштән бушатырга тәкъдим итәм. Бу вазифаны башкару Наркомпред коллегиясе члены Дмитрий Малюгинга йөкләнә, аның белән киңәшеп эшләвегезне үтенәм. Хәрби штабның икмәк бәяләрен күтәрү турындагы карарны юкка чыгаруын тизлек белән халыкка җиткерегез. Дәүләт раслаган нык бәягә кайтуны хәл итегез».

Ленин катнашыннан соң гына губпродколлегиядәге сул эсерлар баш-баштаклыгына, көн туса яңа мөгез чыгаруларына чик куелды. Яңа губпродкомиссар большевик Малюгин унтугызынчы июльдә өяз икмәк органнарына эшне тулаем үз кулларына алырга кушты. Хәл барыбер ифрат авыр иде...

Кыска гына вакыт эчендә ике тапкыр яраландым. Пуля тишеп узган янбашым тиз төзәлде, яшь тән, әмма башның арт чүмече һаман үзен сиздерә. Менә бүген дә иртәдән бирле баш сызлый. «Һава бозылырга ул»,— ди чырылдатып чәй ясап утырган Саҗидә апа. Вакыт сыйдыр-

ганда, мин, яктыра башлауга, торам да кичәге хәлләрнең иң мөһимнәрен шәмәхә тышлы куен дәфтәренә теркәп куям. Хәлләр үтә дә куерып киткән мәлләрдә куен дәфтәре үзем белән йөри... Сул эсерларның давыллы утырышы дәвамында дәфтәремне куеннан берничә мәртәбә чыгардым һәм аерата мөһим дип исәпләгән фикерләремне теркәп тә бардым. «Зубарев — бушбугаз, мәгәр куркыныч кеше»,— дип язып куйганмын... «Пономарев астыртын, ул Зубаревтан да куркынычрак»... Язулар белән дәфтәрем тулды, нәкъ шундый ук икенче дәфтәрне бүген иртәнге чәйдән соң өстәлгә алып куйдым. Язулы дәфтәремне исә, башкалары янына, ераккарак яшердем. Көннәр безне сак булырга өйрәтә, чекада эшли башлаганнан бирле уяулык-саклык турында үзеңә-үзең гел кисәтеп яшисең. Башкача мөмкин дә түгел...

Шәмәхә тышлы дәфтәрем өстәлдә ятып калды. Мин, туры килгәндә дип, шундый дәфтәрләрне берьюлы Зур Проломный урамындагы вак-төяк кибетеннән сатып алган идем. Арада берсенә сирәк кенә булса да шигырьләр язгалыйм... Тик сирәк языла, бик сирәк...

Бүген дә бик соң кайттым. Сәҗидә апаны уятып йөрмәс өчен ишекне эчтән бикләмәвен үтенгән идем, ул үзенең бәләкәй бүлмәсенә керә дә тынычланып, ишеген эчтән бикләп йоклый... Алгы бүлмә минеке. Анда гади тормыш җиһазларыннан, олы мичтән, мич арасындагы юынгычтан башка берни дә юк дип әйтерлек. Минем Мәскәүдән ияреп килгән бар «байлыгымның» нәрсәдән гыйбәрәт икәнен хәтерлисез булыр? Яньчелгән солдат котелогы, кургаш кашык һәм аяк чолгаулары. Казанда өченче аемны яшәсәм дә, мин әллә ни баемадым. Есенин шигырьләре басылган газеталар, Ленин китаплары, кырыну әсбаплары һәм шәмәхә тышлы куен дәфтәрләре. Әгәр шул чагында фикерләремне теркәп бармасам, ул дәфтәрләр сакланмаса, бүген мин, батыраеп, хатирәләр язарга тотынмаган да булыр идем.

Бүген дә соңга калып кайттым, ишек тавышсыз-тынсыз гына ачылды, кердем, ут яндырдым һәм ни өчендер эчке бер сизенү белән өстәлгә карадым. Шәмәхә тышлы дәфтәр анда юк иде. Сәҗидә апаның минем әйберләргә бер чакта да кагылганы юк, ул алмагандыр. Кайтып кергәндә үк, мин нигәдер: «Дәфтәр анда булмас!» — дип уйлаган идем... Ары-бире карандым, бер дә үзгәреш, шикләнерлек нәрсә күренмәде. Шул ук акшарланган тын бүлмә, рәхәтләнеп җәелеп, мич утыра. Тәрәзә дә эчтән ябык... Ишеккә килдем. Ачыла да ябыла. Элекке хуҗалар куйган эчке йозак та урынында. Йозакның бер генә ачкычы сакланып калган, аны Сәҗидә апа йөртә. «Үзең белән йөрт, миңа төнлә ачкыч кирәкми»,— дип әйтеп караганы бар барын, әмма мин ачкычны алмыйм, дөнья хәлен белеп булмый, ут-күз чыгуы бар... Моңарчы шулай яшәгән идек. Мин кайтып керәм дә ишекне эчтән биклим. Бер дә шик-шөбһә уятырлык нәрсә булганы юк иде. Бала-чага кереп, ялтыравыклы шәмәхә тышына кызыгып алганмы әллә дәфтәремне?..

Юк, беркем дә кермәгән, беркем дә алып чыкмаган икән. Сәҗидә апа шулай диде:

— Көне буе өйдә булдым, вак-төяк кер юдым, идәнне сөртеп чыгардым. Кибеткә барганда, ишекне бикләп алдым. Дәфтәрең шунда гына иде, Сережа балам. Ятар алдыннан өстәлеңне сөрттем, ул чакта да күрдем. Шәмәхә тышлы иде, неме?

Икенче көнне миңа Таня шалтыратты, Зоря каберенә барып кайтасы килүен әйтте. Үзенең мине күрәсе килгәнен дә яшермәде. Байтактан күрешә алганыбыз юк, үзем дә Таняны сагынган идем, ашык-пошык кына телефоннан хәбәр алышулар мине канәгатьләндерми башлаган иде... Азга гына китеп тору өчен Кинның рөхсәте кирәк, мин аның янына кердем.

— Павел Андреевич!

Эндәштем дә тынып калдым, ул, күтәрелеп, миңа карады, аңлады.

— Таня белән күрешергәме?

— Әйе.

— Сак бул,— диде Кин.— Коралсыз чыкма.

— Яхшы, Павел Андреевич.
— Нигә өйләнмисең син, Сергей Сергеевич?
— Кая әле! Кыз бик яшь. Эш аңа барып та җитмәгән... Дуслар без. Акыллы кыз, батыр.
— Ярый, ярый. Тик озак торма!
Мин Таняны өйләренә кереп алдым, ул, вакытның кадерле икәнен белеп, капка төбенә үк чыгып көтеп торган иде. Юлда барышлый мин узган төндә булып узган хәлне — шәмәхә тышлы куен дәфтәремнең югалуын сөйләп бирдем.
— Үз өеңнәнме?
— Шунысы гаҗәп тә: өйдән!
— Кемгә кирәк булуы бар аның?
— Белмим. Бер-бер очы чыкмый калмас дип уйлыйм уйлавын...
Без Зоря янына, гадәтебезчә, зираттагы соңгы кешеләр булып, эңгер-меңгер куерганда гына барып җиттек. Таня алдан әзерләп куйган чәчәкләрен апасының аяк очына таратып ташлады. Сүз алышмасак та, уйларның уртаклыгын тоеп, бер-беребезгә янәшә диярлек басып тордык. Шулчак Таняның гәүдәсе калтырап китте. «Ой»,— диде ул ярым пышылдап. Кулым ихтыярсыздан кесәмә үрелде, якында гына нидер кыштырдавын мин дә ишетеп калдым.
— Сережа, анда кемдер бар! — дип пышылдады Таня.
— Кайда?
— Әнә, әнә, куак артында посып тора.
— Чык! — дидем мин зират тынлыгын бозып.— Чык, юкса атам.
Кеше үзе посып торган куакны читләтеп ачыклыкка чыкты, безгә таба бер-ике адым атлады, ике кулы белән миңа чытырдап ябышкан Таня кинәт кычкырып җибәрде: безнең каршыбызда Винокуров басып тора иде.
— Курыкмагыз,— диде ул һаман якынлашып.— Курыкмагыз, зинһар.
Ни уйларга да белмәдем: әгәр бер-бер этлек ниятли икән, болай ачыктан-ачык күренеп йөрмәс иде... Һәм ни өчен зиратта?
— Сезгә ни кирәк? — дидем мин нык итеп.
— Килергә ярамыймы? — диде ул салкын, тонык тавыш белән.
— Нигә без барында киләсез?
— Сез минем монда килеп йөргәнемне белсен өчен!
Таня сүз әйтерлек хәлдә түгел, ул дер-дер калтырый һәм мин ишетелерлек итеп кенә: «Китик моннан, китик!» — дип пышылдый иде.
— Мин дә кеше ич,— диде Винокуров.— Тәрбияле, белемле кеше. Укытучы, педагог! Миндә дә җан бар! Сезгә кадерле булган җан миңа да кадерле иде!
— Ялганлыйсыз! — дип кычкырды Таня.— Сезнең бөтен сүзегез, гомерегез, иманыгыз ялган.
— Ах, Таня, Таня! — диде Винокуров сагыш белән.
— Эндәшмәгез миңа Таня дип! Мин Татьяна Антоновна!
Зоря кабере тынлыгын бозып бәхәскә кереп маташуның мәгънәсе юк иде, мин Таняның беләгеннән тотып:
— Киттек,— дидем.
Винокуров та безгә иярде.
— Тарих ага,— дип сөйләнде ул беркемгә дә карамыйча. Аның ягыннан җил исеп китте, мин коньяк исен сизеп алдым. Без адымнарны кызулаттык. Ул бездән калышмады. Зират каравылчысы капканы бикләгән иде инде. Шакылдатырга туры килде. Карт, сукрана-сукрана килеп җитеп, йозакны ачты.
— Зарланма, картлач! — дип Винокуров аңа кәгазь акча тоттырды.— Без барыбыз да монда булачак кешеләр.
Капканы чыккач, Винокуров үз юлында булыр дип уйлаган идем, юк, һаман безгә тагылып бара. Туктарга мәҗбүр булдык.
— Сергей Сергеевич! — диде ул.— Ачуланмагыз миңа. Мин дә кеше.

Күп уйладым мин бу араларда. Дөнья фани! Үтә китә. Меңнәр үткән эзсез, миллионнар, без дә үтәбез... Әз калдырам диган талашлардан туйдым, ялыктым. Буш сүзләр, буш максатлар, буш талашлар... Ишетәм, ишетеп яшим!

— Сез исерек! — диде кинәт Таня.— Аның янына исереп килгәнсез.

— И бала, аның янына аек килеш килә аламмы соң мин? Сергей Сергеевич, шушы буш гомер уза торган буш юлларда ул якты бер нур булган икән! Мин моны соңгарак калып аңладым... Ә сез аны үтерүче! — диде кинәт Винокуров.— Сез үтердегез аны!

— Ялган! — дип кычкырды Таня, аңа якынлашып.— Аны сез үтердегез! Ялган вәгъдәләр, ялган тормыш вәгъдә итеп, матурлыкны ялганга төреп күрсәтеп!

— Җитәр! — дидем мин Винокуровка.— Сезнең белән сөйләшер сүзем юк.

— Мин сезнең монда киләсен күңелем белән сиздем. Йомышым да бар.

— Нинди йомыш?

— Менә,— диде ул һәм чалбарының арт кесәсеннән минем югалган шәмәхә тышлы куен дәфтәремне тартып чыгарды.

— Каян килеп керде бу сезгә?

— Анысын сорамагыз. Юк, өегезгә кереп алмадым! Безнекеләр... анда,— ул кулы белән каядыр еракка селтәп күрсәтте.— Сезнең язмалар белән кызыксыналар икән... Буш дәфтәр урлап чыкканнар.

Мин, ашыгып, дәфтәрне ачып карадым, беренче битнең уртасына әҗәл тамгасы — баш сөяге һәм аркылы-торкылы салынган ике сөяк төшерелгән иде.

— Бу имзамы? — дип сорадым мин.

— Җүләрләр! — диде Винокуров.— Ахмаклык!.. Мин бер нәрсәгә дә өметләнмим инде.

— Ялган! — диде Таня нәфрәтләнеп.— Кыланасыз, Винокуров.

— Эх, Таня, Танюша! Гүзәл кыз!

Ул, кочагын җәеп, Таняга таба килә башлады, кыз минем артыма качып өлгерде, без борылдык та ашыгып китеп бардык. Ул теш арасыннан: «Эх!» — дип кычкырып калды.

Винокуров белән кайчан да бер очрашасымны белә идем. Мәгәр зиратта, Зоря кабере янында аны күрермен дип башыма да килмәде. Тәмам борчылган Таняны көч-хәл белән тынычландырып өйләренә озатып куйдым.

Өйгә кайтырга иртәрәк иде, мин югында, шушы кыска гына арада да чекада әллә ниләр булгандыр кебек, мине эзлиләрдер сыман... Икенче катка чабып диярлек мендем, шәмәхә тышлы дәфтәремне өстәл тартмасына салыйм дигәндә, актыкы битне ачып карадым, анда, иң аста, вак кына хәрефләр белән «Зубарев» дип язылган иде.

Мөгаен, монысын Винокуров язгандыр инде.

Бала-чагалык дип уйладым башта...

Юк-бар белән маташалар... Тик бу турыда озын-озак уйлап торырга вакыт булмады, мине Кин чакырып алды.

Кердем, утырдым. Кин минем Таня яныннан кайтканымны белә, берни сорашмый, ашыгып, сүз дә катмый. Шактый вакыт узды ахрысы.

— Эшләр шәптән түгел, Сергей Сергеевич,— диде ул.

— Шәбәйсен өчен, мин нишләргә тиеш хәзер?

— Шаярырга вакыт юк.

— Табыйк вакытны, шаярыйк.

Павел Андреевич башын гына чайкады.

— Мин әле генә Винокуровны очраттым.

— Кайда?

— Зиратта.

— Үзенә урын сайлыймы әллә?

— Үзенәме, безгәме — әлегә мәгълүм түгел.

Куен дәфтәрем турында Павел Андреевичка сөйләп маташмадым, ул артык җитди һәм борчылган, ә минем югалту бик вак мәсьәлә булып тоелды.

Ул өстәл астыннан ал, зәңгәр түгәрәкләр белән чуарланып беткән карта тартып чыгарды. Түгәрәкләр күбесенчә Идел буе төбәкләренә сызылган иде.

— Чехлар менә-менә Семберне алачак.

— Эш шуңа бара,— дидем мин килешеп.

— Стратегик яктан ни дигән сүз була инде бу?

— Бумы? — Мин иелеп картага карадым.— Казанга юл ачылды дигән сүз.

Ул урыныннан торып йөреп килде, нигәдер ачык тәрәзәсен ныгытып япты. Урамда йөренеп торган часовойның аяк тавышлары ишетелмәс булды.

— Иртәгә, егермесендә, шәһәрдә һәм губернада хәрби хәл игълан итәбез.

— Нигә бүген үк түгел?

— Бүген өлгермибез. Хәрби комендант булып мин калам. Гарнизонның барлык частьлары миңа буйсыначак. Сүздә шулай...

— Ә асылда? — дидем мин, Кинның шикләнүләренең сәбәбен аңлап. Гарнизондагы частьларда башбаштаклык хөкем сөрә, командирлар уңга да, сулга карый торган җильяк офицерлар. Житди минут килеп җитсә, аларны авызлыклап булырмы дип пошына Кин, шуны уйлап баш ватып утыра икән. Кәгазьдә туры, «буйсыначак», эшкә килгәндә ничек булыр?

— Асылда исә эш үтә четерекле,— диде Кин, минем уйларымны аңлаган төсле итеп.— Кирәк чакта... әйтик, тәртип сакларга яки контрреволюцион чыгышларны басарга булса, мин аларны чакыртып алырга тиеш...

Ул сүзен тәмамлады, тукталып калды, тынды. Стаканга озак итеп су агызды, йотып-йотып, озаклап эчте. Шул арада мин аның күз тирәсендәге бер-берсен кисешеп сарган җыерчыкларына карап тордым. «Ничә яшь соң әле аңа?» — дип уйладым. Белә идем бит, хәзер һич тә хәтерли алмыйм, шушы бер көн эчендә шулай күзгә ташланырлык үзгәргәнме Павел Андреевич?

«Ничә яшь соң әле аңа?» «Ничә яшь һәм аның шушы башыннан ниләр кичмәгән!» Эзсез уза дип каркылдый анда Винокуров... Павел Андреевич Кинның тормышы эзсез узамы? Әнә ич, яшь-яшь башыннан күпне күргән күзләре тирәсен ничаклы пәрәвез сарган. Винокуров кебек эчеп, азып-тузынып алганмы әллә ул эзләрне?

«Казанга юл ачык!» Ә аннан Мәскәүгә юл ачылачак...

Кин картаны ачу белән, бөгәрләп, өстәлгә атып бәрде.

— Күрче инде миңа урынбасар итеп билгеләнгән кешеләрне!

— Кемнәр алар? — дип сорадым сак кына.

— Украинадан килгән Степанов белән Трофимовский!

— Трофимовский?

— Муравьев койрыгы! Аңа качарга ярдәм иткән кеше. Аны тәхеткә утыртырга омтылган бәндә!

— Нигә алай?

Кин иңбашларын сикертте.

— Хәрби-революцион комитет Грузинский урамындагы элекке командующий яшәгән бинага күчә. Комендант итеп Богырыслан коммунистик отряд начальнигы Дорошкевич билгеләнде. Ярыйсы егет! Ичмасам анысы уңай булды. Трофимовскийны билгеләүгә баш-аягым белән каршы идем... «Муравьев качканда, эз югалтырга булышкан кешене, гарнизонда чуалыш башланса, ышанып җибәрә аламмы-юкмы?» — дип әйтеп карыйм. Юк... «Үз янында гына тот, күзәт, ул-бу сизелсә, нишләргә кирәген үзең бик яхшы беләсең?» — диләр. Ул-бу буласын мин хәзер үк беләм!..

— Алай да, белгән хәлдә нигә аны куялар?
— Кеше юк. Хәрби белгечләр җитми. Гаскәр алдына чыгып баса — авторитет! Шул абруйны файдалы эшкә җик, тәрбиялә, үзебезгә тарт, башкаларга да үрнәк булсын диләр.
— Андый урынбасар булганчы, булмавы мең артык! — дидем мин кыза төшеп.
— Түзәрбез,— диде тавышын үзгәртеп Кин.— Түзәргә туры килә. Шушы көннәрдә Мәскәүдән Лацис килә. Чека эшләре тулысынча аның кулына күчә. Килә! ВЧК коллегиясе члены, тәҗрибәле һәм искиткеч тәвәккәл кеше. Ул килсә, тәртип урнаштырыр! Трофимовский ишеләрнең шәһәрен борыр! Винокуровны күрдем дисеңме? Буталып йөри алайса! Лацис кына килсен, аның ише алаканатларның да чарасы табылыр. Сергей Сергеевич, кадерлем, сизенүем дөрес: Харьковтагы эшәке хәлләрне искә төшерәм: монда да бугазга-бугаз килер сәгать сукты!
Чехларның Семберне алырга җыенуы, Трофимовскийны үзенә урынбасар итеп йөкләүләре Павел Андреевич Кинны да, гадәттә сабыр һәм тыйнак кешене дә, чыгырдан чыгарган, ул мондагы тәртипләр белән үзе генә көрәшә алмаслыгын да сизә, шуңа күрә Лациска өметләнә. Аның ВЧК коллегиясе члены булуына да, тәҗрибәсенә дә таянырга өметләнә иде.
Без бер-беребезгә бер чакта да иркәләү сүзе әйтми идек шикелле, тәртип саклау тәкәллеф саклау түгел, ул бүген мине беренче мәртәбә «кадерлем» дип атады, мине байтактан беркемнең дә алай дип атаганы юк иде, кулга алынганнардан каһәрләү сүзләре ишетеп күнеккән колак йомшап китте, дошман белән пычакка-пычак килер алдыннан, тынычлыкның соңгы сәгате сукканда бер-береңә шулай эндәшүнең бер дә юкка түгеллеген аңлый идем. Кин миңа тагын да якынрак, тагын да ышанычлырак иптәш булып күренде.
21 июльдә большевиклар партиясенең Казан шәһәр конференциясе, революцияне саклап калыр өчен, эшчеләрне һәм ярлы крестьяннарны армиягә алырга, эшчеләрне коралландырып, ополчениеләр төзергә карар кылды. Партиянең эшчәнлеген тагын да көчәйтеп, көннән-көн явызлана барган, өстән һәм астан да совет властена каршы көрәшкән сул эсерлар коткысына бирелмәсен өчен, эшчеләр арасында аңлатуны тагын да активлаштырырга кирәк дип тапты.
Хәлиткеч сугыш якынлаша!
Якынлаша!
Кем кемне!
Лацис белән без танышлар. Моңарчы ук аерата якын идек димим, бер-беребезне беләбез, ВЧКда бер генә очрашмадык, анда аның абруе искиткеч зур иде. Уенмыни, революциягә кадәрле стажлы большевик, боевик, профессиональ революционер! Унҗиденче елның апрелендә юлбашчыны Финляндия вокзалында каршы алуын тәэсирләнеп сөйләгәне әле дә хәтеремдә. Вакытлы хөкүмәт эшчеләрдән үч алырга әзерләнгән кайнар июнь көннәрендә дә очрашканнар алар. Бөек Октябрь вакыйгаларында да бергә булганнар, көрешкәннәр.
Лацисның килүен мин түземсезлек белән көттем. Бераз алга китебрәк булса да әйтәсем килә, Кинның да ышанычы акланды, Лацисның килүе, аның ныклыгы, оештыру сәләте Казанда контрреволюционерларның, акгвардиячеләрнең, вак-төяк милләтчеләрнең юлын кисте. Комучларга һәм канлы куллы Каппельгә шәһәр бүләк итәргә теләгән һәртөрле дошманнарның уе челпәрәмә килде.
Лацис белән без чекада көрештек, мин аны каршыларга төшә алмадым, Гайнулла Таһиров белән крепостьтагы корал складларын тикшереп, булган коралның санын ала идек.
Күрештек, сәлам алыштык. Мин аннан:
— Якын араларда Ленин белән очраштыгызмы? — дип сорадым.
— Әлбәттә,— диде Мартин Янович елмаеп.— Монда килердән элек

һәр нәрсәгә нигезле күрсәтмәләрне Владимир Ильичтан алдым.

— Бәхетле кеше сез,— дидем мин сөенеп.

Җирле хәлләрне бераз сөйләшеп утыргач, Мартин Янович тагын шул сүз тирәсенә әйләнеп кайтты.

— Владимир Ильичтан: «Хәзерге этапта контрреволюция белән ничек көрәшергә? Нинди ысуллар белән?» — дип сорадым. «Хәзерендә Көнчыгыш фронтта контрреволюциягә каршы көрәшкә чыккан Гадәттән тыш комиссиянең ВЧК белән арадашлыгы ничек булырга тиеш?» — дип тә кызыксындым. Владимир Ильич туп-туры әйтте: «Идел буена төрле яктан акгвардияче катлам җыйналды, безнең «хәсрәт-социалистлар» — меньшевиклар һәм эсерлар алар белән кулга-кул тотынышып эш итә. Элекке командующий Муравьев безнең совет һәм хәрби аппаратларга үз тарафдарларын күп кыстырган булырга охшый. Бу хәл контрреволюция белән бил алышканда көрәшне ныгытуны таләп итә. Моннан, Мәскәүдән торып, бу авыр эшне очлап чыгу андый комиссия оештыруны тудырды. Идел буендагы хәлләр мине шулай борчый ки, көндәлек шартлар һәм безнең дәүләт аппаратыбызның эшчәнлеге хакында миңа турыдан-туры өзлексез хәбәр итеп торуыгызны үтенәм. Контрреволюцияне тукмау җәһәтенә килгәндә, элек нинди ысуллар белән һәм ничек кыйнасалар, шулай ук тукмарга кирәк. Икеләнүләр азрак булсын, ныклык, пролетар ныклыгы! Революцияне ак пирчәткә киеп ясамыйлар!» Шуларга өстәп, Ленин һәрдаим Дзержинский белән киңәшеп эшләргә кушты. Идел буе чекистлары берләшеп эшләгәндә генә җирле контрреволюцияне җиңеп булыр дигән ышаныч белдерде.

Лацис сөйләгәннәрнең барчасын җанга якын кабул итеп утырдым.

— Якындагы бурычларыбыз шул,— диде ул, сүзенә йомгак ясап.— Көнчыгыш фронтның тылын революция дошманнарыннан чистартырга! Фронтка якынаеп калган Казанда советка каршы фетнәне басарга! Һәм республиканың алтын запасын саклап калырга...

Якын киләчәк бу мөһим эшләрне башкарырга безгә нибарысы ун көн вакыт бирелгәнен раслады...

Кеше туа, яши һәм үлә.

Тереклек әйләнеше шулай.

Тууында аның үз катнашы булмаса да, соңгысында аның н и ч е к яшәвенең роле зур. Революция һәм сугыш елларында кеше тиз житлегә һәм ашыгып картая да... Кайдадыр укыган идем, әгәр кеше яшьтән үк берзаман әҗәл киләсен белеп, үлем якынаюын сизеп яшәсә... алда куйган максатларына ирешә, чөнки ул сузып-нитеп маташмый инде, юлның соңы барын аңлап эш итә, яшәргә генә түгел, эшләргә, үзенә куелганнарны үтәргә ашыга. Яшәргә һәм эшләргә ашыксаң, бүгенгене иртәгә кичектермисең. Бу урында «яшәргә!» дип кенә үтеп тә булыр иде, чөнки гомерен мәгънәле кичкән кешенең яшәү рәвеше — эш.

Без ул чакта туры мәгънәсендә ут астында яшәдек, «бүген» һәм «иртәгә» вакыт берәмлекләре генә түгел, мәгънәле төшенчә, физик берәмлек, без аларны җан-тән белән сиземли идек.

Кешене танып-белү дә ифрат ансат иде: я — дус, безнең яклы, я — дошман, безгә каршы. Безнең яклы икән, ул — иҗатчы, көрәшче, яңа туып килгән җәмгыятьнең яклаучысы. Каршы икән — реакционер, җимерүче, артка сөйрәүче. Анда да без сине юк итәргә ашыкмыйбыз, без сине ышандырырга телибез, үгетлибез, эшкә тартабыз, эш табабыз, бирәбез! Уйла, тормышның бүгенгесен генә түгел, иртәгесен дә безнең кебек аңларга тырыш, сиз, яшә, мәгәр безнең революциянең алга барышына гына комачаулама!

Без күккә карап хыялланучылар түгел идек, без үзебез сайлаган юлны, үзебез яулаган чын властьны чын дошманнардан саклап калучылар идек. Әлбәттә, безнең арада кыеш-мыеш, аңгы-миңге баручылар да булгалады! Кемнендер бармагы үзенә таба гына кәкрәйгән иде, лыгырдыклар артты, берне сөйләп, икенчене эшләп йөргән бушбугазлар да керде безнең

арага. Берләрен иләктереп алып, яктыга чыгара һәм җәзага тарта идек, әмма икенче төрләрен аерып алу ифрат кыен иде. Нәкъ әнә шул «бушбугазлар, алап авызлар» күңелсез кагыйдәләрне дөньяга китерделәр, алар тудырды аны! Үзара бер төрле сөйләнеп, үзең генә калганда бер төрле уйлап та кеше арасына чыккач — җыелышларда, очрашуларда дөреслекне сөйләгән булып кыланучылар шул елларда туды. Аларны танып белү читен иде.

Андыйлар озын гомерле һәм яшәргә җайлашкан булды, безнең көннәргә дә килеп җиттеләр. Берне уйлап, икенчене сөйләп, бер бөртек ышанмаса да, дөреслекне яклап азапланган затлар юкмыни бүген?

Революция бунтарьлыктан башка була алмый, экономик, сәяси һәм мораль җимерүләр һәммәсе дә дөньяда иң гадел җәмгыять төзү максатыннан чыгып эшләнде... Ялгансыз һәм яласыз җәмгыять, курку белмәс җаннар җәмгыяте, киләчәккә шиксез ышанган җәмгыять! Монда икеләнүләргә, берне уйлап, икенчене сөйләп ризык табучыларга урын булырга да мөмкин түгел кебек иде! Хаклык, әлбәттә, көчкә таянырга тиеш, чөнки шулай булмаганда, хаксызлык өскә чыгасын белә идек. Әмма без әлегә беркатлы, тиз ышанучан кешеләр, дошманның аяусызлыгын, шәфкатьсезлеген күреп, ачуыбыз ташый иде, без шәфкатьсезлекнең көчсезлек һәм куркаклык юлдашы икәнен соңыннан гына аңладык.

Соңгы ун көн турында аерып-аерып уйлау мөмкин түгел, авыр.

Бу вакытны сәгать-минутларга түгел, көннәргә бүлү дә авыр, алар минем аңымда тоташ һәм туктаусыз сузылган БЕР КӨНГӘ әйләнделәр. Ун тәүлеккә сузылган БЕР КӨН. Бу язмаларны укыгач, кайберәүләрнең «автор һәммәсен дә үзе күргән кебек сөйләп алдаша» дип шиккә төшүләрен дә, болай әйтүләрен дә теләмим. Бер караганда, ул көннәрдәге хәлләр искиткеч буталчык, катлаулы булып та тоелырга мөмкин. Кая инде ун көннең тоташ БЕР КӨНГӘ сузылуы!

Шушы язмаларны әзерләгәндә, мин Герценның «Узганнар һәм уйлар» дигән гүзәл әсәренә мөрәҗәгать иттем. Эзләгәнемне таптым да. Герцен «Истәлекләрне язарга кемнең хакы бар?» дип сораган да, үзе үк җавабын да биргән: «Бөтен кеше язсын, чөнки язылганнарны укырга берәү дә мәҗбүр итми. Хатирәләреңне язар өчен данлыклы ир-егет, атаклы юлбасар, мәшһүр артист яки дәүләт эшлеклесе булу да кирәкми, моның өчен бары тик кеше булуың да җитә, сөйләр сүзе булган, теләге бар өстенә сөйләү сәләте булган кеше булуың да җиткән. Язмаларың эчпошыргыч һәм язылган тормышың күңелсез генә булмасын! Ул чагында без аны бөтенләй укымыйбыз, китап өчен моннан да зур җәза юк!»

Яши-яши, «заман» үзе дә «җанлыга» әйләнә, үткәннәрне хәзерге мизгелгә яраклаштырып, тырышып-тырышып һәм ашыгып «төзәтергә» тотына. Шундый хәл килеп чыкмасын һәм бүгенге аңым узганнарны дөресләргә тотынмасын өчен, мин моңа кадәр дә үҗәтлек белән көннәрнең, сәгатьләрнең, документларның, газета хәбәрләренең күбесен юмарт рәвештә язмаларыма кертә бардым. Инде аерата мөһим булган бу ункөнлектә тагын да зуррак җаваплылык сизәм, беренче битенә баш сөяге сурәте төшерелгән, актыгына тырнап кына «Зубарев» дип язылган шәмәха тышлы дәфтәремә үз вакытында язылганнарны тулысынча китерәм. Үзгәртмим дә, төзәтмим дә. Бусы бик мөһим, ышаныгыз.

26 июль 1918 ел.

Берничә тапкыр Лацис янына кереп чыктым. Кичен Казанга килеп төшкән Александра Коллонтай лекциясен тыңладым. Лациска хәзер җентекләбрәк карадым, ул миндә елгыр, кискен һәм каты куллы кеше дигәнрәк тәэсир калдырды. Көче артык нык ташып торганга, аның ара-тирә уйлап бетерелмәгән саксыз адым ясавы да ихтимал дип уйладым. Башка сүз белән әйткәндә, бу — югары дәрәҗәләр алган кеше, нәтиҗәгә тизрәк ирешү өчен югалтулар белән дә исәпләшеп тормастан, бик күпкә

маһир, шул җәһәттән «утын ваклап» ташлый да ала! Сабыррак булып, уйлабрак эшләсә, кирәксез корбаннарны булдырмый да кала алыр иде бу тиле тәүкәл! Тыныч вакытта да, сугыш барганда да кабалану аркасында көрәшнең идеясе, мәгънәсе һәм максаты бозыла дип уйлыйм. Моңарчы башымнан кичкән байтак хәлләр шуны раслый. Урман кискәндә йомычка очмый калмый, ә монда тере кешеләр очачак. Синең каршыңда дошман утырса да, аңа бармак аша карарга ярамый. Гомер аңа да бер генә тапкыр бирелгән.

Коллонтай — чибәр, зәвык белән киенгән, хискә бай, акыллы хатын. Революция һәм хатын-кызлар хакында сөйләгәннәре үзе төсле үк сокландыргыч. Аны тыңлаганда мин гел Зоря турында уйлап утырдым. Барабара уйларым Таняга күчте...

Төнлә Гайнулла Таһиров белән сәер бер хәлгә юлыктык. Комендатурадан Кинга шалтыратып, Вознесенский чиркәве ишегалдында сул эсерлар спирт склады ясаганнар дип хәбәр иткәннәр. Комендант взводыннан бер төркем сугышчылар алып, Кин кушканча «барып, белеп, ачыклап кайтырга» киттек. Бардык, сул эсер дружинникларын тиз эзләп таптык.

Кадакланган унике зур тартма саклыйлар икән.

— Ачыгыз,— дибез.

— Ачмыйбыз,— диләр.

— Ни саклыйсыз? — дибез.

Дәшмиләр.

Ниһаять, тартмаларны ачтык: анда, канистрларда, утыз алты чиләк спирт икән! Бик бирелеп, күз керфекләрен дә какмыйча, төннәрен алмаштилмәш ни саклаганнарын белгән дружинниклар ачудан нишләргә белмәделәр. Тартмаларга якын барыр өчен без башта аларны коралсызландырдык: җиде пулемет, иллегә якын граната, винтовкаларын алдык! Комендант взводы сугышчылары тегеләрдән тәгәри-тәгәри көлделәр. Командирлары — сул эсер, без якынлаша башлагач сәбәп табып чыгып ычкынган икән, янәсе «боткалары коры булмагае», югыйсә аңа эләгә иде! «Күз карасы кебек сакларга» ул боерган һәм тартмаларда ни барын белми калмагандыр...

Коралларын да бирмәдек, үзләрен куып тараттык: «Юк-бар белән баш катырып йөрисез!» Ә спиртны башка складка тапшырдык.

Газеталарда революцион ялкын дөрли!

Кызылармеецлар туплана, крестьяннар берләшә, резолюцияләр чыгарыла, ялкынлы речьләр сөйләнә: барысы да Совет властен сакларга әзер! Килсен дошман — хәзер кырып салачаклар! Татар ярлылары берләшә, рус пролетариаты белән татарлар туганлаша. Ә чынлап уйласаң — хәл ифрат авыр. Хәрбиләр аз, бик аз. Чекистлар — тикшерүчеләр, оператив хезмәткәрләр, бигрәк тә җирле шартларны һәм татар телен белүчеләр җитми. Лацис үзе белән ике сыналган иптәшне — латышларны — Эглти белән Пункуны алып килгән. Икесе бер авыз русча белмиләр... Сул эсер калдыкларын себереп ыргытып, әйле-шәйле йөргән тутый кошлардан арынгач, чекада нибарысы унбиш кадровый кеше калды.

Лацис, элеккеге офицерларның бирсен калдырмыйча тентү уздырып, берәм-берәм аларны кулга алырга куша. Ә алар шәһәрнең аулак урыннарында яки якын-тирә авылларда качып-посып ята. Тентү ясарга Вацетистан бер рота кызылармеец сорап алып булмый. Вацетис та хаклы: фронт якынлаша, ышанычлы кызылармеецларны фронтка озатасыңмы, тентү ясарга биреп торасыңмы?

Таня белән сирәк кенә күрешкәлибез. Башкача мөмкинлек юк. Бүген бәхетле көн, азга гына булса да очраштык. Ул торган саен апасына охшый бара. Аның үткен аңы, гадилеге, зирәклеге, уенның йөгереклеге мине сокландыра. Ул бүген: «Ешрак очрашасы иде!» — дип куйды. Аңлаган кешегә аңларлык. Шундый ыгы-зыгылы заманда бөтен күңеле белән егеткә тартыла икән, монда хәлләр шулай... Ул хәзер миңа гаҗәп дәрәҗәдә кадерле җан, ул минем бөтен барлыгымны җылытып, кальбемне

алга өндәп тора. Тик бу турыда аңа иркенләп әйтә алган гына юк, сүзен шаяруга борып: «Менә сугыш кына бетсен, без теләгәнчә һәм теләгәннән артык та очраша башларбыз»,— диган идем, кызыем моңсуланды.

Бүген ул: «Сездә ничек? Караклар яңадан күренмиме?» — дип сорады. «Юк,— дип җавап бирдем һәм кесәмнән ачкыч алып күрсәттем.— Хәзер ишекне ачык калдырып йөргән юк»!

Винокуров турында соравы да булгандыр инде, әлегә аның да үзе дә, күләгәсе дә күренми.

27 июль.

Лацис искиткеч йөрәкле кеше икән, тәвәккәл! Безгә тере үрнәк! Берничә кызылармеец белән караңгы төннәрдә, аулак ишегалларына кереп, контрреволюционерларны кулга төшереп йөри, үзе үк сорау да ала. «Бер икәнсең — сине ун дип танысыннар, ун булганда, йөз чекист килгән дип уйласыннар». Бу аның сүзләре. Һәрчак үзе булып кала. «Знамя революции» газетасы корреспондентына биргән җавапларын һәр кылмышы белән раслый. Интервьюда ул болай диган иде: «Минем белән бергә чекада революциянең сизелерлек көчләре эшли һәм безгә шактый мөһим техник аппаратлар тапшырылган. Акгвардиячеләрнең чыгышын оештырган буржуазиянең һәр талпынуына без мәрхәмәтсез булачакбыз. Без акгвардиячеләрне якты дөньядан себереп түгәчәкбез».

Ул Совет властена бөтен барлыгы, җаны-тәне белән бирелгән кеше иде. Шундый кеше белән без бүген нык кына сүзгә килдек. Ул миңа иртән Петерска суккан телеграммасын күрсәтте.

«Эсерларның ике дружинасы коралсызландырылды. Алардан ике пулемет, 160 винтовка, 150000 патрон һәм 50 бомба тартып алынды. Хәзер кулларында булган мең ярым берданканы йорт каравылчылары тапшырачак. Ун акгвардияче атылды. Комиссия бик нык эшкә керешә, әмма җаваплы урыннарга хезмәткәрләребез җитми».

— Каян алдыгыз мондый саннарны? — дип сорадым гаҗәпләнеп.— Дөрес, Казанда эсерларның берничә дружинасы бар, төгәлрәк әйтсәк, уң эсерларның яшерен дружинасы белән сул эсерларда өчәү. Аның берсе мөселман дружинасы. Әйе, шулардан берсе коралсызландырылды.

— Булса соң?! — диде һич исе китмичә Лацис.— Тиздән башкаларын да коралсызландырырбыз. Ун гына түгел, акгвардиячеләр дә күбрәк атылачак.

Мин гаҗәпләнеп калдым: без чекада саннар белән эш иткәндә монарчы бик сак та, дөрес тә була идек.

— Нигә алай алдан ук шапырынырга? Эш төгәлләнгәч, нәтиҗәсе тәгаен ачыклангач кына хәбәр итәргә иде.

Кылт итеп күңелемә бер шик инде, чекист буларак, шигемне яшереп кала да алмадым.

— Әллә инде сез, Мартин Янович, «мин килгәнче монда йокы симертеп яткannar, мин килгәч кенә асларына су керде!» дип йомгакларга ашыгасызмы?

— Менә нәрсә,— диде Лацис күкерт кебек кабынып.— Ни хәбәр итәргә, ничек хәбәр итәргә кирәклеген үзем дә бик шәп беләм! Әйтер идем инде, йөрисез шунда чалбар төбе туздырып! Юньле-башлы секретарьларыгыз, эш башкаручылар юк. Яхшырак эшләсәгез, мондый телеграммаларның хаҗәте калмас иде.

Мин Ольхеницкийга да, Павел Андреевич Кинга да фикеремне һәрчак ачык итеп җиткерә килдем, булды килешкән чаклары, килешмәгәннәре дә очраштыргалады, ләкин сүзләрдә бер вакытта да ялган өстенлек күренмәде.

— Алайса мин сезнең белән килешеп бетмим,— дидем мин, мөмкин кадәр йомшак булырга тырышып. Ике араның суынуын теләми идем.

— Нигә килешмисез!? Менә мин Мәскәүдән өч секретарь хатынкыз җибәрүләрен үтендем. Тагын килешмисезме?

— Әгәр сез Казанда һәм Идел буенда чын, нәтиҗәле эш җәелдереп җибәрергә уйлыйсыз икән, читтән килгәннәргә генә таянып, берни дә барып чыкмас.

Дөрләп кабынып китә алган Мартин Янович тиз генә сүрелә дә ала икән: тынычланды, баягы әрепләшү бөтенләй булмаган кебек, ягымлы күзләрен очкынландырып миңа төбәлде.

— Ярый, ни әйтергә теләгәнегезне аңладым.

— Секретарь итеп мин бер кызны тәкъдим итә алам,— дидем мин.

— Кем ул?

— Мәскәү кызы. Хәзер әти-әнисе белән Казанда яши. Төпле, ышанычлы, батыр һәм аз сүзле.

— Сезнең шундый сыналган танышыгыз бармы?

— Бар.

— Минем искә төшерерсез,— диде Лацис.— Ә хәзер... үзегезнең шушы минуттан башлап керешергә тиешле төп һәм гадәттән тыш бурычларыгызны тыңлагыз.

Минем колагым үрә торды: тагын нәрсә икән?

— Халык банкысында саклана торган барлык алтынны һәм башка кыйммәтләрне Казаннан озатырга кирәк.

— Димәк...

— Миңа турыдан-туры хәбәр иттеләр. Ленин Халык банкысының Мәскәү бүлеге өлкән контролеры Наконечныйның, Халык банкысы контролеры Андрушкевичның һәм Сембер губернасы финанс комиссары Измайловның мандатларына кул куйган. Берсе РСФСРның төп байлыгын Казаннан күчерү буенча Совнаркомның Аерата мөһим эшләр буенча комиссары, икенчесе комендант, өченчесе комиссар ярдәмчесе итеп расланган.— Лацис көлемсерәде.— Сез каршы килмисездер?

— Ни әйтергә телидегез, Мартин Янович?

— Мөһим комиссия составында казанлылардан берәү дә юк. Күрәм, сез монда яшәгән арада җирле халыкның патриоты булып та өлгергәнсез икән!

— Бу начармы?

— Начар димим... Сез хәзердән шул иптәшләргә булышачаксыз. Җаваплылыгыгыз алардан бер дә ким түгел, бәлки артыграк та булыр. Мәсьәлә үтә катлаулы, четерекле, алда көтелмәгән хәлләр очрап торыр. Хәзер үк иң әүвәл банкка барыгыз, каравылны көчәйтегез, байлыкны эвакуацияләргә әзерләгез. Эшнең барышы турында көненә ике тапкыр миңа хәбәр җиткерегез. Килештекме?

— Тыңлыйм,— дидем дә кырт борылып чыгып киттем.

Иптәшләрчә кисәтүем ошамадымы Мартин Яновичка? Әллә бу авыр вазифаны йөкләү нияте аның күңелендә элек үк бар идеме? Үзеннән читләтергә теләдеме, әллә, киресенчә, якынайтуымы? Ил байлыгы, аның язмышы... Алтын!.. Бер-ике кеше язмышы гына түгел, илнең төп хәзинәсенең язмышы. Әгәр аерата нык ышанмаса, шундый авыр йөкне миңа тапшырыр идеме?

Ничек уйласам да, бу әңгәмәнең күңелсез юшкыны күңелдә утырып калды, мәгәр «төрлесен уйлап — берне эшли торган чак», икеләнергә ярамый, мин моңарчы күрмәгән, белмәгән эшемә тотындым.

Алтын...

Тарих хәтерли: күпме сүзләр сөйләнгән бу хакта! Аны ни белән генә чагыштырмаганнар да, аңа нинди риваятьләр багышламаганнар. Алтын власть бирә, тарихны алга этәрә, язмышлар белән уйный. Испанлылар, америкалылар алтын сәфәрләрендә нинди маҗаралар күрмәгәннәр дә, күпме кан коеп, күпме җан алмаганнар! Алтын өчен күпме тәвәккәлләр баш салмаган! Алтын!.. Әлегә ул кирпеч-кирпеч өелеп, сары тау булып тып-тын гына Казан банкысының тирән подвалларында

ята бирә. Ә аңа төрле яктан легионерлар, ыбыр-чыбыр һәм эре контралар, дөньяны аркылыга-буйга гизгән жуликлар кармавыч кулларын сузарга азапланалар. «Тарта Казанның алтыны» бөтен дөнья хәшәрәтләрен!

Алтын турында күпме китаплар укыганым бар. Бала чакта ишеткән әкиятләр колакка сеңеп калган. Тик моңарчы белгәннәрем бүгенге хәлдә берсе дә ярарлык түгел. Мин моңарчы беркем дә очрашмаган хәлдә алтын белән очрашачакмын.

Күңелемнән генә Лациска рәхмәт тә укыдым: кемнең гомер юлында очрый мондый хәл? Мондый авыр вакыйгага катнашу кемнәргә язган?!

Кичен Лацис мине тагын чакыртып алды. Ул иртәнгә караганда шактый борчулы, йончыган иде.

— Әлерәк кенә Мәскәүдән шалтыраттылар, — диде ул. — Алтын һәм башка кыйммәтләр Казаннан Нижний Новгородка күчереләчәк. Эшне берьюлы башкару өчен дүрт буксир, дүрт баржа һәм моторлы ике катер килә. Наконечный белән Андрушкевичка ярдәм итәргә кушып, главком Вацетис белән Казан советына Мәскәүдән аерым күрсәтмә бирелгән.

Утырганда энә өстендә утыргандай булдым, ары чаптым, бире килдем, кичкә кадәр байтак нәрсәне белеп, ачыклап, үземчә әзерләнеп тә өлгердем.

Банкта булдым. Халык банкысының Казан бүлеге управляющие Марьин белән таныштым. Ул миңа кайбер мөһим документларны күрсәтте (Лацис аңа шалтыратып куйган икән). Марьин күпне белә торган, нык хәтерле кеше булып чыкты. Боларын үзем өчен язып куям.

1915 елда, немецлар Балтыйк буена үтеп кереп, Петроградка куркыныч янагач, башкаладан Казанга алтын акча тутырган биш йөз егерме алты капчык күчерелә. Казан амбарлары ил хәзинәсен саклау урынына әйләнә. 1918 елның февралендә, немецлар Петроградка һөҗүмнәрен яңарткач, Халык Комиссарлары Советы Халык банкы запасын илнең эченәрәк, ул чакта иң куркынычсыз урын саналган Казанга күчерергә куша. (Булган бит Казанның шундый чаклары!) 1918 елның апрель-июнендә Петроградтан — акча сугу дворыннан, тау институтыннан, Үлчәү берәмлекләре Баш палатасыннан, банкның Мәскәү һәм Тамбов бүлекләреннән Казанга хәзинә агыла тора...

— Менә, — диде иртә җыерчыкланган маңгай тирен сөртеп Марьин. — Жиденче июньдә Самарадан «Фельдмаршал Суворов» пароходында безнең банкка 57,5 миллион сум алтын акча, утыз миллион сумлык кредит билетлары килде.

— Ул кадәр байлыкны эшкәртеп бетерә аласызмы соң?

— Кыен, бик кыен. Июнь уртасында безнең хәл тагын да читенләште: РСФСР Халык банкысының баш комиссары Тихон Иванович Попов, Казанда тынычлык бетүен искә алып, эвакуациягә әзерләнергә боерык бирде. Сугыш ахыр чиктә алтынга да барып тия! Менә әзерләнергә тотындык, тишек-тошык капчыкларны алыштырдык, ямардайларын ямадык, бар булган байлыкны барладык. Ул арада җен суккыры Муравьев килеп чыкты... Килде, керде, «Паникерлар, куяннар!» — дип безне эт урынына сүкте. «Сәяси як тотрыклы, ул, ягъни Муравьев, барында куркырлык берни дә юк!» — дип, банк тирәсенә каравылга үз кешеләрен куйды. Нишләргә? Мәскәү: «Әзерләнегез!» — ди, ә Муравьев кешеләре алтынга кагылырга кушмый. Аптырагач, мин Поповка ашыгыч хәбәр салдым, ярый хет аннан телеграмма килеп төште.

Марьин — гомере буе сак эшләргә өйрәнгән кеше, телеграмманы пөхтәләп «Эш»кә тегеп үк куйган.

«Муравьевның мин-минлегенә ышанып гафил булмагыз. Әзерләнегез. Үзгәрешләрне дикъкать белән күзәтә торыгыз, гел миңа хәбәр итегез. Андый-мондый ят хәлләрне чекага житкерегез».

Телеграмманың томанлырак булуын Марьинга әйтеп тормадым, ул

үзе дә Поповның чак кына югалып калганын аңлый иде шикелле, телеграмма тоткан кулы калтырап-калтырап алды.

— Нишләргә! — диде ул миңа ымсынып карап. — Кемнәрдер әнә күзеннән дөя үткәрә дип сөйлиләр. Хәзер бездә республиканың төп хәзинәсе — алтыны! Казан ярым камалышта. Дошман ындыр артында гына. Әнә күзеннән түгел, дошман күзеннән ничек үткәрик алтынны?!

Менә сиңа әзерлек! Менә сиңа уяулык! Тишек-тошыкларны ямаганнар да авыз күтәреп утыралар! Ныклы карар юк, икеле-микеле боерыклар! Каравылны теләсә кем алыштыра ала... Банк тирәсендәге урамда әллә никадәр шикле кеше уза-китә йөренеп тора. Киңәшкә Кин янына кердем. Лацис бүлмәсендә юк иде. «Павел Андреевич, димен, эшләр харап!» Белгән кадәресен аңа сөйләп бирдем. Белгәннәрем дә, төптән уйлаганда, шактый томанлы, чуалчык иде. Кин бераз гына сүзсез утырды да ярдәм итәргә вәгъдә бирде.

— Марьин сөйләгәннәргә өстәп шуны әйтәм, — диде ул. — Муравьев качар алдыннан байлыкны күчерергә әзерләргә боерган. Мөгаен, үзе белән алып качарга ниятләгәндер. Өлгерә генә алмады!

— Ашыгырга кирәк! — дидем мин.

Ашыгырга... Тик кая, ничек?

Бөтен Рәчәй авантюристларының йокысын качырган алтын безнең дә тынычлыкны алды. Озаккамы? Мартин Янович көн саен ике тапкыр миңа хәбәр итә. Ә үзе... Тыңлый да сакалын кашый. Сакалын йолыккалый да тыңлый.

Арган тәнемне йокыга озата алмыйча җаным тыпырчынып ята. Йоклый алмый яткан авыр мизгелләрдә мин гел Таня турында уйларга тырышам. Сикереп торып хәзер үк аның янына барасым килә. Кеше никадәр арган, газапланган булмасын, нинди авыр, болгавыр тормыш белән яшәмәсен, һәммәсеннән — мәшәкать, газаплардан өстен бер нәрсә — мәхәббәт бар. Әле ярый ул бар! — дип куана тыпрпылдап җаным.

Беләм, ап-ачык аңлыйм — Таня бар!

28 июль.

Реввоенсоветта һәркөн утырыш... Бүген мин шунда булдым. Сөйләгән сүзләр мәңге хәтердә уелып калырлык җанлы һәм кискен булсалар да, мин аларны, булдыра алган кадәр, язып та бардым. (Гел-гел хәтергә ышанырга да ярамый, аннары... бу гарасатта исән каламмы, юкмы дигән уй зиһенемне кап урталай бүлеп ялтырап узды!)

Главком Вацетис, әзерләнгән һөҗүм операциясен ваклыклары белән озаклап сөйләде дә, җыелганнарны тагын да ныграк ышандырырга теләгәндәй, зур, йонлач йодрыгы белән һаваны тела-тела сүзен йомгаклады: «Без һаман көчле! Шуны эштә дошманнарга исбатлар чак җитте! Хәлиткеч һөҗүм ясап, мин дошманны Идел сызыгыннан Көнчыгышка алып ташларга карар иттем».

Аның сүзләре кыздырып җибәрдеме, фронт реввоенсоветы члены Данишевский сүзләрен сандалда чүкеп, утка төреп залга чәчә башлады:

— Семберне безнең гаскәрләр алны-артны карамый куркып чапканга дошманга бирдек! Иң хурлыгы шунда ки, качарга тиеш түгел саналган кешеләр иң алдан үкчә ялтыраткан! Оят! Шәһәр коммунистлары Семберне саклар өчен көч куймаганнар, баррикадалар кормаганнар, шәһәр халкын көрәшкә өнди алмаганнар! Хурлык! Шуның өстенә дошман кулына корал, боеприпас запасларын өеп калдырганнар! Җибәргәннәр! Моның өчен гади гаепләү чаралары гына аз, моның өчен беркемне җәлләргә ярамый! Дошманны коралландырып чап инде?! Муравьев авантюрасын җимерә алган Сембер коммунистлары бу юлы җебеп калганнар, үз көчләренә түгел, читтән киләсе ярдәмгә йөз тотканнар. Шәһәрдә сугышка сәләтле гаскәр була торып Семберне дошман кулында калдырганы өчен фронт реввоенсоветы члены Благонравовны эшеннән алып чөяргә! Әгәр шундый хәл Казанда да кабатланса,

шундый сәләтсезлек, йомшаклык күрсәтсәк — оят. Хурлык! Позор! Шәһәрне саклап калырга кирәк һәм без моңа бик нык әзерләнік!

Лацис беркемне дә бүлдермичә тыңлап утырганнан соң сикереп торды:

— Риза! Мин чыгарган боерыкка таянып, җирле чека һәм башка сәяси контрразведка алып баручы барлык башка оешмалар миңа буйсындырылсын. Корал йөртергә моңарчы бирелгән хокуклар көчен югалта... Килештекме? Бүген төнлә чекистлар Крестьян банкысы подвалларыннан ленталары белән унике пулемет, җитмеш берданка һәм бер йөк патрон төяп алып кайттылар. Корал чека складына тапшырылды. Хуҗасы кем дисезме? Әйтәм! Сул эсерлар! Игътибар итик: яңа фетнә әзерләп ятмыймы алар? Бу бер. Әшкә идән астына күчәргә мәҗбүр булган Сембер чекистларыннан хәбәр алынды. Егерме алтысыннан егерме җидесенә каршы төндә Сембердә комуч вәкилләре, легионерлар, интервентлар яшерен киңәшмә уздырган. Анда Казанга поход мәсьәләсе каралган... (Болай да тын утырган зал тагын да тынып калды!) Һәм алар «ашыгыч рәвештә кузгалырга!» дигән карарга килгәннәр. Казаннан килгән офицерлар аларга дәрт өстәгән! Россиядәге француз Хәрби штаб вәкиле капитан Борде аларга көч өстәп утырган! Онытмагыз, Борде Сембергә Казанда булганнан соң китте. Мондагы шартлар белән танышып, исәнәеп йөргән дә, безне таркау, әзерлексез санап, анда барып акгвардиячеләрне активлыкка өнди. Сембергә Казаннан качып киткән дошманнар турында тулы мәгълүмат әлегә юк, мәгәр алар Казанны мушкага алган, белегез, алар туры монда юнәләләр! Утырышта безнең көчләргә ике төрле бәя бирелгән. Тыңлагыз. Мәсәлән, Сембер эсерларының җитәкчесе Климушкин болай дигән: «Казанда шактый санда совет гаскәре тупланган. Шәһәр — зур эшчеләр үзәге. Эшчеләрнең күпчелеге большевиклар йогынтысы астында. Төгәлрәк әйткәндә, бу шәһәр — әлегә большевиклар өне. Күп көч куеп шәһәрне кулга төшерсәк тә, аны кулда тоту өчен көч тагын да күбрәк соралачак. «Ничек сәйрый, ә?! Керенскийның күптәнге тарафдарларыннан берәү, мәгълүмегез Лебедев аңа каршы төшә: «Казанда Россия дәүләтенең алтыны! — ди ул. — Санап бетергесез күләмдә корал, интендантлык кирәк-яраклары, артиллерия тупланган. Казанда большевикларны кырып-себереп түгәргә әзер торган офицерлар җыйналган. Әгәр бүген булмаса иртәгә, большевикларның үзләрен тар-мар китерәчәген алар яхшы аңлый. Казан — Россиянең әһәмиятле, Идел буе төбәгенең төп сәяси урыны. Казанны алырга кирәк, аны алып була. Казанны алу Учредительное собрание яклы комитетларның халыкара абруен югары күтәрәчәк».

— Менә алар безнең хәлне ничек бәялиләр. Фикер алышуларны киңәшмәдә өч кеше йомгаклаган, — дип белдерде Лацис. — Беренчесе — капитан Борде! Ул интервентларның Вологда һәм Вяткага якынлашуын күздә тотып, Казанны тизрәк кулга төшерергә, ике як гаскәрнең тантаналы кушылуына өнди. Моны хәтердә калдырыгыз! Генштаб полковнигы Каппель — канкояр ерткыч, күптән түгел генә «Халык армиясе» дип аталып йөртелгән этрәк-әләмнәрнең командующие — Казаннан килгән офицерлар белән беравыздан: «Сембер мисалында Казанны да сугышсыз-нисез кулга төшереп булачак, анда безне көтәләр, капкаларны киң ачарбыз дип ышанычлы вәгъдәләр бирәләр», — дип белдергән. Аннан кала ыбыр-чыбыр чыгыш ясый, асылда алар Каппель һәм Борде җырын җырлыйлар... Нәтиҗәдә, Казанга ашыгыч һөҗүм башларга карар кылынган. «Халык армиясе» частьлары — полковник Степановка, офицерларның җыелма отрядлары — Каппельга, чехословаклар Швецка тапшырылган. Җәмгысы безгә каршы өч җыелма полк. Идел флотилиясеннән берничә судно, акгвардияче отрядлар чыгачак. Тәкъдимем! — дип нәтиҗә ясады Лацис. — Шәһәрне оборонага әзерләргә. Дошманлыклары нык исбатланган акгвардиячеләрне ашыгыч рәвештә атарга кирәк, чека моңа әзер. Шуның өстенә без шәһәрдә контррево-

люцион чыгышлар булдырмау ягын хәл итәрбез. Безгә ышаныгыз!

РКП(б) губкомының председателе Шейнкман сөйләде.

— Хәлебез катлаулы булса да, алай ук өметсез түгел. Казанда камалыш хәле игълан итәргә вакыт дип саныйм. Димәк, барлык коммунистларны коралландырырга, коралы эшче отрядлар төзергә кирәк. Казан банкысындагы алтын — һәртөр контрреволюционерларның күзен яндыра торган җим, аны тизрәк һәм ышанычлы сак астында Нижний Новгородка күчерү дөрес булыр. Гадәттән тыш экспедиция шәһәргә килеп җитте, ул хәбәр әлерәк кенә алынды, баржа-буксирлар Казанка тамагында торалар. Эвакуацияне кичекмәстән башларга тәкъдим итәм. Сиксән мең пот алтынны хәвеф-хәтәрсез генә күчерү җиңел булмас.

Вацетис хәлгә үзенчә бәя бирергә тырышты:

— Чехословаклар һәм комучлар Казанга бер алтын өчен генә омтылмый. Алар хәрби инициативаны үз кулларына алып, безне һөҗүм мөмкинлекләреннән мәхрүм итеп, үзләре алга ыргылмакчылар. Казаннан Мәскәүгә юл ачыла! Бар булган көчне, шул исәптән шәһәр аша Көнчыгыш фронтка узучы гаскәрне дә монда калдырырга кирәк. Без ныклы һөҗүмгә әзер булмасак та, көчле оборона тотарга сәләтебез җитәрлек һәм Казанны бирмәбез дә! Бәс, шулай икән, нигә кеше куркытып имеш-мимешләр таратырга да, алтын-көмешне кузгатырга? Алтынны күчерү — шәһәрне дошман кулына бирергә ризалашу түгелмени?! Аны күчерү дә җиңел булмас, монда ак-карасыз гына төядек ди, ә юлда? Буксир-баржалар туп-турыдан аклар кулына барып төшсә? Шәһәрне сакларга дигән көчне алтын сакларга бүләргә кушасызмы? Төбәктә аквардиячеләр дә, бандитлар да җитәрлек, алар алтын дигәндә җәһәннәмеңне актарачак! Буксир-баржаларның ник килгәнен, Казанка тамагында ни көтеп торганнарын белмиләр дисезме әллә? Тирәюньдә шпионнар кайнапмы-кайный. Минемчә, алтынны кузгатмаска, бернинди паникасыз шәһәрне оборонага әзерләргә. Алтынның шәһәрдә калуы безгә көч өстәр, гаскәрләрдә җаваплылыкны арттырыр. Оборона, оборона һәм тагын бер тапкыр оборона! Бу хәрбиләр эше һәм мин, главком буларак, тиешле чараларны күрәчәкмен. Без монда килер алдыннан гына җыелып сөйләштек, план әзерләдек, шул план нигезендә Фронтның баш армиясе Кама тамагыннан көньякка, Саратовтан төньякка таба кузгалып һөҗүм башлаячак. Идел буен гына түгел — Урал белән Себерне дә дошманнан арчырбыз! План минем җитәкчелектә төзелде. (Вацетис учына бер-ике тапкыр йөткереп алды.) Мин өстәмә' көчләрнең килеп җиткәнен генә көтәм. Шул минутта ук хәлиткеч һөҗүмгә кузгалачакбыз!

Ярсып киткән Вацетис планның кайбер үзенчәлекләренә тукталып, әүвәлгедән дә кызып сөйли башлаганда, гаҗәеп акыллы, зур күзләрен ялтыратып Шейнкман аны бүлдерде.

— Туктап торыгыз, — диде ул. — План матур. Әйбәткә охшаган, сүз дә юк. Өстәмә көчләр кайчан килер, гомумән, килеп өлгерерме алар — менә мәсьәләнең асылы шунда! Ә дошман әнә генә, Казанның капкасын кага. Полковник Степанов белән Каппель өстәмә көчләрне көтеп торырлармы?.. Ай-һай! Минемчә, күзне ачып карарга бик вакыт. Сез безне бишеккә салып тирбәттегез дә, без йокыга китә яздык... Сез ундүртенче елдан күнеккән, аның кагыйдәләренә нияләнгән җирле сугыш кына түгел бу, аңлыйсызмы, бу гаҗәеп, моңарчы хәрби дәреслекләргә язылмаган, күз күрмәгән сугыш! Илдә дәһшәтле гражданнар сугышы бара. Монда регуляр гаскәрләр генә түгел, киң халык массалары, бөтенләй көтелмәгән яктан, һич уйланылмаган юнәлешләрдән калкып чыгып катнаша. Сезнең патриотик сүзләрне кире какмастан, әйдәгез реаль хәлгә әйләнеп кайтыйк: эшчеләрне коралландырыйк, ышанычлы сак астында республика хәзинәсен күчереп өлгерик.

— Күчермик! — диде Вацетис.

Кемнәрдер аны яклады, хәрбиләр сикерешеп торды.

— Кучерик! — диде купчелек.

Бәхәс кызганнан-кызды, сүзләр кылыч кебек бер-берсен кисешеп, үзара гаепләүләр граната кебек шартлап ярылды, фикерләр бер-берсен юк итеп, күмеп яңгырадылар. һәркем үз фикерен акыллы санап, аны өстен чыгарырга тырышты.

Ниһаять, мондый карарга киленде: Григорий Соколов җитәкчелегендә эшче полк оештыра башларга; алтын-көмешне ышанычлы юл белән баржаларга ташырга; банкны саклауны чекистларга, латыш укчыларына һәм Мөхәммәт Корбановның купчелеге большевиклардан торган татар-башкорт отряды сугышчыларына йөкләргә. Шулар арасыннан конвой взводы төзеп (хәзинәне банктан баржаларга илткәнче дә сакларга кирәк бит әле!), аңа баш итеп 1905 елдан большевик, ревтрибунал председателе Андрей Бочковны билгеләргә...

Миңа тапшырылган эш үз көчендә кала. Реввоенсовет утырышында минем исем яңгырамаса да, мин аның шулай икәнен белә идем.

Кичләрен шәһәрдә атыш тавышлары элек тә ишетелгәли иде. Без аңа күнегеп тә беттек дисәм ялган булыр, һәрчак сискәндерә, уйга сала төнге атыш тавышы, бүген дә кич җитүгә тәртипсез атыш башланды. Бер азаеп, бер көчәеп атыш төне буе дәвам итте. Бүгенге атыш тавышлары куркыныч хәбәр булып, каядыр чакырып, ашыгырга боерып яңгырады. Нарядлар, патрульләр атыш аерата көчле яңгыраган урыннарга ашыктылар, тояк тавышыннан урамнар гүләп йокыдан уянды, безнекеләр барып җиткәндә әле генә шаулап торган урамнар тынып кала, мылтык, пулемет тавышлары бөтенләй киредә, каршы якта үртәп һәм чакырып яңгырый башлый... Кемдер безнең болай да арган нарядларны әлсерәтеп йөртүне максат итеп куйган шикелле иде. Чекистлар берничә кешене, кораллары белән ук, тотып алып кайтсалар да, атыш тавышлары тукталмады, кимемәде дә...

(Бусын иртән язып куям: кичә яза-яза йоклап ук киткәнмен... Өстәлдән башымны калкытсам, көн яктырган. Тәрәзәмне ачып җибәрдем, офык өстендә кара болытлар тирбәлә. Сискәндереп тагын атыш тавышлары яңгырады. Сажидә апа әллә куркып, әллә болай гына, ишеген ачык калдырган. Исем китте, яулык җәеп шунда тезләнгән дә намаз укый. Аның үз алласы белән сөйләшкәнен бер дә күргәнем юк иде. Безнең көчкә ышанычы бетеп, ходасыннан яклау ялварамы?

Кем белсен...

Кичә дә Таня белән күрешеп булмады. Бәлки ул шалтыраткандыр да, мин «өйдә юк» идем шул...)

29 июль.

«Үзәк Комитет Көнчыгыш фронтны ныгыту турында карар кабул итте!» — дигән сөенечле хәбәр Казанга соң гына килеп иреште. Ниһаять! Хәзер эш бераз җиңелрәк булыр: иң кирәк чакта өстәмә көчләр килеп җитәр. Вацетис, вәгъдәсен үтәп, фронт белән штаб арасындагы элемтәне ныгытыр. Югыйсә, алгы сызыктан бер-берсен бөтенләй юкка чыгара торган имеш-мимешләр агылып тора, ә чын хәлне, оятыбызга каршы, беркем дә анык кына белми.

Казанга ВЦИК члены, большевик Захаров килеп төште. Аны политбүлек начальнигы итеп билгеләделәр. Ул агарту, тәрбия эшләрен алып барачак, контрразведка белән җитәкчелек итәчәк. Лацис аны «Әйбәт егет!» диде. Килүе хәерлегә булсын! Әйбәт егетләр, төпле егетләр, ышанычлы кешеләр безгә бик кирәк.

Иртәгә газеталарда сул эсерларның тагын бер дружинасын коралсызландыру турында хәбәр басылачак... Бүген, комитетларының кайдалыгын белүгә, шунда чаптык, барып керсәк, адәм заты калмаган, барысы да табан ялтыратканнар. Гайнулла миңа карый, мин аңа:

кем, кем, кем?! Арабызда хыянәтче барын без торган саен дәлилләрәк сизәбез! Бар ул, бар! Аркага пычак кадарга әзер булып йөри! Кем икәнен ачыклап торырга вакыт кына табалмыйбыз... Җиде пулемет, патроннары белән винтовкалар, гранаталар кулга төште. Байтак корал! Каян алалар диген, төпсез коелары бармы әллә? Барысын тәяп, санап бетергәч Гайнулла шаяртып та маташты:

— Адәм баласы кыен хәлгә юлыкса дигән безнең бабайлар, аннан котылу әмәле күп, мәгәр иң ышанычлы әмәл — вакытын белеп сызу! Сызганнар эсерлар!

Сызуын сызганнар, күз бумаганнар, кемдер аларны искәртеп өлгергән.

Шәһәр эчендә мәшәкатьләр шулкадәр ишәйде, берара югалып калдым, алтын ягына борылып карарга вакыт юк.

Ниһаять, ревтрибунал карары һәм Лацисның боерыгы белән, бүген төнлә гаепләре исбатланган акгвардиячеләр атылачак. Чека бинасы һәм төрмә янында саклар арттырылды. Элекке офицерлар, акгвардияче кораллы дружина членнары һәм шәһәрдә восстание күтәрергә маташкан бәндәләр атылачак. Аларны төрле облавалар вакытында коралы килеш эләктереп алганнар. Лацис сүзендә нык тора әлегә: «Алар Сембер-Самарада безнең иптәшләр белән тәкәллефләнмәделәр, судсыз-нисез тоттылар да аттылар. Нигә без кәнфитләнеп торыйк?! Мин аларча кыланырга димим, мәгәр сугышта икән — сугыштагыча! Башка юл юк!» — диде.

Иртәгә шәһәр стеналарына ябыштырылачак листовканың сүзләре турында озак уйландык. Сүзләр хаклыкны, гаделлекне, бер үк вакытта аяусызлыкны да төгәл һәм кыска итеп халыкка җиткерсен өчен тырыштык. Юк-бар гайбәтләргә урын калмасын өчен үзебез хәбәр итеп өлгерергә кирәк иде!

«Чека кырык кешенең эшен җентекләп карады. Арада унысы — хезмәт ияләренең аерата явыз дошманнары — моннан соң совет властена зыян сала алмас!»

Кыска, аңлаешлы һәм дәһшәтле дә!

Главком һәм фронт реввоенсоветы Казан эшчеләренә һәм кызылармеецларга Өндәмә белән мөрәҗәгать итте.

Казан, кызыл Казан куркыныч эчендә! Өстебезгә явыз дошман килә. Алар сез яулаган ирекне тартып алачак, фабрикаларны хуҗаларына кире кайтарачак. Әгәр сез каушап калсагыз, әгәр сез бер адым гына артка чигенсәгез дә шулай булачак. Алар явызларча җиңү тантанасын көтәләр, алар белән янәшә җирле буржуазия шатлана, алар да арттан пычак кадарга әзер. Юк! Теш ыржайтырга, көлергә иртәрәк! Без һаман көчле! Барыгыз да коралга! Барыбыз да Казанны сакларга! Дошманны бәреп егып сибереп түгик! Яшәсен революция!»

Шейнкманның сүзләре Вацетисның колагына кергән икән, реввоенсовет да шуны куәтләгәч, шәһәрдә эшчеләрне коралландырырга керештеләр. Соңгарак калмадыкмы?

«Латыш кебек кире!» — дигән мәкаль бар. Бу тапкыр сүзне безнең Вацетисны бик якыннан белгәннәр чыгарган диярсең! Үзе бөтен җанытамыры белән хәрби, намуслы һәм ифрат батыр кеше, иллә мәгәр «сугыш эше белән гаскәриләр генә шөгыльләнсен, гражданскилар үз урыннарын белсеннәр!» дип гомерлеккә ининган. Имеш, һәр таракан үз ярыгын, һәр балык үз арыгын белсен! Шуның өстенә, Вацетис үз ихтыяр көченең чиксезлегенә ышанган, ул әйттеме — бетте, үтәлсен, һәркем үзенә төшкәнне башкара килсә, какшамас тәртип урнашачак дигән кагыйдәгә башы-аягы белән табынган кеше.

Хәрбиләр белән гражданскилар арасында дөрләп кабынып алган ызгыш-талаш шәһәрне сакларга нык комачаулар дип куркам.

Соңга калмыйбызмы? Дошман килә, үрмәли, шуыша, якынлаша...

Бүген Вацетис тагын бер «зирәклек» күрсәтте, кавалерия отрядын оештыру турындагы боерыкка кул куйды.

— Безнең атлы гаскәребез юк, — диде ул. — Фронт исә тиз-тиз күчешне сорый. Пехотаны я атка мендерергә, я арбага утыртырга кирәк.

— Атка менү турында уйларга соң, — диде гадәттән тыш салкын канлы военком Авров. — Казанны оборонага әзерләргә кирәк, оборонага! Атка менгән оборона турында ишеткәнем юк әлегә.

Хәрбиләр дә главкомны өнәп бетермиләр булса кирәк...

Гайнулла шукланып:

— Атка менгәч качу җиңеләя! — диде дә ачы елмаеп куйды.

— Өлкәннәрнең боерыгын тикшерергә сезгә иртәрәк әле! — диде һаваланып Вацетис. Мин дә Гайнуллага кушылып хәсрәтле елмаеп бу сүзләрне тыңладым...

30 июль.

Көен дәфтәремә язарга да вакыт калмый, икмәктер! Вакыйгалар тыгызланып бер-берсен куалыйлар, язмыйча барсаң, барысы бергә буталып, онытылып бетәчәк. Елга көзен тушлый да тушлый, бозның зәңгәрлеге калын-калын саргылт юшкын астында кала, елганың төсе онытыла... Фактлар, кешеләр турындагы уйларны, мәгълүматларны мөмкин кадәр гадел рәвештә теркәп калдырырга омтылам.

(Бу дәфтәр кем кулына эләксә дә, аны тарих өчен сакларга тырышыгыз!)

Казанда күпме офицер бар? Керенскийның табанын ялап көн күргән Лебедев таянырга җыенган көч шәһәрдә ни дәрәҗәдә? Штабта, гарнизонда хезмәт итүчеләрнең күпмесе аклар ягына авачак?! Моңарчы тәгаенләп куймаганбыз, бүгенге оперативкада шул турыда сүз кузгалды. Беркем дә төгәл генә санны белми икән. Ә белү зарури, үзеңә каршы кемнәр чыгачагын белмәү күз бәйләп сугышу түгелмени?

Берәүләр: «Казанда акларның килгәнен көтеп торган офицерлар саны ун меңләп»,— дип ышандырырга тырышты. Икенчеләр: «Булмас! Алар биш меңнән дә артмас!» — дип, түшәмнән цифр чүпләде. Военком Межлаукның саннары гына дөреслеккә якын булырга мөмкин...

— Губвоенкоматта, — диде ул, — бүгенге көнгә учетка баскан пехота офицерлары — 1730 кеше, артиллериядән — 418, атлылар — 80, инженерлар — 57, пулеметчылар 80 кеше бар. Хәрби чиновниклар — 520. Җәмгысы, шәһәрдә — 2885, өязләрдә — 830 кеше. Болары — бездә исәптә торучылар. Учетка басмаганнарны якынча да әйтү кыен. Исемлек һәркөн арта тора, шуннан чыгып, бу санны икеләтсәк, без нык оешкан бер-ике офицер батальоны белән очрашачакбыз!

Саннар барыбызны да уйга калдырды: гади арифметикага таянып, Степанов-Каппель отрядларын бу санга кушып караганда, уйга калырлык күңелсез саннар килеп чыга иде.

— Шуны онытмагыз, — диде безнең төксе чырайларга карап Межлаук, — офицер булу — контрреволюционер дигән сүз түгел. Офицер булган өчен генә атарга ярамас!

Лацис һаман үзенекен куды, үҗәтләнеп: «Безнең сафларны йомшартучы һәр кешене я атарга, я төрмәгә тыгарга!» — дип кабатлады.

Межлаук аңа каршы төште. Лацис сикереп үк торды.

— Хәзер ап-ачык беләбез: күп кенә легионерлар һәм акгвардиячеләр позицияләрен ташлап Казан ягына качалар. Андый хәбәрләр көн дә килә. Арта! Чибәр ханымнар янына ашыга дисезме сез аларны?! Түгел шул! Алтын тарта аларны, алтын! Шул котырта. Бездә хәзер алтмышлап кеше утыра. Кубесенең кулында Ярославльдә, Муром һәм Рыбинскида тар-мар ителгән савинковчыларның Казандагы адреслары. Үң эсерлар һәм меньшевиклар белән нәкъ менә Казанда кавышырга ашыкканнар... Бүген төнлә Воронов дигән бәндәне атарга хөкем иттек. Элемтәче икәне бәхәссез. Кем янынадыр килгән. Кем янына? Нинди максат

белән? Әйтми! Без әле нечкәләп сорау ала белмибез, өйрәнергә вакыт та калмады. Шигебезне раслый алсак кына хөкем чыгарабыз чыгаруын. «Үзен Воронов дип атаган бәндәне атарга!» Бәлки, атмаска да ярагандыр? Бәлки, ул бөтенләй Воронов түгелдер? Воронов дигән бәндә дошманның эресе булып, ул ягы безгә билгесез калса?! Без кемне атканыбызны энәсеннән-җебенә хәтле белергә тиешме? Тиеш! Димәк, эшли белмибез әле, өстән-өстән генә, сай сөрәбез...

Ни әйтергә теләде Мартин Янович? «Вакыт таләп иткәнчә эшләргә өйрәник!» — дип бетерде ул сүзен. Таралыштык.

Казан үзенең алтыны белән кемнәрне генә үзенә тартып китерми?! Әгәр эшне белеп, вәзенләп оештырсаң, дошманнарны берәм-берәм төбенә төшерергә җайлы җим буласы икән бу алтын-көмеш дигәннәре! Алар килә тора, ә син чүплә акгвардиячеләрне! Шәп җим! Көч, хәйлә, осталык һәм тәҗрибә булганда, байтак авантюристны эләктерәсе икән без дә... Вакыт аз калды, вакыт! Көч җыеп, тәҗрибә арттырып торырга вакыт юк.

Бүген чекада гына кунарга калдым. Йоклый алмыйча озак кына тырпылдап яттым. Ишегалдында шау-шу ишетеп, тәрәзәгә якынайдым. Таң яралып килә икән. Вәлиуллин белән Аристов кайтып керделәр. Ул төнне алар эшчеләр отряды ярдәмендә дары заводын шартлатудан саклап калганнар икән. Шәһәр идән асларына поскан ак офицерлар Каппельны әнә шундый фейерверк белән каршыларга җыенганнар! Шәһәр халкының, эшчеләрнең ни күрәсен уйлап та карамаганнар таш маңгайлар...

Лацисның кискенлеккә чакыруы нигезле дә булгандыр, дошманнарның этлеге көннән-көн арта тора, арткан саен кулга алулар да күбәя. Чека подвалы гына түгел, ишегалдындагы ике катлы бина-төрмә дә туп-тулы... Мин көндезләрен генә түгел, төннәрен дә сорау алам. Допрослар көннән-көн бер төсле була баралар, бу минем җанны талый. Тоташтан бер төсле, бер үк язмышка очраган офицерлар чылбыры сузылды. Исемнәр генә башка, тормыш юллары, язмышлары, контрреволюциягә тартылу сукмаклары бер төсле диярлек. Керәләр, утыралар, үзләренең контрреволюцион оешма әгъзалары икәнен тартынмыйча әйтеп бирәләр. Һаваланып: «Көчлеләр азайгач, яшәү кыен икән!» — дип уфтанган булалар, үлем куркынычы янавын белгәч, елан сыман кабыкларын салалар, җебеп-мәлҗерәп төшәләр, еш кына күз яшьләре дә сытылып чыга...

Күптән түгел генә Марина Цветаеваның искиткеч тапкыр шигырьләрен укыдым:

Белым был — красным стал:
Кровь обагрила.
Красным был — белым стал:
Смерть победила.

Үлем һәркемгә дә бер төрле карый. Гәрчә Хәтер каршысында кешеләрне тигезләми. Гомерен тырай тибеп уздырган, һавалы, кәпәренгән, үзен чамасыз сөйгән буп-буш типларга карыйсың да, әйе, бу кеше Хәтердә дә шундый булып калачак та, шундый булып кына онытылачак дип уйлыйсың. Үлем дә аны үзгәртә алмый! Хәтта үлем дә!

Менә бүген сорау алган кешеләрем. Дошманнар!

Поручик. Яше утызда, тап-таза, сәламәт, ак керфекләрен йома-йома сиңа әллә каян өстән карап тора. Син аның өчен юк, мөмкин булса, дагалы итекләре белән ул сине сытып кына китәчәк. Сораша башлыйсың. Яшерми. Яшерүне кирәк санамый! 1918 елда Казанда офицерлар «өчлегенә» кергән. Полковник Петровка буйсынган. Аена биш йөз сум хезмәт хакы алган. (Биш йөз сум!) Сигнал бирелүгә, телеграф белән банкны кулга төшерергә тиеш булган.

— Ни өчен телеграф белән банк беренче чиратта? — дип сорадым.

— Казан алтыны безгә алдагы көнгә юл ачачак... Телеграф аша шуны дөньяга, бар халыкларга белдерәчәкбез.

Ни кушсалар, шуны үтәргә әзер торган җанвар. Башта үзен гаҗәп эре тотты! Сүзне бөердән генә чыгара!

— Совет властенмы? Аны җүләрләр генә власть дип таный. — Азрак утыргач килешү ягына борылды. — Власть икән — мин аны таныйм. Кемнең кулында, шуның авызында диләр бит! — Инде иң актыктан, үзен ни көткәнен белеп алгач, агарды, күгәрде, еламсырап ялына ук башлады. — Зинһар тагын бер атна гына атмый торыгыз, минем дә кирәгем чыгар! — диде.

— Нигә бер атна? — дип ачыклауны сорагач, әүвәлге кәпәренүенә кайтып төште.

— Атна узгач, без урыннарны алышырбыз. Мин сездән сорау алачакмын!

Я, мондый бәндәгә ни дисең инде?

Аның артыннан ротмистрны керттеләр. Кулга алганда, бер чекистны җиңел яралаган. Егерме ике кешелек офицерларның яшерен оешмасында член булып исәпләнгән. Анда алпавыт Молостовых, полковник Сужко да булган. Үз тарафдарларыннан канәгать, явыз! «Полковник» дигәндә гәүдәсе турайды, иңбашлары төзләнде. Ерак эзләнәсе түгел, моның хыял чикләре ап-ачык — бу бәндәчек полковник булу турында гомере буе хыялланган... Кызык, шушы йолкыш та бер атнада урыннарны алышырбыз дип ышанамы? Мине каршысына бастырып сорау алырга өметләнәме? Гайнулла Таһировны «гололобый татарин!» дип типкәләп чыгарачакмы? Шейнкманны, «жид!» дип, стенага терәячәкме?

Лацис кызып киткән чакларда мин тулысынча аның яклы түгел идем әле. Ул вакытларда дошманнар да, тараканнар сыман, җылы ярыкларда посып, мыекларын селкетеп, нидер көтәләр иде. (Ротмистрның төрмә камерасында да купшылыгын югалтмаган мул мыегын күргәч, бу чагыштыру күңелемә килде!) Хәзер алар минем каршымда, совет властеның законнары каршында. Алар безнең һәлакәтнең көненсәгатен атап сөйләшәләр, көләләр, мыскыллыйлар, шапырыналар, яныйлар. Исән калсалар, безгә көн күрсәтәчәк түгеллекләрен яшереп тә тормыйлар.

Сорау алулардан хәтеремдә иң сеңеп калганы капитан Иванов белән очрашу булды. Заманында Казан Хәрби округының контрразведкасында хезмәт иткән. Савинков «Союзы»ның члены. Аңлы, акыллы, тәҗрибәле, нык куллы кеше икәне күренеп тора. «Сез» дип кенә эндәшә, гәүдәсе хәрбиләрчә төз, ыспай һәм килешле киенгән. Бите, муены кояшта янып, чуенга әйләнгән. («Кайда посып ятты икән?!») Күзлектән, яңакларын купшы бакенбардлар бизәгән. Тәмәкесен дә ашыкмыйча, һаваланып суыра...

Ул бер нәрсәне дә яшереп тормады, киресенчә, рәхәтләнеп, шуны гына көтеп торган сыман ярсып, һәммәсен ачыктан-ачык сөйләде. Нигә алай? Алар безне беткәнгә исәплиләрме? Исәплиләр икән, нәрсәгә таяналар? Нигә өметләнәләр?

— Әйе. Әзерләдек. Оештырдык. Восстаниены июньдә күтәрергә җыендык. Аннан июльгә күчердек. Хәзер чехословаклар килеп җиткәнне көтәбез.

Хәтәр сүзләр, хәтәр. Үчекләме? Үртәшәме? Күтәрелеп карыйм, каләм тоткан кулым калтырап куя. Юк, җитди, үртәшү уенда да юк. Уйлаганын сөйли.

Сүзе хәтәр, эше аннан да хәтәррәк: Иванов яшәгән йорт подвалыннан егерме револьвер, утыз винтовка, патроннар, гранаталар чыкты.

Капитан да, башка кулга төшкән офицерлар сыман, һавалы, тәкәббер һәм җиңүчән кыяфәттә иде. Ул тайчанмыйча, чирканмыйча «бары тик кабер генә кабул итәчәк партия-совет активының» исемлеген санады, арада минем дә исем бар иде... Хәтере шәп капитанның! «Атарга кирәк сезне!» — диде ул, туп-туры карап. Ул хәзерге көн, узганнар һәм иртәгә киләчәк җиңү турында иренмичә, кат-кат сөйләргә әзер иде ахрысы... Димәк, ул бу хакта бер генә кат уйланмаган, сөйләп, уен да, телен дә чарлаган булса кирәк.

Әйе, ул бүген бездә, сак астында төрмәдә утыра. Гаебе зур. Шул хәлендә дә тайчанмыйча: «Атарга кирәк сезне!» — дип әйтә ала... Мондый дошман белән гел-гел очрашып тормыйсың, сөйләсен әйдә...

— Кешене көнчелек йөртә, — диде ул фәлсәфәгә бирелеп. — Көнчелек, тутык кебек, кешенең акыл-зиһенен кимерә. Сез революция дисез, аның килү юлларында казынып, зарурилыгын исбатлыйсыз. Ә мин гади генә әйтәм: ярлылар артты, байлар аз калды, нәтиҗәдә баланс бозылды. Ярлыларның аз-маз тамагын туйдырсаң, киендерсәң, алардагы көнчелек хисе кимер иде. Шул чакта, көнчелек бермә-бер кимегәч, илдә законлы тәртип бозылмас, бунтлар да чыкмас иде. Хәзер сез тузга язмаган закон чыгармакчы буласыз! «Ярлы алачыкларына гомер, сарайларга үлем!» — дисез... Тормышның дәвамын акыл белән уйласак, алда сез берни дә майтара алмассыз. Гомумтигезлек сездә дә була алмас, көнчелек сезнең җәмгыятьне дә эчтән кимерәчәк. Социаль балanска ирешә аласыз икән — ул чагында эш башка булыр, безнең ялгышларны кабатламассыз, без татыганны күрмәссез. Тик мин аңа ышанмыйм, ышана алмыйм. Көнчелек — кешелек җәмгыятенең мәңгелек юлдашы...

Мин Ивановны бүлдермичә, ахыргача тыңларга теләдем. Ул моның сәбәбен, минем кызыксынуымның серен аңламады, сөйләгән саен кыза барды, үз сөйләгәннәре аңа бик ошый иде. Аның мактануы миңа дошманны ныграк, ачыграк аңларга ярдәм итә иде. Адым саен офицер-философлар очрап тормый, күбесенчә алар ташмаңгайлы, чит кеше ихтыярына карышусыз буйсынып, үзләреннән түбәннәрне дә сүзсез-өнсез буйсындырып кына күнеккәннәр.

— Сез минем бу сүзләрне кире какканны көтәсезме? — дип сорадым мин, капитан тын алган арада. — Юкка көтәсез. Сезнең шапырынуларның ноль икәнен революциядән соңгы шушы кыска гына арада без ил күләмендә расладык инде. Сезнең фәлсәфәдән кабер исе, мәет исе килмәсә, мин аларны шактый кызыклы дияр идем. Ахыр чиктә һәр җүләрлектә дә гыйбрәт бар! Сез дөньяны сүз белән күмергә гадәтләнгән гап-гади бер лыгырдавык икәнсез. Мондый иман белән кая бара алырсыз икән? Киләчәкне томанга төрүне халык кабул итә алмый. Булды, җитте, хәзер төп эшкә күчик: белгән квартираларның адресын бирәсез. Сезнең белән алда ни буласын хәл итәр өчен генә булса да мин барын да белергә телим. Барын да! Демагогиягә таянып кына халыклар язмышын түгел, бер кешенең язмышын да хәл итәргә ярамый. Гәрчә ул кеше явыз дошман булса да! Гәрчә ул кичәге көн кешесе булса да! Сөйләгез!

Ул миңа чынлап торып гаҗәпләнеп карады, мондый борылышны көтмәгән иде ахрысы. Мине бер утын түмәре дип санадымы? Балачага дип белдеме?

— Озак көтәргә вакытым юк, — дидем мин ачыктан-ачык.

Тагын берничә сорау бирдем, утыра-утыра аның һаваланurы кимеде, ул бик теләп, хәтта ашыгып-ашыгып яшерен квартираларның адресларын саный башлады. Язарга өлгереп булмый! Хәтере шәп капитанның!

Кичен, соң гына Лацис янына кереп, көндәлек эшләргә йомгак ясадым.

— Иртүк рапорт язгыгыз да Иванов күрсәткән адреслар буенча оператив группа белән йөреп чыгыгыз. Кем очраса да кулга алыгыз! — дип боерды ул.

Димәк, иртәгә...

31 июль.

Кичәге төпченеп сөйләшүләр, офицерларның кәпәренеп күзгә карап фәлсәфә сатулары, сүз белән күрәләтә җиңәргә маташулары моңарчы без аңышып бетмәгән фактларны ачарга, алар арасындагы бәйләнеш-

ларне билгеләргә ярдәм итте. Көн бушка узмады. Караңгылы-яктылыда торып отчет яза башладым.

«Казанда бүгенге көндә советка каршы дүрт оешма эшли: «Эшсез калган офицерлар союзы», «Генерал Попов группасыннан таралып калган офицер-монархистлар», «Савинковчылар» һәм «Уң эсер калдыклары». 6 июль фетнәсен яклап чыгып теләктәшлек күрсәткән сул эсерлар соңгы төркемгә барып ялгана. Аларның уңмы, сулмы икәнен аеру кыен — советка каршы платформалары бер, тулысынча тәңгәл. Һәммәсен бер максат берләштерә — Совет властен бәреп төшерү. Офицерларның күпчелеге бер командованиегә сүзсез буйсына. Шулар ярдәме белән совет штабларына, гаскәри берләшмәләргә үтеп кергән шпионнары яшерен документларны урлыйлар, корал урлауны оештыралар. Чак кына шик төшүгә эштән качып яшеренәләр. Әлегә аларга яшеренер җирлек бар.

Шәһәрдә фетнәгә катнашырга сәләтле офицерлар оешмасы башында полковник Потчин һәм Сужко(?)лар, подполковник Клочков һәм капитан Иванов торуы документлар нигезендә расланды.

Полковник Потчин гарнизонның артиллерия начальнигы булса, Сужко исә гарнизон штабында хезмәт итә. Соңгы көннәрдә чекага килеп эләккән офицерлар якын араларда үз отрядларының советка каршы күтәрелеп чыгачагын яшермәделәр, чехословакларның якынаюы бу фетнәне җанландырып, аны тизләтәчәк».

Отчетны язып бетергәнче Сажидә апа ясап керткән чәйгә дә кагылмадым, соңгы ноктаны куйгач бәргәләнеп уйландым... «Яшермиләр, димәк, үз көчләренә ышаналар, алдан ук тантана итәләр», — дип отчетка өстәп куярга да уйладым. Уйлана торгач бу уемнан кире кайттым. Аларның тантана көтеп торулары — үлем алдыннан соңгы талпынулары гына түгелме соң?!

Отчетны Мартин Яновичка тапшырдым, ул аны купшы мыекларын сыйпый-сыйпый минем күз алдымда укып чыкты, кулын бирде, оператив отряд алып, кичә мәгълүм булган уникe адрес буйлап эзгә чыктык...

Ни гаҗәп: йортлар буп-буш, кәгазьгә карасаң, бу квартирада Потчин яши, бусында Сужко булырга тиеш... Ләкин без барып кергәндә аларда җан иясен очратмадык. Өченчесенә бардык, дүртенчесе дә кешесез, бу ни хикмәт? Кешеләр яшәгән бүлмәләрдә кеше эзе суынып бетмәгән, кайдадыр самавыр җылынып утыра, квартираларның байтагысында ашык-пошык нидер актарганнар, комод тартмалары ачык; идәнгә өс-баш чәчелгән, аяк киемнәре таралып ята. Сужко квартирасының почмагыннан, идәннән Гайнулла алтын тәңкә табып алды. Шунда да шаярта бит әле:

— Бу тәңкә сезне эзләп килгән, Сергей Сергеевич! — ди.

Хуҗаларны тоташтан кемдер кисәткән булырга тиеш. Әлбәттә, шулай. Уникенең берсе юк икән, бу инде очраклы хәл түгел. Ничек кисәткәннәр? Кем аркылы? Кайчан?!

Мартин Янович янына кайтып кергәндә минем кыяфәт шәп булмагандыр, ул, сизенеп, үткен күзләре белән мине бораулап алды.

— Качканнармы? — дип сорады.

— Берсе дә юк.

— Адресларны һәм аларның бүген кулга алынырга тиеш икәнен кемнәр белә иде?

— Беркем белми. Сез дә мин.

— Кабинетыгыз бикле ме? Протоколлар саклана торган өстәлегез йозаклымы?

— Бикле биклесен. Өстәл йозагы гына ышанычлы түгел. Сейф юк.

— Сезгә адреслар биргән, исемнәрне атаган офицерларны ныграк саклагыз. Һәр изоляторга икешәр сак куегыз. Потчинны күзәтегез. Потчинны!

Бүлмә. Йозак. Янәшәңдә генә, үзең белән бергә хыянәтче барлы-

гын белү жинел түгел... Төне буе йокламыйча борчылып яттым. Һәр адымымны, һәр сулышымны өр-яңадан искә төшерергә тырыштым. Кайда, кем, ничек?.. Йокымсырап ятканда, уйлар йокы белән уяулык арасында гизгәндә зиһенем ачылып китте: кулга алынган офицерлар Сужко, Потчин фамилияләрен бик теләп, хәтта ки ашыгып-ашыгып әйтеп бирделәр, алар шулай итеп, шул юл белән Сужко-Потчиннарның исемен протоколларга керттереп, аларга качарга сигнал биргәннәр була түгелме? Димәк, алар һәммәсе дә минем янәшәмдә генә хыянәтче барын белгәннәр, аның өстәл тартмасына үтеп керәсенә дә шикләнмәгәннәр... Әнә шуңа да алар өстән торып, һаваланып сөйләшкәннәр! Без аларны эләктердек дип куанып йөргәндә, алар мәче белән тычкан уены уйнаганнар. Алар усал тырнаклы мәче булып калган. Ә мин... ә мин... малай!.. Алар үз тарафдарларына «Качыгыз!» дигән сигналны минем аша, минем өстәлем аша биргәннәр!

Уйламыйча ята алмыйм, ә болай уйлау коточкыч авыр иде.

Кем, ничек, кайчан?!

Билгесезлектә бөтен кешедән, хәтта үзеңнән дә шикләнә башлыйсың икән.

Авыр, күңелдән китмәс уйларымнан арыныр өчен мин соңгы вакытларда гел Таня турында уйларга тырышам. Хәзер дә аны күз алдыма тере итеп, җанлы-матур итеп, кайгысыз итеп китереп карадым. Сикереп торасым, чаба-чаба Казанка елгасы ярыннан ерак та түгел боегып утырган тәбәнәк йортка барып җитәсем килде... Кайнар башымны суытыр өчен суга чумар идем, колачлап-иңләп йөзәр идем, кайгыларымны таратыр идем. Фу, тагын арт чүмечем сызлый башлады... Кулымнан каләм төшеп китте. Язганнарымны укып карыйм, танырлык түгел...

Көен дәфтәрем белән сөйләшәм: әллә, чыннан да, Таня янына барып кайтасы инде? Сәгатькә карыйм, уһу, соң икән инде, куркырлар, дөрес аңламаслар... Бераз гына булса да йоклап аласы иде... Бер, ике, өч... Өчне узуга күңел «уникегә» сикерде... Унике квартира буш... Унике дошман качып өлгергән... Йөз һәм меңнәргә тагын дошман өстәлде... Унике... Йөз дә унике... Мең дә унике...

1 август.

Август Казанда иң җылы, иң бәрәкәтле, иң кояшлы ай диләр. Бүген киенгәндә карыйм: тәнем ап-ак, кояш күргән юк... Кемнән ишеткән идем соң мин бу бәяне? Таня әйттеме? Таня бугай...

Революциянең язмышы Казан-Урал-Самара фронтында ак чехларны җиңүгә бәйле икәне фронт реввоенсоветына Лениннан килгән телеграммада ачык әйтелгән иде. Хәзер без — Казанда яшәүчеләр һәм Казанны саклаучылар — Совет власте өчен канлы көрәшнең нәкъ уртасында. Кайчандыр ерак тыл шәһәре саналган Казан — фронт сызыгында...

Август Казанда иң рәхәт, бәрәкәтле ай диләр. Уйнап әйтәләрдер? Казанның хәленә күз салсаң, моңа ышану да кыен...

Гайнулла белән баш ватып утырдык: арабызга кергән хыянәтчене ничек ауларга да, ничегрәк аннан котылырга? Планны бик шәп төзегән идек — тикшерүчеләр, секретарьларның һәрберсенә, берәм-берәм ялган фактлар бөлдереп, кайсысының дошманга мәгълүм булуын күзәтеп торырга иде исәп, әмма аны тормышка ашырырга җай булмады, көне буе контраларны аулап, тотып, сорау алып, бик соң гына кайтып яттым. Каләм тотарга да хәл калмаган.

2 август.

Дошман һаман якынлаша, аулакларда, почмакларда чышын-пышыннар куера бара, сүзләр, сүзләр, сүзләр... Ә тормыш һаман дәвам

итә! Казанда крестьяннарның губерна съезды ачылды. Өч йөзгә якын делегат катнаша (арада фронт сызыгын көч-хәл белән үтеп чыкканнары бар!) — күпчелеге кулаклар. Съездны Шнуровский ачып җибәрде дә Мәскәүдә большевиклар тарафыннан атылып үтерелгән Александрович һәм башка сул эсерлар истәлегенә аягүрә басып бер минут тын торырга тәкъдим кертте.

Чуар кеше бу Казимир Шнуровский! Әле генә шәп тавыш, тантаналы горур кыяфәт белән съездны ачып, кайгылы кыяфәткә кереп матәм ясады, хәзер калтыранган куллары белән куеныннан дүрткә бөкләнгән кәгазь тартып чыгарып, елый-елый, бетәшеп, куырылып үзенең сул эсерлар партиясеннән чыгуы турында белдерүен укыды, мышык-мышык үксеп:

— Сез инде, иптәшләр, башка бер председатель сайлагыз, — дип үтенде. Югарыдан түбәнгә ничек җиңел тәгәри? Чынлыгымы бу аның, әллә уйныймы?

Съездның күпчелек делегатлары — совет властеның дошманнары, күренеп тора. Чырайлары тук, күз кабаклары эчеп шешенгән толпа залны гүләтә башлады. Кем сүз алса, совет властена, большевикларга пычрак ыргыта, беренче ораторлар саграк кыланып, әйләнеп-тулганып төтен җибәреп маташтылар, нәүбәттәгеләр шашынып бәйдән ычкындылар, тора-бара съезд тоташ совет властен сүгүгә әйләнде. Лацис ашыгыч рәвештә Мәскәүгә, Эчке эшләр халык комиссары Петровскийга шалтыратып дошманнар рупорына әверелгән съездны ябарга рөхсәт сорады...

Шул болгавыр көннәрдә «юк-бар уйдырмалар тараткан», Халык комиссарлары советын бәреп төшерергә чакырганы өчен сул эсерларның «Җир һәм ирек өчен» газетасын ябарга» карар кылынды. Съезд көннәрендә бу газета бөтенләй котырынып совет властен хәкарәтли башлаган иде.

Оперативкаларда хәзер Лацисны тыяр хәл юк, янып-кабынып китә:

— Казан камалу хәлендә дип белдерелә. Гаскәри эшелоннар хәзердән беренче чиратта Казанга гына үтәргә тиеш. Әле яшәргә сәләтле барлык хәрби частьлар Казанга тартыла, аларга гомуми җитәкчелек полковник Петр Славенга йөкләнә.

Биш-ун минут эчендә баш әйләнерлек яңалыклар. Берсенә күнегеп тә өлгермисең, икенчесе пешеп-өлгереп алдыңа килеп баса, өстәлә, авырая...

Дошманнарга шәһәр эчендә тын алырга да ирек бирмәскә! Бүгенге көннән «кулга алырга!» дигән ордерларга Лацис, Кин һәм тикшерү бүлеге начальнигы Усватов кына кул куя! Калган имзалар гамәлдә түгел!

Лацис хәйләкәрлеген югалтмый — яңалыкларны берьюлы чыгарып салмый, ул аларны билгеле бер тәртип белән, дәрәҗәләренә карап сөйләп бирә, иң хәтәрләрен азакка калдыра. Бүген дә җитди хәбәрләрнең җитдиен ахырга калдырган.

— Меньшевиклар партиясе Үзәк комитеты члены Майский белән уң эсер Зензиновның Казанга килүе турында хәбәр бар. Тотарга иде аларны, кулга алырга!

Мартин Янович шулай диде дә миңа карады. Гайнулла белән янәшә утыра идек. Таһиров миңа пелебрәк: «Ярый ла бу боерыкны Зензиновка хәбәр итеп өлгермәсәләр!» — дип пышылдады.

Ике сугышчы алып Зензиновны эзләп киттек. Муравьев ук булмаса да, Зензинов шактый билгеле адәм, гаугалы җан.

— Зензинов 1904 елдан эсер, — дип аңлаттым мин Гайнуллага. — Байтак террор актларына катнашкан кеше. Үзе галим, этнограф.

— Этнограф? — дип сорады гаҗәпләнеп Гайнулла.

— Сөргендә чакта якутлар тормышын өйрәнеп, аларның көнкүреше, гореф-гадәтләре турында файдалы китап язып чыкты. Хәзер исә

совет властенең иң явыз дошманы.

— Сергей Сергеевич! — диде Гайнулла туктала төшеп. — Шуны аңлатыгызчы, зинһар. Нигә белеме югары булган саен кешенең дошманлыгы да зуррак була?

— Раифада безнең иптәшләрне яндырганнар югары белемлеме? — дидем мин сорауга каршы сорау куеп. — Я?

— Юк ла! Крестьяннар кемнеңдер явыз коткысына гына бирелгән!

— Дошманның һәммәсе дә дошман!

— Сез элгәре алай дими идегез...

— Дошман үзгәргән саен безнең аңа булган мөнәсәбәтебез дә үзгәрә, Гайнулла.

Егет уйчанланды, артыгын сорашмады... Бер урында булдык, икенчесенә кагылдык, Зензинов булырга мөмкин дип санаган байтак җирләрне айкадык, Мәскәүдән килгән «кошны» очратмадык... Иртәгә тагын эзләргә кала. Аны табарга кирәк! Ифрат куркыныч кеше! Лацис булып Лацис, мине алтын озату эшеннән аерып Зензиновны эзләргә җибәрә икән — аны тотарга кирәк! Башкача булуы мөмкин түгел. Төсен-битен үзгәрткәндер, документлары да сансыздыр аның, ә бәлай... гостиницаларда юк, ресторан-кафеларда күренми. Аның тәмле ашарга, салырга яратуы турында бездә хәбәрләр бар. Тәтәйләрне дә чит куймый икән әле...

3 август.

Иртән Лацис безне әрләргә тотынды: «Шундый кошны ычкындыргансыз!» Гаеп бездәме? Күреп бетермәдекме?.. Бу якка озак тукталырга вакыт юк иде, Лацис артыгын сузмады, яңалыкларын тезә башлады. Бүгеннән фронт тирәсендә буржуаз газеталарны тарату катгый тыела. Таратучыларны туп-туры чекага озатырга. Барлык коммунистлар һәм җаваплы совет хезмәткәрләре бүгеннән корал алалар. Чехословаклар Спасск белән Тәтешне алганнар, мичман Ершов кул астындагы флотилиянең аерым, аръергард кораблары Кама Тамагы тирәсендә күренгән.

«Знамя революции» газетасындагы бер мәкаләгә Лацис бармагы белән төртеп күрсәтте:

— Укыгыз.

«Чехословакларның ябырылуы ВЦИКны «Социалистик Ватан куркыныч эчендә!» дип игълан итәргә мәҗбүр итте. Курку, каушау, җебегәнлек, көчсезлек бетсен! Сугышырга хәле бар һәркем, һәрберегез, кулыгызга корал алып, англо-француз капиталы ялчыларына каршы көрәшкә чыгыгыз!» дип язылган иде анда.

Лацис сакалын учы белән йомарлый-йомарлый безгә карап ала. Димәк, яңалыклары бетеп җитмәгән... Безне тагын ни көтә?

— Зензинов... — Бу урында Мартин Янович бармаклары белән өстәлне кагып-кагып алды. — ...үткән төндә чит фамилия белән Щетинкин номерларында кунып чыккан!

Менә сиңа мә! Кунып- яткан... Бүген кайда икән кәҗә сакал?! Кем исеме белән үзенең мәкерле пәрәвезләрен корып йөри?..

> Враг могуч и хитер! По местам! По местам!
> И настроже око и ухо;
> Бой повсюду пойдет, по земле, по морям,
> и в невидимой области духа...

Кайчандыр бу шигырьне Зоряга укыган идем... Арбаттан ерак та түгел, тар тыкрыкта, яфраклары саргайган карт юкә ышыгында икәү генә басып торган идек... Ә хәзер шигырьнең тапкыр юллары нәкъ үз тормышыма туры килә... Зоря исемә төшеп, йөрәгем сулкылдады... Мин

тынып, онытылып китсәм, Гайнулла сорашып-төпченеп тормый, белә, мин акрын гына үткән көннәргә агам... Әйе, җирдә-суда гына түгел, дошман хәзер үнда-сулда, алда-артта. Шагыйрь дошманның ин куркыныч биләмәсен төгәл билгеләгән: «Күзгә күренми торган рухта — күңелдә».

Дошманны аннан да табып алу безнең — чекистларның бурычы... Әләгерсең, Зензинов!

4 август.

Йокысызлык, тынгысызлык, борчылу-мәшәкатьләр... Бүген башым авыртып уяндым. Сажидә апа җиләк, карлыган яфраклары йөздереп куе чәй ясап эчертте. Әллә аның кулы шифалы, әллә тәмле-ягымлы сүзләре ярдәм итте, чәйдән соң, җиңеләеп аякка бастым. Алай да эшкә бераз соңарып килдем.

— Йоклап ятарга ярамый! — дип каршылады мине Лацис, тиз үк иптәшләрне җыеп, бүген төнлә үзе иҗат иткән крестьяннарга мөрәҗәгатен укып чыкты.

«Шикле бер-бер хәл яки җинаять турында сизенсәгез, төн димәгез, көн димәгез, шунда ук чекага хәбәр итегез. Туп-туры секретарьга керегез, ул сезне яшерен бүлеккә озатыр. Эчке дошманнар турында белгәнегезне шунда сөйләрсез. Казан кешеләре һәм якын-тирәдә яшәүчеләр өчен адрес: Гоголь урамы, 28 нче йорт. Башка очракларда җирле советларга килегез. Иптәшләр, дошман уяу. Сак булыгыз! Совет властеның язмышы һәм киләчәге сезнең кулда!»

Оперативка бетүгә Мартин Янович мине үз янында калдырды.

— Үзегез белән кемне аласыз? Хәзер Казаннан алтын озату юлын тикшерергә барабыз.

Главком Вацетис, Лацис, Гайнулла Таһиров һәм мин нәни генә пароходка төялдек. Борын белән койрыкка латыш укчылары кереп утырды. «Күзгә чалыныррлык булмасын!» — диде Лацис, пароходка да уравыч юллардан, пакгаузлар, ярда янтаеп яткан иске көймәләр арасыннан берәм-берәм узып кердек. Кузгалып шактый бардык. Безнең пароход каршыга йөзгән көймәләрне дә әйләнеп үтәргә тырышты. Иделне кичеп чыгып, Югары Ослан ягында тукталдык. Вацетис гел палубада булды, аягүрә басып тирә-якны күзәтте, сәгатенә карый-карый куен дәфтәренә нидер сызгалап та барды.

— Тау башына берничә батарея куйсаң, Казанга бернинди пароход та якын килә алмас иде! — диде ул Лациска Ослан тауларын күрсәтеп. Алар Лацис белән тагын нидер киңәштеләр, без артык юанмадык, тагын кузгалып киттек... «Батарея куярга җайлы урыннарны главком бүген генә күрде микәнни соң!» — дип сызланды күңелем... Пароход ярга якын гына барганда, Вацетис белән Лацис кай урыннарга сакчылар куеп, кайсы тирәгә кораллы катерлар җибәрергә дип билгеләп, киңәшеп бардылар. Свияжск тирәсеннән кире борылдык.

Без кузгалып киткәндә тын торып калган диярлек пристаньне халык көтүе сарган иде, чамадан тыш гөжлиләр, тарткалашалар, ызгышалар. Түбәннән әлерәк кенә пароход килеп туктаган да, бүселеп ярга чыккан пассажирлар авызларын тыя алмыйлар икән. Бераз тыңлана-сораша торгач аңладык, алар Кама Тамагы тирәсендә безнең флотилиянең аклар белән сугышта җиңелүенә шаһит булганнар икән!

— Күпме паника алып керә инде болар шәһәргә! — диде Лацис үкенечле тавыш белән.

— Әйе, — дип килеште Вацетис. — Җиңү халыкның рухын нығыта, ә җиңелү...

Икесе дә иңнәрен сикертеп куйдылар.

Дошман бар көченә Казанга ыргыла...

Вацетис кичен Мәскәүгә хәбәр житкерде: «Дошман флоты, 4 ав-

густта безнең сугышчан флотилиягә һөҗүм итеп, аны Идел буйлап югарыга качарга мәҗбүр итте. Идел ярларында ике яклап та дошман пехотасының хәрәкәте күзәтелә. Кама Тамагы дошман кулында».

Йөреп кайтуыбызның алтынны озатуга файдасы булырмы, хәзер һәр сәгать узган саен шигем арта бара, белмим, мәгәр Вацетис Югары һәм Түбән Осланнар тирәсенә батареялар меңгереп куярга боерып, Казан ярлары тирәсендә берничә баржа батырырга кушты. Ул Көнчыгыш фронт гаскәрләренә дошман һөҗүмен тыеп торыр өчен ныктан-нык торырга приказ арты приказ озатып, Үзәктән Казан өчен өстәмә көчләр сорады. «Ирекле Россия» бронепоезды начальнигы Романов, тимер юл күпере янында тукталып, күпер аша дошманны үткәрмәскә дигән катгый боерык алды.

Безне Лацис белән партия комитеты утырышына чакырдылар.

Утырышны Шейнкман алып барды.

Сүзләр күп булды дип әйтә алмыйм, моментның хәтәрлеген истә тотып, һәркем кыска сөйләргә тырышты. Казанны саклап калу икеле булганга, комитет мондый карар кабул итте: «Алтын запасын шәһәрдән озатырга. Алып китә алмаган хәрби кирәк-яракларны, дошман кулында калдырмас өчен, юк итәргә. Казанда ышанычлы кешеләр калдырырга».

Үзебезгә кайткач Лацис миңа болай диде:

— Яшерен эш алып барырга, диверсион актлар оештырырга тиешле чекистларның җитәкчесе итеп 1905 елдан партия члены Михаил Ендаков кала.

Ендаковны беләм, бездә күптән эшләмәсә дә, яхшы иптәш итеп танытты, эшче- металлист.

— Аның белән бергә эшләү өчен шәһәрдә сез, тагын Николай Городецкий, Иван Шулаков һәм Гайнулла Таһиров каласыз...

Мин Гайнулла янына ашыктым.

— Димәк...

— Тагын бергә! — диде ул сөенеп.

Без утырышларда йөргән арада ул туктаусыз Зензиновны эзләгән икән.

— Барыбер табам мин аны, — диде Гайнулла үҗәтләнеп.

— Нигәдер Зензинов белән мавыктың әле син!

— Мин юньләп укый алмадым дисәң дә ярый. Гафур абый школасына ике ел йөреп калдым. Алай да акны карадан, дусны дошманнан аера беләм. Ул бит, ул бит... галим! Якутлар тормышын өйрәнгән. Халыкның көнкүрешен. Шунда ярлы белән байны, ачлык белән тук-лыкны аера алмаганмы? Күзе нилектән сукырайган аның! Беләсем килә...

Бераздан Гайнулла елмаеп куйды:

— Тагын бер яңалыгым бер, Сергей Сергеевич!

Мин:

— Мартин Яновичка ияреп, син дә яңалыкларны дәрәҗәсенә карап эзгә сала башладыңмы? — дип сорадым.

— Яңалыкның да нинди әле! Мулланур Вахитов Казанга кайтты! Аның белән бергә Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе членнары да килде. Гаҗәп кеше ул Мулланур абый! Минемчә, хәзер Казанның контрреволюция белән көрәштә үзәк урын тотканын белеп, аны безгә Владимир Ильич җибәргәндер.

Аның эчкерсез сөенүе миңа да йокты...

Димәк, яшибез...

Димәк, тагын бергә...

Димәк, безгә дә Зензинов кебек яшеренеп яшәргә кала. Урыннарны алышабызмы? Зензинов хәзер Гайнулла Таһировны эзәрлекли башлый... Миңа ашыгыч рәвештә Таняны күрергә кирәк... Яшәр өчен урынны аннан башка табып та булыр иде, мәгәр аның белән киңәшү хәерлерәк.

5 август.

Чех Швец житәкләгән дошман флотилиясе, ниһаять, Казан тирәсенә килеп житте... Коралды алты пароход, ярдәмче унбиш судно... Аларга ике мең акгвардияче һәм легионер төялгән. Туплар, пулеметлар, башка кораллар... Ә аларны Казанда күпме теләктәш көтә? Ни көтә?

Шәһәр өстеннән сызгырып беренче туп ядрәләре очты. Аклар Үсиягә десант төшерергә маташтылар, бер үк вакытта стратегик мөһим пункт — Югары Осланны алыр өчен махсус отряд җибәрделәр. Безнекеләр, ышттырдап, Югары Осланга батарея урнаштырып өлгермәделәр, командирлары — Казан губернасының беренче финанс халык комиссары Скачков һәм тупчылар батырларча сугышып һәлак булды...

Десант уза алмады, аны авырлык белән генә кире бордылар. Латыш укчылары, Бишбалта эшчеләре һәм 1 нче татар-башкорт батальоны сугышчылары дошманга юл бирмәделәр.

Вацетис Свердловка телеграмма сукты: «Дошман Казанны утка тота. Любимов пристаньдә десант әзерли. Ярдәмне ашыктырыгыз».

Куркыныч артканнан арта барды, хәл тоташтан үзгәрде, алтынны кузгату да, күчерү дә гаять читенләште. Финанс контролеры Доброхотов миңа Андрушкевич һәм Измайлов кул куйган расписканы күрсәтте. «Совнарком председателе Ленин һәм фронт башкомандующие Вацетис приказы белән Казаннан күчерер өчен 1200000 сумлык алтын акча тутырылган егерме тартма кабул итеп алынды».

Бары шул. Шул гына. Кем гаепле моңа? Әйтүе кыен. Аңлату гына түгел, аңлау да читен. Дошманнар, без көткәнгә караганда, тизрәк килеп өлгердеме, әллә икеле-микеле фикерләргә нигезләнеп акрын кыймылдадыкмы, белгән юк. Әле «Күчерәбез!», әле «Күчермибез!», «Казанны калдырабыз!», «Калдырмыйбыз»... Сүз, сүз, сүз... Ә хәзер дошман кулында шәһәр кала, алтын кала...

Вакыт аз калган иде. Банк подвалларыннан чыгарып алтынны йөккә төяргә, җиде чакрым узып Үсиягә кадәр алып барып баржа трюмнарына кертергә... Сиксән мең пот алтын-көмеш, ягъни 1280 тонна. Безнең кулда нибарысы дүрт автомашина. Һәркайсы икешәр тонна йөк ала... Бару, кайту, төяү-бушату, яңадан төяү — өч-дүрт сәгать вакыт узачак... Димәк, көнгә утыз ике тонна йөк озата алабыз... Һәр рейсны күз карасыдай сакларга кирәк. Ә юлда ул-бу чыгып куйса? Бандитлар һөҗүм ясаса? Рыбнорядск мәйданыннан банк янына кадәр трамвай линиясен сузарга дигән ният тә булды, анысына да өлгермәдек. (Хәзер уйлыйм — иң дөрес һәм иң ышанычлы юл шул булган!)

Дошман пароходыннан туплар ата башлауга ук алтын алырга килгән буксир-баржалар берәм-берәм кузгалып китә башладылар. Дошман пароходларының берсендә пожар башланып, башкалар чигенә төшкәч кенә, кичкырын элек торган урыннарына әйләнеп кайттылар. Банк ишегалдына кергән грузовикларга тиз-тиз генә алтын тутырган капчыкларны төяделәр дә Үсиягә озаттылар... Күчерүне алтынчы август иртәсеннән яңартырга уйлап куйсак та дошман пароходлары утыннан курыккан баржалар төн караңгылыгыннан файдаланып китеп тә бардылар. (Китүләре дөрес тә булды, иртәнге тугызда пристаньне аквардиячеләр басып алган иде инде!)

Иртәгәсе көн ни күрсәтер?

Бәлки, чыннан да, Казанны дошманга бирмәбез? Өстәмә көчләр килеп җитәр дә...

Төне буе аяк өстендә булдым. Югары Иделдә тар-мар ителгән акларның калдыклары Казанга борылган! Бу турыда хәбәр алынгач, өмет тагын да азайды. Савинков үзе дә монда киләчәк икән! Менә кемне эләктерергә иде! Зензиновны һаман сагалап йөргән Гайнулланың ике күзе - утлы күмер кебек яна башлады. Бүген көн дәвамында байтак офицерларны кулга алдык...

6 август.

Казан камалышта. Шәһәрдә комендант вакыты кертелгән. Урамда жыелулар тыела! Буйсынмаганнарга үлем җәзасы! Контрреволюциянең һәр чыгышы, паника тарату, совет властена каршы өндәү шулай ук үлем җәзасы белән хөкем ителә.

Иртәдән үк яңгыр сибәләп торды. Себерелмәгән урам тузанын басты. Күк күкрәгән тавышларга туплар атышы кушылып китте. Ядрәләр бер-бер артлы Казанга ява...

Коммунистлар клубында Назар Ежов эшчеләргә өч меңгә якын винтовка һәм патроннар өләште. Большевистик эшче отрядларны Касыймов, Павлюхин, Фролов һәм Шәфигуллиннар пристань ягына алып та киттеләр. Анда байтак иптәшләр һәлак булган инде...

Чека тәрәзәсе янында басып торам. Тонык кына күк күкрәде. Купшы сакалы киезләнгән, маузер кобурасын тезе өстенә чыгарып салган Лацисның тагын бер яңалыгы калган икән әле.

— Өстәмә көчләр килеп җитә алмый, аларны Свияжскида тоткарлаганнар, — диде ул.

Кем тоткарлаган дип сорыйсым да килмәде, хәзерге минутта аның әһәмияте юк иде: барыбыз да өметләнгән, дүрт күз белән көтеп торган өстәмә көчләр шәһәргә килеп җитә алмаячак. Хакыйкать шул гына, аянычлы, рәхимсез хакыйкать, шуның нәтиҗәсендә реввоенсовет кичке биштә Свияжскига күчә, коммунистлар сәгать җидедә китә — без Казанны калдырабыз...

Тиешле җитәкчелек булмаган хәлдә дә шәһәр батырларча сугыша иде. Акларның беренче колоннасы иртән иртүк Каппель җитәкчелегендә Большие Отары янына килеп җитте һәм, Югары, Урта Кабаннарны узып, Суконныйга бәреп керде. Урам сугышлары кызды, анда да, монда да янгыннар башланды. Икенче колонна исә Яңа бистә аша үтә башлады, өченче колонна Үсиядән шәһәргә таба ыргылды, бөтен якта дошман, бөтен яктан аталар иде шикелле...

Исән калганнар бу турыда язмый калмаслар, мин үзем күргәннәрне яки ышанычлы кешеләрдән ишеткәннәремне генә теркәп узам. Латыш укчылары белән Мөселман коммунистик отряд сугышчылары дошманны батырларча кырганнар, һөҗүм артыннан һөҗүмне кире кайтарганнар...

Ниһаять, мин япа-ялгызым калдым... Иптәшләр алдан билгеләнгән, тәгаенләнгән урыннарга таралдылар. Мин, өс-башымны алыштырып, банк тирәсенә киттем. Андагы хәлләрне күз алдына китерергә мөмкин түгел иде... Беләм, иртән банкны латыш укчылары саклады... Акгвардиячеләрнең һөҗүме киңәя төшкәч, латыш укчыларын ут сызыгына — шәһәрне сакларга чакырып алдылар. Озакламый, аз санлы сугышчыларын иярТеп, алгы сызыкка Мөхәммәтсадә Корбанаев та китеп барды... Алар банкка якынлашкан урам сугышларында катнаштылар... Алардан соң инде банк тирәсендә сак калмаган да диярлек... Мин банк янына халык ташкынын көч-хәл белән ерып үттем... Банкның тимер капкасын каерып ачып ташлаганнар, ишегалдында дүрт-биш сакчы штыкларын курка-курка гына алга сузып халык ташкынын буып торалар иде. Шушы кадәр халыкның берсүзсез, дәшми-тынмый гына һаман эчкә таба ыргылуын котым чыгып күзәттем. Күзләр шашып акайган, муеннар сузылган, терсәкләр туктаусыз хәрәкәттә, Зур Проломный урамының ике ягыннан ябырылып килгән халык ишегалдына кереп өлгергәннәрне кыса, кысрыклый, пыскаклап яуган яңгыр меңләгән җилкәләрдән пар булып күтәрелә. Бер почмакта тыгыз йодрык булып офицерлар, сул эсерларның боевиклары укмашып тора. Алар әле берни дә эшләмиләр, ишегалдын дыңгычлап тутырган комсыз күзләрне ашардай булып карап торалар. «Кызылларга ашыгыч ярдәм килә!» — дигән хәбәр тоткарлыймы аларны, әллә башка нәрсә көтәләрме?.. Нигә халык дулкынын артка аудармый алар, нигә?! Әллә кызыллар ал-

тынны калдырырга ризалашмаслар, хәзер, хәзер килеп житеп хәзинәне алып китә башларлар дип көтәләрме? Карышачакларлы, алтынны бирмәскә тырышачакларлы? Иң почмакта брезент белән томаланган пулеметларны абайлап калдым. Ул арада халык төркеме банк сакчыларын изеп-сытып тагын да алга ыргылды. Кемдер чинап җибәрде, алдагы рәтләр, бер-берсен дәртләндереп, терсәкләрен тагын да тизрәк йөртә башладылар.

— Алтын!..

Шул чакта мин алгы рәтнең иң алдында торган ике кешене танып алдым... Аларның берсе Флегонт Клепиков булса, икенчесе мәгълүмегез Константин Петрович Винокуров иде...

Флегонт Клепиков — күрер күзгә йодрык хәтле генә, бөжыр кебек житез офицер — безнең шәһәргә Ярославльдән килеп төшкән дигән хәбәрләрне байтактан алсак та, үзен очрата алганым юк иде. Менә кемдә яшеренеп яткан да, менә кайчан якты дөньяга чыккан икән!.. Клепиков Винокуровны ияртканме, әллә киресенчәме?.. Ул арада Клепиков банк идарәсе ишегенә кереп югалды һәм бер минуттан әйләнеп тә чыкты. Халык «ах» итеп куйды. Клепиков кулында ачкычлар иде. Почмак якка бөялешкән офицерлар сагайдылар, әмма бер сүз дә дәшмәделәр. Таза-таза ирләр, бер сулыштан алга ыргылып, мине бер читкә алып ыргыттылар, яраланган арт чүмечем дә, пуля тишеп узган иңбашым да үтереп сызлый башлады, мин бер минутка гына аңымны югалттым. Таш стенага ничек килеп сөялгәнмендер, исемә килгәндә банк ишекләре ачылган, халык котырынып банк подвалларына ташланган иде... Банк ишеген ачсалар да, сейфлар салынган подвал ишекләре бикле иде. Берлинның иң атаклы осталары койган тимер ишекләр үкчә белән төйгәнгә генә бирешмәделәр. Флегонт Клепиков ишек алдына чыкты, коеп яңгыр ява иде, аның сирәкләнгән саргылт чәче маңгаена сыланып ябышкан, күзләре акаеп каткан, куллары туктаусыз хәрәкәтләнә иде.

— Ачкычлар управляющийда! — дип кычкырды аңа Винокуров.

— Беләм! — диде Флегонт һәм банк йортына ук урнашкан управляющий квартирасына чапты. Шунда гына аңлап алдым: җыелган офицерлар, эсер боевиклары банкны халыктан талатырга уйлыйлар икән! Кызыллар алып китүгә караганда, әйдә, алтынны казанлылар көрәп калсын. Кызыллардан алырмын димә, ә халыктан... алда күз күрер! Шуның өчен алар кул кушырып, бер нәрсәгә катышмыйча басып торалар. Флегонт Клепиковны да, шул талау эшен башлап йөрергә дип, үзләре котырткандыр әле...

Көндезге сәгать бердән сәгать өчкә кадәр, ике сәгать дәвамында, казанлылар банкны таладылар... Әгәр бормалы баскыч артык текә һәм тар булмаса... алтын тутырылган капчыклар җидешәр катлы киштәдә, өстә сакланмасалар, белмим, банк подвалларында нәрсә калыр иде икән? Ә болай... төшеп өлгергәннәр менә алмады, алар тар борма баскычта бөялешеп, сугышып, ызгышып, бер-берсенең бугазын чәйнәп бик озак маташтылар... Ах, андагы чинау тавышлары... Ах, андагы тартышлар... Винокуров та, Клепиков та күздән югалдылар... Мин, көчсезлегемнән гарьләнеп нишләргә белмичә бер урында калтырап-дерелдәп торганда, тагын бер таныш кешене күреп калдым... Әйе, бу ул — Таняның әтисе иде... Кулында чиләк... Чиләге дә буш түгел иде сыман, бөгелә-сыгыла халыкны ерып бара...

Көндезге сәгать өчләрдә банк урнашкан урам, якындагы мәйданнар аклар кулына күчкәч, бу тирәгә җиңнәренә ак тасмалар бәйләгән гаскәриләр отряды килеп житте. Болары моңарчы идән астында качып-посып яткан контрреволюционерлар иде. Баштанаяк коралланган утызлап кеше очраганнарны бәреп-сугып ишегалдына бәреп тә керделәр, хуҗа булып та алдылар... Китәргә вакыт житкәнен аңлап, мин дә тиз-тиз халык арасына кереп эредем...

Яшеренеп яткан акгвардиячеләр кич белән, шәһәр тулысынча аклар кулына күчкәч кенә, батыраеп урамга чыкканнар. Мин горурланып уйладым: шактый өркеттек шул без аларны! Кызыллар шәһәрне калдыргач кына фетнәчеләр күтәрелеп чыгарга баздылар!

Ул көн авыр истәлекләргә бай иде...

Бер төркем укчылар белән Вацетисның Фронт штабыннан китүен күреп калдым. Кыяфәте алай егетләрчә иде дип әйтә алмыйм... Бу хәл августның алтысында, кичке сәгать сигездә иде.

Лацис, Бакинский һәм башкаларны вокзалга күз белән озаттым... Лариса Рейснер белән Софья Шейнкманның шәһәрдән китүенә дә шаһит идем. Шушы дәһшәтле ыгы-зыгыда икесе дә ирләрен югалткан батыр хатын-кызлар!

Качакларның яңгыр астында, тездән пычракка батып, сүрән йөзләрен җиргә иеп, Свияжск ягына китүләрен күргәч, Лариса Рейснер:

— Чехословакларның «азат итүеннән» качалар инде болар! — дип куйды һәм әрнеп: — Бу колоннада бөтен Россия! — дип өстәде.

Сәгать тугызда Грузинский урамы буйлап шәһәр байлары, чиновниклар узды. Алар җиңүчеләрне котлап ипи-тоз тотканнар иде. Чиркәү чаңнары бердәм телгә килде. Кагалар, кагалар... Әмма аларның тоташ чаңын басып, көмеш тәре таккан руханиларны, капкорсак байгураларны ике якка чәчеп уртадан йөк машиналары узды... Алтын илтеп Үсиядән кайтучылар!.. Коммунистлар клубы бинасы чарлагыннан пулеметлар ут сипте...

Безнекеләр китте...

Мин, иптәшләрем белән, алар тизрәк шәһәргә борылып кайтсын өчен монда калдым...

Арып-талып, чыланып, ашамаганга хәлсезләнеп, караңгы төн уртасында Танялар капкасына кагылдым. Шауламыйча гына кердем, минем арттан капка да өнсез-авазсыз гына ябылды...

Беренче китап тәмам

# Зиннур Мансуров

## Ярымшарлар

Ибне Сина варислары
аңлатадыр: «Бел, кеше!
Сөенергә әмер бирә
миеңнең сул өлеше...»

Менә кайчан, елмаешып,
дөнья ал да гөл, дибез.
Ә уң ягы белән, димәк,
көенәбез, елыйбыз.

Кешелекнең табиблары
шул хакта да уйлыйдыр:
кайсы ярымшары белән
елмая һәм елый Жир?..

## «Диңгезне яндырам!..»

Ышанмагыз бытбылдыкка —
гадәтенчә, лаф ора.
Әмма шушы чеп-чи ялган
Йөрәгемне яндыра...

Хәтта арыш камчысы да
бәгырьләргә сызыла.
Күктән безне күзләп тормый
көянтәле кыз гына...

Жирдә үскән утчәчәккә
чыкмый багар җай бер дә —
янар таулар, канатланып,
күктә очкан дәвердә.

«Диңгезне яндырам!..»

---

ЗИННУР МАНСУРОВ (1949) — шагыйрь, «Кул бирәм», «Йөз суы» (Татарстан китап нәшрияты), «Тысячелистник» (Мәскәү, «Современник») исемле шигырь китаплары авторы. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә эшли. Казанда яши.

Әгәр Жирең әверелсә
утлы яшен ташына,
килүчеләр табылмастыр:
«Калдымы,— дип,— аш миңа?»

...Ышанмагыз бытбылдыкка —
этәчләнеп, лаф ора...
Шушы ялган күпме җанның
тынычлыгын качыра.

## Куркылык

*Борынгы ырым-ышануларга караганда, татарлар, берәр нәрсәдән бик каты курыксалар, эретелгән кургашынны суга агызып, куркылык койганнар. Төрле рәвештә оешучан әлеге кургаш, имеш, кеше кыяфәтендә дә ката икән. Шуннан соң аны курыккан кешегә таккаплар, шулай итсәң, чир китә дип уйлаганнар.*

Яралардан чәйнәп төкерелгән
барлык кургашларны бер итеп,
ташып торган кан-яшь дәрьясына
салып булса икән эретеп...

Канда күбеп беткән кара кургаш
катар иде нинди сурәттә?
Җиңү алиһәсен хәтерләтер
башсыз сындай?! —
Булмый юрап та.

Пәйда булыр, бәлки, иләмсез зур,
гөмбә кыяфәтле зур болыт?!
Имләү түгел, үзе йөрәксезгә
әйләндерер мондый куркылык.

Мондый бөти-имне күтәрергә
көче җитмәс хәтта Җирнең дә...
Ә шулай да нинди бәйләнеш бар
кургаш белән курку чирендә?

Им-том гынадырмы?
Борынгылар
саклый бирсен, әйдә, сер итеп.
Куркусызлар йолдыз итеп тага
кургашынны канда эретеп...

Яуда юлбарыстан көчле халкым
күпме койган шундый «куркылык»!

...Оешмасмы утлы кургашлардан
гөмбә кыяфәтле зур болыт?!

Куркырлык...

## Сызлаулы хәтерне яңарту

Күтәрелеп Кече манарага,
тарих төпкеленә төшкән бар.
...Эскәнҗәдәй кысып язмышларны,
идән булып иңгән түшәмнәр.

Хакимият илаһ кыяфәтле
ташваткычның үзен он иткән!
Болгарымның көле
борынгыда
гөл булганын әллә оныткан.

Чәрдәкләнеп беткән таштабакның
китегендә тере нур калган!
Оешмасмы җырлы тәлинкәгә?! —
ярчыкларның
кайсы янган, кайсы урланган...

Вәхшилекләр күрдем —
культуралы
катлам читен бераз ачтым да.

...Каендагы карга оялары
һаман тора кояш астында.

## Яшәүнең бер хикмәте

Чулман яры. Бер кыз аулактарак
салып тора кысан күлмәген.
Күтәрелә алмый бәргәләнгән
аккош итеп күрдем шул мәлен...

Дирбиясен җил дә салдырыша,
аяк буйлап төшә — тач тышау!
Еллар аша карыйм: үзебезнең
Алабуга кызы На-дю-ша!..[1]

Егерме өч тулган көнне, әнә,
толымнарын кисеп ыргыта;
атлы казак булып киенә дә
ирексезләп үзен... ир итә.

Һәм кушылып китә Сарапулдан
яуга сәфәр тоткан чиругә.
Ир-атларга камыт кидерерлек
кызга менә шундый чир йога.

Ирдәүкәлек өчен үртәлүле
җанын телгәләүче уй-гамьнән

---

[1] Дурова Н. А. (1783—1866) — Россиядә рус хатын-кызларыннан беренче офицер, язучы.

йөрәгендә әллә атай каны
галибанә ярсып уянган?!

Күлмәгенә сыймас гыйсъянчыны
миргә алып чыккан хөр уе.
Куркынычтыр язган тәкъдиреңә
күкрәк белән каршы торуы.

Кызыкайны ияр ястыгына
Дөнья абзый каты утырткан!
Канкайларын түгеп егетләрчә,
эчкә никадәрле ут йоткан.

Язмышбикә сөйми
итәгенә
зәгыйфь затның зәһәр басуын.
Нинди хикмәт чыга кызлар кулы
кысып сыккан чакта таш суын?

Гомеренең алтмыш әйләнәсе
ирләр өммәтендә узылган.
Ялгызлыкта ниләр кичергәнен
сөйләп бирә алмас сүз белән.

Картлык баскач, хәлсез калгач кына
асылына кайтып егылган.
Хатынлыгын тәмам онытканда
әллә егетлеге юк булган?!

...Чулман яры. Бер кыз аулактарак
күлмәк салып тора — әт-тә-тә!..
Әллә, сеңлем, синең эчеңдә дә
иярләнгән ярсу ат ята?

Теләгәнең Гыйффәт туташлыкны
күздән яшерми дә бирелер.
Төшенсәңче бөек хакыйкатькә:
татлы (татлы!) дошман ир булыр...

Иңнәреңдә күтәр яшәешнең
өлешеңә тигән шул гамен.

...Чулман яры. Бер кыз аулактарак
салып тора кысан күлмәген...

●

Өлкәннәр ямьсез елый...

Онытканнармы —
бала чакта,
кояшлы кыска яңгыр төсле,
бит алмасын юып алуларын?!

Өлкәннәр ямьсез елый,
әллә ничек чырай сытып...

Күз яшьләре
авыз читенә сузылып төшкән сырларны,
вакыт-эрозия тирәнәйткән
җыерчыкларны өтеп аламы?!

Өлкәннәр ямьсез елый,
хәтта сөенечтән дә...
Килешми —
теле белән әйтә алмаганны
елап аңлатучы
сабый кыяфәтенә керү...

Өлкәннәр ямьсез елый,
өлкәннәргә елау килешми.

Шуңадыр да олыгайган саен,
җир астына киткән дәрьядай,
күз яшьләре эчкә йотыла бара,
эчкә —
күңел күзенә...

## Кайтавазсыз урманда борчылу

Кабатлыйбыз уйламыйча:
урман булмый киексез...
Киексезгә әйләнмиме —
карагызчы килеп сез.

— Ур-ман бул-мый ки-ек-сез!..

Урман җавап бирә иде
берне түгел — йөз, меңне...
Хәзер инде кайтавазы
җөпләмәстер сүземне.

Шүрәлеле урманнарда
бүген киек аз нигә?

Мәкальләрне үтерәбез —
менә шундый фаҗига...

## Көшел өстендәге көрәк

Таш дәвере,
бронза,
тимер...

Чордан чорга, көрәп-өеп,
ул үзенчә юл саба.
Баштанаяк агач кына,
агач кына булса да...

## Байконур рәсеменә штрих

Ак күбеккә батты очкыч —
(Җир белән Күк тартышы!..)

Еракта бер чабан уйлый:
«Күпме шунда ат көче?..»

## Җиләк кагы

Жырның моңы гына калды:
«Җиләк җыям, как коям...»
Әллә сөю рухы өчен
агып китте такыяң?!

Адаштырып калдырмакчы
идем сине йөрәктә...

Бергә койган җиләк кагы
ачы булды бигрәк тә.

## Төсмер

Бер ишарә кешеләрне
зур иткән һәм хур иткән.
Нинди төсмер белән әйттең:
«Акылың алтын икән,— дип,—
акылың алтын икән!..»

## Җиләк бердән җыела

Кемнәр болын ашъяулыгын
төйнәп алыр җай белә?
Җиләк бердән җыела шул,
җиләк бердән җыела.

Тырышсам да тырысымның
төбе һаман күмелми.
Яхшы әйбер күп булмый шул,
яхшы әйбер күп булмый.

Матурлыкны шулай бердән
туплагандыр мир кулы.
Ә мыскаллап җыелганны
жуеп була берьюлы,
жуеп була берьюлы...

Әхсән Баянов

# МӘҢГЕЛЕК БӘХӘС

ПОВЕСТЬ

## Яши башлыйм дигәндә...

*Китә рәхәт «килә башлый» дигәнче;*
*Яшен һәм юк була «яшьни» дигәнче.*

Г. Тукай.



Зәп-зәңгәр күкле чалт аяз көнне, юк, яшен сугарга тиеш түгел иде. Ничек болай килеп чыкты соң? Ничек?

Көннәр буе бихисап кабатлана торган чылтырау гына иде югыйсә. Кичкә хәтле кабатланган чылтырауларга Алсу тыныч кына җавап кайтара торды:

— Директор юк, әйе, совхозга китте. Әйе, җәнлекләр янына. Тиз кайтырмын дигән иде дә, нишләптер озаклады.

Шулай кич җитте. Секретарь кыз, җиңел башмакларын салып, язгы-көзге туфлиләрен кигәннән соң, болай да гүзәл иреннәрен тагын да матурлар өчен ал төскә буяп торганда, телефон тагын чылтырады. Алсу бу юлы, нишләптер, дертләп китте. Һәм күңеле ничек сизенгән диген: көннәр буе кабатлана торган чылтырауларның бу соңгысы бер-берсенә су тамчылары-дай охшаш көннәр һәм сәгатьләрне берьюлы актарды да ташлады.

— Алло. Директор юк, әйе, совхозга... Ничек? Ничек? Нишләп больницада? Авария? Мөмкин түгел!

Аваз, теге дөньядан килгәндәй, сәер һәм куркыныч тоелып, Алсуны өнсез калдырды. Трубканы кабат үз урынына куярга кирәклеге зиһененә җиткәндә, тавыш тынган, аларны өзлексез пипелдәү алмаштырган иде инде. Үз колагына үзе ышанырга теләмичә: «Мөмкин түгел, түгел!» — дип кабатлый-кабатлый кәгазьләрен җыйнаштырганнан соң, тагын күпмедер хәрәкәтсез утыргач кына, хәбәрне башкаларга җиткерергә кирәклеге исенә төште.

«Уф! Китеп бетмәделәр микән инде?»

Ашыгып, каршыдагы бүлмәгә керде. Директор урынбасарының:

— Әле син мондамыни? Әйдә, уз,— дип елмаюы шулай ук мәгънәсезлек сыман тоелды.

---

ӘХСӘН БАЯНОВ (1927) — шагыйрь, прозаик, драматург. «Елларга сәяхәт», «Тау ягы повесте», «Ут һәм су» һәм башка шигырь, проза китаплары авторы. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә эшли. Казанда яши.

— ...Калага кайтышлый автомобиле юл читенә очкан. Больницадан шалтыраттылар. Ужас нинди!

— Ярый, тынычлан. Башкаларга хәбәр иттеңме?

— Беренче булып — Сезгә.

— Бар, бүтәннәргә дә җиткер.

Секретарь кыз барча бүлекләргә шалтыратса да, институтта җан иясе калмаган иде инде. Лабораторияләрнең берсе шулай да җавап бирде.

— Алло, Нажар абый, Сезме?

— Гафу итегез, мин.

Монысы да шаярмакчы. Ләкин хәбәрне ишеткәч, телен тиз йотты. Бернича минуттан соң директор урынбасары бүлмәсенә күтәрелгәч, сүзнең нәрсә хакында баруына илтифат итмәстән, үзенең соравын ишек төбеннән үк өстәлгә папкасы белән бергә ыргытты.

— Чын хәбәрме? Шаяртмыйсызмы?

— Менә Алсу...— Садир Хәкимович кызга баш изәде.— Ихлас әйтә бит.

— Ниндидер кабан ди, юл баскан ди. Ужас нинди!

— Кабан дисеңме? Кабан? — Яңа хәбәр авырлыгыннан Нажар кинәт урындыкка чүкте.— Шулайдыр, шулайдыр...— Берара аптырап интеккәннән соң, баш күтәреп, чырае качкан кызга күз ташлагач, тиз үк больницага китәргә кирәклеген төшенде.— Кабан! Әлбәттә шул! Ә без... нишләп торабыз болай? Киттек!

Садир Хәкимович, шул сүздән соң гына һушына килгәндәй, телефонга тотынып:

— Дөрес шул, болай килешмәс,— дип, машина чакырды.

Шул вакыт ишек шакыдылар. Аннан төссез кепкалы, чәнти бармак кадәр мыеклы, кечкенә борынлы түгәрәк чырай сузылды. Әмән абзый. Үз холкы буенча шаулап-дөбердәп, директор урынбасары бүлмәсенең нәкъ түренә узды. Әмма түгәрәк көләч чырай:

— Исәннәрмесез, саулармысыз! — дип канатланып керсә дә, иптәшләрнең артык җитди кыяфәтләренә төртелгәндәй, кинәт турайды, хәтта бераз гына арткарак чайкалып куйды.

Нажар торып басса һәм дустының кулын каты гына кысса да, күптән күрешмәү аркасында җыйналган сагыну галәмәтен бөтенләй сиздерә алмады диярлек. Карт, Садир Хәкимович белән күрешкәндә:

— Әллә берәр хәл булдымы? — дип сорамыйча булдыра алмады.

Җавапны Нажар бирергә ашыкты:

— Бар шул. Директор автомобиль авариясенә эләккән.

— Исәндер бит?

— Исән диделәр. Тик... больницада. Ничектер тагы.

— Ә мин күчтәнәчләр алып килдем имеш. Хәбәрләр дә байтак иде.

— Соң... машинада сөйләшербез, ә? — Нажар, Әмән абзыйга эндәшеп, Садир Хәкимовичка карады.

Тегесе каршы сүз әйтмәгәч, өчәүләп китеп тә бардылар. Әмән абзый, машинага кереп утыру белән бәхетсезлекнең кайда һәм ничек килеп чыгуын сорашып белгәч, катгый нәтиҗә ясады:

— Менә сиңа, ә... Мин дә гаепле булып чыгам бит әле, ә... Садир Хәкимович белән икәүләп.

Урынбасар утырган җиреннән борылып карамыйча гына бәхәскә җай тудырмас өчен, тагын да катгыйрак итеп әйтте:

— Ипләп! Шаяру өчен бүтән объект табыгыз, яме?

— Нишләп шаяру? Бик тә чынлап. Сезнең бүлектән алынган гомета... әйе, тере кузәнәк. Кабан дуңгызыннан сез алып калган... Теге хәерсез ташкыннан исән калды бит лаборатория. Сез килми башлагач, мин үзем кызыксынып, бер дуңгызны ясалма аталандырган идем. Алты чын чучка, бер кабан баласы туды. Бер яшь тулгач та урманга качты. Икенче яшендә инде ул, карт кабанны җиңеп, көтү башлыгы булып

урләде. Аннары менә шул начар гадәте беләнә башлады — ике аяклыга әйләнеп, олы юлга чыга да баса... Аны таптатмас өчен, машиналар җайсыз хәлдә кала. Ликсандр Иваныч машинасы шуның корбаны булырга тиеш. Менә шул.

Нажар, өстеннән йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйды:

— Ә мин тагы... Үзем ата алмаган теге кабандыр дип курыккан идем.

— Юк, юк, икенчесе, яшьрәге. Сез җан өргән кабан, Садир Хәкимович, сез саклап калган.

Садир Хәкимович пырхылдап көлде генә. Сөйләшеп тә торасы юк, аның катнашы юк, янәсе. Ләкин эндәшмәве Әмән абзыйсының кем икәнен һәм бәхәсләшүнең үз файдасына булмаячагын белү аркасында гына иде. Шулай да бу юлы эндәшмәве алтынга әйләнә алмас.

— Ликсандр Иваныч исән булсын, шуны телик, Садир энем, безнең вөҗданда кала югыйсә. Төшендекме? — Садир Хәкимович таш сын кебек утыра биргәнлектән, Нажарга борылды.— Инде сиңа да шундый сүз. Син бит теге үзең ялгыш аткан аюдан шулай ук генетик матдә алырга өлгергән идең. Шулай бит?

— Әллә аны да...

— Аны да булмыйча... Мөмкинлек барда. Аю барда. Анысы да шул ук елны туды. Мәгәр урманга качу түгел, куып та җибәрә алмыйбыз. Бер-ике чакрымга илтеп, адаштырырга тырышып та карадым, юк, китми генә — читлегенә кайта да ята.

— Кызганыч икән, бик тә кызганыч.

— Менә әйтәсе хәбәрләрем шушы иде. Сезне сөендерерлек яңалык булмасмы дип көткән идем дә... булмады. Яманрак булып чыкты, гафу итегез. Берегезнең кабаны, икенчегезнең аюы... Икесенең берсе дә рәтле булалмады.

— Үзебезгә охшагандыр инде,— дип шаярткан булды Нажар.

Ләкин беркемнең дә йөзенә елмаю галәмәте чыкмады шикелле. Киресенчә, ике галим дә, авызларына су капкандай, тын калды.

Шул рәвешле больницага җителде.

Директорны тиз таптылар һәм, ул күзгә җүренүгә, өчесе берьюлы аһ иттеләр. Башка китереп булмаслык сурәт: бүрәнә хәтле юан итеп гипсланган аягын ап-ак җепләр белән түшәмгә асканнар, һәм, җитмәсә, тагын бер кулын акка катырганнар. Директор үзе, җитдилеген ахыр чиккәчә югалткан хәлдә, күккә багып ята. Әле кичә генә куәтле булган җитди җитәкче көчсезлегеннән оялып кызара... Әйтерсең гаепле...

Кызганыч та, көлке дә. Көлеп җибәрмәс өчен шактый көч сарыфлап ике-өч минут басып торганнан соң гына, караватъ эргәсенә килделәр. Әмән абзый хәлгә тизрәк җайлашты. Тирән эчтәлекле сүзләр эзләп маташмастан, нәкъ авылча гадилек белән авыруның исән кулын кушкуллап кысты:

— Исәнмесез, иптәш директор. Күрәбез, беләбез. Зыян юк — баш исән булгач, терелербез дә танцыга да йөрербез. Исән калуыгыз белән котлыйм Сезне — бәхетегез һай зур икән!

Бәхетле кеше ихлас елмайды:

— Акыллы сүз, молодцы,— дип куйды.— Югыйсә бәхетсезлектән интегеп ята идем әле. Рәхмәт.

Җайлы форсаттан файдаланып, Әмән абзыйларыннан бушаган кулны Нажар белән Садир да елмаюларын яшермичә генә кыса алдылар: «Менә бит, әә, аяк астында ята бәла!»

Бәла дигәннәре автомобиль катастрофасымы, әллә кабанмы? Аны кем, нәрсә барлыкка китергән? Тиз генә җавап табарлык сорау түгел бугай монысы. Уйлый китсәң, монда утыручыларның барысы, шул исәптән ятып торучы үзе дә гаепле булса кирәк.

Әмән абзый хакны әйтте: моннан өч ел элек, хәле артык та мөшкел, үзе әллә нинди томан эчендә йөзгән кебек булса да, һөнәренә хас гадәт белән Нажар аюның тиешле күзәнәкләрен компонентларга

аерып, консервлап каравылчыга, Әмән абзыйсына нәрсәнең кайда икәнлеген күрсәтеп, аңлатып калдырган иде. Әмән абзый — элеккеге биолог, һәвәскәр галим, хәзерге рәсми зоотехник — үз карамагына күчкән лабораториядә үзенчә эшләп ташлаган. Киңәшмәгән. Ләкин эше нәтиҗәсез бетмәгән — уңышка ирешкән диярга туры килә. Нажар үз кулы белән башкарса да, шул ук хәл булыр иде — генетик программаны ул үзгәртә алмый бит... мөмкинлек аңача барып җитмәгән. Тәҗрибәләрне дәвам итәргә мөмкин. Әмма хәл хәзергә һич тә шатланырлык, аннан бигрәк мактанырлык түгел. Садирның кабаны исә үзен иҗат итүчеләрне хәтта алама хәлгә куйды. Сәбәп — контроль җитмәү, уйлап җиткермәү, саклык кирәген тоеп бетермәү. Ихтыярдан тыш — әнә нинди тискәре көч дөнья буйлата чаба китте...

Җитәкче буларак, директор бу эштә кырысрак тәртип урнаштырырга, Садир белән Нажар исә, генетик банкны алай калдырмаска тиешләр иде. Тугайны су басканнан соң, күп нәрсә җимерелеп, күмелеп калгач, институтның финанс куәте җитәрлек булмаганлыктан, директив оешмалар рөхсәте буенча тәҗрибә хуҗалыгын җәнлекләр бакчасы белән бергә, совхоз бик теләп үзенә кушып куйганлыктан, җаваплылык та аларга күчте дип исәпләргә мөмкин. Шулай да... Шуңа да карамастан, җаваплылыкны җилкәдән төшермәү дөресрәк булыр кебек бит. Бигрәк тә — совхоз хуҗаларының анда институт кешеләренә сынаулар алып барырга шатланып риза булуларын искә алганда. Директор үзе, мәсәлән, төп эзләнүләрен шул базада алып барды һәм шушы көнгәчә дәвам итте. Үзенең яңа ачышлары белән ул, беренче чиратта, совхозга бурычлы. Димәк, контроль дигәндә, ул бигрәк тә читтә кала алмый.

Башкалар ни уйлагандыр, әйтү кыен. Ә менә Нажар директор күзләренә бик кыска бер тынлык эчендә туган шундыйрак фикерләр белән карап торды. Александр Иванович исә, әлбәттә, барысын да төшенеп, карашын читкә борды. Әйе, җаваплылыктан һич тә азатмын дия алмый ул.

Шуңа күрә бугай, әңгәмә әллә ни куерып китмәде. Хәл белергә килүчеләр, арытмыйк дигән, ә директор, вакыт әрәм итмәгез, дигән сылтау белән тизрәк хушлашу җаен карадылар.

Урамга чыккач та киеренкелектән котыла алмадылар. Шул сәбәпле, Әмән абзый, машинага утырмыйча, соңга калам дигән булып, автовокзалга ашыкты. Нажар совхозга тиз арада барырга тиеш, чөнки аңа үзенең тере иҗатын үз күзләре белән күрергә кирәк бит. Әмән абзый әйткәнчә, әгәр эчендә җаны булса.

* * *

Директорның авариягә юлыгуы институтта гүяки яңа борылыш барлыкка китерде, гүяки анда давыл алды тынлыгы урнашты.

Атна-ун көн уздымы, юкмы, Садир Хәкимович үз бүлмәсенә Вәкилне чакырып кертте. Сүзне кыска тотты.

— Кызыклы хәл. Кичә Рим Салихович Александр Иванович янында булган.— Вәкил колагын шәмрәйткәч, дәвам итте.— Син... бик тырышсаң, мондый гына хәбәрне йота алырсың бит?

— Әллә сынатканым булдымы, Садир Хәкимович?

— Больницадан чыккач, Александр Иванович пенсиягә китмәкче икән.

— Яшьләргә юл бирергә күптән вакыт иде.

— Ә яшел утны ул, беләсеңме, кемгә кабызмакчы?

— Габбасовка була күрмәсен тагы.

— Нәкъ шуңа.

— Синең тырышлыгың белән урнашкан иҗади климат бозыла бит алайса. Файдалы эшне тагын кәрәш, бәхәсләр алмаштырачак. Менә бит, ә? Александр Иванович кемнең кем икәнен тәки белә алмады. Ә?

— Нажар директорлыкка лаек кеше.

— Миннән башлаячак. Кулы сиңа ук житә алмас та... тик барыбер каныңа тозны жәлләми сибәчәк.

— Белмим тагы... Уйла инде, акыллы кеше бит син.

Вәкилгә биш әйтүнең хажәте юк, аңа ишарә итү дә бик житкән. Бераз гына кыланчык рәвештә:

— Теге чакта жайлы килеп чыккан иде дә, хәзер ул хутны кабатлап булмас шул,— дип көлеп куйды.

— Ул инде синең белән аракы эчмәс,— дип шаяртты Садир Хәкимович.

— Сине дә ресторанга чакырмас. Ә?

— Ул Фәнүзә Кадыйровна белән бергә булганда көчле. Бер үзе генә калса, бик тиз мескенәя.

— Соң... алайса хәстәренә керешегез.

— Ничек итеп? — дип, гажәпләнгәндәй сорады Садир Хәкимович.

— Әле зур биеклеккә күтәреп, әле упкынга батырып, кешене хәтта шаштырырга була. Фәнүзә дә корычтан коелмагандыр. Ә миңа Нажар калачак...

— Кызык бик тә. Нинди гөнаһын тапмакчы буласың?

— Дөньяда гаепсез кеше булмый, табарбыз. Тик шунысы бар — ул сизәчәк. Мине компрометировать итәчәк. Анысыннан да курыкмыйм. Әгәр миңа ярдәм кулы сузсагыз. Баш сыйган жиргә койрык сыя ул.

— Анысы шулай,— дип елмайды Садир Хәкимович.

— Болай мин Нажар кебек ялгыз эгоист түгел. Эш башкарырлык кешеләрем инде монда да бар.

— Белмим шул. Уйла. Кара.

Торып, Садир Хәкимовичның кулын кыскач, Вәкил, гадәттәгечә, башын боргалый төшеп, арты белән чигенде дә, ишекне ачкач, янә елмайды. Ләкин коридорга чыккач, уйга калды: «Тагын кирәксез гауга көтелә икән. Ничек-ничек шуннан исән котылырга? Больницадан чыкканда, Александр Ивановичны лаеклы каршылау жиңел эш була алмас. Ләкин каршыларга кирәк...»

* * *

Шулай, һәркем үзенчә бәхетле. Вәкил фаразынча, Алсу бик рәхәт көннәр кичерсә, Нажар, нинидер кабан, нинидер аю аркасында изалана бичара. Әмма Нажарга үзенең жанлы ижаты белән дә, Садир Хәкимовичның кабан кыяфәтендәге хатасы белән дә тиз генә очрашырга туры килмәстер әле. Ник дигәндә, ул максатларга икенче бер яңалык комачау итәчәк.

Яңалык дигәнең шуннан гыйбарәт: геологлар ерак тундрада миллион еллар элек яшәгән мамонт гәүдәсенә тап булганнар һәм шул хакта тиешле оешмаларга хәбәр жибәргәннәр. Үзәктәге олы белгечләр карлыбозлы тирән чокырда яткан мамонтның баш сөяге эчендә ми матдәсе исән сакланмагае, мамонтны яңадан бар итеп булмагае дип фаразлыйлар. Шуны бергәләп тикшерү һәм киңәшү өчен, бездән дә бер кеше жибәрүне сораганнар. Мондый эш турыдан-туры Нажар төркеменә кагылганлыктан, Садир Хәкимович, теләгең ничегрәк дип сорамастан, Нажарга киләсе дүшәмбедә юлга чыгарга боерды. Нажар мондый да гайре табигый эшкә боерыксыз да барырга тиеш иде, әлбәттә. Ләкин гел без дигәнчә генә булса икән лә!

Китәргә боерык алганның икенче көнендә, кичке сәгать тугызлар тирәсендә ишек кыңгыравы чың итте дә Нажарның бөтен теләк-ниятләренә нокта булып төште дә куйды.

Телеграмма. Авылдан. Әнисенең хәле хәвефле — тиз арада кайтырга кирәк.

Күрше бүлмәдән Фәнүзә чыкты һәм аның кулындагы кәгазьгә карап бөтенесен сүзсез аңлады. Нажарның нинди дә булса фикергә, аның

карарга килә алмый интегүен күреп, шик-шөбһәләрне берьюлы юкка чыгарды:

— Кайтырга кирәк.

Бу катгыйлыктан: «Институтның хәле алай ук авыр түгел, анда кеше синнән башка да бетмәгән, кемне дә булса бүтәнне җибәрергә мөмкин, ә гомер кабатлана, яңара алмый. Синең хәзерге бурычың — анаң янында булу»,— дигән мәгънәләрне аңлау бик ансат иде. Нәҗар: «Әйе»,— дип баш какты.

Таң-иртә белән вокзалга юл тоттылар. Алдан сөйләшенмәгәч, билет алу шактый җайсыз булып чыкты. Кичке сәгать сигездә китәсе поездга чират хәзердән тезелгән: илле-алтмыш кеше. Төрле юнәлешкә булгач, әллә ни күп тә түгелдер, әмма Нәҗар станциясенә билет булырмы-юкмы, булса — җитәрме-юкмы — моны белешмәләр бюросы да һич әйтә алмады. Бердәнбер чара — көтәргә.

Нәҗар чиратка басты. Ул чират торган арада Фәнүзә, кайбер кучтәнәчләр алырга дип, базарга китешли:

— Билетны алып өлгерсәң дә, мине шушында көт,— дип кисәтте.

Мәгәр ким дигәндә ике сәгать чамасы йөреп килсә дә, Нәҗар ул киткәндә кайда калса, нәкъ шул төштә басып тора иде. Фәнүзә гаҗәпләнеп кенә куйды һәм тәрәзә төбенә барып, Нәҗарның портфеленә җимеш-җомыш салган арада туган фикерен Нәҗарга портфеле-ние белән тоттыргандай итте:

— Менә нәрсә, иптәш, болай көн буе торсаң да билетсыз калуың бар — аяксыз калуыңны әйткән дә юк. Телеграмманы тот та...

— Телеграмма? Өйдә калды бит телеграмма.

— Телеграмма минем кесәдә — менә. Шушының белән вокзал начальнигына кер, болай булмый.

— Ничек инде начальникка? Ул билет сатамыни!

— Әни берәү генә, аның соңгы тапкыр болай авыр чирләгән булуы ихтимал. Начальникның да әнисе бардыр — аңлар.

Нәҗар, моңа каршы берни әйтә алмыйча, сүзнең дәвам итүеннән курыккандай, аны авыз йомып кына уздырырга исәпләгән иде дә, ләкин Фәнүзәнең исенә бер уй төштеме, син аннан тиз генә котылам димә инде. Үзәгенә үткәнче онытмый ул аны — кабатлый бирә:

— Авыл гыйбаты кебек торма, яме, бар, тизрәк бул.

Гадәтенчә, шулай иренең горурлыгын кузгатмакчы. Аның кем икәнен дә күп белгәнгә күрә, бәхәсне артык куертмыйча, кискен рәвештә:

— Беләм, инерция — ихтыяр ялкаулыгы, — дип нәтиҗә ясарга ашыкты. — Кеше күзенә күренергә куркасың, чөнки кеше белән сөйләшә, аралаша белмисең. Их, узды бит гомер...

— Син, Фәнүзә!..

— Бир удостоверениеңны.

— Анысы ни эшкә?

— Сурәтеңне карыйсым килә — сагындым.

— Морданны диген.

— Гүзәл кыяфәтеңне. Я? Мин чынлап әйтәм. — Иренең нишләргә белми торуын сизгәч, йомшара төште. — Карап ышанасым гына килә: өйдә калдырмадыңмы? Юлныкын бит белеп булмый — алла сакласын, берәр бәлагә очрасаң, кая, кемгә хәбәр итсеннәр?

— Кесәдә удостоверение, хәтта паспорт та.

— Әйбәт. Алайса мине дә тынычландыр.

Шулай итеп, таныклыкны кесәдән тәки чыгартты, һәм кулына алуга, капыл китеп тә барды. Ярты сәгать уздымы-юкмы, елмаю өчен вакытның җайсыз чагы булганлыктан, җиңү шатлыгын да иреннәрен кысып тыйган хәлдә, ләкин барыбер тантаналырак төстә иренә удостоверениесен һәм шуңа өстәп бер поезд билетын да сузды.

— Бронь белән икенче кассадан икән — теге бинада.

— Синең бронең бар идеме?

— Бар иде. Син дә яшисең бит дөньяда, Нажар, ә? Нәрсә исәбенә чуттан төшеп калмыйча барасың син, ә?

— Синең билет белән... Билет булгач, төшереп калдырмыйлар.

— Начальник, между прочим, сине белә икән. Ишетеп. Мин аның үзен күрүгә шат булыр идем, ник керми ди. Кайгыдан рәтләп сөйләшә алмам дип курыкты дигән булдым. Ә синең, әлбәттә, фаҗигаң мәңгелек.

— Җитте, булды.

— Җитте, әлбәттә. Сине тәрбияләп ни файда. Аюн[illegible] тәләр, ә сине... Әйе, булды. Мә, сакла.

Таныклык белән билетны Нажар кесәсенә салгач, китәргә дә җыенды. Ире аны трамвайга хәтле озата барды. Урамнан атлаганда исә вак-төяк тарткалашулар онытылып, сүз инде яшәү белән үлемгә бәйле мәңгелек уйлар һәм тойгылар тирәсендә әйләнде. Бу аңгәмәне дә Фәнүзә шактый хәйләле башлады.

— Әгәр мин, бик каты чирләп, үлә башласам, син мине коткарырга тырышыр идеңме?

— Тырышыр идем.

— Ә әниеңне?

Нажар, капыл борылыш көтмәгәнлектән, аптырамыйча булдыра алмый. Башын иеп, ул моңаерга әзер, әмма җавап дигәндә... чынлап та... Ярдәм итәргә көче җитмәсә, һич югы тырышырга кирәк ләбаса?

Фәнүзә Нажарның әнисенә елга ким дигәндә ике тапкыр посылка тутыра да адрес һәм хат кисәге язуны, шулай ук почтага кертүне иренә калдыра. Әрҗәдә нигездә чәй әйберләре — җиләк-җимеш һәм кайбер витаминнар, дарулар була. Димәк, ананың исәнлек-саулыгына азмы күпме ярдәм күрсәтелгән. Ә чирне дәвалау дигәндә, әниләре аларны, авырып, бик интектермәде. Салкын тию, бераз картая төшкәч, ялгыш кул-бармак сындыру кебек вак-төяк сырхаулар хакында гына хәбәрләр килгәли торды. Ә болай ныклап чирләве — инде картлык галәмәте. Нишлисең, ни чаклы гына кадерле, ни чаклы гына якын булмасын, ахыр чиктә ярдәм итү мөмкин түгел, кеше үз тәненнән, үз дәвереннән аерылып кала алмый — күзәнәкләр үлә тора, яңару кими бара. Котылу юк. Котылырга кирәкме — анысы да бәхәсле.

Фәнүзә әлеге сүзе белән, әлбәттә, әнә шул бәхәскә әйләнеп кайтты. Алай гына да түгел, теорияләрне читтәрәк калдырып, мәсьәләне үткен ягы белән куйды.

— Бездә бит... Тәҗрибә дәрәҗәсендә дисәк тә, кайбер препаратлар инде эшкә керешерлек. Ә? Карт организмга ярдәм итә торган. Безнең әнкәйгә нәкъ шул кирәк тә. Сазуленны әйтәм. Декамевит төсле үк гади нәрсәгә әйләнәчәк бит ул бервакыт.

— Ә хәзергә...

— Хәзергә ярамыймы? — дип, Фәнүзә ирен бүлдерергә ашыкты. — Ләкин ул бит инде бар. Нигә файдаланмаска?

— Ә кем рөхсәт итә?

— Мин. Үзем синтезлаган...

— Акылыңдамы соң син? Бу бит... бу — наркотик урлаган төслерәк булачак, башың бармы?

— Бар.

— Ничәү?

— Берәү.

— Шулай булгач?

— Әни дә берәү генә.

Трамвайлы урамга җиткәч, Нажар хатынын җитәкләмәкче иде, тик Фәнүзә кулын тиз генә ычкындырды: урамны тотынышмый узу дөресрәк. Тукталышка җиткәннән соң исә, иренең кулын ике куллап каты гына кысты һәм, үпкән кыяфәт ясап, битеннән сыйпап куйды да, хәерле юл теләп, эшенә китеп барды.

Юк, Нажар башы авыртканчы уйласа да, тәгаен фикергә тәки

килә алмады. Бер нәрсә ачык: кайбер нәрсәләр хакында ул, әгәр әнисенең зиһене томаланмаган булса, кайткач, аның белән киңәшергә тиеш булачак.

Нажар — авылда нибары уналты ел яшәп, балалык, үсмерлек елларын гына шунда кичергән кеше. Дөньяга мөнәсәбәте авылда чакта ук абайланса да, аның белән күзгә-күз карашып сөйләшү, бәхәсләшү студент елларыннан башланды һәм һаман кискенләшә барды. Өлгергән акыллы олы Нажар — каланыкы, ә яланаяклы малай, яшел урман, яшел болынны таптап йөргән гөнаһсыз үсмер — авылныкы.

Нажар үзенең бәләкәй чакларын төштә күбрәк күрә. Кая гына барса да, кышкы суыкларда боздай салкын идән әле дә ул малайның аякларын әрнетә. Малай, шуңа күрә бугай, бәрәннәр белән бергә сикерепә, йөгерә, моржа кырыена менеп куна. Урамда кар көри, чана белән тау шуа. Куян сукмаклары буйлап, озын колакларны күрәчәгенә ышанып, көннәр буе карга бата-чума йөри.

Ә җәйләр — бөтенләй бүтән. Җәй — яшел әкият, аны гомер буе сөйләп тә бетерә торган түгел.

Ләкин моңарчы беркемгә дә сөйләнелмәгән. Нажарның балачагы, үсмерчагы булганмы, юкмы, беркемгә дә билгеле түгел. Хәтта үзенә дә... Әйе, сөйләү түгел, бу хакта уйланырга да вакыт күп калмаган — барча хыяллар белән бергә, бөтен зиһенен фән — микробиология, микродөнья биләп алган да үз эчендә биләп торган икән. Фәнүзә шактый хаклы шул.

Гомеренең бер өлеше, бәлки иң изге, иң матур кыйтгасы бәяләнмичә калган... Моның өчен озын юл да җитми калды. Поездан төшеп, автобуска утыргач, аннан да төшеп, алты-җиде чакрым җәяү атлагач исә, сораулы фикер күз алдына аерымачык булып килеп басты.

Таныш юл, таныш басулар, таныш урманнар.

Алар инде бик үк таныш та түгел икән. Чик-чамасыз ераклыкларга сузылган басуларны яңа урман тасмалары бүлгәләгән. Яшелләкләр, зәңгәр төсләр дә бүтәнчәрәк кебек.

Бу кырлар, бу урман-болыннар, караганда күзне яшьләндергән күк кебек, күңелнең иң тирән төшләрен дә әлҗе-мәлҗе китерә икән. Күңел төпкелендә изге бер дөнья сиздермичә генә, тын гына, тыныч кына яшәп яткан икән. Нажар үзе моны белмәгән, бәлки әле юк дип, бушлык дип уйлап йөргәндер.

Ләкин табигатьнең үзе кебек үк, күңел бушлыкны яратмый, ул үзен фикерләр, уйлар, хыяллар, истәлекләр белән тутыра. Ә менә Нажар... Нажар үз тормышын чынлап та бераз тарайткан ахрысы.

Бәясез калган көннәр һәм елларны югалтмаска — тикшереп, бәяләрен биреп, яңадан барып алырга, кире кайтарырга һәм, бүгенге көн хыянәт итсә, шулар ярдәмендә кабат яшәргә мөмкин, ахрысы.

Кабат яшәргә? Әйе, моңарчы яшьлеккә кайтуның бердәнбер ысулы хәтер иде. Ә хәзер? Ә Сазулен? Фикернең генә түгел, тәннең дә яшьлеккә кайтуы әкияттән реаль тормышка күчә дигән сүз түгелме? Халыкның шаян җыры аклана түгелме соң?

Әҗәлгә дару бар диләр,
Мәхәббәткә бар микән?

Табигыйме, һәм, әгәр дә бар дисәк, кирәклеме ул?

Монысы хакында Нажар әнисе белән киңәшәчәк. Тик әнисе нинди хәлдә икән?

Йөрәк лепелдәп куйды да бөтен уй-фаразларны бер кеше — әни алмаштырды. Бөтен нәрсә, бөтен табигать, бөтен тормыш әни кыяфәтенә керде. Әни... Исәнме икән? Исәнме?

Нажар соңгы ике чакрымны тирә-юньне күрмәгән, бер нәрсә ишетмәгән хәлдә йөгерә-атлый узды. Һәм менә, ниһаять, туган җир, туган урам, туган өй, ихата!

Нажарның кайтуын әллә кайдан күреп, каршыларга чыктылар. Димәк, исән.

Каршылаучыларның иң алдан чыкканы — Нажарның апасының улы, шахтер егет Фәсил. Ярым елмайган хәлдә килә. Бу, әлбәттә, сагыну галәмәте, шулай ук әни дә әле исән дигәнне күрсәтә. Кул биреп күрештеләр, әмма... бу нәрсә? Ник Фәсил болай сулагай күрешә? Уң кулы... уңы — кап-кара протез... Шахтада күмер төялгән вагоннар озатканда кулын өздергән... Тагын бер кайгы... Шулай да егет кыяфәтендә һич мескенлек сизелми, хәтта шушындый көндә.

Артык баш ватып, моңаеп торырга вакыт калдырмас өчен диярсең, тиз арада Нажарның бертуган энесе, башка энеләре һәм сеңелләре килеп житә. Алар чыраенда да, кырысрак булса да, тыныч гамь. «Исән».

— Исәнме?

Сорауның кем хакында икәне ап-ачык.

— Исән әле.

Эх, «әле»се дә булмаса!

Ак өйнең керешли уң ягында — чаршаулы бүлем. Кереп, ике-өч минут үткәч үк Вәзимә апасы чаршауны тартып куйды. Чаршау эчендәге караватта ул ята...

— Исәнме, әни, хәлең ничек? Мин кайттым менә. Сине күрергә. Ә син сынаткансың икән.

Нажар әнисеннән сүз ишетергә өметләнеп, һәр сүздән соң бераз тукталып, көтеп торды. Тагын шундый кизү сүзләр дәвам итәчәк иде. Тик әнисе чак кына ыңгырашып куйгач та, телгә килде.

— Нажар... балам... таныдым.

— Әйе, кайттым, әни, хәлеңне белергә. Болай ук каты чирләргә ярамый бит инде.

— Таныдым... улыңны гына танымыйм...

Нажарның янында Фәсил басып тора икән. Авыру зиһен шуны Нажарның улы итеп күрергә тырыша иде бугай. Нишлисең бит, Нажарның улы юк, ул инде була да алмастыр. Ә ана нәселнең дәвамы турында уйланган булса кирәк. Әйе, нәсел уләргә тиеш түгел, үсәргә тиеш. Ә менә бер малаең аны дәвам итә алмас ахры — ул малай белән кайта алмады. Шулай булгач, ана кеше, син үзең үлмәскә тиеш — мөмкин кадәр озак яшәргә тиеш — исән калырга тиеш. Нажар өчен дә, аның була алмаган малае өчен дә үзең яшәргә тиеш. Фәнүзә тагын хаклы булып чыга — сиңа әҗәлне җиңә торган дару кирәк булачак.

— Ничек соң, әни, бик авырмы хәлең? Кай төшең авырта?

Шул сүзләрне әйткән вакытта Нажарга урындык бирделәр һәм ул, әгәр мөмкин булса, әнисе һушы-акылында чакта бөтен сүзне әйтеп, сорыйсын сорап калырга тырышачак.

— Бер җирем дә авыртмый, балам, хәлем генә юк.

«Фәнүзә хаклы. Нәкъ Сазулен кирәк...»

Шулай уйлап, ул икенче төрле әйтте:

— Алай булгач, ярый әле, тиз терелерсең.

— Терелү анысы булмас инде ул.

— Бераз дәвалана төшкәч.

— Монда әллә ни... әйбәт врач та юк.

— Шәһәргә барырбыз, бераз ныгый төшкәч.

— Берәр профессорны монда гына чакыртып булмыймы соң?

— Бер дә таныш кешем юк, китертеп булмас, әни.

— Ярар инде, барыбер ярдәм итә алмас — әҗәлдән дару юк.

— Бар, әни,— сүзнең шулай үзе курыккан темага табигый борылуына Нажар хәтта сөенеп куйды.— Хәзер әҗәл даруы булырга тора, әни.

— Алладан юктыр, бүтәннән булса гына — иблистән...

— Кеше, әни, менә без, синең киленең, шундый дару ясарга җыена. Болай табылган да инде ул, тикшереп, сынап кына бетерәсе калган.

Бераз гына сабыр итсәң... Нәкъ менә сез әйтә килгән әҗәл даруы. Шуны эчсәң, яңадан яшьлегеңә кайта язасың. Гомер озынная һәрхәлдә.

— Мең яшәгән Локман кебекме?

— Әйе, шулайрак.

— Мең яшәгән Локманны да җир үз куенына алган шул. Барыбер үләсе, барыбер килеп җитә икән ул көн.

— Әни, беләсеңме, яңадан бер йөз елдан кешенең, гомумән, Локман кебек яши башлавы ихтимал.

— Миңа тәкъдир икенче төрлене язган — теге дөньяда мәңге яшәүне. Миңа шул бик җиткән, балам. Ясалма гомер — гөнаһ ул, көферлек. Гадел дә түгел. Минем яшьтәшләрем әллә кайчан үлеп бетте. Болай да оят алардан. Үзебезнең чишмә суын күп эчтем шул. Шул суда андыз кайнатып та эчә торганыем. Бүтәннәр ышанмады, тиз киттеләр. Ә мин... Шуның сихәтенә гел ышандым. Чишмәбезнең андызлы суын әйтәм.

— Алдагы заманда ул чишмәнең борынгы куәте тагын кайтачак.

— Кайтса да, балам, сезнеке генә булыр ул.

— Әле бит син бер дә бәхетле булып яшәмәдең...

— Йөз елдан соң мин, надан кортка, яңа затлы кешеләргә чит-ят булырмын. Кеше арасында ким-хур булып яшәгәнче, үлгәнең артык. Күңелсез булыр анда миңа, яшәү җәзага әйләнер.

Әнисе үзенең уен, теләген аермачык әйтте дә бирде шулай. Аңарга кешедән, яшьтәшләреннән артыгы кирәкми. Аларга караганда дөньядан күбрәкне алса, вөҗдансызлык булачак. Кешеләргә ничек, аңа шулай.

Нажарның әнисе югары әхлак кагыйдәләре турында беркайчан сөйләмәде, бәхәсләшмәде. Ләкин ул гомер буе шул кагыйдәләрдән чыкмый яшәде һәм шулар белән үләргә әзер. Аның тәрбиясе кан аша нәсел-нәсәптән, ыруг-токымнан киләдер, әгәр әйтергә яраса, бәлки әле Нажарга да күчкәндер. Ул да бит шул матдәләрдән ясалган... Күзәнәкләр бер үк, генетик программа... Аюдан чыпчык яралмый, дуңгыздан сандугач тумый. Нажар бүген үзенең дә кем икәнлеген дөресрәк төшенә башлады кебек. Күпме укып, тикшереп белә алмаганны бүген берьюлы һәм ачыграк аңлады бугай, мәңгелек дөреслекне, әйтерсең, ялангач хәлендә күрде...

Һәм әнисе белән бәхәскә керүнең акыллы эш түгелен чамалап, тыңлап кына утырасы итте. Әнисе исә тиз арада бөтенләй башка юнәлештә фикерли башлады.

— Мин сине укыта алмадым, балам. Үзеңне үзең укыттың. Әле үзең безгә ярдәм итеп килдең. Җәй көне ел саен кайтып печән әзерләдең. Малларга. Сыердан өзелмәгәч, сыйлы булдык. Гомерне шулай ходай кушканча сакладык.

— Шулай булды шул, әни, дөрес хәтерлисең.

— Миннән фатиха, балам. Барыгызга да миннән хәер-дога. Инде үз балаларыгыздан игелек күрегез. Үзегезгә дә тыныч вөҗдан белән дөнья куярга язсын.

«Бәхилләшүе шушы түгелме соң?» — Нажар сискәнеп киткәндәй булды. Һәм бүтән сүз дә әйтә алмыйча калды. Әнисенә тынлык кирәк иде инде — ул әллә йокыга талды, әллә һушыннан язды. Дөресрәге, йокысы-һушсызлыгы бергә булгандыр.

Әнисе уянган, теләнә килгән саен, Нажар аның янында булырга тырышты. Вәзимә апасыннан юдырып, кала күчтәнәчләрен биреп карады.

— Шушы җимешләрне ашасаң, терелерсең, әни. Яле.

Әфлисун телеме калтыранган иреннәрдән ары узмады. Анар бөртекләре узгандай тоелган иде, анысы да кире чыкты. Мескен ана! Бу чакта ул әле ашарга да өйрәнә алмаган сабый кыяфәтендә иде. Шул кадәр хәлсез, шул кадәр ярдәмсез. Аерма тик шунда гына, әгәр бала ризыкны чәйни алмыйча кире чыгарса, ул моның өчен үзендә бернинди гаеп

сизми һәм кәефе бозылмый. Ә менә карт кеше үзенең хәлсезлеге-көчсезлегеннән шул хәтле кыенсынды, күзләре шул чаклы кызганыч карады ки, ул оялудан башын читкә борып кына котылырга тырышты, ләкин барыбер котыла алмагандыр.

Әнисен тынычлыкта калдырыр өчен, Нажар тышка ук чыгып китте. Бакчаларны, су буйларын карап әйләнде. Тик анда да һаман бер мәгънә, бер үк таныш авазлар ишетелә иде.

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра, ни дип кычкыра икән? Кемнәр аңлый аны, кем ишетә, ә кемнәр ишетми, аңламый икән?

Мәңгелек аваз: мин бит монда, син мине эзлисең, мин сиңа кирәк һәм син минем язмышым! — хатын-кыз ир-егеткә эндәшә, женес — женескә. Ата-ана — балага, ә бала үткәннәргә һәм киләчәккә сүз куша. Берсен-берсе мәңге эзлиләр кешеләр. Берсен-берсе алар я таба, я тапмыйлар.

Кеше кычкыра: «Галәмдәге ерак җан һәм акыл ияләре, сез кайда? Мин сезне эзлим. Бу зур бушлыкларда — йолдыз сахраларында исән калу өчен сез кирәк миңа һәм бәлки мин дә сезгә кирәклеләр. Бергәләп исән калыйк — саклап калыйк акылны һәм шәфкатьне!

Елга буенда — казлар. Әгәр алар тавышсыз калсалар?

Әгәр кеше телсез һәм өнсез калса, ниләр булыр иде — нинди мәгънә калыр иде галәмдә?

Җаваплар эзлә, тап, хәбәр ит».

Инеш һәм сазлык кырыеннан, арырак атлады Нажар. Чишмә тавына җитте. Көн шактый суык булуга карамастан, изге су белән кулларын юды, эчеп карады. Мондый да тәмле суның булуы мөмкин түгелдер. Нажар, вакытны да, дөньяны да шактый күргән кеше, моннан да тәмле һәм саф суның хәзергә бер җирдә дә юклыгын белеп яши. Юкка гына Яшьлек чишмәсе дип атамаганнар бит аны!

Чишмә төбендә — таныш сурәт... Нажарның яшь чактагы сурәте бугай. Аны бүгенге көнгә чыгара башласаң, чишмә рәнҗемәячәк, сызланып, яшь төсле түгеләчәк кенә... Яшь кыз төсле, беренче мәхәббәт төсле...

— Чылтыр-чылтыр, чылтыр-чылтыр.

Суларның һәм чыңнарның башы да юк, азагы да...

Халыкның иң саф уйлары, җырлары, ниятләре — барысы-барысы шул сулар чылтыравы рәвешендә аваз алуга ирешә. Ә ераграк заманда кешеләргә тормыш итү өчен көндәлек көч кенә биреп калмыйча, аларның аккан сулардай кире кайтмас яшь гомерләрен кире кайтарып торган бөек кодрәткә дә ия булган имеш бу чишмә. Бик бәләкәй чакта Нажарга әнисе сөйләгән кебек, ул хәзер дә чылтырап шул риваятьне кабатлый сыман.

Элек заманда бер генә өйле бу авыл кара урманның сихерле дәвамы гына булган һәм бүтән авылныкылар чишмәнең нинди икәнлеген белмәгән дә, ишетмәгән дә. Бервакыт әти кеше үзенең өч малаен башка чыгара икән. Биләмәсен балаларына туганнарча үзбаш бүлешергә боера бу. Малайларның иң зурысы — иген игелә торган басуларны сайлый. Икенчесе, моңа бераз кәефе китсә дә, нишләсен, беренче булып тумагач, беренче булып сайлау хокукы аңа бирелмәгән. Шулай да алданып ук калмас өчен биләмәнең икенче зур өлешен — урманнарны сайлый ул. Ә төпчек малайга эш бөтенләй җиңеләя — абыйларыннан соң аңа бары тик тау итәкләре һәм сазлы-болынлы җирләр генә кала. «Нишләп алар миңа караганда күбрәкне эләктерергә тиеш икән?» — дип аптыраса да, күңелен төшерми: «Анда бит чишмә бар — шуның чылтыравын тыңлап гомер итәрмен әле», — дип, үзен юата.

Төпчек бала чишмә буенда әкияттәге төсле матур, челтәр-челтәр тәрәзәләр белән бизәп, сарылы-яшелле коймалар, зәңгәр капкалар белән уратып, әйбәт кенә өй салдырса да, абыйлары кебек куәтле була алмый. Җәй көне печән чаба, балык тота. Күзләрен ауга йөри — вак

җәнлекләрдән тыш, бүре, хәтта аюны җиңгән чаклары була. Бер аюны, борынчак кидереп, авылдан-авылга хәтта биетеп тә йөртә.

Аудагы уңышлары аркасында һәм саз буенда ялгыз яшәгәне өчен Аю Әббәс кушаматы алган егет күп гомерен чишмә аһәңнәрен тыңлап, үзе дә шуңа кушылып-җырлап моңая, бахыр. Җырына-моңына сокланган бер чибәргә өйләнгәч, балалары туа. Аларга тамак туйдырырга рәт калмаганлыктан, үскәне берсе читкә китә тора.

Шулай тагын байтак ара яшәгәч, хәл белергә дип, олы туганнары килеп чыга болар янына. Картайганнар, тешләре төшеп беткән... Ә энеләре егет чакта ничек булса, һаман шул ук чибәр кыяфәттә икән. Гаҗәпләнәләр, сорашалар — булган бөтен беләмәләрен бирмәкчеләр, тик матурлык — яшьлекнең серен генә ач, янәсе. Ә ул нинди сер белсен, нәрсә әйтсен? — Шуңа күрә, абыйлары аларның ничек яшәгәннәрен үзләре күзәтергә карар кылалар.

Таң белән чалгысын иңенә салып печән чабарга китә ир-егет. Яшел үләннәр рәт-рәт булып тезелеп кала. Бәхетле Әббәс янагычлаганда чалгысы шундый итеп чыңлый, нәкъ менә яшь өмет, яшь дәрт шикелле инде.

Ярты көн буе кулларын уңга-сулга селтәп арыган иргә хатыны ашарга китерә. Ризыктан бераз авыз иткәч, тау буендагы әлеге җырлы чишмәгә нәкъ яшьләрчә көлешә-көлешә төшеп китә болар. Карап-күзәтеп тора абыйлары: килде болар чишмәгә, утырды шунда такта басмага. Чишмә тавышын тыңлап тын гына утырдылар. Аннары исә әкрен генә, мөгаен, чишмәдән откан якты моңнарын көйли башладылар — нәкъ яшьләрчә. Яшь чакта Әббәснең хатынына багышлап чыгарган көен әүвәлгечә ихлас җырлый болар. Күпмедер вакыттан соң икәүләп кулларын, битләрен юалар. Юалар да чиста кулларына агызып кына, рәхәт чигеп, су эчәләр. Бер йотым, ике йотым, өч йотым...

Ә торып бассалар, күзләре кичәгедән дә нурлырак, йөзләре кичәгедән дә чибәррәк һәм яшьрәк. Аңлап алды абыйлары боларның серен: бөтен хикмәт чишмәдә икән, чишмәдә!

Әнә бит Әббәснең бичәсе, кыз чагына кайтты куйды: кулындагы чәчәк бәйләменә һәм иренә чытлыкланып карый-карый биегән була. Көлә, шаяра — гүяки яңа чыккан кияүгә! Тегесе дә әле генә гашыйк булгандай, ничәмә ел гомер сөргән кортканы сөеп кочаклый!

Шушыны манзара кылган туганнар инде нишләргә кирәкне белгәннәр. Энеләре икенче килүгә ни күзләре белән күрсен: чишмә биек койма белән уратып алынган, ә капкасы төбендә эт белән сакчы тора. Әббәснең үзе булып үзенә мылтык төскәделәр:

— Әй, кем анда? Киләсе булмагыз, атып үтерәбез! Өс, өс!

Каравылчы сүзләрен куәтләп, бозау хәтле эт һау да һау Әббәс өстенә ташлана. Әббәс егылгач, аның аякларын чәйни. Чишмә тирәсе кан белән чуарлана. Күз яше төсле саф суга кушыла кан төсләре һәм чишмәнең элекке төсе күзгә күренеп үзгәрә-тоныклана...

Ниһаять, этне янадан үз янына чакырып алган каравылчы соңгы тапкыр акыра:

— Бу чишмә сезгә ялгыш бирелгән булган — атагыз хатасы. Бу чишмә асылда синең олы туганың урманында — әнә кара, бу җир, бу урман аныкы. Моңарчы аның киң күңелле булганлыгы аркасында гына рәхәт күргәнсез. Кеше малы белән кеше көн күрмәс — бетте, бар, юлыңда бул, бүтән бу тирәгә аякларыгыз басмасын.

Нишләсен Әббәс, каргана-каргана карчыгы янына кайтып китә бу: «Харам ризык белән әллә кая житеп булмый, бик тиз арада чукынышып катарсыз әле, алла боерса», — дип, чыннан да карчыгы янына баш иеп кайтудан башка чара тапмый шул.

Инде шунысын өстәү кирәктер: чишмә олы туганнарга бик үк озак шифа кыла алмаган имеш. Кеше авызыннан өзеп чөмерсәләр дә, аяк очларындагы сакал, авыз, күз тирәләрендәге җыерчыклар һич тә шо-

марырга чамаламаган һәм, киресенчә, тиз арада картаеп, ике олы туган берьюлы диярлек тәпиләрен сузгач, алар корган биек коймалар да, ни хәтле генә биек булмасын, барыбер череп ауган һәм чишмә нәкъ әүвәлгечә үз ирке белән чылтыкарга керешкән. Әмма аның элеккеге кү-әтле шифасы кире кайта алмаган. Карчык бер көнне, картының маңгай сырларын шомартырга теләгәндәй, үзенең шундый ук буразналы куллары белән сыйпый-сыйпый, авыр сулыш алган:

— И, картым, син дә бирештең лабаса.

— Үзең дә әллә кем үк түгел, кортка: аркаңа тау кунды. Төрлесен күрдең, рәнҗегән чакларың да булгандыр. Мәгәр кичер, бәхиллек бир!

— Ә чишмә... чишмә кемгә калыр икән?

— Малайга хәбәр җибәрик — кайтсын.

Шәһәрдә тормышын әллә ни көйли алмаган малайлары, ата-ана сүзен тыңлап, нигезне корытмаска ризалык бирә. Әнә шуннан башлана Габбасовларның нәсел чишмәсе.

Туган чишмәнең югалган шифасын һәм серен эзләү легенда хәлендә Нажарга да килеп ирешә.

Фәндә һәм табигатьтә даими үсешне һәм кинәт сикерешләрне инкарь итү дә, берсен икенчесенә каршы кую да ярамый. Бөтен бер лаборатория күзәтүләрен тән картаюына организм эшчәнлегенең яраклашуын өйрәнүгә туплау, яки картаюның сәбәпләрен һәм аңа юл куймау ысулларын эзләүне киләчәккә калдыру шулай ук дөрес булмас иде. Шушы фикер ачыклангач, Фәнүзә белән Нажар икесе ике якка тайпылды: берсе урманга, икенчесе — сазлыкка, чишмәләргә таба... Фәнүзә тизрәк тапты — моңарчы булмаган биоген стимуляторы синтезлауга кадәр барып житте. Бу табышмак риваятьтәгечә, яшәүгә кирәкле матдәләр нәкъ менә саз үләннәрендә күбрәк булып чыкты — тормыш әүвәлгечә, бөтен каршылыклары белән бергә һаман суда яралырга тырыша икән. Агуы да, даруы да — андыз белән аксыргак шикелле янәшә яши...

Фәнүзә күп кенә үсемлекләр һәм хайваннар табигатен өйрәнә килеп, тереклек итү барышында организмның яшәү процессыннан үз-үзен читләштерүе күренешен ачыклады. Хәзер ул шушы күренешнең тәгаен механизмын билгеләргә тырыша. Нәрсәдер табыла да язды диярргә кирәк. Тәҗрибәләр, эзләнүләр, күзәтүләр соңгы өч елда шул хәтле күбәйде ки, Садир Хәкимович аларны диссертация итеп язарга тәкъдим итте. Александр Иванович каршы килмәде. Фәнүзә, әлбәттә, көчен дә, вакытын да кызганмады. Ул инде бөтен кешелек хыялланган ачышка якынлашты диярргә мөмкин.

Нажар энисенең каты авырып киткәнлеген ишеткәч, Сазуленнан файдалану хакында да сүзне башлап Фәнүзә кузгатты.

Ният изгелеге сизелеп торгач, мөмкин булмаганны вәгъдә иткәндә дә күнелгә, ничектер, җиңел булып китә бит. Гамәлдә, авылның изге чишмәсе шикелле үк, Сазулен да легенда рәвешендә генә яшәсә дә... инде нииндидер өмет уята лабаса!..

Әнисенең чын хәлен улы менә хәзер генә бөтен житдилеге белән аңлады бугай. Әнисен хәзер әҗәл даруы гына коткарса коткара алачактыр. Ә болай... соңгы чик якын — бик якында гына инде. Нажарның үзен дөньяга китергән, күкрәк сөте һәм көче белән үстергән ана җир йөзендә бөтенләй булмаска тиешмени? Бик теләсәң, бик каты теләсәң дә бүтән һич күреп булмаска тиешме? Гаделме бу? Табигатьнең шушы хәтле дә рәхимсез катылыгы белән кеше килешергә тиешме? Юк, моның белән адәм баласы гомере буе бер генә көн, бер генә сәгатькә дә килешә алмаган һәм килешмәс тә. Юккамыни алайса дөньяда барча акыл ияләре адәмнең җаны һәм тәне чиксезлегенә һаман тирәнрәк, эчкәрәк керергә омтыла? Юккамы Нажар кешенең нәсел хәбәрен укырга һәм, кирәк булса, яңадан төзәтеп язарга хыяллана? Хыялдан узып, моңарчы акылга да сыймаган «язма»ларны кулына тотып, үз күзләре белән карый? Юккамы геннар хирургиясе чирле геннарны сәламәт геннар

белән алмаштыру дәрәҗәсенә ирешергә тырыша? Юкка гынамыни профессор Бетфорд, имин киләчәккә өметләнеп, үзенең рак ябышкан гәүдәсен тере килеш түбән температуралы анобиоз хәленә куйдырып, герметик кабергә салдырды? Юкка гынамыни?

Ә әни? Ул риза түгел андыйга. Нажар исә бу нияте белән әнисе тәненә мәңге кагыла алмаячак. Әнисе аның өчен артык изге. Изге әйбергә кул белән кагылу мөмкин түгел! Әйе, кеше күңелендә икенче төрле тойгы, икенче төрле караш та бар икән әле. Кеше үзенә табигать биргәннән артыграк алуны иблистән килгән гөнаһ дип саный. Бәлки андый хиснең табигыйлегенә Нажар ышанмас та иде, ләкин үз әнисенә аның беркайчан да ышанмыйча караганы булмады. Әнисе аңа шикләнер өчен әчмуха хәтле дә сәбәп бирмәде. Баланың анага табигый ышанычы һәм ихтирамы аркасында гына түгел, гомумән, алдаусыз дөреслекне үз колагы белән ишетеп, үз күзләре белән күреп торганга, шикләнергә хакы юк Нажарның. Һич тайчанмыйча нәтиҗә ясарга туры килә: Нажарның әнисе кешелек мәңге хыялланган әҗәл даруыннан баш тартты...

* * *

Хушлашканда әнисе: «Бәхилмен», — диде һәм үзе дә бәхиллек сорады.

— Бәхил, әни, әлбәттә, бәхил. Тик әле син терелгәч, тагын бер кабат иркенләп сөйләшербез. Кеше чирләми тормый бит, — дигән булды Нажар.

Әмма ул әнисенең терелмәячәген күреп тора иде, һәм үз хәлен ана үзе дә яхшы тойган булып чыкты.

Каранур дигән станциягә Нажарны автомобиль белән ике энесе озата килде. Ә билет алу дигәндә, монысы шәһәрдәгедән дә җайсызрак икән. Узган кичтән үк чират тезелгән. Күпме билет сатылачагын ходай да белмидер. Кечкенә вокзал шыгрым тулы. Болай да җимерек кәеф, үз шкаласының иң түбәнге сызыгына төртелеп, бүтән төшәр җае булмаганга күрә генә тукталгандыр. Чырайдан гына түгел, чыгырдан ук чыгарган яңа үзгәреш — касса ачылды һәм чын мәгънәсендә мәхшәр купты. Чиратка Нажардан соң беркем дә басарга җыенмый. Аннан алдамы, әле генә килгәнме, барысы-барысы алга узарга, билетны чиратсыз алырга азаплана — этеш, төртеш, кычкырыш һәм кәгазь түзмәс сүзләр. Димәк, Нажар Каранурда утырып кала. Ике көннән — командировка. Әйе, җәнҗал... Менә ул — күз алдында, хәзер үк башланды лабаса. Этеш һәм төртеш! Син дә эшкә кереш!

Абыйсының нәрсәләр уйлавын чамалап бугай, энесе Фәсил: «Сабыр ит, Нажар абый», — дип, кесәсеннән ниндидер таныклык алып кулына тотты да, адәм урманын аралый-аралый, кызыл касса авызына якынлаша башлады. Аның кулындагы документны күргәнгә, ахры, махсус рәвештә каршы килүче булмаса да, барыбер юл бирергә дә ашыкмадылар. Шуңа күрә Нажарның олы энесе Фәсилне эчкәрәк этәргә керешге. Этеш-төртеш Фәсил өчен кулай түгел. Аның кулы авыртадыр, протез кулның төшеп калуы да ихтималдыр. Авырту көзән җыерган рәвешле булып Фәсилнең йөзенә үк чыккан да инде — төркем арасыннан кызганыч чырай күренеп-күренеп, бәгырьне әнисе янында торган чактагы кебек үк кисеп-кисеп куя. Ләкин нишләргә? Читтән карап күзәтергә генә кала. Ә бүтәннәр?.. Бүтәннәр көрәшә!

Ни өчен? Нәрсә хакына? Кечкенә нәрсә өчен, билет өчен генә болай ук тартышмас-этешмәсләр иде. Зуррак, әһәмиятлерәк нәрсә өчен булырга тиеш. Кассадан билет түгел, барча авырлыклардан берьюлы котылдыра торган хикмәтле әйбер бирә торганнардыр... Нәрсә? Ни? Ах, ничек әле зиһене шуны төшенми торган — ул хикмәтле әйбернең исеме дә бар бит, ул «Сазулен» дип атала. Әйе, кешене яшәртә торган... Картларча әйткәндә, әҗәл даруы. Мөгаен шул даруны аптекадан барып алырга рөхсәт язуы бирәләр кассада. Шул даруны башкалардан

тизрәк һәм күбрәк эләктереп калу өчен сугыша адәм балалары... Шуның өчен, шуның өчен!

Читтәрәк, тыныч почмакта, җимеш әрҗәләре катлы-катлы тезелгән төштә, көньяктан килеп чыккан сатучы икәнлекләре күренеп торган өч ир кеше тыныч кына басып тора. Аларның берсе инде поезд туктальшына, платформага да барып килде һәм аңлашылмаган телдә нәрсәдер әйткәч, каршыдагы иптәше кесәсеннән билетлар чыгарды һәм аларның мөгаен кайсы вагонга икәнлеген яңадан барлап, яңадан кесәсенә салып куйды. Болар әлеге җәнҗалга катнашмадылар, димәк. Билетны башка ишектән — җайлырак ысул белән һәм чак кына алданрак алганнар... Монысы бәхәссездер ки... Димәк, елгырлардан да өлгеррәкләр бар. Яшәү өчен тырыша барчасы — тизрәк һәм күбрәк булдырырга: ризыкны, чишмәдәге суны, билетны, данны, бәхетне, тормышны, даруны... әҗәл даруын...

Адәм балалары! Бар бит менә шундыйлар да. Барча бәндәләр Наҗарның әнисе кебек түгел ләбаса! Баш тартмыйлар, даулыйлар, сугышалар!

Ул арада Фәсил дә плащ төймәләре өзгәләнгән һәм үзе тирләгән-пешкән, бердәнбер кулына зәңгәр кәгазь (зәңгәр кош) тоткан хәлдә, адәм дәрьясыннан атылып чыкты. Шатлануы — чамасыз.

— Булды, Наҗар абый, менә!

Наҗар үзе дә баш тартмады...

Баш тартырга җае да, хакы да юк, союз күләмендәге әһәмиятле командировканы өзәргә беркем дә рөхсәт итмәячәк. Ә башкаларның? Менә тарткалаш-төрткәләшне уңышлы рәвештә әле дә дәвам иткән гражданнарның? Бәлки аларның да Наҗарныкы кебек үк «кичерерлек сәбәпләре» бардыр? Югыйсә нишләп үзен-үзе суккалап та тарткалап мыскыллатсын һәм миңрәтсен ди кеше? Аның да тәне авырта, җаны сызлый беләдер бит? Шул ук материалдан ясалган бит алар да... Күгәрчен һәм әрлән төсле, тургай һәм аю төсле, кабан төсле үк?

Һәркемнең гомере бер генә. Үзенә бирелгән вакытның минутын да әрәм итмичә яшәргә, ашарга, ләззәт кичерергә, мунча керергә, опера тыңларга ашыга адәм баласы. Билет, билет, билетлар кирәк кешегә. Магазиннарга барырга — акча, акча һәм акча кирәк, күбрәк, мөмкин кадәр күбрәк һәм тизрәк. Шул вакытта гына ул үзенең тулы хокуклы, бүтәннәрдән һич ким дәрәҗәдә булмавын сизәчәк. Өстенлек сизсә, шуңа җай туры килсә, тагын да шәбрәк. Шәбрәк! Матди һәм әхлакый капитал — өстенлекнең алшарты, нигезе һәм төбәсе. Нык ит шуны, биек ит. Башкаларның кулы һәм теше үтмәслек, житмәслек булу хәерлерәк. Хәерлерәк! Яшәргә кирәк! Мөмкин кадәр озаграк. Берничә гомер бирелсә дә баш тарту хаҗәт түгел.

Кояшка һәм әҗәлгә туры карап булмый — күзләр тиз яшьләнә. Кояш шуңа күрә үзе безгә туры карасын, ә әҗәлнең күзләре сукырайсын!

Поезд китәргә сәгать чамасы гына калгач, инде борчылыр сәбәп калмагач, энекәшләр, башка ашыгыч вазифаларын үти торыр өчен, авылга кайтып киткәч, Наҗарга ямансулап йөрергә тагын бераз вакыт бирелде. Кызганыч та бит, нишлисең.

Наҗар Фәсил энесе калдырып киткән билетның дәреслегенә ышаныр өчен җентекләбрәк карыйсы иткән иде, кимчелек тиз көттермичә үк килде чыкты. Энесе аңа очсызлы билет, инвалидларга бирелә торган билет алган лабаса. Кулга тоткан удостоверениесе шундый булгач, шуны биргәннәр. Ә Наҗар, билетны башкалардан алдарак алу белән берләттән, әле очсызгарак та эләктергән икән... Тагын бер ялган катнашачак...

Уф, ихтыяр көче бир, түзем бир, ходай! Нишләргә?

Инде билетның булганы сатылып беткән, булмаганны таптыра алмаганлыктан, җәнҗал да басылган, касса ябылган. Шакысаң, ачулану лары мөмкин.

Тук, тук, тук.

— Минем билетны алмаштырып булмас микән?

— Ничек, ничек?

— Миңа льготалыны биргәнсез... ялгыштыр инде...— (Тагын ялган!) — Тулы хакы белән бирсәгез, әйбәт булыр иде.

— Нindие эләккән, шуның белән китегез.

Тик хәерсез, бүтән сүз ишетү мөмкинлеген шунда ук харап итеп, касса капкачы шап ябылды. Тагын шакып карасаң, әдәпсезлеккә, тинтәклеккә охшаячак. Шулай бит? Шулай, тынычлан.

Нажар мөмкин кадәр тыныч булырга тырышкан хәлдә, поездга юнәлде. Купеда ниндидер командировкадан кайтып килүче слесарь-монтажникларның көн-төн эчеп кайтуын исәпләмәгәндә, хафаланырлык сәбәп чынлап та сизелмәде. Әйбәт кенә кайтып җителде.

* * *

Әмма таңда тагын юлга чыгарга кирәк. Ә күз алдында — һаман әнисе, чаршаулы карават. Инде ни хәлдә икән? Соңгы сәгатьләрен кичерәдер ана.

Сизенүнең чынлыгын раслап, кич белән... телеграмма...

Нажар, хәлне аңлатып, Садир Хәкимовичка шалтыраткан иде, көтелгән һәм ишетелгән таныш җавап: «Үз үлемеңнән башка уважительный сәбәп була алмый. Командировка иң югары инстанцияләрдә хәл ителгән».

Катылыкның ниндидер мәгънәсе төсмерләнә кебек. Кешелек тарихында терелтү мөмкин булган мамонтның табылу очрагы бүтәнчә мәңге кабатланмаска мөмкин. Ләкин әни? Нажарның әнисе кабатлана алачакмыни?

Тик Нажар командировкага бармыйча кала алмады. Һәм күңелендә гомер буе җуелмаячак төссез сурәт белән кайтты.

Мамонт баш сөяге эченнән «яхшы сакланган» дип табылган миматдәсен илнең иң күренекле һәм ышанычлы белгечләре бергәләп алдылар. Битараф сыекча эчендә күзәнәкләрнең кайберләре тере кебек, аратирә селкенеп куйгандай итте. Микроскоп астында импульс кабатлангандай тоелды. Ләкин озак та үтмичә тынды. Сыекчага кушылып, аның үзәк өлеше юкка чыкты. Шул рәвешле түгәрәк, контурлы сызык — бөҗра — барлыкка килде. Ягъни, ноль сурәте пәйда булды. Нәтиҗә — ноль! Соңынтын исә ноль үзе дә эреп, шул рәвешле мамонт бу дөньядан тәмам китте... бетте...

Нажар моны чын фаҗига итеп кичерде. Өстәвенә әллә юлда, әллә тундраның үзендә үк салкын тиеп, тагын тамагы үзен сиздерә башлады. Шулай да өйгә исән кайтып егылды дияргә кирәк.

Ике кулы белән маңгаен, чигәләрен кысып диванда утырганда, Фәнүзә авылдан килгән хәбәрне җиткерде. Тундрада илнең могтәбәр белгечләре белән бергәләп, мамонтны кабат бар итәргә җыенган чакта, Нажарның әнисен соңгы юлга озатканнар. Нинди генә көчле логика белән дә аңлатып, аклап була алмас үкенеч: соңгы чиктә Нажар үзенең бала булу бурычын, табигать, әхлак, кешелек бурычын үти алмады — соңгы сәгать-минутларында әнисенең баш очында була алмады.

Мәңгелек үкенеч булыр төсле һәм аны беркайчан да төзәтеп булмас төсле. Мәңге кайтарып булмаслык югалту. Ул әнисен югалтты. Һәм әнисен генә дә түгел бугай...

## Кинәтлек өстенлеге

Бәла ялгыз йөрми диләр. Соңгы вакытта ул Нажарны үз итте. Кайтып, өч көн эшләгәч тә, сәер ангина башланды. Тәндә температура юк, ә баш авырта — бөтен гәүдә кыйналган кебек, кан оешкан кебек.

Врач чакырдылар. Кичкә таба практикант студентлар килеп керде. Авыз ачтырып маташтылар, ул инде шешкән иде — рәтләп ачылмаганга күрә, әйбәтләп карый алмасалар да, бик хафаланмадылар. Ангинадан антибиотик таблеткаларга рецепт яздылар да муенга тоз җылытып куярга, яки аракыдан компресс ясарга куштылар.

Көн — төнгә, төн көнгә әйләнде — йокысыз тоташ томан. Температура — утыз тугыз градус. Шулай да пенициллинны алып, поликлиникага барырга кирәк. Җыенып беткәч кенә, кичәге практикант янадан килеп керде дә тамак-колак авырулары белгеченә күренергә кирәклеген әйтте.

Врач авызны ачтырып бер секунд та карамагандыр, кулындагы тимер калагын үз урынына бастырып та куйды.

— Бра-ат! Хәзер үк — больницага. Бүген үк операциягә — абсцесс! Икенче төрле әйтсән, бу инде чирнең канга йогуы, эренле шешнең үпкәгә таба шуыша баруы дигән сүз... Бу — үлем дигән сүз. Фәнүзә шуннан соң бер дә елмая, шаярта алмас булды. Такси чакыртып, тиз генә больницага юл тоттылар.

Авыруларны кабул итү бүлмәсендә аның ярым һушсыз хәлдә ярты көн диярлек утырырга мәҗбүр булуы, көндезге сәгать икеләрдә генә чират житеп, анда да белемнәрен камилләштерергә авыл больницаларыннан килгән яшь кенә ике хатын-кыз врач, аннары ике ир кеше — лор бүлеге врачы белән ассистент — төшеп каравы һәм шуннан соң гына палатага урнаштырулары истә сәер саташу шикелле булып калды.

— Лимфалар төененә тыштан керергә туры килә,— дип куйды врач.

Практикага авылдан килгән врач хатыннарның берсе аһылдап куйгангамы, хәлнең шәп түгеллеге Нажарның үзенә дә аңлашылып житте.

— Ияк астында олы җөй калачак,— диде ул.

— Зур түгел, кечкенәрәк.

— Барыбер.

— Яшәүне хәл итә торган нәрсә...

— Барыбер...

Врач баш чайкады бугай, һәм шуннан соң Нажарга тагын палатага кереп, кара томан ябынып ятудан башка чара калмады. Томан эчендә йоклапмы, йокламыйчамы төн уздырганнан соң торып караса, икенче ияк барлыкка килгән иде. Сул як бигрәк тә каты шешкән. Чакырылгач, ашханәгә керсә дә, кая ул, тамчы ризык үтмәле түгел. «Ризык барганда, аша да, эч тә син»,— ди торган иде аңа бабасы — Фәнүзәнең әтисе — исән чагында. Соң аңлыйбыз, артыгы белән соң аңлыйбыз шул...

Врач бүлмәсе. Кичәге урта яшьләрдәге врач һәм өлкән яшьтәге хирург. Башкалар мөнәсәбәтенә күз салсаң, соңгысының зур абруйлы белгеч икәнлеген күрү кыен түгел... «Яков Моисеевич, Яков Моисеевич»,— дип кенә торалар. Ә кичәге таныш врачка Унар Усманович дип эндәшәләр. Анысы Яков Моисеевичка — бүлек мөдире булган фән докторына кичәге уңышсызлыкларны санап чыккач:

— Шеш авызны ачарга ирек бирми, ләкин эчке яктан керергә иде,— дигән теләк белдерде.

Яков Моисеевич, бер сүз дә әйтмәстән, инструментка үзе тотынды.

Нажар авызны чак кына булса да ныграк ачты бугай, чөнки Яков Моисеевич үзенең бу хактагы искәрмәсен бүтән ясамас булды. Боерыклары: «Төкерегез, төкерегез, тиз, тизрәк!» — дигән кыска сүзләргә генә кайтып калды. Инструментлар алмашына торды. Доктор кискен тавыш белән: «Тиз, тиз, тиз», дигән сүзләрне генә ярдәмчеләренә әйтә һәм еш кына: «Сез нәрсә, үлдегезме әллә, тере түгелме әллә сез?» дип, тавышын югарырак нотага да күтәрә иде...

— Тиз, тиз. Төкерегез!

Нәрсәнедер кисә, үзе кискән жиренә кечкенә марля кисәге белән ниндидер порошок сөртә тора. Аннары, нәрсәнедер төенләп, төенгә беркетелгән тимер кисәген читкә каерып куйгач, яңа инструмент сорый:

— Тиз.

Нажар сизә: үткен, нечкә тимер, тамак төбеннән аскарак уза, нәрсәнедер тишә, кисә һәм... секунд эчендә әйтеп аңлата алмаслык үзгәреш — Нажар хәтта ояла бугай. Мәгәр нишләсен, шеш үз әшәкелеген үтәгән — эренләгән. Нажарның борынына шуның исе килеп бәрелгәч, уңайсыз булып китә, башкаларга да сизелгәндер дип кыенсына. Ярый әле врачлар бүтән халык... Аларны мондые түгел, гаяррәкләре дә чиркандыра алмый — алар табигатькә якын — кеше организмын үзгәртү өчен көч һәм вакыт исраф иткән галимнәрнең үзләренә караганда да якынрак, батыррак һәм, ихтимал, кешелеклерәк.

Менә доктор үзе генә үтеп керә алган әҗәл чыганагын корытыр өчен һава белән эшли торган суырткыч сорап алды һәм аның белән дә тиешле тирәнлеккә үтте. Агулы сыекчаны ачулы суыртырга керәште. Һәрхәлдә, Нажарга шулай тоелды. Аннары гына бәйләп куйган төеннәрен чишеп, тагын, тагын порошок сипте.

Эш бетте бугай. Үзеннән башка беркем дә эшли алмаганны үтәүдән микән, канәгатьләнү алыр өченме, читкәрәк барып утырды да Нажарга текәлеп калды.

— Сезнең тегендә китеп баруыгыз да ихтимал иде.

— Бик тырышсакмы?

— Тырышмыйча гына. Хәзер куркыныч бетте. Ләкин эш бетмәде... Миндальләр өшеп ләшперәйгән. Бигрәк тә сул як. Шунысын алып ташларга кирәк. Әгәр үзегез риза булсагыз.

— Шулай кирәкме?

— Әйе.

— Ничек тиеш тапсагыз, шулай эшләгез.

«Бер тапкыр үлемнән коткарган кешегә гомер буе ышанырга мөмкин»,— дип тә өстисе килгән иде дә, кызганыч, мондый фикерне әйтү читен. Яхшылыктан яхшысынмый адәм баласы... төчелектән курка. Әмма доктор аның йөзенә карап барысын да аңлады мөгаен. Нажар үзе дә коткаручысы күңелендә тиз арада яңа гамь туганын күреп алды. Әнә доктор башка врачларга борылды:

— Канның оешу тизлеге ничек?

— Без, без... неотложка бит,— диде дежур врач.

— Өлгерә алмадыгыз!

Барчасы — ык-мык. Курку, гаҗәпләнү, сөенү. Алар Нажарны коткарырга шулкадәр ашыкканнар ки, кан оешу тизлеген тикшерергә үк онытканнар. Температура кызулыгының кырык градус икәнен бәлки белгән хәлдә... Менә шушы буладыр «неотложка» дигәннәре. «Үз каныма булыгып үлүем мөмкин булган һәм тагын очраклылык коткарган»,— дип уйлап өлгергәнче, яңа боерык:

— Тиз, тиз генә анализлагыз. Тиз. Тиз генә операциягә. Хәзер үк.

Шул сүз белән Нажар, палатага кереп тормыйча, лаборатория бүлмәсенә менгән иде, анысы бикле икән инде. Палатага кереп хәл алудан башка чара юк. Икенче көнне иртән лаборатория ачылышына менәм дип торганда исә ишекне өлкән сестра ачты:

— Габбасов, киттек, сезне көтәләр.

«Лаборатория ачылган икән»,— дип уйлап өлгергәнче, ниндидер таныш булмаган икенче кыз аны култыклап алды да:

— Операция бүлмәсенә,— дип куйды.

«Бер тапкыр үлемнән коткарган кешеләргә икенче тапкыр ышану кыен түгел».

Кан оешуы кичә харап итмәде бит — врачлар үзләре күреп ышанды. Шуңа күрәдер инде, бу юлы да анализ нәтиҗәсе белән кызыксынучы булмады.

Алып төшкән кыз белән икенче врач хатын аны операция урындыгына утыртып, авыз-борын турысын гына ачык калдырып, ак киндер белән биләп куйдылар. Нажар яңадан сабый хәленә кайтты. Тамак төбенә уколлар кадагач һәм нәрсәдер исләткәч, ул тормыштан янә ераклашты.

Кешеләр ят дөнья әһелләре кебек тоела башлады. Дөнья караңгыланды. «Кояшка һәм әҗәлгә туры карап булмый». Бу фикер инде көчен җуйгандай тоела иде. Ул күз алдында әҗәлне күргәндәй булды. Әҗәл, ни өчендер, кабан дуңгызы рәвешендә алга килеп басты...

Әмма Нажар каушамады. Үзен киләчәктә һәм галәмдә яшәячәк зат итеп сизде һәм җирдән кайчандыр үзе юллаган мәгънәләрне чит кеше булып тыңлагандай тоелды. Күңелендә ышаныч: «Кешелек — галәмдә ялгыз. Ләкин ул үзен саклый алачак, исән калачак! Галәмнәргә адәм үзенең барлыгы хакында хәбәр җибәрде. Кеше — үлемсез. Үлемсезлек — вакытны җиңү дигән сүз».

Тавышлар...

Тавышлар — төрле. Тавыш — колактан бирелә торган дару яки агу. Нажар шифалы тавышлар ишетә. Ул үз дөньясына кире кайта да инде каршында кем торуын күрә: кичә Нажарны бүлек мөдиренә тәкъдим иткән яшьрәк хирург — Батыршин күзгә күренгәч, кара дуңгыз тиз арада юкка чыга.

Хирургның кәефе кичәге төсле түгел. Бүген тәнне ярыйсы ук мул кискәләсә дә үз Прометееның нык торачагын ул инде белә. Шулай да операциягә әзерлекнең нинди булганын тикшерер өчен генәме, әллә болай бәйләнешкә керер өчен:

— Авыртмыймы? — дип сорый.

Ә Нажарның теле дә, тавышы да юк, иректә күзләре генә калган. Әйтәсе килгәнне ул күзләре белән әйтә — доктор аңлый. Кызык бит элемтә — бар бит менә физионизм дигәннәре, бар бит менә сүзсез аңлашу. Нажар еш кына шулай үз директоры белән — Александр Иванович белән аңлаша иде. Кайчан да булса киләчәктә барлык кешеләрнең сүзсез-тавышсыз гына сөйләшә алачагына ышана Нажар. Бу зиһен үсешенең алдагы дәрәҗәсе булачак.

Пычак белән тамак төбендәге миндальнең ничек киселүе тоелып тора, әмма авыртмый. «Прометейга наркоз ясап тормаганнар шул — аның хәле авыррак булгандыр...»

— Без сезгә өлешчә наркоз ясадык,— ди Нажарның нәрсә уйлаганын сизгән хирург.

Биотоклар! Әйе, шулар! Укый бит фикерне Батыршин, ул зиһен үсешенең алдагы дәрәҗәсенә бүген ирешкән. Нәкъ Александр Иванович кебек. Дөньяда Нажар белгән ике шәхес кешелекнең ерак киләчәгенә иң беренче булып барып җиткәннәр. Аларны аңлаучылар, кирәгенчә, тиешенчә аңлаучылар, ай-һай, әле бар микән. Нажар тоя, чөнки аның эше шул тирәдә. Нажар үзенең барлык күзәтүләрен дөньяга игълан иткәннән соң, практика өчен менә шушындый үткен һәм сизгер куллы — нә очы белән эшли алырлык хирурглар кирәк булачак. Әгәр Нажарны үлемнән коткаручы Батыршинны һәм доктор Яков Моисеевич Вертлибне шул көннәргәчә саклап булса, кешелек башка төр операцияләр ясауга ирешәчәк!

Батыршин кыскычы тамак эченнән чама белән ике квадрат сантиметр ит кисәге йолкып чыгарды. Үз тәненнең бер өлешен ит кисәге итеп күрү шулай ук сәер...

— Бөтен нәрсә бик гади бит,— ди Батыршин фикер булып формалашып бетмәгән тойгыны аңлап.

Һәм хирург тагын вак-төяк кисәкләр йолкып чыгаргач, Нажар, үз тәненең ничектер җиңеләеп калганын, операциянең уңышлы төгәлләнгәнен сизде. Батыршинның үз эшеннән канәгать икәнлеге, кичәге Яков Моисеевич кыяфәте белән каршыга утырып, пациентына текәлеп калуыннан да күренде.

— Я, ничек?

Тел инде азат икән.

— Тагын ниләр эшләргә кирәк, барысын да эшләгез.

— Хәзергә җитеп торыр.

Бая операциягә әзерләшкән чибәр кыз (әйе, аның чибәрлеге күренә дә башлаган икән!) Нажарны култыклап баскычка таба алып китте. Бер-ике генә адым арттан атлаган Батыршин:

— Сезгә сестраның менә нинди чибәрен сайладык,— дип шаяртты.

— Болай булса, мин көн дә бер операциягә риза.

— Болай булса, тиз терелерсез.

Дөнья шулай тагын елмая, көлә башласа да, терелү теләге ашыгарак төшкән икән. Җиһанда кешегә тормыш, дару бирүчеләр арасында агу бирергә азапланучыларның да яшәп ятуын Нажарга җаны белән генә түгел, тәне белән дә тоеп расларга язган икән.

Ике көн тыныч узды.

Кичә бу вакытта Фәнүзә күчтәнәчләр белән бергә шактый озын хат җибәргән һәм аны: «Аска төшә аласыңмы? Көтәм»,— дип төгәлләгән иде. Нажар төшә алмаса да, ярыйсы ук күтәренке кәеф белән: «Хәлем шәп, бер операция булды, иртәгә тагын берне ясаячаклар»,— дип җавап бирде. Фәнүзә бүген дә киләсе иде. Нажар кемнең дә булса ишектән баш сузып:

«Габбасов шушы бүлмәдәме, сезгә килгәннәр анда!» — дигән шатлыклы хәбәрен көтә башлады. Кичә, зиһене эшләмәгән көнне ишетелгән иде шундый матур сүзләр, ә бүген, нишләптер, соңлады.

Эше җитди шул Фәнүзәнең: берничә көннән — диссертация. Нажар бу көннәрдә аның янында булырга, чынлап ярдәм итә алмаса, яхшы сүзе белән үсендерергә тиеш иде. Нинди вакытта, нинди вакытта бер үзен калдырып китте бит. Шулай да бөтенесе көйләнер, чөнки директор урынбасары булган Садир Хәкимовичның бу араларда гаять ярдәмчел кеше икәнлеге күренде, артык борчылырга ничек тә ирек куймас.

Менә бит кеше ничек үзгәрә: университетта уку һәм аспирантура елларында да, соңрак төрле урыннарга киткәч тә якын дус булдылар, аннары бәйләнешләре суынды, арада боз таулары калыкты һәм алар менә тагын язгы кар шикелле акыртын гына эреп югала башлады.

Ярдәм итәр Садир дус, ташламас...

Төш җиткәнне белдереп, ашханәгә дәштеләр. Анысы каршыда гына. Нажар торып чыккач, гадәти аш бирделәр. Ашап караса да...юк, бармады аш, уза алмады тамактан. Дөрес икән шул, әй дә хак икән: «Ашый алганда аша, эчә алганда эч».

Чәй дә эчеп булмады, узмады.

Фәнүзә ни дә булса тамактан үза торганны китергән булыр иде...

Тагын палатага кер, ял ит, уйла, башың эшләсә.

— Габбасов, температурагызны үлчик әле?

Температура утыз сигезгә төшкән иде.

Тирә-юньдәге әйберләр үз төсләре һәм үз рәвешләре белән күренә башлаган икән. Торып басарга һәм тәнгә бераз тормыш бирергә кирәк. Ләкин аякка баскач күз алдында йолдызлы күк йөзе барлыкка килеп җемелдәргә керешкәч, йөрәк җилкенү аркасында, Нажар караватка яңадан утырырга мәҗбүр булды. Нәкъ менә шул вакытта бүлмәгә яшь кенә егет кереп, аңа пакет тоттырды. Фәнүзә килгән! Язуында бу юлы ике-өч кенә сүз — хәл сораша. Ә Нажар аның үзеннән хәбәр көтә бит. Тиздән — яклау көне... Ничек бара икән эшләре? Төрлесен көтәргә мөмкин ләбаса!

Хат алып менгән егет — унынчы класс укучысы, шушы ук бүлмәдә ята. Нажарның нәрсәдер язганын һәм кире җибәрәсе вак-төяк белән бергә пакетка салганын күргәч, санитаркаларны көтәргә бирмичә, аска, Фәнүзәгә үзе үк алып төшеп китте. Фәнүзә аннан хәлне тагын сорашкан.

— Ул беркем белән дә сөйләшә алмый, аның тавышы юк,— дигән егет.

Тавышсызлык кара сакал шикелле һич тә калмый, иярә бит, иярә бирә...

Фәнүзә китеп бер-ике сәгать үттеме-юкмы, күчтәнәчсез генә икенче язу менгезделәр. Кемнән булыр дип уйлап өлгергәнче, әллә нинди мәгънә-

сез сүзләр, җәядән ычкынган уклар мисалында, йөрәкнең нәкъ үзегенә килеп тә кадалдылар. Аларның мәгънәсенә түгел, үзләренең була алуына да ышану мөмкин түгел иде. Ләкин менә күр, алар менә язылган, алар менә күз алдында йөгерешә һәм биешәләр:

«Хөрмәтле Нажар Зәбирович!

Авырып киткәнсез икән. Шул сәбәпле без бик кайгырабыз, борчылабыз. Хәлегезне бераз булса да җиңеләйтү иде теләгебез. Тик менә үзебез дә кыен хәлдә калдык бит. Һәм монын да сәбәбе сезгә бәйләнгән. Эш шунда ки, сез моңарчы без белгән хөрмәтле һәм намуслы кеше түгел, ә бәлки гап-гади карак булып чыктыгыз.

Мәгълүм булганча, үзәк нәшриятта бер фәнни җыентык чыккан. Анда илнең атаклы галимнәре рәтендә сезнең исем белән дә зур хезмәт басылган. Әйбәт мәкалә. Тик менә аның авторы сез түгел бит. Сез үз аспирантыгызның хезмәтен үзләштергәнсез. Җитмәсә, шул нигездә доклад әзерләп, башкалага барырга җыенасыз икән. Тик менә белеп торыгыз, әгәр дә могтәбәр галимнәр каршында шул докладны ясарга җөрьәт итсәгез, шунда ук фаш ителәчәксез.

Без сезгә ул хезмәттән рәсми төстә баш тартырга, аспирантыгыздан гафу үтенергә киңәш итәбез. Моны шушы көннәрдә эшләргә кирәк.

Үтенәбез: сак булыгыз, акыллы булыгыз!

Хәер-хак дусларыгыз».

Дөньяны эссе һава, кара төс күмде. Нажар кәгазьне учына йомарлап бөтен көченә кысса да, сүзләр юкка чыгарга ашыкмады. Нажар караватында үрсәләнеп ятканга, ахрысы, бүлмәдәгеләр тиз арада чыгып киттеләр. Вакыт һәм мәгънә һуштан язды...

Кичке ашка чакырдылар — Нажар аңламады, кузгалмады. Кемдер кереп телевизорда әйбәт тапшыру барлыгын әйтеп карады — Нажар ишетмәде. Аның бөтен тәнен кара ут чолгап алды. Мөмкин булган барча авыртулар бөтен куәтен туплап күпме көйдергән, сызлаткандыр, әйтү кыен. Әмма бервакыт сызлау-авыртулар акрын-акрын кими, сүрелә барып, аннары тәнне тынычрак эсселек оета башлады кебек. Тагын күпмедер вакыттан соң, гүяки аның бүлмәсенә телевизор үзе кереп, бүлмәдә әллә нинди сәер сурәтләр барлыкка килде. Каршысында адәмгәме, әллә роботка яки берничә ел элек Нажар ядрәләреннән качкан кабангамы охшаган кара йолкыш пәйда булды сыман. Чакырмыйча килгән кунак, хәерсезгә каршы, артык кыю, хәтта артык әрсез булып чыкты. Әнә ул чит кеше караватына утырды да, аның тумбочкасыннан нидер алып, шатыр-шотыр кимерергә кереште. Шул хәтле шатырдатмаса, Нажарның колак төпләрен авырттырмаслык кыланса мөмкиндер дә бит — ни кеше, адәм дә, робот та була алмаган кара дуңгыздан. Тумбочканың үзен үк кимерә бугай яраксыз нәмәрсә. Кимереп-кимереп, нәрсәнедер голт-голт итеп йоткач һәм чәмергәч, бушаган савытларын тумбочка өстенә шакылдатып куйды. Лап-лоп атлап ишек катынарак килгәч, кайбер нәрсәләрне шулай ук шапылдатып раковина янындагы кәрҗингә ыргытты. Эше беткәндер, чыгып үз юлына китәрдер дип өметләнергә мөмкин иде. Юк. Кабан, ике аякланып, Нажар каршына килде дә, тиле кеше сыман авызын ачып, текәлеп калды. Нажар бу җан иясенең кем икәнен чамалый. Ясалма рәвештә тудырылган чын кабан ул. Аңа исем кирәктер. Нинди исем кулай булыр икән? Биокиборг — биологик һәм кибернетик җайланмалар белән барлыкка китерелгән ясалма кеше дә шундыйрак буладыр. Экстра-тойгылар, экстра-фикерләүләр дәрәҗәсенә ирешкән Демон... Шуны гамәлдә раслар өчен туп-туры сорау:

— Син кем?

Карачкы, гаҗәпләнгән рәвештә чәүмәлгәндәй, башын чак кына алгарак иеп куйды:

— Ничек, ничек?

— Син Тилебаш бит?

— Мин?

— Исемең — Тилебаш. Явызлык тулы шушы хатны син яздың, кулыма үзең тоттырдың.

Кабанның бераз гына кәефе киткәндәй тоелды.

— Шулаймыни? Мин Тилебашмыни? Ә син аны каян беләсең?

— Чөнки сине бар иткәндә минем белгечлегем дә ярдәм итте. Мин — микробиолог, геннар инженерлыгын барлыкка китерүчеләрнең берсе. Ә чын иҗатчың — Садир...

— Менә ничек! Менә нинди кызык!

— Син әле дөньяда мөстәкыйль рәвештә шушы көннәрдә генә йөри башладың.

— Син чирләгәннән соң.

— Әйе. Ләкин сине контрольдән ычкындыручы мин түгел. Без сине авыл белгечләренә тапшырган идек. Алар кем икәнеңне, куркыныч икәнеңне белеп җиткермәгәннәр. Хәзер син, Тилебаш, авылдан шәһәргә, бер оешмадан икенчесенә тиз арада узып, акыллы кешеләрне куркытып, алардан өстен чыгачаксың да коточкыч деспотка әвереләчәксең. Хуҗа булачаксың да аннары бөтен дөньяны үзең теләгәнчә идарә итәчәксең.

— Юл күрсәтүеңә рәхмәт. Нәкъ шулай булачак.

— Иреккә чыгаручыларга әйтерсең рәхмәтләреңне.

— Монысын да шәп әйттең, бик кызык. Шулкадәр дә башлы адәм икәнсең.

— Бик тә кызганыч. Үзебезнең ачыш үзебезгә куркыныч дошман булып чыкты. Син безне харап итәчәксең, бернинди бомбаларсыз, тавышсыз-тынсыз.

— Минем җиңү — бөтенләйгә!..

— Синең җиңүеңә кешеләр арасындагы каршылыклар ярдәм итәчәк.

— Алар миңа хәзер үк булыша.

— Син хөкемдарлык иткән, син яшәгән гарип дөньяны шундый адәмнәр үз кулларына алачак. Намуслы, вөҗданлы кешеләр колларга әвереләчәк. Җәмгыятегез әшәке җаннар җәмгыяте булып торачак. Ә бу инде теләсә генә нинди җимергеч сугыш нәтиҗәсеннән дә яман булачак. Әшәке җаннар җәмгыяте!

— Мәңгелеккә!

— Сезнең өченмени, Тилебашны мәңгелек итәр өченмени без тырыштык, шуның өченмени Фәнүзә һәм аның җитәкчеләре кеше гомерен озынайту юлларын шул кадәр олы газаплар аша эзлиләр?! Без үләбез, бетәбез. Ә сез каласыз. Вәкил дигән адәм кала. Чын иркенлек алгач, ул нишләмәс! Кеше гомерен озайту нигә, нәрсәгә кирәк иде? Тормышны мәңгелек залим кулына тапшыру өченме?!

Тилебаш җавап бирмәде. Үзенең тәрбияле дуңгыз һәм кыргый кабан кушылмасыннан барлыкка килгән калын һәм куәтле тавышы белән нәкъ җүләр кеше сыман кычкырып көлә-көлә, ишектән чыгып китте.

Менә нинди тавыш та яралды — менә нинди коточкыч тавыш та яңгырап китте галәм чиксезлекләренә! Әшәке җаннар җәмгыяте мәнфәгатьләрен яклаган куәтле аваз! Кем уйлаган!?

Ә бит теләкләр нинди изге иде. Теләкләр, өметләр, хыяллар төгәл фикер орлыклары булып өлгергән иде. Рациональ орлыкның генетик программасын ачыклау, икенче төрле әйткәндә, каты чикләвекне вату күпме намуслы кешеләрне тешсез калдырган иде, җитмәсә, чикләвеге кортлы булып чыкты. Төкерергә кыенсынып тору мөмкин, әмма төкермичә дә булмый.

Тормыш мәгънәсен җуйды — мәңге яшәячәк кешеләр дә бер төс, бер аваз, бер ихтыярны тыңлап канәгать яшәячәк.

Анда кояш инде бу кояш түгел, ай инде ай түгел: салкын, күңелсез һәм күзгә бер нәрсә дә күренми — бүген дә, иртәгә дә, аннан аргы көннәрдә дә.

Ә дөнья буйлата кабан дуңгызы һәм кеше рәвешен берләштергән Тилебаш йөри... Кешелекне үз кулында тота, патшалык итә...

* * *

Ләкин караңгылык патшалыгы күпме дәвам итте икән? Чиксез вакытмы? Ә чиксезлекнең азагы була микәнни? Әнә бит нинди ягымлы тавыш, кызлар тавышы төнне җиңде куйды:

— Хәерле иртә!

Эх, җавап бирүче дә булса!

— Габбасов сезме?

— Мин.

— Градусник куегыз әле.

Нажар күзләрен ачарга тырыша, ләкин алар тагын йомыла. Шулай да ул градусникны ала һәм җайлап кына куя. Шуннан соң йокы акрынлап тарала. Аң кайта. Ләкин тәндәге кайнарлык кимергә һич җыенмаган, киресенчә арта гына төшкән, ахрысы. Яңадан кереп градусникны караган сестра шул тоемны расларга мәҗбүр:

— Менә сиңа — яңадан утыз тугыз!

Һәм караватт култыксасына беркетелгән кәгазьгә, шул санны, мөгаен, төшереп тә куя. Сүзгә ышанасы килмәгәнлектән, Нажар язуны торып карарга азаплана. Ләкин нишли баш? Башта мең-мең йолдыз мириадасы айкала...

Шулай да Нажар, башын учлап бераз утырганнан соң, үҗәтләнеп аягүрә басты. Тастымал белән тәннәрен сөртте дә кран янына килде. Җылымса су белән юынгач, күзләре көннең ярыйсы ук якты икәнлеген абайлады.

Нажар кухня ишеге янындагы чиратка басты. Нибары ун-унбиш кеше. Ләкин чират бозучылар шунда да бар. Бүлмәдән берәү алдарак чыгып баскан да бүтәннәре аның янына елыша. Минутларны булса да, кемнән булса да отып, хәрәмләшеп алырга кирәк. Уффу! Үртәлә Нажар. Хәлсезлектән генә түгел.

Чират бозу — кешелекнең иң алама чире. Кемгәдер, кемнәргәдер күбрәк кирәк — көч, өстенлек, җир, күк... Нәкъ тере организмдагыча — югары төзелешле күзәнәкләр урынын түбән төзелешле күзәнәкләр ала. Башта бу чир сыман тоелмаса да, соңыннан яман шешкә әйләнә. Кешенең җанына күпме шеш, эрен җыйналган, ә үзе сау-сәламәт төсле йөри — башкаларны акылга, сафлыкка чакырып һәм яман чир йоктырып. «Хөрмәтле Батыршин, хөрмәтле Вертлиб, зинһар минем җаныма операция ясагыз!» — дип алар килмиләр. Я ходай! Килмәячәкләр, чөнки бу чир аларга файда китерә. Операция — куркыныч. Әгәр аларның шешләрен ачсаң, дөньяның барча гөнаһсыз адәмнәре борыннарын томалап йөрерләр иде...

Әнә бит Нажар да максатына ирешә — аның да чираты барыбер җитте. Хәтта бүген аш биреп торучы хатын, фамилия сорап, операция ясалган кешегә махсус ризык әзерләнгән булуын әйтә белде һәм, хатасын төзәтеп, сөт тәсләрәк аш салып бирде:

— Аллалар ризыгы!

Бу сүзнең шаярту гына түгеллеген Нажар бер кашык аш капкач ук үзенең мескен тамагы белән тойды. Ризык бернинди ышкылусыз, терекөмеш шикелле, тиешле юнәлеш табып узды китте. Бер, ике, өч кашык. Тагын, тагын. Башкалардан һич калышмастан тамагын туйдырды Нажар. Калориянең тәнгә генә түгел, инде фикергә дә җитүе ихтимал...

Юынган чакта Батыршин кереп сәлам бирде дә кабул итү бүлмәсенә чакырды.

Профессор үзе тишкәләгән һәм кискәләгән урыннарны караганда:

— Чиста, чиста, ярый,— дип кабатлый торды һәм авырудан да хәл сорашты.

Нажар зарлана белми:

— Әйбәт,— дип кенә куйды.

— Әйбәт? Ә нигә температура төшмәгән?

Яков Моисеевич бу сүзләрне Батыршинга карап әйтсә дә, Нажар оялып башын иде. Батыршин шулай ук аптыраудан уза алмыйча:

— Логикага бөтенләй туры килмәгәнчә! — дип кенә куйды.

Чамаларга мөмкин булганча, дәвалаучыларның агулаучыларга каршы көрәшендә Нажар үзе ярдәм итә алмаганлыктан, шушындый рухтагы аңгәмәләр озакка сузылачак икән. Пеницилинның электән дә күп бирелүе аркасында, Нажарга тәэсир итми башлавы ачыкланып, ампиокиска күчеләчәк, лимфалардагы шеш җиңелергә ашыкмагач, тубс-кварц билгеләнәчәк, капельница дигән аппарат белән яңа кан яралышына булыша торган, кан бәясе торган эретмә биреләчәк һәм фурацилин яки стрептоцидлы сыекча белән тамак чайкау даими шөгыльгә әйләнәчәк. Ләкин сүз йоктырган өянәкләргә каршы докторлар дәва билгели алырмы? Бармы икән дөньяда шундый дару?

Бу хәлдә Нажарга бер генә кеше — Фәнүзә генә ярдәм итәр иде кебек, ләкин ул нәкъ кирәк мәлендә юкка чыкты. Нажар моның сәбәбен фараз итсә, йөрәге тагын жуылдап куя. «Әгәр... Әгәр дә Нажарны аяктан еккан хәбәр Фәнүзәгә дә сугылып узган булса? Шулайдыр, мөгаен, шулайдыр. Югыйсә ник килмәсен ди Фәнүзә?»

Әмма күңел булмастайга исәп тота, бәлки әле Фәнүзә эш аркасында гына килә алмыйдыр дип өмет итә, көтә.

Һәм менә, ниһаять, хәерле вакыт җитте дә бугай. Ишектән санитарка сузылып, кемнеңдер килгәнен хәбәр итте. Ашыга-ашыга, каушый-каушый төшсә, аста аны кызы Энже көтә икән. Кызын күргә ул беренче тапкыр тиешенчә сөенә алмады: «Эх, бала, балакай!»

Кочаклашып күрештеләр. Кыз этисен күргәч шундый шатланып кычкырды, хәтта йөз кешенең йөзәве дә борылып карады бугай.

— И, эти, эти! Шушы хәтле куркытырга соң безне? Үзебез генә калабыз дип торабыз. Синсез шул хәтле күңелсез икән — бернишлисе дә килми.

— Укыйсы да килмиме?

— Укыйсы да. Хәтта телевизор карыйсы килми.

— Барыбер карыйсыңдыр әле?

— Карамасаң, гел кайгырып утырырга туры килә.

— Үзегезнең хәл ничек соң?

— Үземнеке ярыйсы да бит.

— Әниең?

— Ул авырып тора.

— Авырып? — Нажар сискәнеп киткәндәй булды.— Грипп түгелдер?

— Грипп шикелле. Бүген бераз дарулар кабып, аякларына грелка куеп калды.

Кызының дөресен сөйләсә дә, нәрсәнедер әйтми калганлыгын күзеннән абайлап, Нажар кабат сорады:

— Ә болай булгач... институтта... анда ничек булыр икән инде?

— Белмим шул, эти. Анысын ул миңа әйтмәде.

Чире грипп кына булган очракта да Фәнүзә өчен моның Нажар чиреннән авыррак булачагы хәзер үк ап-ачык күренә иде. Шул сәбәпле, шатлыклы күрешү сагышлы саубуллашуга тоташты. Киткән чакта Энже үзе дә этисе күкрәгенә башын куеп, моңаеп алды.

— Эти, их, эти. Тизрәк терел, эти.

Бу сүзләрдә әйтеп бетерелмәгән уфтану ишетергә мөмкин иде. Шуңа күрә бугай, җаны тынычлана алмады. Хәле чак авырайдымы, әллә күз алдында, әллә кайдадыр еракта шомлы күләгә арлы-бирле йөренергә керешә. Тилебаш дигән кара өрәк йөри дөнья буйлата. Фәнүзә белән Энжене куркытыр өчен балконга үрмәли, тәрәзә кага, ишек шакый. Алай да булмаса, автомат телефон будкасына кереп, үзенең яман авазын телефон аша җиткерә. Кешеләргә ял итәргә ирек бирмәскә, йоклатмаска азаплана Тилебаш!

Нәкъ менә шуның аркасында Нажарның температурасы яңадан

күтәрелә башлады һәм кан басымы төшмичә аптыратты, ангина өр-яңадан тигән кебек, авырту кабат-кабат көчәя торды. Кан анализы РОЭның артык югары икәнен күрсәтә — илле ике, кырык бер, утыз биш, унтугыз, кырык ике...

Чирнең китәргә ашыкмавын күрсәтә торды саннар.

* * *

Фәнүзә Нажарны больницада әллә ничек бөтенләйгә калдырып кайткан кебек хис итте. Өстеннән йөк төшкәндәй булып, өй генә түгел, ирек тә киңәеп киткәндәй һәм, икенчедән, ничәмә ел бергә гомер кичергән кешесен инде ул тере килеш алып чыга алмас шикелле тоелып, җанына декабрь җиледәй салкын шом да җуылдап керде. Урамга чыккач та кая таба барырга икәнен чамалый алмыйча интекте.

Алар монда такси белән килде бит, троллейбус яки трамвай юлының кайда икәнлеген белмәве дә һич гаҗәп түгел. Әмма больницадан чыккач хәтсез араны ул трамвайгамы яки троллейбускамы барырга кирәген уйламыйча ук атлаган булып чыкты. Биш-ун минуттан соң гына сорарга дип каршыга килүче бер апаны туктаткан иде, бөтенләй кире якка баруы ачыкланды. Тукталышның кайдалыгын һәм өйгә кайтырга кирәклеген төшенгәч, каядыр ашыккандай йөгерә-атлый китте. Күңеле нилектәндер өши, күзләре елыйсы килгәндәй әчетә иде.

Беренче нәүбәттә Садир Хәкимовичка керде. Хезмәттәше көтелмәгән хәбәрне хафаланып кабул итте. Соңыннан гына тынычландырырга тырышып:

— Ул хәтле үк коелып төшмик, Фәнүзә Кадыйровна, кеше чирләми тормас. Терелер. Өч көннән, әйе, нинди олы эш... Шуны онытма һәм батыр бул. Җиңеп чыккач, мин сиңа бераз моңаерга да рөхсәт итәрмен, — диде.

— Рәхмәт, Садир Хәкимович, ярый әле сез бар.

— Хатын-кызны өйрәтәсе юк, ләкин алдан искәртеп куям — сез ул көнне гомер буе кайгы дигәнне белмәгән кеше булып күренергә тиешсез. Килештек бит шулай?

— Килештек, Садир Хәкимович.

Садир Хәкимович, әгәр мөмкинчелек булса, хәл белешергә барачагын әйтеп, больница адресын календарь битенә язып куярга да онытмагач, бераз күңеле тынычлана төшкән Фәнүзә, барыбер файдалы нәрсә башкара алмам дип тиз арада өйгә кайтып китте.

Йорт мәшәкатьләре белән асылда бит, иркенләп шөгыльләнергә туры килми бит — хәзер өстәлне тәртипкә китерергә кирәк. Күпме кер җыелган...

Ванна бүлмәсендәге кранны ачып, кухня ягында газ колонкасын кабызды да кер җебетергә тотынды. Бөтен өйне, бөтен киемнәрне чистарту хисе әллә ничек күңел җилкендергеч максатка әйләнеп куйды. Үз киемнәреннән тыш, бүтән вакытта үзе юсын дип калдыра торган Энҗе киемнәрен дә ванна бүлмәсенә чыгарды. Аннары Нажарныкыларга тотынды. Сабынлауны шулардан башлады.

Гадәттә Нажар киеп ташлаган кием яңа юылган кердән аерылмый. Аларны ул үзе генә аера белә. Шулай да барыбер юарга кирәк — чисталыкның чиге юк. Менә шулай... Иренең күлмәген кулына алгач һәм кайнар диярлек су ага башлагач, күңел бераз җылына төште шикелле. Әлбәттә, эшләргә кирәк, нәрсә белән булса да шөгыльләнмәсәң, ялгызлык тиз арада ихтыярны какшата, үтә җил шикелле өреп, җанны өшетә. Ә бу күлмәкләр һәм эчке киемнәрне юу үзе бер бәхет, ахрысы.

Телефон шалтырый. Эшне бүлдерерләр микәнни? Әллә тыңламаскамы? Юк, алай ярамый, институттан булуы бар, больницадан булуы бар.

— Әйе.

— Бу Нажар Габбасов квартирасымы?

— Әйе.
— Фәнүзәме бу?
— Әйе.
— Бу сезгә яхшылык теләп шалтырата торган кеше.
— Кем соң сез?
— Эш менә нәрсәдә, Фәнүзә, мин сезнең күзләрегезне ачмакчы булам, дөреслекне күрсен өчен.
— Менә инде... Нинди дөреслек?.. Юк, кем соң әле бу?
— Сезнең ирегез хакында...
— Әллә ул... зинһар, куркытмагыз.
— Юк, куркырлык нәрсә юк. Шулай да белеп торырга тиешсез.
— Ходаем, операция уңышлы узды дигәннәр иде бит.
— Белеп торырга тиешсез. Әйе, ул... Ул бер лаборантка белән сезгә хыянәт итә бит.
— Уф, котымны алдыгыз. Әллә ниләр уйлап бетерә яздым.
— Ә сезгә хыянәт... сезнең өчен кечкенә нәрсәмени?
— Хыянәт? Нинди хыянәт?
— Әйтәм бит, сез белмисез. Сез белмәгән бер лаборантка белән көн саен бергә булалар.
— Ә сез көнләшәсезме? Үзегез белән булмаганга күрәме?
— Ышанмаска тырышасыз. Ярый, бик әйбәт. Бер заман ышанырсыз да, соң булыр.
— Житте, сез Нажар салып ташлаган эчке киемдә казынмакчы буласыз. Сез... үзегез дә пычрак... пычрак эшкә тотынгансыз. Белеп торыгыз, аның үзенә түгел, киеменә дә кер кунмый. Сезнең генә кулыгыздан килмәс, пычрата алмассыз.

Фәнүзә ачу белән шыпылдатып трубканы урынына куйды да баскан җирендә каккан казыктай катып калды. Күңеле нәфрәт, җирәнү хисе белән тулды, ә башы һичнәрсә уйлый алмый иде. Була икән, шушындый хәл дә була, шушындый бәндәләр дә бар икән. Һәм алар әле кеше арасында йөри — кайберәүләргә чисталык хакында вәгазьләр укый, кемнәрнедер оялта... Үзен судан пакь, сөттән ак дип ихлас уйлап йөри. Син алар өчен тырышасың, шул кешеләрнең гомерен озынайту бәрабәренә үзеңнекен кыскартасың... Ә алар? Алар сиңа ярдәм итәргә тиеш, ә гамәлдә үз гомерен озынайтырга тырышкан кешеләрнең гомерен кыскарту өчен менә ничек тырыша, нинди түбәнлекләргә бара-бара үзләренең бөек максатларына ирешәләр! Ирешәләр!
Юк, дөрес түгел, сез Фәнүзәнең әле кем икәнен белми эш итәсез. Сезгә Фәнүзә гомерен кыскарта алу сәләте бирелмәгән. Сез... Сез...
Тукта, чү! Гайбәт һәркайчан гайбәт булып кала. Ләкин аңа бит бераз гына җай, элмәк кирәк. Кем бирде шундый җайны? Нажар? Чынлап та бирде микән, чынлап та ялгышты микән әллә?
Юк, мондый хәлнең ишетелгәне түгел, сизелгәне дә булмады. Сәбәп шул гына: кемгәдер Нажарның яманатын чыгарырга, пычрак атарга, намусын сатарга кирәк. Кемгә кирәк, ник?
Бу кеше Нажарның больницага кергәнен, Фәнүзәнең үзе генә, ялгыз гына калганын һәм зәһәр белән агулау өчен иң җайлы вакыт икәнен белеп эшли. Кешегә төркем эчендә кул күтәрү җайсыз, шуңа күрә әшәке җан кешенең ялгыз калганын көтә һәм үзенең пычрак гамәлен кыла — почмакта сагалап торып, арттан килеп һөҗүм итә. Кинәтлек өстенлеге аркасында синнән көчлерәк булып чыга. Бу исемсез хатын да әнә шундый мәлне көткән. Үзенә күрә аның планы бардыр. Беренче өлеше инде үтәлде...
Икенче өлеше: Фәнүзә, хыянәт җәрәхәтеннән зиһене зәгыйфьләнгән хәлдә, үлем түшәгендә яткан иренең битенә көнләшү зәһәрен бөркиячәк.
Өченчесе: Көтелмәгән чукмардан Нажарның хәле тагын да авыраячак. Ни хәтле начарланса, шул хәтле яхшы.
Дүртенчесе: Хыянәт авырлыгыннан һәм Нажарның ихтимал һәлакәтеннән, ә киметеп әйткәндә, аерылышу авырлыгыннан Фәнүзә үз их-

тырын да югалтачак һәм... диссертациясен яклый алмаячак. Конференц-зал тулы халыкка үзенең фикерләрен баштанаяк сөйләп, аңлатып чыга алмаячак. Алган хәлдә дә бик интегәчәк мескенкәй! Иң ихтималы — яклауга бара да алмаячак, ә барса, чыгыш ясарлык көч тапмаячак.

Бер атуда ничә куян?! Бер атуда! Менә бит әшәкелекнең көче. Бер җиңүгә ирешкәч, аның ул уңышын рәтле кешеләр мәңге тартып ала алмаячак бит. Менә бит нинди стимул! Нинди матур чишелеш!

Күңелдәге буталчык уйлар һәм тойгылар ваннадагы кер каралыгы белән буталып чайкалдылар. Рәнҗү, ваннага гына түгел, күңелгә генә түгел, дөньяга, галәмгә сыешмас дәрәҗәдәге рәнҗү җилкәне сыгып төшергәч, Фәнүзә ванна төбенә таянып, егылмыйча калды. Бөтен рәнҗүе тамак төбенә тыгылып, аннары кулына, бармакларына, күзләренә күчеп, күкрәкне, чигәләрне кыскач... авыртуга чыдый алмыйча кычкырып җибәрмәс өчен, тәндәге барлык әрнүләрен җыеп, аларны Нажарның юеш күлмәге белән бергә аяк астына кысты. Шул вакыт болай да суга манчылган күлмәккә Фәнүзәнең күз яшьләре өстәлә башлады. Күз яшьләре шабырдап түгеләме, әллә сабынлы кара сумы — белүе дә кыен иде.

Бер мизгелдә Нажар кайтып керер дә аның башын тотар, маңгаен, чәчләрен сыйпар төсле тоелып китте. Көтте. Ләкин тирә-як тып-тын иде... Тынлыкны ишетү бераз айныткандай булгач, Фәнүзә тураеп басты. Күлмәк әле һаман аның кулында икән. Аңа күзе төшүгә, Нажарның нинди хәлдә ятканы хәтеренә килеп, кызгану хисе яңаргач, ул өнсез ачыргаланган хәлдә, инде аңлы рәвештә юеш күлмәкне күкрәгенә кысты һәм тагын елап җибәрде. Тик бу юлы инде ул яшьләрен тыярга да тырышмады — үкседе дә үкседе — хәлдән тайганчы.

Күпмедер вакыттан соң юасы керләрен ваннада калдырып, залга чыкты һәм, мендәр салып, йокларга ятты. Нажар янына барырга вакыт җиткәнен тоеп, яңадан торса... бүген анда бара алмаячагын, телефоннан чаккан гайбәтченең беренче максатына инде ирешкән булуын аңлады. Ярый әле Энҗе кайтып житте. Әнисенең чырайсыз-хәлсез калганын тиз үк күрсә дә гаҗәпләнмәде — этисенең авыр хәленә юрады. Ул, әлбәттә, бераз хаклы иде.

Такси чакырып, китеп тә барды.

Кызының ягымлы сүзләреннән бигрәк, тыныч карашыннан һәм ышанычлы хәрәкәтләреннән көч йоккандай булгач, һәм битләрен-күзләрен әйбәтләп югач, җанга чынлап та бераз булса да сабырлык иңде. «Ярамый, ярамый җебеп-таралып төшәргә. Алар кушканны һәм көткәнне үтәмәскә, башкачарак, үзебезгә файдалы булганчарак тырышырга кирәк. Менә шулай, нинди эш башлаган идең әле? Чистарту, юу? Дөньяны чистартырга алыну бәлки дөрес булмагандыр, иллә һич югында үз өеңне чиста тотарга тиешсең. Дәвам ит».

Унбиш-егерме минут дигәндә, Фәнүзә барлык керләрне сабынлады да чиләккә шабырдатып су агызганнан соң, иелеп-бөгелеп, үрмәли-мүкәйли идән юарга кереште. Өч бүлмәнең өчесен дә юып чыккач, йокы бүлмәсенекен һәм Энҗе бүлмәсенең форточкаларын киереп ачып, аннары кухня ягында аш әзерли башлады. Кызы кайтып кергәндә өйгә инде күңел көрлеге һәм тәмле аш исе тәмам таралган иде.

— И, әллә нинди тәмле исләр чыгаргансың, әни, — дип кайтып керде Энҗе. Нәкъ элеккечә шат үзе.

— Ничек соң, кызым?

— Әйбәт. Әти үз аягы белән минем янга төште.

— Кит аннан! — Фәнүзәнең дә чырае яктырды.

— Кочаклаштык, сөйләштек. Температурасы утыз жидегә төшкән. Саташмыйча йоклый башлаган.

— Менә әйбәт, кызым. Син барганга күрә ул шулай.

— Сиңа — сәлам. Авырый дигәч кенә бераз кәефе китте. Син инде, әни, чирләмәскә тиеш, болай булгач.

— Аңладым, кызым, менә бит ничек, син мине хәзер алмаштыра алырлык яшькә життең.

— Үстем инде, әни: зу-у-ур булдым.

Шунда кыз белән ана гадәттәгечә кочаклашып куйдылар һәм, Энҗе тиз-тиз чишенеп юынгач, тәмле итеп кичке'аш ашадылар.

Болай булгач, бер кайгы икенчесен җиңәргә ярдәм итте һәм тормыш тукталмады түгелме соң?

Әмма кич барыбер борчулы булды. Телефон шалтыраган саен Фәнүзә дертләп куя, Энҗе сөйләшкәндә сагаеп тыңлый һәм трубка рычагка куелгач кына тынычлана иде.

Гадәттәгедән аермалы буларак, төн дә шулай кабат-кабат бүленде. Берничә мәртәбә тәрәзәгә җил кагып уятты.

Әмма җиңелмәслек фаҗига юк сыман иде.

Иртән эшкә баргач кына, хәл тагын начар якка үзгәреп, сынавын дәвам итте.

Директор урынбасары яки гыйльми секретарьның нинди дә булса сүзләре юкмы икән дип кабул итү бүлмәсенә керүгә Алсу Нажар абыйсының хәлен сорашырга кереште. Аннары кичә дә, бүген дә Фәнүзәне сорап кемнеңдер шалтыратканын әйтте.

— Хатын-кыз тавышымы? — дип сорады Фәнүзә кичәге ямьсез авазны кылт искә төшереп.

Алсу нидәндер уңайсызланып кызарды. Ник? Аның тавышы түгел иде бит, югыйсә Фәнүзә таныган булыр иде... Шулай да...

— Юк, ирләр тавышы.— Ирләр дигән сүзен Алсу сизелерлек ихтирам белән кабатлады.— Нажар абыйның өйдә юклыгын белгәндер инде.

Урынсыз шаяртуы да уңайсызлану галәмәтедер. Ләкин кыек атып туры тидергән булуы ихтимал. Кичәге хатын чынлап та бит Нажарның өйдә юклыгын белеп шалтыратты. Тик ул арада кайдан белгәннәр диген?

Садир Хәкимович та, гыйльми секретарь да килеп җитмәгәннәр иде. Соңыннан керермен дип Фәнүзә үз кабинетына, аннары исә лабораториягә үк төшеп китте. Садир Хәкимович бу көнне Нажарның хәлен белешергә үзе төште. Больницага күчтәнәчләр белән барырга җыенуын искәрткән иде, шул вакыт кинәт үзгәргән Фәнүзә:

— Барсагыз үзегез генә барыгыз зинһар, башкаларга әйтмәгез, адресны да бирә күрмәгез, — дигән үтенече белән житәкчене шактый гаҗәпләндерде. — Гафу итегез. Чөнки соңгы вакытта әллә нинди шикле хәлләр күбәйде.

Үзе больницаның кайда һәм нинди икәнлеген хәл сорашучыларга да әйтмәде.

Көннең икенче яртысында ясалачак чыгышын кабат күздән үткәрде. Карамыйча укырлык хәлгә житкәнче ятлады. Текст белән Александр Иванович та, Садир Хәкимович та күптән таныш, аны алар да «әйбәт» дигәннәр иде. Борчылырлык нәрсә юк та кебек... Ләкин йөрәк барыбер ашыгып тибә, бөтен тән кыза. Шуңа Нажар борчуы өстәлә...

Житмәсә, әнә ишек ачылды. Аслу елмая:

— Фәнүзә Кадыйровна, сезне — телефонга. Иртәнге тавыш.— Кызның күзендә мут ишарә.

— Фәнүзә Кадыйровнамы бу?

— Әйе. Сез кем?

— Мин... мин... Эш миндә түгел. Эш Нажар Зәбировичка кагыла.

— Ә ник мине чакырттыгыз?

— Сезгә би-ик кызыклы бер әйбер тапшырасым бар. Ул... Ул — Нажарның фоторәсемнәре.

— Бирерсез... үзенә.

— Ул карточкалар сезнең өчен кызыклырак булачак. Чөнки... чөнки анда сезнең ирегез атабыз Адәм кыяфәтендә.

— Ничек?

— Адәм инде, жирдәге беренче кеше. Ул ялангач булган бит.

— Сез... гафу итегез... Сез кабахәт кеше!

— Ә сезнеңчә, шәрә килеш сурәткә эләккән бәндә нинди кеше була?

— Сез, сез...

— Ашыкмагыз, хәбәрем кызыклы бит, чөнки ирегез ул сурәттә берүзе генә түгел, анда бүтән кеше дә бар... Анысы да шәрә. Ник сора-

мыйсыз кем икәнен? Анысы — хатын-кыз... Анабыз Һава. Мин сезгә ул сурәтләрне тапшыра алам. Кайчан дисәгез, шулчак. — Фәнүзәнең шаккатып калганлыктан тиргәшә дә, телефон трубкасын да куя алмавыннан файдаланып, исемсез кеше үзенең уен тузын чыгарып чәпәде: — Монда бер унлап сурәт — хакын кыйбат сорамам. Йөз тәңкәгә негативы-ние белән бирәм. Ризамы соң? Свидание билгеләсәгез, очрашырбыз. Кайда? Сез ничек теләсәгез, шулай булыр.

Фәнүзә сурәтләрне инде күз алдына китереп, калтырый ук башлады һәм, бөтен көчен җыеп, ишетелер-ишетелмәс кенә ике-өч сүз укмаштыра алды:

— Бераз... уйлыйм... Бер сәгатьтән шалтыратыгыз.

— Ярый. Шалтыратырмын, бер сәгатьтән.

Әмма, ярый, килештек дисә дә, бер сәгатьтән соң шалтыратырмын дисә дә, ул тавышны бүтән ишетергә насыйп булмады. Алсу бүлмәсенә Фәнүзә үзе кереп утырса һәм тагын бер сәгать көтсә дә, кара хәбәр китергән ак телефон дәшмәде. Эш көне тәмам. Алсуга китәргә вакыт. Әх, аңа гына түгел, Фәнүзәгә дә китәргә кирәк ләбаса. Бүген Нажар янына ул барырга тиеш, чөнки Энже ике көн рәттән барды инде. Фәнүзәнең өч көн рәттән хәл белешмәве Нажарны каты рәнҗетәчәк. Ләкин барып, ничек сөйләшергә?

Эш беткән чакта транспортның хәле билгеле — барысы да шыгрым тулы. Этеш-төртеш, кычкырыш-талаш. Чират тору юк — һәркем алданрак өлгерергә азаплана. Фәнүзәгә дә тиз барырга кирәк, соңласа, кабул итү бүлмәсе бикләнәчәк. Ләкин ул, беренчедән, хатын-кыз, икенчедән, Нажар хатыны. Ул көтә генә ала. Әмма көтеп тә уңышка ирешмәгәч, тере дәрья эченә керә һәм, троллейбус килгәч, теләсә-теләмәсә дә агым белән вагонның нәкъ уртасына уза. Бер троллейбуста шулай, икенчесендә. Һәм бераз җәяүләп барасы.

Артык интекмичә генә тапты больницаны. Нажарга язу да менгереп җибәрде. Кызы янына төшсә дә хатыны янына ире төшмәс сыман тоелды — Фәнүзә, әйтерсең, үзе гаепле. Аның күңелендә әллә нинди алама уйлар, пычрак хәбәрләр. Шикләнүләр, рәнҗүләр, әрнүләр һәм тагын әллә нинди исемсез хисләр тулы. Шундый хәлдә ничек инде бернәрсә белмәгән, уйламаган кеше янында басып торырсың? Төшмәсә, күрми китсә, хәерлерәк төсле. Ләкин күрмичә китәсе дә килми. Көтәргә генә кала.

Нажар. Йөзе ап-ак булса да күзләрендә күрешү шатлыгы бәхетнең үзе төсле очкынланып тора.

— Фәнүзә!

Фәнүзә елмаерга тырыша.

— Я, күрешмибезмени?

Җавап көтмәстән, Нажар Фәнүзәнең кулын үзе ала һәм кысып-кысып тотуы белән сагынып өлгергәнлеген аңлата. Ә Фәнүзә — жансыз. Нажар шуны сизә.

— Терелеп җитмәгәнсең ахры, — дип, Фәнүзәнең башын тоткач, тагын сүзгә үзе керешә. — Болай кайнар түгел дә... Ничек соң?

— Температура юк.

— Авыртуын авыртамы?

— Күз аллары караңгы, буталчык.

— Болай ярамый. Һич тә. Кайт та томаланып ят. Грелка куй, кайнар нәрсәләр ашап эч. Берсекөнгә бит... үзең беләсең. Шуны белеп тор: әгәр син җиңеп чыксаң, мин дә тиздән терелеп өйгә кайтачакмын. Җиңелсәң, үз аякларым белән чыга алмам. Менә шулай, хатынкаем. Үзең нидер әйтергә дә җыенган кебек. Нәрсә бар соң? Ә?

Фәнүзәнең тагын елыйсы килеп китә. Елап кына кеше көлкесенә калмасам ярар иде дип иреннәрен тешли, күзләрен киереп ача һәм башын Нажар кулбашына терәп, тынып тора.

Шулай күпмедер вакыт узса да, сүзләр ябышмый. Инде Нажарның аякларына салкын үрмәли. Башкалар тыныч кына, матур гына гөрләшә, гәпләшә, ә ул аягына тигән салкынны сизә. Аның калтыраганын абайлаган Фәнүзә кайтырга кирәген чамалый.

— Ярый, өзлегә күрмә, бар, кит инде менеп.

— Башта син...

Тагын бераздан соң Фәнүзә чынлап та кузгала һәм ишек төбеннән хәтта елмайгандай итеп кул изи. Нажар ихлас теләк теләп, ихлас кул болгап озата:

— Исән йөр! Авырма!

* * *

Фәнүзә, гадәттә иртәрәк торып, чәйләр әзерләгәч кенә кызын уята. Ә бу көнне киресенчә килеп чыкты. Бераз соңгарак калып уянган Энже шактый вакыт әнисенең адымнарын һәм кухняда савыт-саба шалтыратуын ишетергә тырышса да, ни өчендер, шылт иткән аваз да килмәде. Көннең яктырган икәнлеген күргәч, хәлнең көйле түгеллеген чамалап, үзе торырга мәҗбүр булды. Сагаеп кына йокы бүлмәсенә күз ташлады. Әнисе күзләрен ачкан килеш бернәрсәгә дә игътибар итмичә ята иде.

— Әни, хәлең ничек?

— Ярыйсы, кызым.

Кызы тиз генә килеп әнисенең башын тотып карады.

— Болай әйбәт кебек. Берәр җирең авыртамы?

— Бер җирем дә авыртмый, кызым, борчылма.

— Алайса нигә тормыйсың? Нинди көн икәнен беләсең бит.

— Беләм шул, кызым.

— Шулай булгач?

— Әле сәгать икедә бит ул.

Энҗегә әнисенең искитмәүчәнлеге бөтенләй яңа һәм ят тоелганга, мондыйга һич тә күнекмәгәнгә күрә, гаҗәпләнә калды.

— Менә инде, әни, икедә дип... Көтелмәгән нәрсә килеп чыкмасын... Килеп чыкса, чарасын күрергә кирәк булса... Соңыннан борчылмас өчен алдан ук тикшереп куярга кирәк булса... Тулы ышаныч белән залга керер өчен... Каушамыйча чыгыш ясар өчен... — Җөмләләрен очлап бетерә алмаса да фикере төгәл иде кызның.

Фәнүзә сизә, Энҗе, әлбәттә, әнисеннән ишетеп-тыңлап күнеккәнчәрәк, «нотык» укый. Әмма кайгырта, борчыла белүе әни кешегә җан кертә — ул хәтта елмаерга тырыша.

— Ярый, кызым, мин тиз... Чәйләр куя тор, бар.

Гадәттә әнисе башкара торган иртәнге вазифаларны кыз үз өстенә алып, чәйнеккә су агызырга керешә һәм тагын өйгә җан керде.

Телефон.

Кухнядагы шалтырауларын бүлеп, Энҗе трубканы ала.

— Әйе. Юк, ул түгел, бу аның кызы. Сез кем соң? — Трубкада шуннан соң кыска гудоклар.— Менә кызык. Кем дип сораган идем, әйтәсе килми. Бүгенге көндә син теләсә кем белән сөйләшә алмыйсың бит инде, ә? Шулай бит, әни?

Кыз тәки олы кешегә әйләнгән икән. Кай арада! Фәнүзә инде беркайчан да ялгыз булмаячак, яклаучысыз калмаячак икән. Шуңа күрә күңеле тагын да ныгый төште. Кичке якта сөйләшергә туры килсә, чак кына иртәрәк кайткан булса, бәлки әле төн йокысы да әйбәтрәк булыр иде. Ә болай йокы шәп үк була алмады шул. Уенда төн буе Нажар мең сораулары белән күз алдына килде дә басты, килде дә сүз кушты. Хәзер иренең авыруыннан һәм аны кызгануыннан бигрәк, әллә нинди аңлата алмаслык рәнҗү хисләре җанга тула башлады. Беркайчан булмаган авыр хис хәзер барлыкка килде. Ник? Ник болай?

Чын гөнаһ табып та шаулата алмаган гайбәтче максатына барыбер ирешә түгелме соң? Ник болай? Әллә... Әллә бераз гына хаклымы «яхшылык теләп» шалтыратучылар? Әллә хыянәт чынмы? Юк, юк, чын түгел хыянәт, монысы көн кебек ачык. Әмма ник соң йөрәк телгәләнә? Юк икәнен белгән килеш ник ярсыну яңара?

Әйе, шик туды, шик мәгънәле сорау булып укмашты. Димәк, ул ачыклау таләп итәчәк!

Чылтырау. Трубканы алмадылар. Тиз-тиз капкалап, Энҗе үз эшенә китте.

Әмма телефон тагын шалтырады. Трубканы алмаска карар кылган Фәнүзә бу юлы үзе дә сизмәстән, телефонга ташланды. «Шулар гына булса ярар иде».

Теләге кабул килде. Шулар! Ике көн элек ишетелгән тавыш.

— Фәнүзә Кадыйровнамы бу?

— Әйе.

— Без сөйләшеп бетермәгән идек бугай бит. Теге фотокарточкаларны нишләтәсез? Аласызмы? Әллә...

— Фотокарточкалар? Әйе, хәтерлим. Күпме акча кирәк сезгә?

— Кичә булса йөз сум иде, бүген — йөз илле. Иртәгә... анда инде соң булачак.

— Сез ни әйтмәкче буласыз?

— Йөз илле сум. Матур сурәтләр — үзегезгә дә ошаячак. Ирегез, гафу итегез, чибәр кыз кочагында.

— Нинди түбәнлек!

— Мин сезнең белән килешәм. Я? Ничек?

— Килегез, алып китегез йөз илле сумыгызны.

— Әллә очрашыйк кынамы?

— Кайда?

— Соцгородны беләсез бит? Шунда культура сарае янында. Мин сезне сәгать икедә көтәм.

— Сәгать икедә? Көндезге?

— Әйе көндезге.

Кайбер нәрсәләр шунда яшен тизлеге белән ачыкланып китте. Һәм сүзе дә табылды: «Шантаж!» Юк, бернинди сурәт тә юк!

— Әгәр чынлап та фотогыз булса, акча кирәк булса, сез бер сәгатьтән Чернышевский белән Профсоюз урамнары почмагына килегез. Минем бүтәнчә мөмкинлегем юк.

—Ярый алайса, карарбыз, хәлегезгә керергә тырышырбыз! Булмастай булса, ярты сәгатьтән тагы шалтыратырбыз.

Менә нинди гуманистлар! Әмма ничек исән котылырга бу гуманистлардан? Һәм аларның ярдәменнән?! Һәм нишләргә? Кем белән киңәшергә? Менә ничек бит — күңелдәгене актыгынача бушатырлык бер генә кеше дә юк икән. Наҗардан һәм Энҗедән башка. Нинди ялгыз икән Фәнүзә! Ә аралаша торган кешеләре, хезмәттәшләре кичә генә нихәтле күп иде! Ә бүген шушы олы бер дөньяда, бөтен бер галәмдә Фәнүзә япа-ялгыз! Һәм нинди көндә!

Әчеткән күзләрен ышкып, тагы бер түйганчы еларга теләсә дә, бу юлы күзләренә яшь килмәде — йөрәк кенә тигәнәк кадалгандай тоташ бер авырту белән авырта: «Кем? Кем белән киңәшим? Кемгә таяныйм, кем иңенә башымны куйыйм?»

Уйлый торгач, бер кеше табылды да, Фәнүзә ашыга-кабалана номерлар җыйды.

— Садир Хәкимович? Сезме? Садир Хәкимович, исәнмесез?!— Фәнүзәнең тавышы, нишләптер, шат кеше тавышы сыман әйбәт яңгырады. Һәм житәкче аны шулайдыр дип кабул итте дә.

— Исәнмесез, Фәнүзә Кадыйровна. Тавышыгыз көр чыга, хуплыйм. Кәеф бик тә шәптер инде, димәк?

— Кәеф бик тә шәп, Садир Хәкимович. Сугышка баручы солдат итеп тоям үземне. — Башка бөтенләй кереп тә карамаган сүзләр каян чыга икән?

— Молодчина. Шулай тиеш тә. Тырыштык бит инде, ни сучка, ни задоронки — бөтенесе хәл ителгән, принципта сөйләшенгән. Хәзер инде матур киенеп, кунакларны гашыйк итәрлек кыяфәт белән кил дә бернәрсәдән курыкмыйча чыгыш ясa.

— Курыкмаска, каушамаска сүз бирәм. Сезнең йөзгә кызыллык китермәскә.

— Миңа рәхмәт, шәп сүз әйттең.

— Сезгә — теләктәшлегегез өчен рәхмәт. Пока, Садир Хәкимович.

Зарланырга, мескенәергә, ярдәм сорарга диебрәк, дөресрәге, ник икәнен белмичәрәк кенә шалтыраткан Фәнүзә шул рәвешле үзе җитәкчене тынычландырып куйды. Директор урынбасары моңа үзе дә шундый бәя биргән булырга тиеш. Минә бит ничек, көтмәгәндә хәл үзгәрә дә куя. Димәк, хәрәкәттә — бәрәкәт. Димәк курку, борчылу — урынсыз. Теге яман адәм сурәтләрне китергән хәлдә дә. Фәнүзә инде бирешмәячәк — коелып төшмәячәк. Иренең хыянәте фашланса да, көч табачак. Садир Хәкимович белән сөйләшүдән әнә шундый ышаныч туды. Димәк, шалтырату дөрес булды. Димәк, киңәшер кеше бөтенләй юк түгел икән — акыл, ихтыяр яңадан кайтты.

Ярты сәгать үтте. Телефон шалтырамады. Шулай да Фәнүзә иренең сурәтләрен сатып алырга әзер иде. Ире алай очсыз ук тормый икән, ни әйтсәң дә, йөз илле таңкә бит ул кемнеңдер айлык эш хакы!

Ләкин аны сөйләшенгән почмакта беркем дә көтеп алмады. Биш, ун минут узды. Матур киенгән хатынга, гадәти кызыксынулы карашлардан башка, игътибар итүче булмады. Туп-тулы бер сәгатьтән соң да килүче күренмәде.

Тагын бер кабат расланды: юк, бернинди әдәпсез сурәтләр була алмый. Нажар шундый алама хәлгә төшә алмый һәм беркайчан да төшмәячәк! Минә шул. Ә соң, алайса, Фәнүзә ник ышанды, ник килде?

Ярый әле килде. Мөгаен ул шушының белән шантажчыларның карталарын бераз гына булса да бутады. Алар мөгаен, килмәс, куркыр, сөйләшмәс, кешелеген җуеп, өйдә генә ятар дип уйлаганнардыр. Озакламый сезнең үзегезгә куркыныч килүе ихтимал. Сезнең тавышыгызны, пычрак тавышыгызны тану — язып алу мөмкинлеге барын һәм тиешле төштә үзегез казыган базга үзегезнең төшү ихтималы барын онытмагыз.

Күренергә курыктыгызмы? Килмәдегез? Бу инде көч билгесе түгел. Әшәкелек — куркак! Әшәкелек мәңге куркак булган һәм үз куркаклыгыннан калтырап яшәгән. Бүген дә шулай, иртәгә дә шулай булачак.

Сәгать унике. Институтка шушыннан гына барырга мөмкин. Шулай уйлаган иде Фәнүзә. Тик... Тик чыгышының тексты өйдә калган бит. Кайтмыйча булмый димәк. Ашыга төшәргә туры килә. Шулай да зыянсыз. Өйдә нишләргә белмичә калтырап утыруга караганда, алама булса да, шөгыль табылу хәерлерәк. Пычрак бәндәләрнең явыз нияте тагын әйбәткә әверелде. Гел шулай булачак — кемдер начарлык кылам дисә, чынлыкта ул һаман ярдәм итү генә булып килде һәм шулай булачак.

Фәнүзә кайтты. Бая ашык-пошык эчкән кофены яңадан кайнатып, бая ашый алмаган ризыгын өр-яңадан ашарга, аннары үзенең тышкы рәвешен кабат рәтләргә дә вакыт табылды. Садир Хәкимович теләгәнчә, үзенең тыйнак та, матур да булган киемен киде.

Бөтенесе әзер. Газларны, суларны өченче кат тикшергәч, аякларына, өсләренә киде. Һәм... тагын шалтырау. Алыргамы? Әлбәттә, алырга.

— Әйе.

— Фәнүзә, исәнме?

— Нажар!

— Я, кәефләрең шәпме?

— ...Нажар... Нажар! — Кинәт күкрәкне тагын түзеп булмаслык авырту каплап алды — тавышы еламсырагандай чыкты.

Зәгыйфь тавыш яфрак шыбырдавыннан чак кына көчлерәк аваз:

— Фәнүзә, мин ышанып көтәм, хәтта таләп итәм — нык бул, ишетәсеңме? Фәнүзә? Фәнүзә!

«Хәбәр аңа да барып җиткән! Ничек? Нишләп?!»

Битләрен, күзләрен сыйпап торгач кына Фәнүзә һушына килгәндәй булды. Нажар бит авыруын да, фаҗиганы да җиңеп, инкарь итеп шалтырата һәм аның тавышы да бар, йомшак булса да.

— Фәнүзә, хәлең ничек?

— Синеке ничек?

— Минеке ярый, бүген — синең көн. Дөньяда син генә бар. Син җиңеп чыксаң, мин дә исән булырмын. Ишетәсеңме — бөтенесе синнән тора.

— Ишеттем, Нажар. Әйе. Тырышырмын, бигрәк тә синең өчен.

— Сиңа ышанам, сагынам, җиңү көтәм!

— Рәхмәт, Нажар.

— Исән бул, мине онытма!

— Хуш!

Сәгать бер. Китәргә чынлап вакыт. Болай булгач, Фәнүзә инде һәр тарафтан әзер. Нәрсә генә онытыла? Менә сиңа, кара — чыгыш тагын онытыла! Ярый әле кире керәсе булмады, вакытында искә төште.

Китте Фәнүзә үзенең җиңүенәме яки җиңелүенәме таба. Әлбәттә, җиңүгә! Бүгенге низаглардан чыккан нәтиҗә: нәрсә эшләнсә дә, файдага була икән — Вольтер каһарманы дөрес уйлаган.

Институтта ул башта Садир Хәкимович бүлмәсенә керде. Анда Фәнүзәнең башкаладан килгән җитәкчесе, оппонентлар... Барсы да аягүрә бастылар. Хәерлегә, әлбәттә, хәерлегә!

Кичә аларны каршыларга поездга төшәргә кирәк булган икән дә... хәтереннән чыккан. Шуның өчен ул күрешкәндә үк гафу үтенде. Кунаклар үзләре:

— Зыян юк, соңгы килү булмас әле, — дигән булып шаяртсалар да, барыбер хатаның хата икәнлеге аңлашылып калды.

Анда да Садир Хәкимовичның ярдәме тиде. Ул:

— Аның каравы, ул әйбәт итеп озатачак, — диде.

— Чынлап та, күңелем сезгә рәхмәт хисләре белән тулы. Тик... өйдә безнең җайсыз, авыр чак туры килде. Бөтен хаталарым шуның аркасындадыр, — дип акланырга туры килде Фәнүзәгә. — Мин барча хаталарымны төзәтергә сүз бирәм. Бүген үк. Аннары — иртәгә.

— Аннары гомер буе.

— Дөрес сүзегез өчен рәхмәт, Садир Хәкимович.

Елмайган була Фәнүзә Габбасова, ә йөрәге — дөп, дөп, дөп... Минутлар, секундлар дөпелди. Дөнья тагын караңгылана, кешеләр, үзләренең чынлыкларын җуеп, тагын шәүләләргә әйләнә. Ниндидер сүзләр ишетелә, сөйләшәләр, ә зиһен, җилсез кич рәвешле бөтен нәрсә эңгер эченә керә бара.

— Вакыт, киттек.

Садир Хәкимович аның терсәгенә кагылып кая барырга икәнен сиздермәсә, нишләр иде икән Фәнүзә?

Вакыты шундый вакыт ки, әйтерсең, эшафотка алып баралар. Нишләп соң болай? Болай булмаска тиеш ләбаса. Авырлыкны югалту дигән нәрсә җирдә булырга тиеш түгел. Зиһен нихәтле генә таркалса да, яңадан оешырга тиеш. Инде әнә утырыштылар да. Гаҗәпкә каршы, конференц-зал шыгрым тулы. Шушы хәтле игътибарны нәрсә белән аңлатырга? Әллә яклауга куелган тема мөһимлеге беләнме? Әллә аның бүгенге көндә буталчыклыгы, хәл ителеп бетмәгәнлеге сәбәпме?

***

Садир Хәкимович, совет утырышын ачып, көн тәртибен игълан иткәч һәм вакытлыча гыйльми секретарь вазифаларын башкаручы Вәкил Якташ залда утыручыларны диссертантның фәнни һәм биографик документлары белән таныштырганнан соң, кай арада! сүзне Фәнүзә Кадыйровна Габбасовага биреп тә куйды. Тик Фәнүзә берни аңламыйча утыра биргәнлектән, кабатларга мәҗбүр булды:

— Сүз сезгә, Фәнүзә Кадыйровна.

— Миңа?

Аның гаҗәпләнүеннән зал көлеп куйгач, үзе дә көләргә тырышкан

булды да... тик көлүе каушаганын яшерә алырлык түгел иде шул, көчсезлек дәлиле генә иде.

— Зыян юк, зыян юк, — дип куярга мәҗбүр булды башкаладан килгән җитәкче.

Шуннан соң гына Фәнүзә трибунага барып җитәрлек көч таба алды. Тынычланыр өчен ашыкмаска тырышып кына кәгазьләрен җайлап куйды һәм бу эшне башкарганда беркемгә дә күтәрелеп карамады. Бер җөмләне тавышсыз укыгач кына залга карады. Зал тыныч, карашлар җитди. Мыскыл сирпүчеләр күренми. Шулай булгач, башларга мөмкин.

Фәнүзә язылганны укырга кереште. Тавышы йомшак, көчсез, вак кисәкчекләргә кискәләнгән һәм ышанычсыз иде. Әмма аның хәленә кергәндәй, ризасызлык сиздерүче булмады. Югыйсә бит мондый вакытта астан: «Кычкырыбрак!» — дип кисәтергә дә күп алмыйлар.

Фәнүзәгә биш минут чамасы үз тавышы чит кешенекедәй, каяндыр киләчәктән ишетелгәндәй һәм аны башкалар да шулайрак кабул иткәндәй тоелды. Шулай булгандыр да ул. Чөнки тере организмның картаю механизмы тәгаен процесс буларак бер илдә дә беркем тарафыннан да тасвирланмаган бит. Күп нәрсә әле дә бәхәсле. Дөресрәге, кайбер төгәллекләргә үтеп керергә әле өлгереп җитмәгәннәр. Әмма күренеш принципта контурлар рәвешендә булса да, тасвирланган һәм кайбер тотрыклы галәмәтләре табылган инде. Алар рефератта да, диссертациянең үзендә дә җентекле күрсәтелгән һәм эксперименталь күзәтүләр белән ныгытылган.

Шул фикерләр укылганнан соң, Фәнүзә үзенең бераз гына булса да эш башкарганын сизеп, тагын кешеләргә күтәрелеп карады. Башлангандагы кебек үк иминлек. Бусы әйбәт. Әмма урта бер җирдә ниндидер сәер хәрәкәт. Күн куртка кигән симез бер егет үз янәшәсендәге иптәшеннән ниндидер кәгазьләр алды да алдарак утырган кызларга бирде. Кызлар кулына күчкән кәгазьләрнең фотокарточкалар икәнлеге аерым-ачык иде. Фәнүзә «ә» дигәнче төшенде: йөз илле сумлык фотолар! Шулар! Алгы рәтләргә җибәрде аларны симез егет — кыйбатрак түләтмәкче, диссертация һәм язмыш бәясе белән. Әмма син, егет, күбрәк өмет иттең һәм, күпне өмет итеп, мөмкин булганнан мәхрүм калдың. Фәнүзә өчен ул сурәтләрнең бүгеннән соң әһәмияте бетәчәк. Чөнки Фәнүзә инде төп фикерләрне әйтеп өлгерде — аны ишеттеләр, аңладылар да, мөгаен. Өстәмәгә әнә фотоларны һәр кеше ким дигәндә биш минут карый. Шулай булгач, кулдан-кулга күчә барган серле бозыклык президиумга менеп җиткәнче, Фәнүзә язмышы хәл ителәчәк. Фәнүзә үзенең язмышын сезнең әдәпсез сурәтләр өчен генә яраклы булган шакшы кулларыгыз белән тотарга ирек куймас! Көтмәгез.

Фәнүзәнең беразга тотлыгуын залда утыручыларның бераз җанланып, пышылдашып алуыннан күреп бугай, Гыйльми совет рәисе буларак, Садир Хәкимович ручка башы белән өстәл шакып куйгач, сурәт караучылар да берни булмагандай башларын күтәреп, чыгышны тыңларга мәҗбүр булдылар һәм, димәк, сүзсез көрәш Фәнүзәнең чираттагы тактик отышы белән төгәлләнде. Һәм, Фәнүзә, үзе дә сизмәстән, тәмам тынычланды. Дөресрәге, аның таркау күңеле сурәт караучыларга нәфрәт аркасында көтмәгәндә усаллашып ныгыды. Тавышы тиз арада көчәеп китте. Залның күзенә туп-туры караган хәлдә, артист күптән ятлаган сүзләрен кыю рәвештә халыкка сипкән шикелле, бернинди абыну-сөртенүсез сөйләргә кереште Фәнүзә. Алда яткан текстны ул, әйтерсең, бармаклары белән укый иде. Бармаклары кәгазь өстеннән шома гына шуган кебек, сүзләре дә залга тоткарлыксыз сибелә торды.

Кешеләрнең күзләрендә күптән түгел генә җемелдәгән кызгану хисе соклану, җөпләү галәмәтләре белән алмашынды һәм зал үзе дә яктырганнан яктыра барды. Куркыныч хәл Фәнүзәгә тел ачкычы бирде. Ә кемнәрнеңдер исәпләре бөтенләй бүтән иде. Инде күн курткалы си-

мез бәндә дә авызын ярым ачкан да шашкан адәм кебек шаккатып калган. Ә син кара, күр: әнә синең төннәр буе утырып кара уйлар белән ясаган пычрак сурәтләрең бая тукталган җирдән ары китә алмады. Ә Фәнүзә инде чыгышның ахырына җитте.

— Тыңлаганыгыз өчен сезгә рәхмәт! — дигәч, хәтта кул чабып куйдылар.

Курткалы егет үзе дә ике кулын бер-берсенә ярты кабат булса да чәпәп куйды. Монысы аптыраганнан булмагае. Бу аптырау йөз илле таңкәнең генә түгел, зуррак максатның юкка чыгуы, чәлпәрәмә ватылуы дигән сүздер. Кемнәрнеңдер яман нияте шушы мизгелдә кырылып төшкәндәй булды һәм Фәнүзә гүяки пыялаларга баса-баса үз урынына узды һәм аннары оппонентларга сүз бирелгәч, шулай ук алар да Фәнүзәнең зур эш башкарган булуын әйткәч, теоретик фаразларның үстерeләчәгенә өметләр белдергән чакта Фәнүзә инде кайбер фикерләрне ишетер, аңлар дәрәҗәгә килгән иде. Ләкин җитәкче сүзләрен, Садир Хәкимович сүзләрен ул үзенең чын яклаучылары икәнен белеп, тоеп кына утырды — мәгънәләренә керә алмады. Сораулар башлангач кына, зиһен үзлегеннән кайта язды. Көтелгәнчә, беренче кеше булып, кара курткалы симез адәм торып басты.

— Сезнең формулаларда, — дип әшәке карточка тоткан кулы белән түрдәге таблицага ишарәләде кара куртка, — күзәнәкләр ярадышында аерым компонентларның шул эштән үзләрен үзләре азат итүе, читләшү механизмы ышандырырлык күрсәтелгән. Экспериментлар белән дә ярыйсы ныгытылган. Сез шушы күренешне табигатьнең хатасы дип исәплисезме? Монысы бер. Икенчедән, шул процессны уңай якка үзгәртерлек чара инде тәмам табылган дип саныйсызмы?

Кара курткадан провокацион сорау ишетелмәве гаҗәбрәк иде. Шуңа күрә, кискен отпорга әзерләнгән нервалар киеренкелеген бераз бушатыр өчен, Фәнүзә берара сүзсез торды. Тавышына мөмкин кадәр җылылык өстәп, кара курткага ягымлырак карарга үз-үзен мәҗбүр итте.

— Беренче сорау. Әйе, табигать хатасы дияргә мөмкин. Шулай да, иң әүвәл, вакыт белән тере организмның мәңгелек бәхәсе төенләнгән күренеш дияр идем. Табигатьнең әле тиешле үсеш дәрәҗәсенә җитмәве белән аңлатыла торган камилсезлеге, кимчелеге дип атау дөресрәк булыр. Без, кешеләр, шушы процесста табигатькә ярдәм итәргә алындык. Икенчедән, формулалары күрсәтелгән синтезларны бу максатка ярдәм итә торган беренче табыш дип исәплим. Эзләнүләр дәвам итәчәк. Ихтимал, проблема киләчәк буыннар тырышлыгы белән хәл ителә барыр.

Фәнүзә бу сүзләрдән соң җитәкчесенә карады. Сак җаваптан җитәкче риза иде. Шулай да ул укучысының үзара бәхәсләшүгә кайтып калган бүтән сорауларга җавап биргәндә сәхнә түрендәге таблицалар, диаграммалар күрсәтү беләнрәк чикләнүен тулыландыру өчен шактый сорауларга җавап бирүне үз өстенә алды.

Чыгышларны тыңлаганда исә, Фәнүзәнең зиһене аңлау функциясеннән үзен тагын азат итте. Сизми дә калды, ниһаять, инде аны котлар вакыт та җиткән икән! Ничәмә елдан соң!

Шулай кемнәрдер аның кулларын кыса, ниндидер теләк белдерә. Ә ул үзе ишетми, һәртөрле сүзгә «рәхмәт»тән башканы әйтә дә алмый. Ә күзләре — һаман аста, бая кемнәргәдер карточкалар күрсәткән курткалы егеттә. Ул симез кеше, Фәнүзәнең аерым игътибарын шәйләгәндәй, үзе дә бу якка текәлебрәк карый башлады һәм, кыюлыгын җыеп булса кирәк, сәхнәгә менде дә Фәнүзәгә йөз тапкыр әйтелгән сүзләрне кабатлады.

— Котлыйм сезне, университет әһелләре исеменнән, бигрәк тә биофак исеменнән. Сезнең өчен шатбыз!

Кулында — күптән түгел генә Фәнүзәне чыгырыннан чыгарырга тиеш булган, әмма, киресенчә, дәртләндерә генә төшкән карточкалар.

Әмма бернинди әдәпсез сурәт юк. Алар кулдан язылган картотека карточкалары икән!..

Бу минутта, әгәр мөмкин булса, хәлсезлектән Фәнүзә баскан төшендә жиргә утырырга тиеш иде. Әдәп рөхсәт итсә, симез егетне бөтен көченә кысып кочарга тиеш иде. Ярый әле оят дигән нәрсә бар — шул саклады. Әмма ул барыбер шушы егеткә рәхмәтне житәкчеләренә әйткәнгә караганда да ихласрак белдерде:

— Рәхмәт яусын, сез мине бик зур бәладән коткардыгыз. Ярый әле мендегез, котладыгыз.

Егет, әлбәттә, бу пайпылдауның мәгънәсенә төшенеп бетмәгәнлектән, аймылыш сүзләр сәбәбен каушаганлыкка юрап:

— Ярый, ярый, зыян юк, әйбәт! — дип кенә баш ия-ия китеп барды.

Сурәтләрнең юклыгы тәмам исбат ителде. Әгәр дә алар булса, чынлап та кулдан-кулга күчә-күчә президиумга тиз арада менеп житәр иде һәм астыртын мыскыллы хихылдаулар залны иңләп-буйлап аяк асларыннан шуышыр иде. Сирәк кенә шундый көлү болай да үрмәләргә азапланды бит. Ләкин моның өчен явыз бәндәләр кулына жинаять дәлилләре эләкмәгән икән шул. Ә эләккән булса! Сурәтләре чынлап та булса! Күрер идең син аларны! «Молодец, Нажар, харап иттермәдең! Мин сиңа, синең затлы кеше булуыңа ышанып яшәдем һәм менә ышанычым нықлыгы тагын яңарды. Дошманнар синең кешелегеңне мыскыллый алмадылар. Моның исә хәтта матди отышлы ягы да ачылды — синең шәрә кыз белән төрле рәвештә анадан тума төшкән фотоларны сатып алырга дигән акчаң янга калды.

Мәгәр күңелне әллә нәрсә барыбер яшертен генә астыртын гына тырный иде. Кунакларны озаткан кичтә бу тойгы тагын арта төште.

## Ихтыярдан тыш

Көндезге сәгать дүртләрдән соң Нажар өенә кабат-кабат шалтыратса да, жавап бирүче булмады. Институтның да үз секторлары аваз бирергә ашыкмады. Чит секторлар, трубканы алсалар да, бернинди мәгълүмат бирмәгәнлектән, күңелендә чак кына сәбәпсез ризасызлык туса да, Нажар моны акылы белән хәерлегә юрады: эш бара дигән сүздер бу.

Кич Энже килде.

— Хәерле кич, кызым.

— Хәерле кич, эти. Хәлең ничек?

— Минеке әйбәт. Сезнеке ничек?

— Безнеке дә әйбәт бугай, эти.

— Әниең нишли?

— Әни кайтмады әле.

— Кайтмады? Шалтыратмады дамы?

— Юк шул.

— Син аның янында булмадыңмыни?

— Юк, лекцияләрдә утырдым.

— Әниең янына барырга иде, кызым.

— Ул үзе кушмады. Болай да бик каушармын, кызарып, оялып утырырсың диде.

— Ярый, кызым. Тагын ниләр бар?

— Бүтән нәрсә юк инде, эти.

— Әниеңнең эше ничек беткәнен зарыктырмый хәбәр итегез, яме?
— Ярый, тыныч йокы, әти.
Эшнең ничек тәмамлануын ул көнне тәки белә алмады Нажар. Һәм шуңа күрә йокысы тыныч була алмады. Тамак авыртуы көчәеп, тәнне калтырата бирде. Җып-җылы бүлмәдә, юрган астында аяк өши... Иртән үлчәсәләр, температура яңадан утыз сигезгә менгән. Моның җан газабыннан һәм кичә астагы салкын бүлмәгә еш төшеп, трубканы кем дә булса алыр әле дип телефонга йөрүләрдән иканен врачларга ничек әйтергә? Шуңа тагын кеше тулы бүлмәдә ялгызлык өстәлүен ничек аңлатырга?
Бер, ике, өч көн...
Өченче кичтә, ниһаять — Фәнүзә. Язуында бер генә җөмлә: «Диссертация белән эш бетте!»
Әмма нәкъ шул сөенечле көнне Нажарның аска төшәргә хәленнән килмәде. Җавап кәгазендә кич шалтыратырга вәгъдә итсә дә, шул вәгъдәсен дә үти алмады.
Хәлне төшенгәнгә күрә микән, Фәнүзә көн саен килә башлады. Язулары яшь чакта алышынган хатларның дәвамы кебек иде.
Читтән торып хәбәрләшүләргә тагын берничә көн үткәч кенә чик куелды. Ниһаять, Нажар аска үзе төште.
Фәнүзә ишек төбенә өелгән бер төркем кешеләрдән арттарак басып тора иде. Кыяфәте — чирле. Нажар моны коридордан борылгач ук шәйләгәнгә күрә, күрешүдән артык канатланып китә алмады. Әдәп өчен генә елмаеп, хатынын шулай ук әдәп өчен генә кочаклагандай итте. Шуннан соң гына Фәнүзәнең күзләренә карады. Ә күзләрдә... җиңү тантанасы китерергә тиешле яктылыкның әсәре дә сизелми ичмасам. Бу күзләрдә хәтта ниндидер ят мәгънә, читләшү төсмере бар бугай. Ниндидер хәерсез үзгәреш... Монысын Нажар аермачык күрде. Шулай да яман каефкә бирелергә ярамавын да чамалап, хатынын бик вакытлы рәвештә котлый белде:
— Мин сине котлыйм, Фәнүзә, молодец.
— Котладың бит инде язмача...
Читтәге бер почмакта озак кына сөйләшеп тордылар. Фәнүзә Садир Хәкимовичның һәм башкала кунакларының үзенә бик ярдәм итүләрен, хәтта дусларча якынлык күрсәтүләрен сөйләгәннән соң гына, иренә тиеш булганча, ихлас елмаеп куйды:
— Башкала кешеләре синең эш белән дә кызыксыналар. Бигрәк тә соңгы мәкаләңне яратканнар. Үзләре дә бу темалар буенча нык эзләнәләр, тикшеренәләр икән. Теләктәшлек тәкъдим иттеләр.
— Ә син?
— Мин үз исемемнән дә, синең исемнән дә рәхмәт әйттем. Син ризамы соң?
— Ыһы. Тагын ниләр?
— Бүтән юк. Искә төшкәндә тагын сөйләшербез. Нюанслар калгандыр әле. Ә син тизрәк чык инде.
— Больницага йөрү туйдырдымы?
— Аннан гына булса... Хатынның нигә кирәге бар? — Күзләрдә таныш якынлык чалымнары.
— Тагын бер сорыйсы нәрсә бар иде.
— Сора, Нажар.
— Минем кайсы больницада ятканны институтта беләләрме?
— Садир Хәкимовичтан башка беркем дә белми.
— Ләкин кемнәрдер белә. Гаҗәп.
— Ник алай дисең?
— Әйтә алмыйм әле. Ярый, хәзергә җитеп торыр. Юл бик кыен булса, килеп интекмәгез.
— Үпкәләмичә генә дәвалан, килербез, тик барыбер тиз терел.
— Тырышырмын.

Гадәттәгечә, Нажар хатынын ишектән чыкканчы озата килде. Һәм шулай ук гадәти рәвештә кул болгады. Көрешү тәмам.

Айның калган өлеше шушы рәвештәрәк узды. Больницадан Нажар ай ярымнан соң — яңа ел алдыннан гына чыга алды.

Сәгать икеләр тирәсендә ул урамда иде инде.

Шимбә көн булгач, Энже дә, Фәнүзә дә өйдәдер дип шалтыратып караган иде, трубканы алмадылар. Энже институттадыр, ә Фәнүзә кибетләргә чыгып китте микән?

Нажарның кайчан кайтасын алар төгәл генә белми, чөнки врачлар бүген генә әйттеләр бит — алай-болай өйдән озаккарак чыгып китмәсеннәр тагы. Алай да зыян юк. Нажарның үз ачкычы үзендә. Керер дә өйдәгеләрнең кайтуларына үзе ишек ачар.

Көн шактый салкын икән. Әмма ай ярым хәрәкәтсез ятканлыктан, әлбәттә, ипләп кенә атлаган хәлдә дә маңгайга тир бәреп чыкты, җилкәләр юешләнде. Салкын тию ихтимал. Җитмәсә, троллейбуслар туктalышы шактый ерак имеш. Тагын да яманрагы, мондагы троллейбуслар артык сирәк йөргәнгә, алар көндез дә шыгрым тулы икән. Ким дигәндә ярты сәгать көткән троллейбуска утыра алмыйча һәм такси да тота алмыйча, икенче линиягә кадәр тагын ун-унбиш минут чамасы атларга туры килде. Шунда гына ул Фәнүзәнең хәлен аңлады. Ә бит Фәнүзәгә әле бөтен кеше эштән кайткан сәгатьләрдә йөрергә туры килә иде. Хатыны да, кызы да көн саен диярлек батырлык эшләгән булып чыга.

Шул уй белән якаларын күтәреп, һәм, авыз-борынны каплаган хәлдә, ашыга-ашыга, тирли-тирли, өйгә кайтып җитте Нажар. Кыңгырау чылтыратты, тик эчтә хәрәкәт сизелмәде. Ишекне үз ачкычы белән ачып керде. Кешесез өйгә кайтып керү күңелсез дә соң, нишлисең.

Чишенде. Беренче булып, ванна бүлмәсенә керде һәм кулларын, битләрен рәхәтләнеп юды. Аннары кухня ягына чыгып нәрсәләрнедер барлыйсы итте. Энже бүлмәсен ачып куйды һәм зал ишегеннән узган гына иде... уң як кушеткада — хатыны! Бөрешеп, бәләкәйләнеп калган. Чырае — күп-күмгәк. Шул кадәр кызганыч төскә кергән!

— Фәнүзә?! Син? Нишләп болай?

Фәнүзә кушеткада утырган җиреннән бер генә секундка күз ялтыратып куйды да, башын иеп һәм ике тезен берьюлы кочаклап, тын калды. Нинди дә хәерсез нәрсә сизенсә дә, вакытлы үзгәрешкә ышанырга теләмәстән, Нажар Фәнүзәне башыннан кочакламакчы булып килгән иде, тик хатыны башын кинәт чайкап борылды да, тагын ике аягына сыенып утырды. Аның суырылып калганын, чырайдан язган булуын шунда гына шәйли алды Нажар. Бөтенләй сабыйга охшап калган. Каян шушындый кинәт үзгәреш! Җитмәсә, ябык, нечкә гәүдәсен бөкрәйтеп тезләренә йомылуы аны тагын да кызганычрак иткән — кечкенә бер дүмгәләк — ике кулыңа күтәр дә ал.

— Ни булды? Авырыйсыңмыни?

Ичмасам, күзләреннән бер генә очкын сирпелсен икән!

— Фәнүзә... Соң... болай нәрсә инде? Нәрсә аңлатмакчы буласың? Терелеп кайтуым ошамадымы? Кайтмаска идеме әллә? Соң... Бик теләсәң, кире китәм, алайса.

— Кая китмәкче буласың?

Ниһаять беренче сүз. Мәгънәсе бары тик үртәлүдән генә торса да, өнсезлектән ул юньлерәк — нәрсәнедер ачыклый башларга мөмкин.

— Теләсәң кая.

— Кая гына качсаң да, ялангач күләгәләрең артыңнан калмас, иярер.

— Качарга? Мин нәрсә... Җинаять эшләгәнме әллә?

— Ә син эшләмәдем дип йөрдеңме?

— Ипләбрәк, Фәнүзә. Югыйсә бит нервлар миндә дә бар. Минем дә протест белдерә башлавым ихтимал.

Күләгәләр нәрсәдер сөйлиләр. Нинди күләгәләр?

Соң бит Фәнүзә инде хәерсез сурәтләрнең юклыгын гамәлдә үзе раслаган, аннары, мең мәртәбә уйлап, иренең гаепсез икәнен тәмам аңлаган лабаса! Нажарны юкка рәнҗетүен, үзенең гаделсез тузынуын да бик яхшы белә ул. Тик менә күңелдәге җенне барыбер тыя алмый...

Ай ярым вакыт эчендә бөтен кар-яңгыр аның ялгыз башына яуганлыктан, бөтен җанында һәм тәнендә тулышкан кара дәрья тыелгысызга әйләнгәнлектән, ихтыярны саташу алмаштырырга азаплана. Әйе, тулган шеш тишелмичә кала алмый, югыйсә ул кешенең исән күзәнәкләрен, бөтен гомерен агулый башлаячак. Мөгаен шулай. Фәнүзә моны яхшы белә һәм белгән килеш үзенә-үзе хуҗа була алмый.

Менә ул сугышырга җыенган тәрбиясез зат сыман кискен борылып, диварга арка терәп утырды да гаепләүләрен баягыдан да аяусызрак итеп ыргытырга керешге:

— Сиңа инде бернәрсә дә ярдәм итә алмас. Белмим, кеше күзенә ничек күренерсең. Ояты бит, ояты ни тора!

— Кешедән оялырлык мин нәрсә эшләгән? Нәрсә? Нәрсә дип сорыйм мин синнән!

— Үзең шәп беләсең.

— Больницада... Нәрсә өйрәнергә мөмкин?

— Аңарчы булганы бик җиткән.

— Аңарчы нәрсә булган?

— Үзең белгәнне күбрәктер. Миңа сурәтләр генә килеп җитте.

— Нинди сурәтләр?

— Синеке һәм тагын бер кешенеке. Анысы — хатын-кыз.

— Шуннан?

— Җитмәдемени? Җитми калдымы? Бар, тагын төш сурәткә — ялангач килеш.

— Тфү! Акылдан язган бит бу хатын. Ә мин адәмчә сөйләшмәкче булам тиле хатын белән.

— Ә сурәткә төшмәдеңме?

— Нинди сурәткә?

— Сөяркәң белән, оҗмахтагы кебек, шыр ялангач!

Нажар әле һаман бер нәрсә дә аңламый, ә дөресрәге аңламаска тырыша сыман иде. Ләкин инде хәлнең мондый ук аламалыкка тоташуы тиз арада ачыклау таләп итә иде. Битеңә шушындый әшәке нәрсә сибелгән икән, син инде дөньяга бу чырай белән карый алмыйсың — сөртергә, юарга, чистартырга тиешсең. Йөзеңне акла — тиз, бик тиз.

— Менә нәрсә, Фәнүзә. Бу шаяра торган нәрсә түгел.

— Ә син шаярмадыңмы? Шаярмыйча, чынлап гөнаһ кылдыңмы?

— Мин сиңа иң дөресен әйтеп карыйм — житди итеп. Минем бернинди сөяркәм юк. Булганы да юк.

— Булмагач, ничек сурәткә төштегез?

— Әһә, менә ничек! Күрсәт сурәтләреңне.

— Сурәтләр сезнеке!

— Әйе, минем сурәтләрне күрсәт!

— Үзең сатып ал, йөз таңкә сорыйлар.

— Кем сорый, кайда?

Шуннан соң, бик интегебрәк булса да, Фәнүзәгә күптән түгел булган хәлне — үзен ничек интектерүләрен, диссертация яклар алдыннан булган соңгы кичтә һәм хәтта көндез нихәтле бәргәләнүләрен, өзгәләнүләрен сөйләп бирергә туры килде. Шуннан соң гына Нажар иркен сулыш алды. Дөресен әйткәндә, җанына әллә нинди чиркандыргыч нәрсәләр килеп тулгандай булып, ул шушындый кабахәтлеккә бара алган кешеләрнең яшәвеннән, шуларның да кеше исемен күтәреп йөрүләреннән, кеше генә түгел, галим дигән изге дәрәҗәгә күтәрелүләреннән, ә үзенең, ә Фәнүзәнең вәхшилек каршында көчсез, яклаусыз булуларыннан чамасыз зур оят кичерә иде. Кинәт аның битләрен, күзләрен юасы, сабынлый-сабынлый кат-кат юасы килеп китте. Больницага, тып-тыныч

палатага шушы вәхшәтнең бер дулкыны гына кагылуы аңлашылгач, күзләренә тузан тулгандай, күкрәкләре, чигәләре чатнагандай, колак пәрдәләре ертылгандай ачытырга, әрнергә һәм әллә нинди агулы, әллә нинди ямьсез авазлар бөтен зиһенне мәсхәрәләп чеңгелдәргә кереште. Шулай да бөгелеп төшәргә ярамый, чөнки Фәнүзәгә хәзер иң шифалы сүзне әйтеп калдыру кирәк. Әйтмичә калу исә әшәкелек-түбәнлекләрнең тагын да зураюына — чын төсле тоела башлавына сәбәп булыр иде. Нәҗар үзен кулга алырга тиеш. Һәм ул шуңа ирешә дә. Якындагы урындыкны мөмкин кадәр тыныч хәрәкәт белән кучереп, хатыны каршына килеп утырды.

— Ышанасыңмы, ышанмыйсыңмы — анысы синең эш. Тик мин шуны әйтәм: кем беләндер, кайчандыр син әйткәнчә шыр ялангач кыяфәттә, бигрәк тә, кемнеңдер бозык фантазиясе күпертеп күрсәткәнчә, әдәпсез кыяфәтләрдә минем беркайчан да фотога төшкәнем булмады. Син әйткән сурәтләрнең булуы мөмкин түгел. Бүтән сүзем юк. Больницадан, үлемнән котылып чыгуым белән бик әйбәт котладың, гаҗәп матур каршыладың. Рәхмәт. Бетте сүзем.

Нәҗар торып урындыгын үз урынына баягыча ук саклык белән күчереп куйгач, зал ишегеннән чыгып барган җиреннән тукталып, шуны да өстәргә кирәк тапты:

— Әгәр ул сурәтләр чынлап та булса, ул бәндәләр аларны зал буенча таратып йөртерләр иде. Җитәкчеләргә дә, башкала кунакларына да тиз ирештерерләр иде. Синең башка документларың белән бергә, ВАКка да ияртеп җибәрерләр иде.

— Бәлки җибәрерләр дә... Өлгерерләр әле.

— Алар, димәк, шундый рәсемгә җай эзләгәннәр, форсат көткәннәр. Кызганыч, минем андый ук батыр кеше түгеллегем комачау иткән. Өметләре акланмагач... ялган үрдәк булса да очыртып җибәрергә тиеш тапканнар.

— Аларга бу ник кирәк булды дисең?

Нәҗар, урындыкка утырып, тагын шәрехләп аңлатырга мәҗбүр булды.

— Исәпләре бик мәкерле, әлбәттә. Бер атуда — берничә куян.

— Нинди?

— Алар минем больницага кергәнне белделәр бит?

— Мин синең кайсы больницада икәнеңне беркемгә әйтмәдем.

— Садир Хәкимовичка?

— Аңа да ышанмагач, кем кала?

— Менә шул иң ышанычлы кешеләр агуның колактан бирелә торганын тапканнар.

— Ходаем! Сиңамы?

— Икебезгә берьюлы. Икенче исәпләре — сине диссертация якларга бара алмаслык хәлгә китерү. Үзләре яхшы булып калган шартта. Тик анысы да эшкә ашмаган — син алар уйлаганнан көчлерәк булып чыктың.

— Ниятләребез гел изгелектә иде ләбаса! Шуны белгән килеш!

— Төкерәләр алар изгелеккә. Үз кирәкләре өчен алар үз әниләрен, бөтен кешелекне сата алачаклар.

— Без шундый кешеләр гомерен озынайтырга тиеш булабызмы? Юк, адәмнәр мондый кайгыртуга лаек түгел, безнең хезмәтләр әрәмгә китте ахры. Мин хәзер элеккечә эшли алмам, булдыра алмам! Кеше моңа лаек түгел, түгел, түгел!

— Әле генә мине үлемнән коткарган кешеләр... алар да лаек түгелме?

— Белмим, беләсем дә килми!

Моңарчы Нәҗар Фәнүзәнең болай ук ачыргалануын, үрсәләнүен күргәне юк иде. Димәк, ялгыз хатынны мөмкин кадәр җәзалаганнар.

Хәзер ул менә ихтыярын бөтенләй югалткан халдә. Аңа шушылай тугарылырга туры килгән. Тик хәзер аның янында аркаланып өчен ышанычлы кешесе бар. Хәзер аны ул кадәр үк беркем дә газаплый, котырта, агулый алмаячак.

Нажар бер сүз әйтмичә генә хатынының чәчләрен, аркаларын сыйпап торганнан соң, йокы бүлмәсеннән мендәр алып чыкты һәм, сабыйны көйләгәндәй, хатыны өстенә калын шәл китереп япты да, Фәнүзә елавыннан туктагач, ванна бүлмәсенә кереп, кайнар су агызырга кереште. Аннары озак-озак ванна керде, кат-кат юынды.

Аңлашылмаган нәрсә калмаган кебек иде инде. Шулай да Фәнүзәнең чырае тиз генә ачылмады. Күңелендә сулкылдап торган җәрәхәтләр һәм шикләр бөтенләй тынычланырга тиз генә ирек бирмәячәктер. Белдермәскә, сиздермәскә, күрсәтмәскә тырышкан килеш тә ир белән хатын арасы барыбер сизелерлек ерагайды. Өйне күңелле шау-шу белән тутырырга тырышкан Энҗе дә элекке җиңеллекне, ихлас әңгәмәләрне кайтара алмаячактыр.

Сурәтләр, сурәтләр. Кала буйлата чышан-пышан үрмәләгән гайбәтләр артыннан шул кара күләгәләр әле дә ияреп йөри кебек.

Җиңү, гыйльми дәрәҗә шатлык китермәде.

Кемнәрдер үзләренең мәкерле максатларына шул рәвешле барыбер ирештеләр. Әйе.

Кемнәр? Кемнәр алар?

Нажарның эш ансат — төп-төгәл генә атар да куяр: Садир Хәкимович һәм Вәкил, янәсе. Алар юкта мондый түбәнлекләр эшләндеме? Юк. Садир Хәкимович эшли башлагач күренгән фотокарточкалар Вәкил дусты килгәч бермә-бер арттымы? Артты. Бу кешеләрне бу кадәр дәрәҗәле эшкә кем күтәрде? Әлбәттә, алар моның өчен хәлиткеч чараларны үзләре күрделәр. Хәзер югары оешмада эшли торган элекке гыйльми секретарь аша байтак нәрсә майтардылар. Әмма директор бик тә принципиаль булса, ныграк торса, әлеге директор урынбасары лабораториядә гади хезмәткәр булып утыра бирсә (Нажар нәкъ шулай гына булыр дип уйлый да иде бит), Вәкил бу институтка урнаша алмаячак иде. Җитмәсә, тагын күп кенә яшь аспирантлар алар тирәсендә чуала. Аларга да бу җитәкчеләр үз тәрбияләрен бирмәсмени? Бирәчәкләр. Дөресрәге, хәзер үк бирәләр инде. Моны хәзер үк сизәргә мөмкин — артык зирәк булмаган хәлдә дә.

Иң зур оят, дөресрәге, оятсызлык шул — мәхәббәтне, аның да иң табигый, иң нәзберегән җинаятькә тиңләп рисвай итәргә бөтен дөнья әзер. Ә бит бөтенләй киресенчә, мәхәббәтне мыскыл итүчеләрне, тойгыларның эчкерсез мәлен сагалап, күзәтеп, пычратып йөрүчеләрне хурлык баганасына бәйләп яки асып куярга кирәк иде. Баштүбән йөреп, астан тиешсез урынга карарга күнеккән әхлакны ничек аякларына бастырып куярга? Кайчан, ниһаять?!

Вәкилнең кем икәнлеген электән белгән Нажар аның институтка эшкә керүенә башта ук катгый рәвештә каршы иде. Фикерен директорга ап-ачык итеп әйтте. Ләкин директор мөнәсәбәтләр тирәнлегенә, аларның катлаулану мөмкинлегенә әһәмият биреп бетермәде. Аңа югарыдан шалтыраттылар. Элек шушында гыйльми секретарь, аннары директор урынбасары булып эшләгән, хәзер югары инстанциягә күчкән Рим Салихович дигән коллегасына исә Садир Хәкимович дусларча сүз кушкан иде. Кул — кулны, ике кул битне юа. Александр Иванович шуны белгән көе, ахыргача нык тора алмады. Әйе, өстән килгән телефон тавышы тынып ярты сәгать уздымы-юкмы, Вәкил директор кабинетына килеп тә керде. Александр Ивановичка да, хәтта Нажарга да, билгән иелеп, сәлам бирде. Директор урын тәкъдим итмәгәнлектән, әнисе йомышы белән килгән малай кыяфәтендә басып калды. Һәм шулай борын тартып шактый вакыт торырга туры килде. Директор аны юри сыный, юри интектерә — Вәкил моны сизә. Директорның максаты көн

кебек ачык — шул ысул белән булса да иптәшкә үз дәрәҗәсен аңларга ярдәм итмәкче ул. Вәкилне үпкәләтергә һәм үпкәләтеп шәхес тойгысын уятырга, мыскылдан саклану дәрте кабызырга тырыша, килгән юлыннан борылып кире чыгып китмәсме дип өметләнә. Кешеләрне белеп бетерми иптәш директор. Ә Вәкилне бигрәк тә...

Әйе, һичнинди коткы-фәләнгә алдана торган кеше түгел ул Вәкил. Башкалар бәлки белеп бетермидер, ә ул үзен шәп белә. Нык тора. Әрсезләнергә туры килә килүен дә, ләкин... ләкин нишлисең — назлы назланып торган арада әрсез ашап туйган бит. Ул да — Вәкил дигән кеше дә шушындый җаваплы, хәлиткеч мизгелдә горурлык хакына ниятеннән чигенә торган дивана түгел. Кирәк икән, кимсетелүдән дә курыкмый, кирәк икән, иптәш директор, әгәр әдәбең сыйдырса, кил дә син аның битенә төкер. Вәкил түзәчәк. Түзү генә димә,- елмаячак һәм сиңа матур сүз әйтәчәк — синең зирәклегең, кыюлыгың хакында. Кайгыру, үкенү юк — соңыннан бит барыбер әҗәтне кайтарырга җай чыгачак. Шулчакта кемнең кайчан кимсетелгәне, кемнең кимсеткәне саф су астындагы кара таш шикелле күренеп торачак һәм исәп-хисап дөрес хәл ителәчәк. Гаепле кеше һичшиксез, үзе кылган катылыкны үзе татыячак. Хәтта артыгы белән.

Вәкил, изгелекнең, ихтирамның җанлы рәвеше сыйфатында, директорның нәкъ каршысына килеп утырды. Утырды да, туп-туры караган хәлдә, үзенең балачактан кадерләп саклаган һөнәрен яңартып, колакларын... әйе, ике колагын берьюлы селкетергә кереште. Бик җитди кыяфәттә. Директор, нидер сизенеп, башын күтәрде дә, ни уйларга белмичә, шаккатты да калды. Әйе, күр, иптәш директор, үз кул астында эшләячәк кешеләрнең нәрсәгә сәләтле икәнлеген җитәкче белеп торырга бурычлы. Күрегез менә — нинди тирән фикерле күзләр белән карап, сезнең кабул ителәчәк хезмәткәрегез үзенең сөякле колакларын селкетепме селкетә ләбаса. Тагын кайсы кешегезнең хәленнән килә бу?!

Директорның күзләре чынлап түгәрәкләнде. Колаклар аның саен катырак, күнеллерәк селкенә иде. Ах, менә бит шайтан токымы, менә бит нишли! Нишли! Мондый чакта теше сызлаган кеше дә кычкырып көлмичә булдыра алмас. Олы ир кеше үзен-үзе хуҗаның ишәге итеп күргәзсен әле!

Директор сирәк була торган ихлас көлү белән кычкырып көлеп җибәрүен сизми дә калды. Шул секундта ук Вәкил үзе дә сабый шикелле ихлас кеткелдәп җибәрде. Ләкин кызыктан түгел, үзенең җиңүен сизүдән һәм шуның лаеклы тантанасы шатлыгыннан көлде ул. Аларның көлүе Нажар чыраена гына кара күләгә булып төште.

Мәсьәлә хәл ителде.

Берничә көннән мөдир дигән кеше гыйльми секретарьга, ә соңрак директор урынбасарына — Садир Хәкимовичка әйләнде.

Нажар нәкъ шул көннәрдә тагын командировкага киткәнлектән, соңгы вакыйгаларга катнаша алмады. Өйдә чагы туры килсә дә, каршы килүдән инде барыбер файда юк дип, бәлки әле кул гына селтәгән булыр иде. Ә Фәнүзә кул селти алмады. Әмма Вәкилнең дә, мөдирнең дә интригаларга сәләтле генә түгел, хәтта шуларсыз яши алмый торган кешеләр икәнлеген, шуны акыл билгесе, көч билгесе, ихтыяр билгесе дип санауларын, ни хәтле генә аңлатырга тырышса да, юк, уңышка ирешмәде.

— Әгәр без һәрвакыт үзебез теләгәнне генә эшли алсак, дөньяда күптән берниндн проблема калмас иде, яшәүнең кызыгы кимер иде, — дип елмаерга тырышты Александр Иванович.

Әйе, шуннан соң яшәү шактый кызыкланып та китте шул. Тик директорның хәзергесе көндә, елмаясы гына, ай-һай, киләме икән?

Әгәр Вәкилнең колак селкетүенә алданмаса һәм шикле иптәш кыңгыравыннан курыкмаса... автомобиль һәлакәте дә килеп чыкмыйсы иде...

*Ахыры бар.*

# Мөхәммәт Шәйхи

## Иделләрем, илләрем...

* * *

Иделләрем, илләрем —
инешләрем, күлләрем...
Кемгәдер яшәп китәр җир,
иң изге җир кемгәдер.

Иделләрем, илләрем —
авылым, калаларым...
Төзәлеп тә, күңелнең гел
сызлаган яралары.

Иделләрем, илләрем —
гомер көтәр җирләрем...
Мин бу җиргә бер көнгә дип,
кунак булып килмәдем!..

Иделләрем-илләрем!

## Җанда бер исем

Булган болгавыр, михнәтле еллар,
халык тынычлык эзләгән, күчкән...
Калыккан җирдә яңа авыллар,
Шуларның берсе —
«Еники-Чишмә...»

Алдагы көне — киләчәк заман,
Үткәне аның Болгарга җиткән.
Җанда җыр булып яңгырап тора:
«Еники-Чишмә...»
«Еники-Чишмә...»

Олы юл буйлап кешеләр узган,
Ширбәттәй татлы суларын эчкән.
Су белән бергә агып кергән ул:
«Еники-Чишмә...»
«Еники-Чишмә...»

Китканнәр сагынып кайтканнар аны,
Онытa алмыйча йөргәннәр читтә.
Җанга догадай сеңгән бер исем:
«Еники-Чишмә...»
«Еники-Чишмә...»

Шушы исемне якын, үз итеп
Гомерлеккә яр-киленнәр төшкән.
Иренең ил-җире — иң изге туфрак:
«Еники-Чишмә...»
«Еники-Чишмә...»

Бу исем минем җырым чишмәсе,
Мәңге бетмәслек моңнарын эчәм.
Дөньяга күзем ачылган урын:
«Еники-Чишмәм...»
«Еники-Чишмәм!..»

---

МӨХӘММӘТ ШӘЙХИ (1949) — шагыйрь, «Көн үзәге» исемле китап авторы. Түбән Кама шәһәрендә яши.

## Бу — минем туган җирем

...Беләм дә, белмим дә сыман,
Аңлыйм да, аңламыйм да —
Әйтелмәгән нindидер сер,
Нindидер моң бар монда...

Бик ераклардан килә ул,
Узганнан, борынгыдан —
Бу җирдә халык язмышы
сыналган урын булган...

Серләре шуңа тирәндә,
тирәндә яралары...

Без менә шушы төбәктә
дөньяга яралганбыз...

Серләре, сагыш-моңнары
җаннарга сеңгән күптән...
Шуңа бу җиргә берегеп
бабамнар гомер иткән...

...Беләм дә, белмим дә сыман,
аңлыйм да, аңламыйм да,
Гомер буе өйрәнергә
серле моң калган миңа...

## Талпыну

Чулман суның дулкыннары актыр,
Төпләрендә асылташлар ятыр —
Алкын суның, һәй тоныклыгы...

Ерак диңгезләрне кичәр идем,
Кәүсәр чишмәләрен эчәр идем —
Таза ла көймәләрнең, әй, юклыгы...

Күзләремне еракларга теким,
Ничек кенә гомеркәйләр көтим —
Югалды ла минем бүз чаптарым...

Эзләп йөрим, далаларны иңләп,
Тик кылганнар гына йөгерә җилдә —
Табулар, әй, кыен югалтканны...

Мәңгелеккә илтә бара сыман,
Мине дәшеп хәбәр сала сыман —
Сызылып киткән очар кошлар юлы...

Кояш күзе астында дөнья иркен,
Күңел канаткайларын ла җилпеп,
Очып китим микән кошлар булып?!

## Хуҗалар тавы

*(Борынгы Бүләр җыры)*

Хуҗалар тавына менгән чакта
кизләүләрнең күзләренә кара.
Йөрәгеңнең януларын аңлыйм,
Авыр хәлләр, дускай, авыр яра...

Хуҗалар тавына менгән чакта
Кизләүләргә ташла алтын-көмеш.
Без күрәсен генә кемнәр күрсен,
Язмыш бүлгән безгә шундый өлеш...

Хуҗалар тавына менгән чакта
Битләреңне чылат салкын суга.
Без генәме җирдә хәсрәт күргән,
Безнекеннән авыр хәлләр булган...

Хуҗалар тавына менгән чакта
Кизләүләрнең салкын суларын ал.
Жиребез сау, шөкер кылыйк әле,
Сусын басар салкын чишмәбез бар...

Хуҗалар тавына менгән чакта
Бер кычкырып җырла, барсы ишетсен.
Күрсен җиһан, барча җан уянсын,
Хәсрәтләрне сулар алып китсен...

Хуҗалар тавына менгән чакта
Арма, дускай, ару хәле яман.
Җәрәхәтләр гел төзәлми тормас,
Тауларга бит үзебез хуҗа һаман...

## Суар капкасы

*Какма кеше капкасын,*
*Үзеңнекен кагарлар.*

Әйтем.

Шәм-Суарның горурлыгы — җиде капка,
капкасының такталары — имән ярка.
Шул капканы әчып кергән адәмнәргә
акыл керә, гамь уяна, мәне арта...

Шәм-Суарның горурлыгы — җиде капка,
түбәләре зәңгәр күккә тиеп тора.
Дөнья әле бик болгавыр, ни язгандыр,
капкаларын ачып кер дә хәлен сора...

Шәм-Суарның горурлыгы — җиде капка,
ап-ак ташлы юллар килә төрле яктан.
Килгәннәргә илең күрсәт, җирең күрсәт,
мактанырлык чамаң булса, әйдә, мактан...

Шәм-Суарның горурлыгы — җиде капка,
капкасында җиде алып тора сакта.
Дуслар килсә, ач киереп җидесен дә,
дошман килсә җидесен дә куй йозаклап...

Шәм-Суарның горурлыгы — җиде капка,
Шәм-Суарга кемнәр килеп, кемнәр китмәс.
Дөнья фани, уйлар төрле. Уй чигенә
чыгар өчен бер буынның гомере җитмәс...

Шәм-Суарның горурлыгы — җиде капка,
искән җил дә үтә алмас капкасыннан.
Кирәк булса, без дә барып кагалабыз,—
ятлар килеп капкабызны какмасыннар!

................

## Илдар Әхсәнов

# ЯКТЫРДЫҢ ЧОРГА, ЗАМАНДАШ...

### Уралым

Кабат киләм, тайга урманнары,
Киләм сезгә — инде ничәнче;
Балавызлар сыгып хушлангансыз
Башта — ап-ак күлмәк кигәнче.
«Хуш киләсең!» — дия Төньяк Урал,
Сулар һавасыннан җиңел тән.
Эрбетләрнең яшел иңнәрендә
Кар энҗесе уйный җемелдәп.—
Матурлыкка дәшкән маяк алар,
Күк гөмбәзен тота очлары.
Туганнарым йорты сыман газиз
Ватанымның шушы почмагы.
Ыругдашлар әүвәл заманнардан
Руда-ташлар чапкан Уралда...
Кайтавазлар яңгырый:
— Яктыга бар,
Сагышларга бирүк уралма!..

*

Бу трассалар юлы киң Себернең
Кай җиренә сине ташламас;
Тундраның кызыл кояшында
Кызынмыйча булмас, замандаш!
Ни чикләсен безнең алгысуны? —
Кеше бире аяк басмаган.
Арттырырга булгач ил җегәрен,
Михнәте дә кичсен башлардан!

...Безга туңа нәни тәрәзәсе,
Вагоннарда әле торабыз;
Газүткәргеч өчен завод хәтле
Тизләткечләр рәте корабыз.

---

ИЛДАР ӘХСӘНОВ (1935) — шагыйрь, «Кыйбла» исемле шигырь китабы авторы. Әлмәттә яши.

Тәндә шулай йөрәк кан куадыр,
Басымына түзсен торбалар.
Агымыннан көнләп газ-ташкынның,
Ил дошманы корттай үрмәләр!

Көч-кодрәтен туплап, поляр төндә
Йокысыннан бу җир тордымы,
Иңбашына ала ал кояшын,
Галәмгәчә — тизлек-ыргымы.

## Колонна

Гайрәт, төтен чәчеп ак дөньяга,
Ямбургка бара колонна;
Узып китә тоташ атналарың,
Күпме генә ярсып кабынма.
Уза юлда бер тамгасыз-нисез,
Әллә чигә юлың, әллә юк...
Озын поляр төндә күк читләре
Куйган була бераз алланып.
Йолкып ала гүя ут-фаралар
Караңгыдан салкын бушлыкны.
Ис тә китми мотор гүләвенә,
Жан эзли тик йоклар ышыкны.
Безнең йөктә — азык-ягулыктыр,
Сүндермәбез яккан учакны!
Шул изгелек белән безнең җаннар
Сыналмаган юлда көч тапты.
Томанлана кинәт күз карашы:
Рух-зиһенгә инде ял биреп,
Ак диңгездә вагоннары белән
Утрау сыман калка Ямбург!
...Синнән алда бире юл салганнар,
Син дә соңгылардан түгелсең:
Зур тормыш бу,
Алда — яшәү үзе,
Яккан учак ничек сүрелсен!

●

Өтеп ала февраль суыклары,
Боз шикелле металл таркала.
Ак күбеккә төшкән ат диярсең,
Капланадыр бәскә аркалар.

Машиналар «теше» үтмәс җирдә
Туң чабабыз кәйлә-лом белән.
Ут чәчсә дә җилләр боз иленнән,
Көн буена билләр бөгелгән.

Бетон житкер станца нигезенә,
Сулыш белән җылыт бетонны...
Поляр якта Таймыр, Уренгойлар
Чыныктыра безнең буынны.

Эш-фигылең белән, замандашым,
Бар сынына чорга яктырдың;
Синең белән таптым бәхетемне,
Синең белән илдә батырмын!

## Ямбург

Гөрелдидер буровойлар,
Мәңге туңга гамь биреп.
Басты дөнья каршысына
Куш йөрәкле Ямбург.

Ишетергә язган аңа
Җанлы сүзен кешенең;
Иминлеккә башлавыдыр
Тарихында эш көнен.

Дулкынлана ак киңлекләр,
Җыергалап маңгайны:
— Хәлгә керер юллар төшсә,
Яшәүләре уңайлы!

Сузган ике кулы белән
Якты шәмен яндырып,
Карлар ера-ера атлый
Зур тормышка Ямбург.

*

Яз сөйләшә башлагандыр
Туган якта, мөгаен;
Гөрләвекләр шаулатса да,
Белер димен үз җаен;

Үз көенә бар нәрсәне
Яз яңарта нечкәләп;
Кем соң аңа кырыс дияр,
Анда түгел һич сәбәп.

Яңармыйча булмый: җан да
Язларында яңара;
Рух өстәлә торса аңа,
Дөньялар да җай бара!

Пакьлек бөркер шомырт-балан,
Ак чәчәген сибер дә.
Керфек кагып алыр шул чак
Дәү эрбетләр Себердә.

Яз сөйләшми килмәс инде,
Өметләрем — бөредә;
Яңарасы көннәрем бар —
Гел куанып йөрергә!

*КПССның XXVII съезды карарларын — тормышка!*

## Ю. В. Кожевников

# ВУЗНЫҢ ИРТӘГӘГЕ КӨНЕ

Илебез фәне, техникасы авиация, кибернетика, радиотехника, приборлар төзү өлкәсендә яңадан-яңа уңышларга ирешеп тора. Бу хәл ул тармаклар өчен белгечләр хәзерләүче безнең институт укытучыларында һәм студентларында тагын да тырышыбрак эшләү, уку дәрте уята.

Безнең авиация институтында белгечләр күп юнәлешләр буенча әзерләнә. Уку планы да биш ел саен үзгәреп тора. Төп курсларның эчтәлеге тамырдан яңара. Укыту һәм тәрбияләүнең яңа методлары, чаралары кертелә. Институтның инфраструктурасы, тармаклар, предприятиеләр белән элемтәләре дә яңартыла бара.

Эшебез катлаулы да, кыен да! Бу юлда ялгышлар, югалтулар да булгалый. Шунсыз мөмкин түгел. Яңа бишьеллыкның үсеш баскычларын ышанычлы иттереп билгеләү өчен аларның чыганакларын табу, аңлау бигрәк тә мөһим.

Бүген безнең институт, инженерлар әзерли торган башка вузлар кебек үк, үсешенең чираттагы шактый катлаулы этабын кичерә. Аның төп үзенчәлеге һәм каршылыгы шунда: бер яктан, инженерлык эшчәнлегенең катлаулылыгы, җаваплылыгы арта бара, ә икенче яктан, яшьләрнең шактый өлешенең инженерлык белеме алуга әзерлек стандартлары түбәнәя. Вузларның фәнни-педагогик һәм техник потенциалы тайпылышсыз үсә, ә мәктәптәге әзерлеге йомшак, ихтыяры ныгымаган яшьләр аны тарта алмый. Техник вузларга конкурс кимүнең төп сәбәпләреннән берсе әнә шунда. Кайберәүләр моның белән килешми. Башка тармакларның, әйтик, көнкүреш хезмәте күрсәтү сферасының «тарту көче» зурайды дип аңлатырга телиләр. Алай түгел! Көч, ихтыяр сынала торган кыен эшләр яшьләрне гомер-гомергә кызыктырды. Хәзер дә алар тау инженеры, металлург, математик, очучы кебек кыюлык сораучы һөнәрләргә сокланып карыйлар. Ә инде хәтта хыялында да авырлыкны иярләргә үзендә көч сизмисең икән, ул чакта юрганыңа карап аяк сузарга кала.

Монда гомуми һәм профессиональ белем мәктәбе реформасына кадәр, мәҗбүри урта белем бирү турындагы законны үтибез дип, процент куу, күз йомып карау да үзен нык сиздерде. Партия һәм хөкүмәтнең реформа турындагы карары моңа чик куйды. Яшьләргә хезмәт тәрбиясе бирүгә йөз тоту — хәзерге вуз тормышындагы әлеге төп каршылыкны хәл итүнең принципиаль һәм бик вакытлы юлы.

Ләкин вузда әле үткәндәгенең яман тәэсире шактый вакытлар сизеләчәк. Безгә, институтка килүче яшьләрне чын инженерлар итү өчен, мәктәптә бирелергә тиешле булган белем һәм тәрбияне иңдереп җиткерү буенча да зур тырышлык куярга туры килә. Педагогия коллективларына һәм җәмәгать оешмаларына һәр студент белән аудиториядә генә түгел, тулай торакта, өмәләрдә, спорт мәйданчыкларында да бик ныклап эшләргә кирәк булачак.

Үз-үзебезгә һәм студентларга карата таләпчәнлекне киметүгә юл куярга һич ярамый. Югыйсә реформага кадәрге урта мәктәптән башланган тискәре нәтиҗәләр вузда гына түгел, илебезнең инженерлар корпусында да үзен сиздерәчәк.

Мактанып булмый: безнең институтта студентларның уку барышында төшеп калу проценты илдә иң зурлардан. Әмма, ирешкән дәрәҗәбездән чыгып караганда, ул кимрәк була да алмый. Югыйсә, күз буяу кебегрәк аяныч хәл килеп чыгар иде.

Уку-укыту эшләре хәзергечә куелган шартларда байтак студентлар дәрес калдыра, өй эшен үтәү графикларын өзә, әхлаксызлык күренешләре очрап тора. Һәркайдагы

---

КОЖЕВНИКОВ ЮРИЙ ВАСИЛЬЕВИЧ (1932) — Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе, техник фәннәре докторы, профессор. Күпсанлы фәнни хезмәтләр авторы. А. Н. Туполев исемендәге Казан авиация институты ректоры.

кебек бездә дә мондый кимчелекләрне бетерүдә таләпчәнлекне, оешканлык һәм дисциплинаны югарырак дәрәҗәгә күтәрү ярдәм итәргә тиеш.

Шушы елдан башлап без институтта «Дисциплина» дигән максатчан эчке программа кертәбез. Ул уку процессын тәшкил иткән һәр тармакта администрациянең, партия, профсоюз, комсомол оешмаларының тырышлыкларын бергә туплый.

Бу чаралар арасында яңа нәрсәләр юк диярлек. Сүз студентларның һәм укытучыларның, күптән мәгълүм булып та, еш кына истән чыга яисә игътибар ителми торган төшенчәләр һәм нормаларны төгәл, эзлекле үтәве турында бара. Бу программаны тормышка ашыруның төп катлаулылыгы да яңартыла торган чараларның әһәмиятсез, юк кына нәрсә булып күренүендә. Шулай да ул инде үзенең нәтиҗәләрен бирә. Менә беренче, зур булмаса да, кызыклы нәтиҗә. Очу аппаратларының двигательләре факультетында лекцияләргә йөрү яхшырды һәм деканат сводкалары буенча алганда дәрес калдырулар... 2-3 тапкыр артты. Бу каршылык — эшкә чынлап тотынуларын күрсәтүче куанычлы факт.

Хәзер техник вузларның бүгенге тормышына шактый зур йогынты ясаучы икенче бер факторга тукталыйк. Сүз җәмгыятьтә инженер фигурасының абруе һаман киму турында бара. Уйлап карасаң, аның җитди сәбәпләре бар. Җәмгатьчелек фикере белән исәпләшмичә булмый. Яшь белгечләр җибәргәндә завод вәкиле аларның нинди белемнәр алып чыгуы белән кызыксынып тормый икән, монда инде ачык күренә: аларны инженердан бигрәк штат расписаниесен тутыру гына кызыксындыра.

«Йөз тәңкәлек» инженерлар армиясе әнә шулай барлыкка килә. Аларның башкарган эшләре институтта бишәр ел алган белемнәреннән ерак тора, идеалларына, принципларына бер дә туры килми. Киләчәктә әҗерен кайтарыр дип инженерны институтта күпме әзерлибез, ә аны бик кыйммәткә төшкән бу багажының һич кирәге булмаган эшкә билгелиләр. Кирәк чакта урам себерергә чыгаралар, яшелчә аралауга да иң элек шулар китә. Кайберәүләрнең инженер курткасын эшче киеменә алмаштыру турында уйлый башлавы да гаҗәп түгел.

Ә бит ул кеше яшьтәшләре станокта эшләгән, җир сөргән, ил саклаган вакытта биш ел гомерен институтта үткәргән. Аңа күпме акча тотылган. Бурычы бик күп җыелган. Йөз тәңкәлек эштә гомерең буена да түләп бетерерлек түгел.

Шуның өчен генә булса да инженерның абруе югалуга чик куярга вакыт. Әйтик, бәлки, инженерлык дипломы баса торган станокларны башка эшкә көйләргә кирәктер? Уйлашыйк!

Җәмгыятьтә бәһанең анык, мораль һәм материаль яктан нигезләнгән, социаль акланган шкаласы булырга тиеш. Монда күп нәрсә тарих барышында формалашкан, аларның вакланууыннан сакланырга кирәк. Шул исәптән инженерның югары исеменә дә баштагы абруен, дәрәҗәсен кайтару мөһим. Бу аларны әзерли торган уку йортларының да абруена файда итәр иде.

Инженерларны оптималь масштабларда һәм пропорцияләрдә хәзерләү, алардан дөрес файдалану мәсьәләсен ничек хәл итәргә соң? РСФСР югары белем министрлыгы буенча хәзер кертелә торган система шуңа юнәлдерелә. Ул белгечләрне предприятиеләр белән килешеп, максатлы иттереп хәзерләүне күздә тота. Булачак белгечләрне баштан ук, иң яхшысы — институтка кабул ителү белән үк, киләчәктә эшләячәк урынына билгеләү планлаштырыла.

Республика вузлары эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләсе партия өлкә комитеты бюросында каралды. Анда инженерларны хәзерләү һәм бүлү проблемалары буенча ачыктан-ачык һәм кискен фикер алышу булды. Алда зарур дип табылган юнәлешләр шундый: институтка керүчеләрне формалаштыруда предприятиеләр актив позициядә торырга тиешләр, институтта индивидуаль планнар һәм программалар булдырылсын, институт һәм предприятиеләрдәге җәмгать оешмалары студентларның максатчан группалары белән идея-тәрбия эше алып барсын, студентлар баштан ук завод тормышына тартылсын. Бу положениеләр фәнни-техник эзләнүләрнең нигезен тәшкил итә. Фәнни лаборатор базаны яңарту программасы да эшләнде. Хәзер яшь белгечләр хәзерләү бурычы институтка гына түгел, предприятиеләргә дә бик якын. Бу яңалык КПССның XXVII съезды карарларына турыдан-туры җавап бирә. Болай эшләгәндә инде предприятиеләр әзер яшь инженерлар килгәнен әүвәлгечә кул кушырып көтеп тора алмый, мәсьәләне чишүгә үзләре дә турыдан-туры катнаша.

Инженерларны максатчан хәзерләү укытуның эчтәлегенә һәм технологиясенә дә яңача карарга мәҗбүр итте, белгечлекләрне, специальләшүне үзгәртеп коруда тизрәк кыймылдарга этәргеч ясады. Безгә, мәсәлән, туры элемтәләр басымы астында бер белгечлекне ябып икенчесен ачарга; технологик юнәлешне көчәйтергә, укыту процессының барлык якларына ЭВМ кертүне тизләтергә; яңа үзгәрешләргә, аерым алганда, яңа белгечлекләр булдыруга һәм булганнарын үзгәртеп оештыруга әзерләнергә туры килде.

Вуз тормышын активлаштыруда куәтле юнәлешләрнең берсе — укыту-фәнни процессны кибернетикага көйләү хәзер генә башланган нәрсә булмаса да, бу — яңа күренеш. Аның төп казанышлары алда әле. Шунысын өзеп әйтик, физик-математик, конструкторлык-

технология, дөньяга караш юнәлешләре белән беррәттән кибернетика инженерлар хәзерләүдә баштан ахырга кадәр бара торган иң мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора.

Элек студент логарифм линейкасы һәм сызым тактасы белән генә эш итә иде. Хәзер катлаулы электрон-хисаплау машиналары, шуңа бәйләнешле башка нәрсәләр сорала. Яңа штатлар, мәйданнар, махсус тәэминат, шактый кыйммәткә төшә торган чаралар кирәк булып чыга. Бу башлангыч институтта юл яра инде, элекке гадәтләрне кысрыклап, яңадан-яңа мәсьәләләр баш калкыта. Моңа әзер торырга, шул исәптән вузда производство мәйданнары һәм штат нормативларын яңадан карап чыгуга да әзер булырга кирәк.

Яңача эш итү авыр. Хисаплау техникасын булдыру үзе генә дә ни тора! Үз-үзен аклау ягыннан вузлардагы ЭВМ бик файдалы, әмма аны табу, алу безгә бик кыен, кыйммәт. Заманча ЭВМнарның җитмәве бик нык сизелә. Бу бер бездә генә дә түгел, шуңа күрә вузларны хисаплау техникасы белән тәэмин итү механизмын җайга салырга кирәк. Әлегә исә эш шәхси бәйләнешләргә таянып кына алып барыла.

Предприятие җитәкчеләре еш кына, вуздан килүчеләр эшкә тиз генә кереп китә алмый, дип зарланалар. (Сүз кичке факультетларда укучылар турында бармый). Минемчә, зарланырга кирәкми. Ни өчен дигәндә, вуз белән производство икесе — бөтенләй ике дөнья, һәм кеше аларның берсеннән берсенә күчкәндә тиз генә күнегеп китә алмый. Яңа машинаны да әле беренче көннән үк тулы нагрузкага эшләтмиләр. Инде сүз яшь белгечләрнең алгы позициягә басуы турында бара икән, бусы — башка мәсьәлә.

Бу яклап алганда, вузда әлегә бөтенесе дә эшләнми. Мәсәлән, «Производство экономикасы, производствоны оештыру һәм идарә итү» курсында эштәге мөнәсәбәтләрнең этикасы һәм культурасы белән бәйле бүлекләргә ныграк игътибар бирү, аларны тирәнәйтү кирәк иде. Хәзерге курс инженерның оештыру һәм идарә итү сәләтен җитәрлек үстерми әле. Үз институтыбызда без бу юнәлештә кайбер чаралар күрдек тә инде: «Инженерлык педагогикасы һәм психологиясе» дигән кафедра ачтык. Хәзер бу кафедраның төп дисциплиналары турында ныклап уйлыйсы бар.

Үзгәртеп корулар уңаеннан әйтәсе килгән тагын бер теләк: укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләп алып бару турындагы ленинчыл положение югары мәктәпкә дә тулысынча кагылсын иде. Югыйсә, сәер хәл килеп чыга: урта мәктәп тәрбиянең шушы үтә мөһим принцибы яктылыгында үзгәртеп корыла, ә аны тәмамлап чыгучылар, үсә төшкәч, институт аудиторияләренә килеп керәләр, монда исә әлеге принципны искә төшерүче дә юк. Уку планына «Хезмәт» дигән дисциплина кертелмәгән. Хәтта, без күздә тотканча, предприятиеләрдә кафедра һәм лаборатория филиалларының киң челтәрен ачу да хезмәткә тарту проблемасын хәл итеп бетерә алмый әле. Бу мәсьәлә теоретик яктан да, практик яктан да өр-яңа чишелеш көтә.

Сүз, көндезге укудан баш тартып, кичке укуга күчү турында бармый. Көндезге укуны хезмәт белән бәйләп алып бару юлын табарга кирәк. Аның структурасын хезмәт көннәре, предприятиеләрдә өзлексез лаборатор практика үтү, бөтен уку барышында реаль курс һәм диплом проектлары эшләү рәвешендә күз алдына китерергә мөмкин.

Яшьләргә хезмәт тәрбиясе бирү мәсьәләләре буенча вузда гына түгел, гомуми һәм профессиональ белем мәктәпләрендә башкарасы эшләр күп. Шунлыктан, югары мәктәпне үзгәртеп кору алдыннан — агропром үрнәге буенча — урта белем реформасының кайбер положениеләрен ачыклау да урынлы булыр иде.

Бүгенге вузларны ике нәрсә борчый: алда әйтелгәнчә, яшьләрнең институтта укуга җитәрлек әзерлекле булмавы һәм, икенчедән, мәктәп — армия — вуз чылбыры егетләрнең яшь үзенчәлекләре белән туры килми. Армиягә институтның беренче курсын тәмамлаучылар китә. Бу хәл бөтен эшкә таркаулык кертә.

Минем ышануымча, кайсы күзлектән генә карама — хезмәт тәрбиясе, социаль гаделлек, өзлексезлек ягыннан да, логика ягыннан да, урта белем алуны 18 яшькә кадәр дәвам итү файдалы кебек. Шуннан соң барлык егетләр Армиягә китә, вузга шуннан соң гына кабул итү хәерле. Гади дә, аңлаешлы да, гадел дә! Урта белем алуның сузылуы дәүләт өчен кыйммәткә төшмәсен, яшьләрнең әхлагына, моралена зыян китермәсен өчен урта мәктәпнең соңгы ике елын кичке схема буенча укытырга була.

Минем тәкъдим шундый: 6 яшьтән 15 яшькә кадәр балаларны гимназия тибындагы мәктәпләрдә, 15-18 яшьлекләрне соңгы ике елы кичке мәктәп тибындагы училищеларда укытырга; аннан соң егетләр чын ир-атлар булып формалашу өчен Совет Армиясендә хезмәт итәләр. Менә шундый дүрт еллык хезмәт һәм гражданлык чыныгуы үткәннән соң гына вузга керүне планлаштырырга мөмкин. Шуның өстенә без югары мәктәпне дә тиешенчә үзгәртеп корсак, илебез моңарчы күрелмәгән энергия, ихтыяр һәм акыл көченә ия булган инженерлар алачак. Туполевлар, Королевлар, Бардиннар, Завенягиннар, Тевосяннарның яңа буыны киләчәк!

Шулай итмәгәндә, нәрсә килеп чыга соң? Хәзер кадрларны кабаттан хәзерләү зур эш булып алга баса. Шуның өчен бөтен бер факультет ачабыз. Инде әллә кайчан укып чыккан, олыгайганнарны укыту күздә тотылса, бер хәер иде. Юк бит, шактыеның техник вузларны чагыштырмача күптән түгел генә тәмамлаган булуы күздә тотыла. Бүген вуз тәмам-

лап чыгучылардан күбесенең, тормыш чынлыгы җитмәгәнлектән, тормыштан, производстводан, коллективларга җитәкчелек итүдән куркуы сер түгел бит.

Вуз техникумнан нәрсәсе белән аерыла соң? Өйрәнелә торган предметларның катлаулылыгы белән дип һич тә әйтмәс идем. Бөтен хикмәт шунда: вуз үз укучыларын эшчәнлекнең югары формасына — чынбарлыкны иҗади үзгәртүгә, идеяләр тудыру һәм аларны машиналарга, приборларга, программ комплексларга әверелдерү «технологиясенә» өйрәтә.

Укытучылар үзләре идеяләрнең конструкторлары һәм технологлары, ягъни зур галимнәр булмаганда, моңа өйрәтү мөмкин түгел. Монда вуз гади уку йорты гына түгел, ә зур фәнни-тикшеренү үзәге булырга тиеш.

Шулай икән, үзеннән үзе мондый нәтиҗә килеп чыга: фән — югары белем бирүнең табигый нигезе, һәм вуз фәненең төп җимеше — институтны тәмамлап чыгучылар.

Вузның нәтиҗәлелегенә бәя биргәндә моны еш кына онытып җибәрәләр, күпме мәкалә һәм монография басылып чыгуын, кертелгән яңалыклардан ничә сум экономия алынуын санарга тотыналар.

Вуз төрле белгечлеккә өйрәтә икән, фәнни «монокультурага» гына ябышып ятып булмый. Фәнни юнәлешләрнең күплеге, үз чиратында, тикшеренүләрне комплекслаштыруны таләп итә.

Вуздагы фәннәрнең менә шундый үзенчәлекләрен онытырга һич ярамый. Ул гына да түгел, аларны дөрес бәяләү турында да уйларга кирәк. Башлангычы ягыннан фундаменталь, ә кулланылышында да әллә ни нәтиҗәле булмаса, ул чын, җанлы фәнлектән туктар иде. Вуз фәненең гамәли эффектларын да исәптән алып ташлау һич мөмкин түгел. Бу — аның тормышчанлыгы һәм җәмгыять каршындагы бурычы.

Институтта бу каршылыклы диалектиканы үрнәк төстә хәл итү мисаллары бар. Менә СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты профессор В. Е. Алемасов җитәкчелегендәге кафедра. Биредә хәзерге двигательләр теориясе барлыкка килде. Бу — физика, химия, математиканың соңгы казанышларына таяна торган зур фән. Шушы теория нигезендә дәреслек язылды. Барлык авиация вузлары студентлары шул дәреслектән укый. Бу теорияне практикада куллланудан миллионнарча сум файда алына. Аның СССР Дәүләт премиясенә лаек булуы тикмәгә түгел.

Профессор Т. К. Сиражетдинов кафедрасында динамикалы системаларны оптималь идарә итү теориясе күп еллар буена уңышлы үстерелә. Институтның укыту һәм фәнни белгечлекләреннән берсе шул теориягә таяна. Ул, парашют динамикасы бурычларын хәл итүдән алып, бөтен бер тармакны идарә итү моделен булдыруга кадәр промышленность белән ныклы элемтә тотып, шуннан яшәү көче ала.

Менә шундый төрдәге эшчәнлек вуз фәненең илебездәге фәнни-техник прогресска йогынтысын арттыру ысулының рухландыргыч үрнәге була ала. Проблемалылык, материаль дөньяның иң яңа һәм иң нечкә законнарына таяну, студентлар белән тыгыз элемтәдә тору — безнең көннәрдәге вуз фәненең мөһим сыйфатлары әнә шундый.

КПССның XXVII съезды карарлары таләп иткәнчә, фәнни-техник прогрессны кардиналь тизләтү һәммәбезнең уртак бурычы булып әверелде. Вузларның гаять зур мөмкинлекләре кайберәүләрдә мондый иллюзия тудыра: имеш, галимнәр алынсын гына, фәнни-техник прогрессның төп мәсьәләләре шунда ук хәл ителәчәк. Алай гына булса икән! Беренчедән, фәнни-техник прогресс тибындагы процесслар фәннең үзендә үк актуаль. Икенчедән, галимнәр үзләренең йөзләрчә, меңнәрчә яңалыкларын, идеяләрен тормышка ашыруны оештырса да, моны әле фәнни-техник прогресс дип әйтеп булмый. Сүз производство сферасында яңа культура, яңа «цивилизация» булдыру турында бара. Шунысын яхшы аңларга кирәк: бу цивилизация өчен көрәшнең стратегик мәйданнарында галимнәр, чыгыш ясый алса да, «патрон ташучы», көрәшнең төп тупларының «фитилен кабызучы» кебек ярдәмче рольдә булачаклар.

Бу көрәшнең төп хәрәкәтләндерүче көче — җәмгыятебез базисының экономик законнарын камилләштерү. Һәм монда, партиянең XXVII съездында билгеләп үтелгәнчә, Госпланның тоташтан планлаштыруы нигезендә фәнни-техник прогрессны идарә итүнең бөтен системасын үзгәртеп кору, «барлык яңаны һәм алдынгыны актив кертә торган, югары сыйфатлы һәм файдалы әйберләр җитештерү юлларын эзли торган тикшеренү учреждениеләренә, промышленность предприятиеләренә генә өстенлек тәэмин итүче этәргечләрне табу» бурычы тора.

Шушы алымны үткәрү фәнни-техник прогресста тамырдан борылышка китереп, аны җитештерүче көчләр үсешенең төп закончалыгы итеп кенә калмас, фәннең үзенең дә гөрләп үсүе өчен яңа стимуллар бирер. Ф. Энгельсның мәгълүм формуласын искә төшерик: «Җәмгыятьтә техник ихтыяҗ барлыкка килә икән, бу фәнне бер дистә университетка караганда ныграк алга җибәрер».

Мондый борылышны дөрес аңлау һәм зиһенгә алу өчен безгә фикер сөрешебезне, психологиябезне үзгәртеп корырга кирәк.

XXVII съезд карарлары фән эшлекләре алдына күтәренке таләпләр куйды. Бу исә

җәмгыятьнең экономик базисында үзгәртеп корулар процессы инде башланып китүнең ышанычлы бер билгесе, һәм безгә, галимнәргә, үз хезмәтебезнең нәтиҗәләрелеге өчен җәмгыятьнең тагын да катырак таләпләренә әзер торырга кирәк. Кайбер урыннарда әле дә очраучы гамьсезлек, җавапсызлыкны бетерергә туры киләчәк. һәм никадәр тизрәк бетсә, шулкадәр яхшырак!

Гади генә мисал. Мәгълүм булганча, партия һәм хөкүмәтебез инженер-техник һәм фәнни работникларның хезмәт хакын камилләштерү турында мөһим карар кабул иткән иде. Иҗади хезмәтне стимуллаштыру, тигезләүчелек тенденцияләрен бетерү турында сүз бара. Әмма без бу чарадан файдаланырга ашыкмыйбыз, чөнки яңалык күнегелгән тынычлыгыбызны боза, агым уңаена җай гына барырга мөмкинлек калдырмый.

Вуз галимнәре, эшчәнлекләрен активлаштырганда, әлбәттә, производствоның фәннилек сорала торган мәсьәләләрне теләбрәк кабул итүенә исәп тотачаклар. Монда әле күп нәрсәне төзәтәсе, үзгәртәсе бар. һәр тармак, һәр предприятие, өстән күрсәтмә көтеп тормыйча, фәнни-техник прогресс нигезендә производствоны һәм үзләренең бөтен эшчәнлеген яңарту буенча анык, озак вакытка исәпләнгән программалар төзесә, бик дөрес булыр иде. Предприятиеләр һәм оешмаларга фәнни-техник прогрессны формалаштыруда мөстәкыйльлек кирәк. Моның өчен яңа техника һәм технология службаларын, завод фәнен командалык югарылыгына, директив дәрәҗәгә күтәрү мөһим. Аларны оператив эшчәнлектән бушату, оештыру һәм материаль яктан шактый ныгыту, аерым алганда, эксперименталь цехлар һәм участоклар, хуҗалык исәбендә эшләүче үзешчән инженерлык үзәкләре булдыру, эчке иҗади инициативага юл ача торган башка формалар куллану таләп ителә.

Бу чараларны тормышка ашыру — ә ул инде хәзер үк мөмкин эш — съезд карарлары таләп иткәнчә, производствоны фәнгә йөз белән борырга, фәнни-техник прогресска ныграк тартылдырырга мөмкинлек бирер иде. Ниһаять, вуз галименең үз яңалыгын кертү өчен завод юлында гомер үткәрүе һич тә килешми, чөнки бу анык төп хезмәтенә зыян китерә, ә производство үзе фәнни идеяләр һәм ачышларны йолкып алырга, аны эшкә җигү белән кызыксынырга тиеш.

Съездда чыгыш ясаганда партия өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов: «Иртәгәге көн бик тиз бүгенге көнгә әверелә», дип бик дөрес әйтте. Хәзер бу фикер аеруча әһәмият ала. Артта сөйрәлмәс өчен, вакыйгаларны читтән күзәтеп торучы хәленә төшмәс өчен һәр көнне, һәр сәгатьне конкрет яңарту эшләренә багышларга, тизләтүнең текә баскычларыннан киң адымнар белән атларга кирәк.



**З. Г. Кәримов,**
КПССның Аксубай райкомы беренче секретаре.

# АКСУБАЙЛЫЛАРНЫҢ ЙӨЗЕ АК

Республиканың көньягына урнашкан безнең Аксубай Чистай, Октябрь һәм Алексеевский районнары белән чиктәш. Аның мәйданы төньяктан көньякка табан — 50 километр, көнчыгыштан көнбатышка 48 километр араны били. Халкының 39 процентын — татарлар, 41 процентын — чувашлар, калганын рус һәм башка милләт вәкилләре алып тора.

Район нигездә авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә. Бездә унтугыз авыл Советы, бер поссовет бар. Район үзәгебез — Аксубай поселогы арада иң зур пункт булып тора. Анда җиде мең чамасы кеше яши. Ул Норлаттагы тимер юл станциясеннән — 56 чакрым, Чистайдагы Кама елгасы пристаненнан 63 чакрым ераклыкта урнашкан.

Безнең район, элекке Чистай өязенә караган дүрт волостьны эченә алып, 1930 елда оештырыла. Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр бу яклар Казан губернасының иң караңгы волостьларыннан саналган. Халык ачлыктан, наданлыктан арына алмыйинтеккән. Иген игеп, анысы уңмаган кешеләрнең, бала туып, гаиләсе шатлана алмаган. Берсе арты берсе кабатланып торучы кизүләр меңәрләгән кешеләрнең гомерен корыткан. Бигрәк тә сабыйларның күпләп үлүе үзәкләргә үткән.

Җир эшкәртүдә тоташтан кул хезмәте кулланылган. Сука да көрәк. Сабанны бары тик кулак хуҗалыкларында гына күргәннәр.

Совет власте елларында төбәкнең хуҗалыгы да, культурасы һәм социаль йөзе дә танымаслык булып үзгәрде. Башта кечкенә генә күмәк хуҗалыкларга, кооперативларга берләшеп көн итәргә тотынган крестьяннар тора-бара көчле техникага бай, эре колхоз-совхозлар оештырдылар. Хәзер безнең басуларда сигез йөзләп трактор, өч йөз иллеләп йөк автомобиле, алты йөздән артык комбайн эшли.

Аксубай ермаклар белән челтәрләнгән биниһая киң үзәнлектә утыра. Җитмеш дүрт мең гектарга җәелгән катнаш урманнарыбыз пошн, кабан дуңгызы, бүре, төлке, куян, бурсык кебек җәнлек-җанварларга бай. Вак елгалар Идел-Кама суларына коя. Алар арасында зуррак елгадан саналган Олы һәм Кече Сөлчәне күрсәтергә мөмкин. Басуларны корылыктан коткару өчен унбишләп ясалма сусаклагыч булдырдык. Аларның гомуми күләме тугыз миллион кубометрга тарта.

Йөз мең гектардан артык җирләребезнең туксан мең гектардан күбрәге — чәчүлекләр. Җир әче кара туфраклы. Уңыш алыйм, дисәң, аны известьләп торырга кирәк. Кыскасы, игенчелек өчен шартлар бар. Басуларда республикабызга хас барлык культураларны үстерергә мөмкин. Без аеруча бодай, арыш һәм шикәр чөгендере игүне кулай күрәбез. Унсигез колхозыбыз, җиде совхозыбыз, дуңгыз симертү берләшмәсе һәм авыл хуҗалыгы белгечләре әзерли торган училищебыз бар.

Соңгы бишьеллыкларда районны һәрьяклап ныгыту өчен күп чыгымнар тотылды. Хуҗалыкларны машина-тракторлар, электр энергиясе белән тәэмин итү 1,6—1,8 мәртәбә артты. Хәзер җирләрне сугару киңәйтелгәннән-киңәйтелә бара. Алты мең гектардан артыграк мәйдандагы басулар су сиптерү җайланмаларына көйләнгән. Соңгы елларда җиргә ашлама кертүне дә эзлекле системага салдык.

Шунысы куанычлы: авыл хуҗалыгын үстерергә дип тотылган чыгымнар җилгә очмады, телгә алып сөйләрлек нәтиҗәләр күз алдында. 1983 елны ирешкән уңышлар өчен безгә РСФСР Министрлар Советының һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байрагы бирелде. 1984 ел йомгакларыннан соң Аксубай совхозы РСФСР Министрлар Советы һәм ВЦСПСның Дипломы һәм күчмә Кызыл Байрак белән бүләкләнде.

1985 ел Татарстан районнары өчен бик катлаулы булды. Җәй суык килде, көзге яңгырлар авыл хуҗалыгы эшләренә өстәмә мәшәкатьләр тудырды. Шуңа да карамастан, без эшебездәге барлык төрләр буенча планны үтәдек, Ватанга, план буенча каралган 26 000 тонна урынына, 27 300 тонна ашлык саттык. Шикәр чөгендере сату планын да шактый арттырып үтәдек. Район бөртеклеләрнең һәр гектарыннан уртача 18,7 центнер

ашлык җыеп алды. Бу җиңүләребезне Х. Мифтахов, В. Мартынов, А. Евстафьев, В. Молодкин кебек алдынгы механизаторлар әйдәп бара.

Кырчылыктагы уңышлар терлекчелектә дә сынатмаска мөмкинлек тудыра. Сөтчелек, дуңгызчылык, сарык асраучылык тармакларында алга китеш бигрәк тә ачык сизелә. Узган ел без дәүләткә җиде мең тоннага якын — ит, егерме мең тоннадан артык сөт саттык. Г. Ризванова, Ф. Әхмәрова, В. Никитина кебек савымчыларыбыз һәр сыердан дүрт мең килограмм сөт саву максаты куеп тырышалар. Бу өлкәдә сизелерлек яңалыкка ирешү өчен безгә «Сельхозтехника», «Сельхозхимия» берләшмәләре, «Татмелиоводстрой», «Ленколхозстрой», «Татсельстрой» колонналары нык ярдәм итә.

1984 елны районда шактый куәтле май заводы эшли башлады. Бу яңалык кешеләрне сөт ризыклары белән яхшырак тәэмин итәргә җирлек тудырды. Аксубайда яшелчә киптерә торган завод та бар. Монда суган, бәрәңге киптерәләр, кесәл ясыйлар, яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне консервлыйлар, лимонад чыгаралар. Бу завод кешеләребезнең үз хуҗалыкларында үстерелгән яшелчәне дә кабул итә. Шуңадыр, мөгаен, безнең районда йорт яны бакчаларында күпләп суган үстерү гадәткә кергән. Аны дәүләткә сатып зур табыш алалар.

Болардан тыш район үзәгендә бау ишү цехының филиалы, кирпеч сугу цехы эшли. Киләчәктә кирпеч цехын мөстәкыйль завод итеп оештырып җибәрү күздә тотыла.

Бораулаучыларның 3 партиясе безнең районда эзләнү эшләре алып бара. Нефтьчеләр үзләре бер кечкенә генә поселок булып яши башладылар хәтта. Аларның тырышлыгыни белән бетәр — әлегә әйтүе кыен.

Урманчыларыбыз да бик кирәкле, файдалы эш белән шөгыльләнәләр: халыкка ягулык бүлеп бирәләр, төзелеш материаллары ясыйлар, урманны яшәртә торалар.

Халыкка көнкүреш хезмәтен яхшырту буенча да Аксубайда күп кенә чаралар күрелә. Районда ике универмаг бар, азык-төлек, кием-салым, хуҗалык кирәк-яраклары сата торган кибетләр саны йөз егермедән артып китә. Ашханәләр, кафелар күбәя бара. Ательe һәм дистәләгән кабул итү пунктлары кешеләргә егермегә якын төрдә эш башкара. Районда телефон челтәре киңәя, ел саен күбрәк өйләргә телефон кертелә бара.

Кешеләрнең сәламәтлеген саклау — безнең иң беренче бурычыбыз. Бу мөһим эш һәрчак игътибар үзәгендә тора. Район үзәгендә бер сменага 300 кеше кабул итәрлек мөмкинлеге булган поликлиника сафка басты. Әле моңардан тыш тагын өч больницабыз, санэпидстанциябез бар. Аптекабыз да шактый бай.

Районлагы дистәләгән мәктәпләр һәм 88 СПТУ коллективларында яңа реформаны тормышка ашыру максат итеп куелган. Йөзләгән педагоглар арасында РСФСРның һәм ТАССРның атказанган укытучылары, СССР мәгарифе һәм халык мәгарифе отличниклары да шактый. Мәктәпләрнең биналарын яңартабыз. Ел саен районның бер-ике мәктәбе яңа бинага күчерелә. Балаларны кечкенәдән хезмәткә тарту юлы белән тәрбияләү өчен укучыларның эш бригадалары төзелә. Мәктәпләргә авыл хуҗалыгы техникасы кайтарыла.

Хезмәттә сер бирмәгән кешеләребез ял сәгатьләрен дә күңелле уздырырга яраталар. Аларның бу теләген канәгатьләндерү өчен районда илледән артык Культура йортлары һәм клублар эшли. Аларда кино күрсәтү җайланмалары да бар. Аксубайның үзендә махсус кинотеатрга да йөриләр. Район китапханәләрендә китаплар саны 300 000 данәдән артык.

Безнең район әдәбият дөньясына күп кенә әдипләр чыгарган: Хәсән Туфан, Полорусов-Шелеби, Михаил Белов, Чыгтай, Газиз Кашапов, Нәбирә Гыйматдинова. Шулай ук С. Абруков, М. Габдрахманов, С. Ильин кебек галимнәр дә безнең районда туып үскәннәр.

Аксубайлылар Бөек Ватан сугышында катнашкан каһарманнарын һәрчак олылап телгә ала. Андыйлардан Г. Романов белән Б. Габдрахманов Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек булдылар. Шул батырларга тиң рәвештә тырышып эшләүче кешеләребез Социалистик Хезмәт Герое дип танылдылар: Л. Петров, В. Сорокина, Ш. Хафизов, А. Волков, А. Михеев.

Кыскасы, районның йөзе яктыра бара. Кешеләребезнең хезмәте нәтиҗәләреккә әйләнә, көнкүрешебезгә муллык, матурлык иңә. Соңгы дүрт-биш елда гына да культура һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү оешмалары хаҗәтләренә ике миллион сумнан артык акча тотылган, узган бишьеллыкта утыз мең квадрат метр торак салынды, юлларны, күперләрне рәтләү көн тәртибенә килеп басты.

Әмма авылларны заманга төс иттереп, алар өчен киләчәктә дә кызармаслык иттереп төзекләндерү, бизәү, уңайландыру — тиз арада гына тәгәлләнә торган мәсьәлә түгел. Шунысы куанычлы: районыбызның халкы һичнинди бурычлар алдында да куркып калмый. Шунлыктан уникенче бишьеллык планда каралган берсеннән берсе зуррак эшләребезне җиренә җиткереп башкарачагыбызга ышаныч зур.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

Марат Әмирханов

# БЕРЕНЧЕ ПРЕДСЕДАТЕЛЬ

Рөхсәт тә сорап тормыйча, кемдер председатель ишеген каерып ачты. Бусагада «Күтәрелгән чирәм»дәге Щукарь дәдәйгә тартым бер карт пәйда булды. Бүреген баш очына гына элгән, изүе ачык, күзләреннән җорлык, шуклык чәчелеп тора. Янында ниндидер карчык та бар.

— Рәшит Габделхакович, язылышырга килдек менә, тиз генә оештырып җибәр әле,— диде карт.

Председатель кулын гына селтәде:

— Евсей Калистратович, эш тыгыз, зинһар өчен йомышыңны тизрәк әйт әле.

— Әллә ышанмыйсыңмы?

Картның күз тирәсенә җыелган вак сырлары йөзенә сибелде, шунда ук карчык киң итәкле күлмәк кесәсеннән саргаеп беткән бер кәгазь кисәге алып, өстәл өстенә китереп салды.

— Улым, менә шушы язуның күчермәсен алырга ие!

— И, Евсей дәдәй, Евсей дәдәй,— дип, Рәшит Габделхакович башын чайкап торды,— мондый үтенечләрне секретарь башкарганын беләсең ләбаса инде.

Карт председательнең каршысына ук килеп басты:

— Хак тукымыйсың, иптәш Рәхимов, сәвит башлыгы барысына да хуҗа, аннан башка поселокта кыл да кыймылдарга тиеш түгел, без сине шуның өчен сайладык, белдеңме?

Алар чыгып китүгә, хушбуй исләрен җиләтеп, бүлмәгә ыспай гәүдәле бер яшь ханым керде.

— Авылдан әниемне алып килергә булдым, пропискага рөхсәт язуы кирәк,— диде ул. Аның бөтен килеш-килбәте, йөз торышы: каршы төшеп маташмагыз, барыбер мин дигәнчә булачак, дигән мәгънәне аңлата иде. Председатель хәтта бер мәлгә аптырабрак та калды шикелле.

— Әниегезнең үз йорты бармы соң?

— Йортны әтигә калдырабыз, әчә ул, яшәсен ялгызы...

— Алар язылышкандыр бит? Без гаиләләрне тарката алмыйбыз.

— Мин жалу язачакмын!

— Ихтыярыгыз.

— Әнисен яздырып, зуррак фатир эләктереп калмакчы,— диде Рәшит, тәкәббер ханым артыннан ишек ябылуга,— кызганычка каршы, андый хәйләкәрләр бер ул гына түгел.

— Евсей дәдәйне үпкәләттең ахрысы,— дидем председательгә, нигәдер күңелгә ошап калган иде ул.

— Әйбәт карт,— диде Рәшит елмаеп,— гаҗәеп актив кеше, поселок халләрен минутында җиткерә мәгәр, тик менә артык шук, карт-корыга һич тынгы бирми, хәзер әнә, аның коткысы белән бар булган документларының күчермәсен ала башладылар.

Кама Аланында пенсионерлар проблемасы, беренче карашка булмаска да тиеш кебек үзе, чөнки төзелештә яшьләр эшли. Шуңа да карамастан, бу проблема бар, ник дисәң, АЭС төзелү уңаеннан ике авыл күчерелде, ул авылларда исә нигездә өлкән яшьтәге кешеләр генә торып калган иде.

хәзер аларның шактые поселокта яши. Йорт-җир, абзар-кура мәшәкате юк, ә вакытны үткәрергә кирәк!

Үз эшчәнлегендә поселок советы бу үзенчәлекне дә күз уңында тотарга бурычлы, билгеле. Болары сүз уңаенда, ә без, дөресен әйткәндә, башкарак гозер белән керүчеләрне көтә идек, һич югында район оешмаларыннан телефон шалтырарга тиеш иде.

Рәшит Габделхакович сәгатенә күз төшереп алды да, алдында яткан кәгазьне тагын бер кат җентекләп укып чыкты. Әлеге кәгазьдә нәрсә язылганын ул түгел, мин дә яттан белә идем инде: поселок территориясендәге рөхсәтсез салынган вак корылмаларны өч көн эчендә сүтеп бетерергә. Бу карар белән һәр корылма иясен таныштырып, имзаларын алырга...

Кайберәүләр санга сукмый әлеге карарны, үтәр әле дип уйлыйлар, күрәсең. Андыйларның корылмаларын махсус комиссия катнашында җимертергә туры килә.

Бу хәл председательне бик борчый иде: ашыгычлык күрсәтелмәдеме, кешеләрдә ризасызлык тумасмы? Шул ук вакытта мәсьәләнең икенче ягы да бар, күпләр поселокта тәртип юк дип зарлана. Ә ул чыннан да шулай. Әйтик, аз гына яңгыр явып китсә дә, озын кунычлы итекләр аяктан төшми, язгы-көзге көннәр хакында әйтеп тә торасы юк. Хәлбуки, юлларны, тротуарларны асфальтлау өчен меңәрләгән сум акча тотылган.

Тәҗрибәсезлек, беркатлылык шулай инде ул, кайсы яктан булса да китереп суга. Төзүчеләрнең тасма теленә артыграк дәрәҗәдә ышанып җибәрде шул, янәсе, без заман каласы салабыз, кварталлар эчендә бернинди койма, киртә-миртә булырга тиеш түгел, бу рольне яшеллек үтиячәк. Яшеллек дигәненең үсерәсе дә бар бит әле аның. Дөрес, һәр язны, һәр көзне күпләп-күпләп агач утырталар, ә тернәкләнгәннәрен бармак белән генә санарлык. Хәзер поселокта дистәләгән йортлар күтәрелеп чыкты, аларда меңнәрчә кеше яши, тик әле булса тулысынча әзер квартал юк. Кама Аланы чибәркәйләренең дә биек үкчәле туфлиләрен киеп йөриселәре киләдер ләбаса?!

Соңгы вакытта мена шушы уйлар борчый председательне. Депутатлар белән җентекләп сөйләшкәннән соң поселокны төзекләндерү мәсьәләсен, сессиягә куеп, махсус тикшерергә дигән нәтиҗәгә килә. Билгеле, кайберәүләргә ошап бетми.

— Урман кискәндә, йомычка оча инде ул,— дип кинаяле итеп аклана сессиядә «Тататомстрой» идарәсе начальнигы.

— Без заказчы, монда без хуҗа! — Моныcы АЭС дирекциясе вәкиле сүзләре.

Председатель сессиядә утлы күмер өстендә утыргандай хис итә үзен, кызып китеп, эшне харап итмәсәм генә ярар иде дигән уй бөтерелә аның башында. Салкын канлылык, түземлелек, саллы дәлилләр — менә аның таянычлары, һәм беренче сорау:

— Сездә эшче көчләр җитәрлекме, Михаил Исакович?

Идарә начальнигы бу нинди урынсыз сорау дигәндәй председательгә сәерсенеп карый:

— Аның кайчан җиткәне бар?

— Алайса нигә соң яшь-яшь хатыннар өйләрендә утыра? Үзләренең төзүче һөнәре дә бар.

— Яшь бала карыйлардыр...

— Ә сез 320 урынлы балалар бакчасын төп-төгәл егерме дүрт ай буе салдыгыз һәм моны да бик зур казаныш итеп санайсыз. Ә беләсезме, поселокта хәзер балалар бакчасына ничә гариза бар? Меңгә якын. Инде килеп мактәп мәсьәләсенә тукталыйк...

— Җитәр, болай да аңлашыла...

Башка орылып-бәрелүче табылмый, сессия уңышлы үтә.

Кама Аланы «Прикамский» совхозының ерак бер бүлекчәсе генә иде. Авыл советы — 12 чакрымдагы Ширәмәттә. Хәер, авыл советы гына түгел, Түбән Кама район советы да башта төзүчеләрнең эшенә күзәтчелек итмәде, анда нигәдер җир бүлеп бирү белән миссиябез үтәлде дигән ялгыш караш та торалар иде. Нәрсә телим, шуны эшлим чире әнә шулай яман гадәткә әйләнде. Әйтик, ком-таш кирәк булуга, Камага аяк сузып утырган мәһабәт тауны «кимерергә» тотыналар, җитмәсә ике урыннан бит әле, рәсми оешмалардан ник бер каршы килүче табылсын? Хәзер поссовет анда шәхси машиналар өчен гаражлар салдыру хәстәрен күрә.

Рәшит Рәхимов Сарман районының Ләшәү-Тамак авылында туып үскән. Минзәләдә педучилище бетергәч, балаларга белем биргән, комсомолда, партия райкомында эшләп алган. Горькийдагы югары партия мәктәбендә укыган, аннан соң җиде ел рәттән Түбән Кама районының «Родина» совхозында парторг. Кыскасы, кендеге белән авылга береккән кеше.

Менә шушы хәзинә белән КамАЗ, БАМ, Атоммаш кебек гасыр төзелешләрендә азау ярган, абруй казанган төзүчеләр белән җитәкчелек итәргә алына Рәхимов. Бу урында бер нәрсәгә ачыклык кертергә кирәктер, мөгаен: укучыларда төзүчеләр гел кирегә генә каералар икән диган фикер калмаска тиеш, чөнки баштагы чорда һәркайда авыр: КамАЗда да, Түбән Камада да шулай булды ул. Тик төзүчеләр, кагыйдә буларак, беренче чиратта төп объектка, бу очракта АЭСка, күбрәк игътибар итәләр. Социаль-культура һәм көнкүреш корылмалары икенче пландарак кала. Каршылыклар нигездә менә шушы җирлектә туа да инде.

• • •

Бу көн минем хәтердә дә уелып калган. 1983 елның 10 феврале иде. Җилсез дымык көн. Томандай сыек болыт җиргә ак мамыкларын коя. Алар үз көйләренә тын гына сибеләләр дә сибеләләр.

— Их, рәхәтләнеп ауныйсы иде шушы яшь кар өстендә!

— Сессия үтсен инде,— дип көлде әңгәмәдәшем мастер Садыйков,— председатель сайлыйсы бар бит әле.

Шул вакыт клуб янына УАЗ машинасы килеп туктады. Аннан калын гына гәүдәле, тулы битле, кысыграк күзле бер кеше төште, кашы, чәчләре сумала кебек кара.

— Мәктәп кайда икән, белмисезме? — дип сорады ул һәм җавабын алгач җәт-җәт атлап шул якка таба китеп барды.

Бу Рәхимов булып чыкты, оештыру сессиясендә аны поссовет председателе итеп сайладылар.

АЭС шәһәрчегенең Кама Аланы поселок советының беренче председателе. Беренче булу — һәрвакыт дәрәҗәле диләр. Ихтимал, ул шулайдыр да, әмма беренчелекне акларга да кирәк бит әле. Фәкать авыл мәшәкатьләре белән генә яшәгән кешегә әлеге вазифа гади урын алыштыру гына түгел, бу бөтенләй башка, яңа эш. Монда инде саф авылчалык ярап та бетми. Әйтик, шул ук сабырлык чамадан артып китә икән, ул үзенең торгынлык кебек антиподына да әверелергә мөмкин. Яңа төзелештә кайчак мәсьәләне бик оператив рәвештә хәл итәргә туры килә. Мәсәлән, әгәр поссовет вакытында чаң суккан булса, әлеге тау җәрәхәтләнмәс иде, һич югында икенче өлеше сакланыр иде.

— Мәктәп мәсьәләсе тәмам акылга утыртты,— дип хәтеренә төшерә хәзер председатель,— шактый чиләнергә туры килде.

Төзелеш башланганда Кама Аланы сигезьеллык мәктәбенә 32 укучы йөри, аннан соң аларның саны айдан-айга артып бара. Торак йортның мәктәп өчен бүлеп бирелгән өлеше җитми башлый, хәтта поссоветның үз бүлмәсе дә класска әверелә.

Бу вакытта 1568 урынга исәпләнгән урта мәктәп бинасына нигез салынган иде инде. Өч көнгә куян тиресе дә чыдый дип уйлыйлар монда, киләчәге ышанычлы булгач, бүгенгесенә генә түзәргә мөмкин. Ә уку елы тәгәлләнергә атна-ун көн кала, поссоветта телефон шалтырый. Төзелеш идарәсеннән икән.

— Рәшит Габделхакович, мәктәптән бушаган бүлмәләрдән безгә дә өлеш чыгарырсыздыр, шәт,— ди профком председателе.

— Балаларны кайда укытырбыз?

— Яңа мәктәпне ни өчен төзибез соң без?

— Ышан син һавадагы торнага.

— Хафаланмагыз, Рәшит Габделхакович, мәктәп беренче сентябрьгә әзер булачак!

Тагын берничә көннән поссовет әлеге объектта кешеләр санын 500 гә җиткереп, эшне өч сменада оештыру турында карар чыгара. Мондый ашыгыч чаралар һич тә нигезсез булмый. Ник дисәң, унбиш айда 1614 мең сумлык төзү-монтаж эшләренең 700 мең сумы гына үзләштерелгән. Хәзер исә эшнең иң четерекле, осталык кына түгел, зур түземлек тә сорый торган өлеше калган. Һәм боларның барысын да июль-август айларында башкарырга кирәк. Мөмкинме бу?

Районда үткән бер киңәшмәдә Рәхимовны урыныннан торгызып бастыралар.

— Мәктәптә эшләр ничек бара? — дип сорый аннан райбашкарма комитеты председателе.

— 1 сентябрьгә өлгерәчәк!

Киңәшмәдән соң «Тататомстрой» идарәсе начальнигы Вайнер дусларча ягымлы итеп Рәшитнең аркасыннан кага.

— Рәхмәт, батырмадың,— ди ул.

— Нигә, дөрес әйтмәдемме әллә?

— Дөрес, ни... әлбәттә, дөрес.

Мондый икеле-микеле җавап председательне шиккә төшерә, тиз арада мәсьәләгә ачыклык кертергә кирәк, дип уйлый ул һәм, Түбән Камадан кайтуга, АЭС дирекциясеннән мәктәп төзелешенә кураторлык итүче Александр Голышев белән шунда юнәләләр. Каерылып ташланган тау-тау балчык, кәс өемнәре арасыннан мәктәп бинасының өске катлары гына күренеп тора, кая ул машина белән, җәяүләп үтү өчен дә альпинист осталыгы таләп ителә, ялгышрак бассаң, мәтәлеп китүеңне көт тә тор. Бина эче исә тагын да начаррак тәэсир калдыра, урыны-урыны белән хәтта түбәләр дә ябылмаган, һәр тарафта тәртипсезлек, хуҗасызлык.

— Бу хәлендә объектны 1 нче сентябрьгә чуртан балык кодрәте белән генә өлгертергә мөмкиндер,— дип куя куратор.

— Алай өздереп әйтмәгез,— дип аңа каршы төшә прораб,— кешеләр җитәрлек булганда...

— Хәзер ничә кеше эшли? — Прорабны председатель бүлдерә.

— Йөз егермеләп...

Кичке сәгать биштән соң төзелеш бөтенләй тынып кала икән, чөнки эш бер генә сменада оештырыла. Менә сиңа вәгъдә, менә сиңа карар!

— Борчылмагыз, Рәшит Габделхакович,— дип юата аны Вайнер,— уку елына мәктәпнең бер блогын булса да өлгертәчәкбез.

Тәп башына утырту дип, халык шушындый хәлләрдә әйтәдер. Әле ярый иске мәктәпкә тимәгән идек, дип куана Рәшит, монысына баш җитте.

Кешеләргә, сүз дә юк, ышанырга кирәк. Үзара мөнәсәбәт шуңа нигезләнергә тиеш. Рәхимов нәкъ менә рухи якынлык ягында тора да инде. Ләкин рәсми кешенең рәсми булуы да зарур. Бу — хакыйкать. Тик аңа төрле кеше төрлечә килә. Рәшит Габделхаковичны, мәсәлән, үзе әйтмешли, мәктәп вакыйгасы тетрәткән. Бу очракта әлеге вакыйга мөлдерәмә тулы чиләккә тамган бер тамчы ролен үтәгән һәм чиләктәге су ташый башламасынмы!..

Беренче булып моны балалар бакчасын төзүчеләр сизеп ала. Әйтик, алар объектка вакытлы юл салу урынына машиналарын торак йортлар арасыннан йөртәләр. Бөтен тирә-як балчыкка батып бетә, урыны-урыны белән асфальт кубып чыга, кешеләргә уңайсыз. Бер кисәтә бу хакта председатель, ике, өченчесендә милиция җибәреп, машиналар йөртүне тыйдыра. Аңлашылганча, телефон шалтыравы да озак көттерми. Түбәндәгечә сөйләшү булып ала:

— Рәшит Габделхакович, ни эшлисең? Саботаж ич бу!

— Поссовет карарын үтәмәү саботаж түгелме?

— Бакчаны тизрәк өлгертергә кирәк диден бит!

— Ә аны башка корылмаларны вату-җимерү исәбенә җиткерәбезмени?

— Соңгы мәртәбә әйтәм, Рәшит Габделхакович, ал каравылыңны.

— Юк, сезгә башта юл ясарга туры килер.

Гадел таләп куйганда, аяк терәп сөйләшеп була анысы, телефонның аргы башындагы начальник та, чәбәләнеп, әллә ни майтарып булмасын аңлый, күрәсең, сәгать ярымда юлга балчык әттереп, эшне төгәлләп тә куялар. Өч-дүрт айга сузылган сүз боткасы әнә шулай җиңел генә төгәлләнә. Кайчакта таякны тоткан урыныннан сындыру да хәерлерәк шул.

Тиздән поселокта ашханә, азык-төлек, яшелчә кибетләре сафка баса, нәниләр өчен йөзү бассейнлы чыныктыру пункты, аларга ук сөт кухнясы җиһазлана, музыка мәктәбе ачу хәстәрлегенә керешәләр.

Кама Аланының административ берәмлек буларак, тагын бер үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: бередәге уннарча оешманы поселок Советы бер җепкә теркәп тора. Брежневта, әйтик, Зәйдә, Түбән Камада төзелеш эшләре белән турыдан-туры партиянең шәһәр комитетлары, шәһәр Советлары шөгыльләнде, контрольлек итте, кирәк чакта ярдәмен күрсәтте. Төзелеш оешмаларының да баш подразделениеләре шул шәһәрләрдә урнашкан иде. Җыеп

кына әйткәндә, җитәкчелек урында югары дәрәҗәдә тәэмин ителде. Кама Аланында исә бөтенләй башка хәл, ул читтә тора. Һәм мондый шартларда гомуми мәнфәгатьләрне яклау поселок советы өстенә төшә.

Без Рәхимовның әлеге четерекле эшкә нинди хәзинә белән алынганын әйткән идек инде. Бу урында В. И. Ленинның бик акыллы сүзләрен китерәсе килә: «Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп»,— дигән иде ул. Кама Аланы поселок советының беренче председателе, безгә калса, белергә теләве белән алдыра. Үзгәрә Рәшит, тора-бара ул мондагы иң тынгысыз кешегә әверелә. Казан урамнарында да тап буласың аңа, Түбән Кама, Брежнев шәһәрләрендә дә еш очрый, һаман каядыр ашыга, ниндидер мәсьәләне хәл итү артыннан йөри.

— Минем кебек соранып йөргән кешеләрне бик өнәп тә бетермиләр инде аны,— дип куя ул сүз арасында.

Өнәү-өнәмәү мәсьәләсе, кем әйтмешли, ике яклы. Тик шунысы көн кебек ачык, иртәме-соңмы, кемнең кем икәнлеге барыбер ачыклана ул. Абруй алып киләме бу ачыклык, өметсезлек яки битарафлыкмы — анысы инде кешенең кылган эшенә бәйле. Рәхимовка килгәндә исә, әйдәгез, бер мисалга мөрәҗәгать итик.

• • •

АЭС директоры Лев Николаевич Журавлев үзенең төгәллеге, интеллигентлыгы белән аерылып тора, сөйләшенгән вакытка, ник таш ямый шунда, кабул итәчәк, чае дә һәрвакыт әзер булыр. Тик монысында киңәшмә җыйган иде, алай да секретарьга әйтеп куйган: турыдан-туры киңәшмәгә керсен.

Бүлмәгә кергәч, барысы да аңлашылды: сүз поселокны җылылык, су белән тәэмин итү турында бара. Мәсьәләне төпле рәвештә хәл итү өчен проектта каралган котельныйны өлгертү зарур.

— Төзүчеләрне кысарга вакыт, объект сафка басарга тиештер бит инде, ниһаять,— дип торып басты чәрелдек тавышлы бер инженер.

— Кызмагыз әле, зинһар, Вадим Борисович,— диде аңа директор,— сез миңа шуны әйтегез: төзүчеләрне проект документлары белән тулысынча тәэмин итә алабызмы?

— Икеле.

— Миндә бер тәкъдим бар,— диде зур күзлекле юантык кеше,— вакытлы котельныйга тагын ике казан монтажларга!

— Эшлекле тәкъдим,— диде Лев Николаевич,— тагын?

— Бу мәсьәләне поссовет белән килештерми ярамас.— Бу сүзләрне поселок советында: «Без заказчы, монда без хуҗа!» — дип күкрәк каккан иптәш әйтте. Менә бит кеше ничек үзгәрә. Моны КПСС Үзәк Комитетының апрель Пленумыннан соң киң рәвештә кулланышка кергән «кеше факторы»ның бер реаль чагылышы дип тә аңларга кирәктер, мөгаен. Чөнки «кеше факторы» җитештерү сферасының гына түгел, идарә итүнең дә асылын тәшкил итә. Җитәкченең компетентлыгы, абруе бик зур роль уйный.

Әгәр Кама Аланына тагын бер мәртәбә барып чыкмаган булсам, бәлки язмам шушы эпизод белән төгәлләнер дә иде. Кешене ныклап белү өчен аның белән бер пот тоз ашарга кирәк дип, юкка гына әйтмиләр. Бу юлы бөтенләй икенче ягы белән ачылып китте Рәшит.

• • •

Көн кичкә авышкан иде инде. Кама аръягындагы челтәр болытларга алсу төс куна башлаган, биткә, чәчләргә сыйпалып сизелер-сизелмәс кенә талгын җил исеп куя. Өттергеч эсседән соң тирә-як ниндидер сихри тынлыкка чумган, атлаган саен атлыйсы килә. Яшел чирәм түшәлгән тар сукмак мине үзәнлекләр, уйсулыклар аша тау сыртына алып чыкты. Аста әрәмәлек, тагын да арырак чал Чулман. Көмеш су өстендә бүрек кадәре генә булып балыкчы көймәләре күренә. Ялгыз имән янында озын гына буйлы бер кеше басып тора, 7-8 яшьләрдәге малай да бар, күрәсең, улы, эти кеше, кулларын алга суза-суза, аңа нидер аңлата.

Әлеге күзәтченең килеш-килбәтендә таныш чалымнар шәйләдем — Рәхимов ич!

— Нинди җилләр ташлады? — дип каршы алды ул мине.

— Хозурланып йөрим. Ә сез?

— Бүген җәмгыятькә файдалы эш эшләдек,— диде Рәшит улының башыннан сыйпап,— бәрәңге өйдек, әниләре Казанда белемен күтәрә, укытучы ул, кайткан җиренә эш бетеп торсын, шулаймы, Рушат?

Малай иякен кагып куйды.

— Монда кадәр килгәч, чишмә суын да авыз итеп карагыз инде,— диде Рәшит.

Без тауның, ашала-ашала, текә ярга әверелгән ягына атладык. Дистәгә якын вак чишмә бар монда. Бер ишесе таш арасыннан саркый, кайберләре ком бөртекләрен кайнатып астан бөркелә. Суы саф, чиста. Тешләрне камаштырырлык салкын. Балачактагы кебек чишмә өстенә ятып су эчтек. Ул арада Рәшит җырлап җибәрде:

Чылтырап аккан чишмәгә
Суга дип килгән идем...

— Рәшит, сез шигырьләр дә язасыз, ахры, шулаймы?

— Үзем өчен генә сызгалыйм шунда... Поселок янында дүрт чишмә бар, аларны чистартып, тирә-юньнәрен бизәп куярга уйлыйбыз,— дип сөйләп китте Рәшит,— конкурс игълан иттек, кешеләр бик теләп алынды.

* * *

Иртән иртүк Евсей дәдәй, кулына ниндидер төргәк тоткан бер капчыкны уңына салып, поссоветка менеп килә иде инде. Бүреге элеккечә баш очында гына эленеп тора.

— Марфаның би-и-к җитди язулары табылды бит әле,— диде ул мутланып,— күчермәләрен юнәтергә кирәк менә...

Евсей Калистратович кинәт бүленеп калды. Яныбыздан көлешә-көлешә бер төркем яшьләр узып бара иде. Көнләшеп, тә яратып та, горурланып та карый иде карт аларга.

# ЯҢАЛЫК — ТОРМЫШТА ҺӘМ ӘДӘБИЯТТА

ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР ӘҢГӘМӘСЕ

ӘХМӘТ СӘХӘПОВ:

— Шифалы яңгыр көтеп утырган иген кыры кебек, без дә социаль һәм рухи тормышыбызга матур үзгәрешләр алып киләчәк яңалыкка сусаган идек. Әнә шундый уй-теләкләребез, ният-гамьнәребез партиябезнең тарихи XXVII съезды кабул иткән мөһим документларда табигый чагылды. Съезд илебезнең социаль-экономик үсешен тизләтү стратегиясен генә булдырып калмады, халкыбызның рухи тормышын яңарту, әхлакый яктан сәламәтләндерүнең киң программасын да эшләде.

Әнә шулай, һәр кешенең күңел түрендә йөргән хыялы чынбарлыкка әйләнде. Ләкин эчке ихтыяҗ таләбе белән туган яңалык — абстракт төшенчә түгел, ул конкрет бер мәгънәгә ия.

Яңалыкны мин, шәхсән, экономикада матди байлыкларыбызны икеләтә арттыру, социаль өлкәдә ленинчыл принципларны тагын да ныгыту, рухи тормышыбызда күңел дөньябызны баету, камилләштерү, заман таләбенчә үстерү дип аңлыйм һәм бөтен барлыгым белән шуңа ышанам. Җәмгыятебез үсешенең бу борылыш чоры никадәр катлаулы һәм үзенчәлекле булмасын, һәр кеше үз урынында намус белән эшләгәндә, хәләл көчен һәм булган сәләтен тулысынча эшкә җиккәндә, заман ихтыяҗын тизрәк канәгатьләндереп булачак, яңалыкның тулысынча җиңүе өчен тиешле шартлар туачак дип уйлыйм. Бары шулай булганда гына илебезнең куәте ныгыячак, байлыгы артачак. Димәк, безнең тормыш-көнкүрешебез дә күзгә күренеп яхшырачак, рухи-әхлакый дөньябыз ямьләнәчәк, яшәү принципларыбыз матураячак.

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА:

— Әйе, илебез зур социаль үзгәрешләр, яңалыклар чорына керде дип әйтәбез икән, димәк, без үзебез дә тормышны яңача үзгәртеп корырга тиешбез. Беренче карашка бу яңалык, үзгәреш илнең экономикасына, бигрәк тә производствода югары җитештерүчәнлеккә ирешүгә, авыл хуҗалыгында һәр тармакның рентабельле булуына, техник прогресска, сыйфат мәсьәләсенә кагыла кебек... Ләкин әле бернинди отчетларга да теркәлми, планнарга сыймый торган тагы бер зур өлкә бар. Шул өлкәдә уңай якка үзгәреш булмый торып, югарыда санаганнарга ирешү кыенга киләчәк. Ул өлкә — кешенең аңы, күңел дөньясы, илдә барган шушы үзгәрешләргә аңлы мөнәсәбәте, гражданлык позициясе. Бу — шулай ук зур көрәш мәйданы.

Көрәш дигәнгә гаҗәпләнергә кирәкми. Чөнки бу үзгәрешләр, бу яңалыклар каршылыксыз, көрәшсез генә бирелми. Соңгы елларда илдә бюрократлык, битарафлык, хуҗасызлык тамырны тирән җибәрде, кешенең шәхси тормышы, шәхси хуҗалыгы беренче планга чыгып, ил мәнфәгатьләре онытыла, зыян күрә башлады. Менә шушы тискәре күренешләр көрәшсез генә юкка чыгамы? Соңгы елларда йомшак кәнәфиләренә чумган чиновниклар җиңел генә урыннарыннан торып китәме? Авылларда дәүләт милкенә кул салып, кулак дәрәҗәсенә җиткән бәгъзе кешеләр үзләрен гаеплегә саныймы? Юк шул — алай түгел. Алар инде бүген үк, күкрәк кагып, трибуналарда нотык тоталар, үзгәреш, яңалык диләр, ә үзләре һаман искечә яшәү рәвешләрен дәвам итәләр!.. Әдәбият, бигрәк тә драматургия, аннан килеп журналистика менә кемнәрне көн яктысына тартып чыгарырга тиеш, менә кемнәр белән көрәшергә тиеш!

ГАЗИНУР МОРАТОВ:

— Хәзерге шартларда яңалык критерием беренче нәүбәттә ФТР һәм кеше арасындагы мөнәсәбәтләр билгели. Акыллы машиналар, компьютерлар, дәһшәтле атом-төш кораллары алдында кешеләр кешелеген саклап кала алырмы? Үзләренең табигать баласы икәнлекләрен онытмаслармы алар? Һәм тагын — Чыңгыз Айтматовның «Гасырга тиң көн» романындагы теге манкорт хәленә төшмәсләрме? Кешедәге кешелекне саклап калу проблемасы... Яңалыкмы бу? Әлбәттә. Һәм нинди генә яңалык әле!

Бүгенге көндә кешелек җәмгыятенә, беркайчан да булмаганча, реаль куркыныч яный. Юкка чыгу куркынычы! Димәк, әлеге мәсьәләгә дә яңача якын килү сорала.

РАВИЛ КУКУШКИН:

— Тышкы ялтырау белән мавыкмыйча, әйбернең, күренешнең асылына үтеп керергә омтылу — тормышта һәм танып белүдә дөреслеккә ирешүнең иң мөһим адымнарыннан беренчеседер, мөгаен. Иҗтимагый хәрәкәтнең эчке механизмын ачык итеп күрү генә гомум үсеш процессындагы перспективаларны тоемларга һәм мондагы төрле тайпылышларга төгәл диагноз куярга, димәк, аларны төзәтү-дәвалауның җитди чараларын билгеләргә дә мөмкинлек бирә. Минемчә, бу беренче мөһим адымны бүген яшәешебезнең һәрбер өлкәсендә сизәргә була.

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА:

— Ләкин илдә үзгәреш, яңалык дигәч, нишләптер безнең күп кенә язучылар производство темасын гына күз алдына китерәләр. Минемчә, бу мәсьәләне гадиләштереп аңлау. Әдәби әсәрдә станоклар гөжләве, технологик процесс турында түгел, ә шунда эшләүче кешенең күңеле, аң дәрәҗәсе, язмышы турында язарга кирәк! Аның аңында барган катлаулы үзгәрешләр турында. Эшче дә бит моннан 60 ел элеккеге эшче түгел, ул да күп яңа сыйфатларга ия, ә кайберләрен югалтты. Кызыклы вакыйгалар аша менә шуңа социаль анализ ясарга, сәбәпләрен ачарга кирәктер? Менә шушы процесс, үзгәрешләр тулысынча яктыртыла алмаганга, заманында зур сүзләр тудырган күп кенә производство әсәрләре онытыла, төшеп кала бара.

Тагы шунысы да бар: борылышлар чорына, гадәттә, публицистик рух хас, әмма тормыш барышында кеше күңеле, кеше язмышы турындагы чын сәнгать әсәрләре барыбер мәңгеләшеп калалар. Халык өчен кеше язмышы кадерлерәк, якынрак.

Производство темасына да әсәрләр кирәк. Ләкин алар документаль җирлектә булсалар, шул төзелеш өчен, ил өчен күбрәк файда китерер иде. Әйтик, мең битле производство романына караганда, гаепле кешеләрен конкрет күрсәтеп язган ун битле проблемалы мәкалә зуррак эш эшли ала. Журналист буларак авылларга чыкканда, заводларда йөргәндә, кайвакыт халык тормышыннан үзәк өзгеч хәлләргә очрыйсың, тәртипсезлекне күрәсең. Әлбәттә, кайтып-китеп, бик вәзенләп, ике ел буе шул хакта роман да язарга мөмкин. Ләкин халыкка синең ярдәмең бүген кирәк! Хәзер кирәк! Җимерелеп беткәч анализ ясау түгел, саклап калу кирәк. Көчәнә-көчәнә романга сузганчы, бер сүз белән, вакытында ярдәм итик кешеләргә. Ә роман-повестьларыбызны кеше күңеленең гүзәллеген, анда барган үзгәрешләрне, каршылыкларны, табу һәм югалтуларны тасвирлауга багышлыйк.

ӘХМӘТ СӘХӘПОВ:

— Әгәр без әдәбиятны иҗтимагый аң көзгесе дип атыйбыз икән, илебезнең социаль һәм рухи тормышындагы яңалык иң беренче чиратта аңарда чагыла. Әдәбиятыбызны заманнан калыша дип әйтеп булмый. Әдипләребезнең соңгы елларда иҗат иткән әсәрләрендә чорыбызның үткен проблемалары да яктырып куйдылар. Әйтик, Ә. Еникинең «Тынычлану», А. Гыйләҗевның «Әтәч менгән читәнгә», «Җомга көн кич белән», М. Юнысның «Табу һәм югалту», В. Нуруллинның «Һәлакәт», Ә. Баяновның «Таш китап», һ. б. әсәрләрдә җәмгыятебез үсешен тоткарлап торган киртәләрне җимерү зарурлыгы сәнгатьчә камил итеп исбатланды. Шул рәвешчә, рухи өлкәдә яңалыкның җиңүе өчен кайбер омтылышлар булды дияргә мөмкин.

Ләкин шуны да әйтергә кирәк: кайбер әдипләребез чорыбызның кимчелекле яклары хакында сөйләгәндә, ничектер, юашланып калалар. Социаль һәм рухи явызлык белән актив көрәш алар иҗат иткән әсәрләрдә сүлпән бара. Еш кына, яхшылык белән явызлыкның алышы ике якның килешүе белән тәмамлана. Әйтерсең лә яшел келәмдә ике дус очрашып көч сынашкан! Әсәрләрдәге шундый «матур бетемнәр» инде рухи торгынлык, гамьсезлек, битарафлык кебек тискәре сыйфатларның тамырын көйдерергә сәләтсезләр. Күңел дөньябызга рухи хәзинәләр өстәгән, әхлагыйбызга матур гадәтләр алып килгән яңалыкның көндәлек тормышыбызда тамырлануын тоткарлыйлар.

Аннары, яңалыкның әдәби әсәрләрдә чагылуын зәгыйфьләндерә торган сәбәпләрнең берсе: кайбер әдипләребез тормыш басымына түзә алмыйча, еш кына, аның агымына буйсына, нярә, көчсезлек күрсәтә. Бу хәл бүгенге көн аша киләчәккә күз сала алмаганда килеп чыга. Моңардан әдипләрне тормышның кайбер көчләренә каршы тору, тормыш агышына бирешмәү генә коткара ала. Яшәеш һәм кешелек белән бергә туган мәңгелек проблемалар әсәрләрдә чор таләбе югарылыгында куелганда гына, тормыш агышына тиешле юнәлеш бирергә, һәм димәк, яңалыкның көнкүрешебездә җиңүе өчен ышанычлы плацдарм әзерләргә мөмкин.

РАВИЛ КУКУШКИН:

— Яңалыкны һәм яңарышны тар мәгънәдә генә күзалларга кирәк микән? Замандашларын һәм килер буынны сокландырган яңа, саф агымнар һәрбер чорда булган һәм алар һәрвакыт бар. Мәрҗани, Насыйри, Тукай, Әмирхан, Такташ, Җәлил кебек әдипләребез иҗаты һәм эшчәнлеге моңа ачык мисал. Яңаруны тормыш һәм заман дәреслеген, тарих дәреслеген җуймау, аны бертуктаусыз эзләү һәм саклау, дәвам итү дип аңларга кирәктер. Хәлбуки, күпчелек әдипләребез тормышның үзеннән, үзегеннән шактый читтә йөри әле. Әлбәттә, безнең бүгенге культура үсешебездә дә тормыш каршылыкларын тулы тоеп, үз принципларын кыю алга сөреп, көрәшеп иҗат итә белгән фидакарь җаннар юк түгел. Моңа мисал итеп мин Н. Исәнбәтне, Ә. Еникине, С. Хәкимне, Ә. Каримуллинны һ. б. күрсәтер идем. Без, яшьләргә алардан шактый үрнәк алаcылар бар әле. Миңа калса, аларның иҗат иткәне — һәрвакыт яңа, китаплары һәрвакыт көтелгән кунак.

Әдәбият фәне өлкәсендә соңгы еллардагы үзгәрешләр аеруча күзгә ташлана. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында классикларыбызның күп томлыклары, татар халык авыз иҗатының уникә томлыгы, әдәбият тарихының алты томлыгын әзерләп чыгарылу, әйтик, культура тарихыбызда өр-яңа бер сәхифә итеп сакланырлык күренеш.

ГАЗИНУР МОРАТОВ:

— Соңгы елларда совет әдәбиятында сугыш һәм тынычлык проблемасына багышланган байтак гүзәл әсәрләр дә иҗат ителде. В. Быковның «Бәла билгесе», Ю. Бондаревның «Уен», Евг. Евтушенконың «Фуку!», Х. Камаловның «Безне өйдә көтәләр» әсәрләре әнә шундыйлардан.

Сер түгел, элегрәк елларда сугыш мәхшәрен тасвирлаганда, романтик буяулардан артык мул файдаланучы әдипләр булгалады. Кайбер роман-повестьлар чын мәгънәсендә детектив әсәрләрне хәтерләтә иде. Ә геройлары — әкият геройларын.

Кызганычка каршы, андый әсәрләр хәзер дә язылып һәм басылып тора әле. Бигрәк тә балалар өчен. Бусы, минемчә, икеләтә аянычлы. Язучы кем өчен генә язса да һәм нәрсә генә язса да, беренче чиратта дөресен язарга тиеш. Хәтта чынбарлыктан да чынрак итеп язарга тиеш ул.

ӘХМӘТ СӘХӘПОВ:

— Мәгълүм булганча, К. Маркcның бер хезмәтендә сәнгать башка нәрсәләрдән тыш, бөек социаль идеяләр язмышының халык тормышындагы чагылышын да тикшерергә тиеш диелә. Бу фикер халыкның матди һәм рухи культура үсешенең даими характерда булуын гына искәртеп калмый, бәлки, әдәбият алдында торган мөһим бурычларның берсенә дә ишарә итә. Бу очракта, тормыштагы яңалыкның кеше күңеле аша әдәбиятта чагылуы күздә тотыла.

Безнең җәмгыять шартларындагы бөек социаль идеянең — бу очракта социаль-экономик тизләнеш стратегиясенең һәм рухи климатны сәламәтләндерү программасының язмышы — халык тормышы белән ни дәрәҗәдә тыгыз бәйләнгән соң? Һәм ул яңа чор кешесенең рухи ихтыяҗларын ничек канәгатьләндерә ала?

Минем уемча, бүгенге көндә әдәбият алдында менә шундый җитди сорауларга җавап эзләү бурычы тора. Бу җиңел бурыч түгел. Чөнки, яңа чор кешесенең рухи дөньясы, тормышыбыз кебек үк каршылыклы һәм күп төсмерле. Ләкин бу каршылык үзегендә сыйныфлар конфликты ятмый. Конфликтның социаль асылы үзгәрде, заман кешесенең күңеленә күчте. Шулай булгач, әдәбиятыбыз да яңа чор кешесенең җанын борчыган авырту тойгысын бөтен хасияте белән чагылдырырга тиеш. Дөнья гаме белән янып яшәгән олы җанлы кешенең кичерешләрен табигый халәтендә сурәтләргә тиеш. Аның җанында кайнаган эчке каршылыклар диалектикасын тулы итеп ачу, катлаулы рухи дөньясын тирән анализлау, борылыш чорын үзенең эчке ихтыяҗына әверелдергән замандашыбызның образын дәвернең социаль һәм фәлсәфи проблемалары югарылыгында иҗат итү — мөһим бурычларның берсе дияргә була.

Һәм, шул ук вакытта, тормышыбыздагы яңалыкны әдәби әсәрләрдә күрсәтү белән генә дә чикләнеп калырга ярамый. Без аның сокландыргыч куәтен расларга, зур өстенлеген дәлилләргә, матур киләчәген яктырту хакында да уйланырга тиешбез.

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА:

— Яңа чор кешесенең рухи ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү. Миңа калса, халык кайсы чорда да әдәбияттан югары сәнгатьчәлек һәм дөреслек көткән. Хәзер бу сыйфатлар бигрәк тә кирәк. Тормышның кырыс хакыйкатен нечкә зәвык, зур осталык, сизгерлек белән җаннарны тетрәндерерлек, аңнарны уятырлык итеп әйтә белергә кирәк. Чыңгыз

Айтматов, Әмирхан Еники кебек. Аның өчен тормышның үзеннән — зур, хәтта ки фаҗигале язмышларны таба белергә кирәк. Соңгы вакытта татар әдәбиятында характерлар, типлар күп, фәлсәфә күп — язмыш юк. Халык шуңа сусады.

ГАЗИНУР МОРАТОВ:

— Барыбыз да күреп торабыз: соңгы елларда халыкның тормыш хәле яхшырды. Шактый мул, җитеш яшибез без хәзер. Бигрәк тә авылларның йөзе танымаслык булып үзгәрде. Әйтергә кирәк, зур тизлек белән шәһәрләшә башлады. Яңалыкмы бу? Яңалык! Хәтердә: әле без үскәндә дә бөтен авылына бер, күп булса, ике телевизор бар иде. (Магнитофон, суыткыч, җиңел машина турында әйткән дә юк). Телевизордан хоккей буенча дөнья беренчелеге ярышларын күрсәтәләр, ә без үзебез бозда кәшәкә сугабыз. Телевизордан «Күрсәтермен әле!» бара, ә без үзебез җыйнаулашып куышлы уйныйбыз. Ә хәзер?.. Олысы да, кечесе дә — телевизор каршында. Шул исәптән — үзебез дә. Дус-ишләр белән дә күбрәк кичә караган телевизион фильмнар, футбол, хоккей матчлары турында гәпләшәбез. Әйтерсең, башка сөйләшер сүз калмаган!

Дөресен әйтергә кирәк, бүгенге көндә телевизор кешенең рухи дөньясына шулкадәр тирән үтеп керде ки, хәзер күбебезнең әдәби китап укырга вакыты калмый да диярлек. Телевизордан әле кызыклы фильм була, әле — футбол... Кешелек җәмгыятенең бөек язучылары иҗат иткән том-том китаплар да өй җиһазына әверелеп бара шикелле.

Димәк, телибезме-теләмибезме, бүгенге көндә телевизор һәм әдәбият үзара конкурентлар булып чыга!

Ләкин шундый язучылар була, аларның әсәрләрен һәрвакыт чират торып укыйлар. Хәтта поэзия әсәрләрен дә! Димәк, бөтен хикмәт — әсәрләрнең талантлы һәм укымышлы булуында!

Соңгы вакытта тираж турында шактый сүзләр әйтелде. Һәм хак сүзләр әйтелде. Шулай да, бер мең данәдә генә чыккан кайбер шигырь китапларының киштәләрдә озак еллар буена сатылмыйча ятуын ничек аңлатырга? Югыйсә араларында талантлы шагыйрьләр дә юк түгел. Димәк, талантлы әсәрләр дә укылышсыз булырга мөмкин?! Ләкин язучының төп вазифасы укылышлы әсәр язудан гыйбарәт!

РАВИЛ КУКУШКИН:

— Әйе, әдәбиятның бервакытта да искерми торган бурычы — кешене өйрәнү. Безгә дә замандашларыбызны һәм үз-үзебезне аңлауда тирәнгәрәк төшеп эш итү сораладыр. Соңгы елларда тормышның теге яки бу аспектын чикләп алган модалы темалар кулланышка керде: табигатьне саклау темасы, производство темасы, яшүсмерләр темасы h. б. Чын сәнгать турында сүз барганда, әдәбиятның бурычын болай чикләп кую аз дигәндә — урынсыз. Сәнгатьтә бер генә тема бар, ул — Кеше! Монда табигате дә, производствосы да... барысы да сыйган. Тормышны ясалма кысалар эченә кертеп, чикләп карау күңелдә һәрвакыт канәгатьсезлек уята. Иң куркынычы — мондый әсәрләрдә кешенең шәхес буларак гармоник бөтенлеген аңлауга игътибар нык кими. Кеше — механик бер роботка әверелдерелә.

ФӘУЗИЯ БӘЙРӘМОВА:

— Мине күбрәк прозабызның хәле борчый. Безнең прозада сөйләп бирү күп, производство темасы күп, артык шәхси, вак әйберләр тирәсендә фәлсәфә куерту күп. Нәрсә аз? Эре, кабатланмас халыкчан язмышлар аз, зур нечкәлек, зәвык белән тасвирлап бирү, кеше күңеленең мөмкинлекләрен ачып бирү, дөресен язу, символлар белән оста эш итү, поэтик тел белән яза белү аз. Күп планлылык, параллельлек юк, мәгънә бик өстә ята. Без як-ягыбызга каранып, чамалап кына язабыз. Әдәбиятта акыллы кыюлык кирәк! Әдәбиятта талант кирәк! Татар язучыларыннан, каләмдәшләремнән мин шуны көтәм.

ӘХМӘТ СӘХӘПОВ:

— Дөрес, бүгенге әдәбиятта безне борчыган проблемалар күп. Ә минем күңелне иң тырнаганы — уңай герой проблемасы. Чөнки уңай герой проблемасы — образлы телгә күчерсәк, ул әдәбиятның нигез ташы.

Билгеле, безнең әдәбият уңай герой проблемасын күз уңаеннан ычкындырмый. Һәр яңа әсәрнең үзәгендә уңай герой образы тора, һәм автор уенча, ул үзенең мөлаем сыйфатлары белән әйләнә-тирәгә нур чәчә. Ә чынлыкта, кызганычка каршы, бер дә алай булып чыкмый. Дөньяны яңартырга килгән уңай герой әсәрдә күп вакыт вак-төяк проблемалар диңгезенә чума. Кабалана, ашыга, ыгы-зыгы килә, ләкин әсәрнең, соңгы бите ябылу белән үк, гомере өзелә. Ул укучы күңелендә икенче гомер белән яши алмый.

Моның сәбәпләре төрле булса да, берсенә аеруча тукталу кирәктер. Ул да булса, уңай геройның активлыгы мәсьәләсе. Юк, сүз тышкы активлык, төрле эшләргә кысылып йөрү хакында түгел, ә рухи тормыш белән яшәүдәге активлык турында бара.

Кем өчен дә сер түгел: безнең уңай геройларыбызның рухи дөньясы бай түгел. Дәвамлы рухи тормыш белән яшь алмыйлар алар. Әйләнә-тирәбезне чолгап алган җисемнәрнең җанлысын да җансызын да сурәтли, эченә керә белә язучы, ә менә уңай геройның тирән күңеленә ташбака адымнары белән генә якынлаша. Намуслы, көчле рухлы, үз заманы йөген күтәрергә сәләтле актив уңай геройның роле бүгенге көндә тагын да күтәрелә төште. Төрле рәвешләргә керә, хамелеондай төрле шартларга тиз яраша алган явызлыкны җәмгыятебездән кысрыклап чыгару, аның яшәү тирәлеген чикләү кебек изге миссия йөкләнгән аңа.

Үсешкә-яңарышка комачаулый торган явызлык көчләренә соңгы хөкемне бары ул гына — ачык максатлы Заман герое гына чыгара ала.

Җөмләдән, актив уңай герой образын тудыруда очраган кыенлыкларның берсенә тукталу урынлы булыр. Билгеле булганча, заман герое ул җәмгыятебезне алга әйдәүче, үсешебезне тизләтүче көч. Аңарда бүгенге заман билгеләреннән тыш, узган чорның кайбер эзләрен табып, киләчәкнең асыл сыйфатларын да төсмерләп була. Шул сәбәпле, кайвакыт ул каршылыклы, ике төрле тәэсир калдыра, фикердәш-җандашларын таба алмый интегә. Чөнки, аның бүген кылган гамәлләре һәрвакыт киләчәккә юнәлгән була. Еш кына герой өчен үзе яшәгән тирәлекнең рухи дөньясы шактый тар булып чыга. Чордашлары уңай герой рухының тизләтелгән үсешенә иярә алмый ярты юлда туктап калалар. Уңай герой киләчәктә яши, ә замандашлары бүгенге чорда көн итәләр. Шул җирлектә каршылык чыга, конфликт туа, драматик ситуацияләр баш калкыта...

Фикерне йомгаклап әйткәндә, бүгенге әдәбиятта мине иң борчыган проблема — ул актив уңай герой проблемасы. Әдипләребезнең иҗади эзләнүләре шушы юнәлештә тагын да көчәер дип юанам...

РАВИЛ КУКУШКИН:

— Әдипнең эшчәнлеген мин икегә бүлеп карар идем: иҗаты һәм иҗтимагый культура үсешенә иткән хезмәте. Миңа калса, бездә һәр икесе авторның үз инициативасы белән генә — бик стихияле төстә алып барыла. Беренчесе ярар да инде — һәркем әйтер сүзен үзенчә эзли. Ә менә соңгысының үзәкләштерелгән бер план нигезендә оештырылуы язучының үзе өчен дә, культура үсеше өчен дә отышлырак булмас идемени?

Бездә җайга саласы эшләр аз түгел.

Район һәм авылларда китап сату яисә китапханәне комплектлаштыру эшләренә карасаң — чәчләр үрә торырлык. Яшь язучыларга да «әйбәт карау»дан әллә ни уза алмыйбыз шикелле. Аларга дөнья философиясен, эстетика фәнен, психологларның бүгенге казанышларын уртага салып аңлаткан дискуссия-дәресләр, гыйбрәтле кино караулар, яңа спектакльгә барып бергә анализ ясаулар, очрашулар, үз иҗатлары турында төпле анализфикерләр ишетү, эшләгән эшкә отчет бирү, булган кыенлыклар белән уртаклашу һ. б. әлегә хыялларда гына кала. Бу дискуссия-сөйләшүләр ничектер урамга куып чыгарылган сыман. Ә еш кына ул сыра залларына барып керә. Әлеге шартларда яшь әдипнең шәхесен тирәнәйтү турында нинди сүз алып барырга мөмкин?.. Үзеңне кызыксындырган сорауларга консультацияләр, һич югы әдәбият алу мөмкинлеге булса иде. Дөнья классикларын өйрәнү кирәк дибез. Аларның томнарын табу мөмкинлеге булса иде. Китап кибетендә эшләүчеләргә кызыгып гомер үткәрмисе иде. Язучыларны бүген соң өлгерә дибез. Аның башкача булуы мөмкин дә түгел — иң элементар яшәү шартлары булдыру өчен дә без 35-40 ка, ягъни дөньядан арып җанда язу дәрте сүрелә башлаган яшькә җитәргә тиешбез.

Кыскасы, әлегә бездән эш сораучы да, аны оештыручы һәм шартлар куярга әзер торган кеше дә күренми. Үз көнең үзеңә.

Әмма безне бер нәрсә өметләндерә — шушы хәлне җиңеп чыгу гына синең талантлы булуың турында сөйләячәк. Безне бер генә нәрсә юата — культурабыз үсеше гомергомергә фидакарьләр көче белән алга этәрелгән — нишләп әле бүгенге заман гына аерылып торырга тиеш ди?!

Аннан соң тагын бер фикер: «Казан утлары» журналы битләрендә төрле сөйләшүаңгәмәләр еш булып тора. Киләчәктә аларны ешрак оештырганда да зарар итмәс иде. Тик менә бу сөйләшүләрнең нәтиҗәләрен ачыграк күрү теләге туа. Бәлки журнал үзе күзгаткан фикер, проблема, тәкъдимнәрнең ни дәрәҗәдә тормышка ашырылуын укучылары белән таныштырып баруны да үз өстенә алыр? Әйтик, журнал битләрендә махсус бер контроль-рубрика оештырганда һич начар булмас иде кебек. Әйтелгән сүзнең үтәлүүтәлмәвен төгәл белгән очракта гына теге яки бу эшне (сөйләшүне, тәкъдимне) кыю дәвам иттерергә мөмкин бит...

# ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

## Гариф Ахунов:

Тәрҗемә практикабызда эчтәлекне тулы килеш саклау да, милли колоритны бирә белү дә, метафораларны түкми-чәчми укучыга китереп җиткерә алу да бик мөһим. Болар бәхәсле мәсьәләләр түгел. Ләкин шуңа ничек ирешергә? Менә монысы катлаулы мәсьәлә. Һәм без аны әдәби тәрҗемә өлкәсендә тәҗрибә туплаган талантлы авторлар ярдәменнән башка чишә алмабыздыр, мөгаен. Безнең республикада тәрҗемә теориясе буенча җитди шөгыльләнүче кеше, минем белүемчә, фәннәр докторы Рүзәл Юсупов кына. Ул әтрафлы мәкаләләр язып, журналда бастырса, бик файдалы эш эшләгән булыр иде. Ләкин бит ул да рус теленнән татарчага тәрҗемә кылу мәсьәләләре белән генә шөгыльләнә. Бездә русчаны да, татарчаны да яхшы белгән, дөресрәге, русчаны бик яхшы, камил белгән, шул телдә иҗат итә алган, татарчаны чагыштырып карардай дәрәҗәдә белгән Рафаэль Мостафин бар. Ул инде үзәк газеталарда да, республика матбугатында да бу хакта язып чыкты. Әгәр Мостафин капитал бер хезмәтен тәрҗемә мәсьәләләренә багышласа һәм ул хезмәт татар әдәбиятын русчага тәрҗемә итүгә багышланса, зур эш эшләнгән булыр.

Эчтәлекне һәм метафораларны укучыга тулы килеш җиткерү үзеннән-үзе билгеле мәсьәлә. Ул бары тик тәрҗемәнең (квалификацияле тәрҗемәченең) үз эшенә намус белән каравы, иренмичә, җеп-бөртекләп эшләвенә бәйле булса, милли колоритны саклау мәсьәләсе шактый ук четерекле, тәрҗемәченең индивидуаль үзенчәлегенә кайтып кала. Соңгы вакытта миңа берничә тәрҗемә әсәрен рецензияләргә туры килде. Әйтик, Лирон Хәмидуллин казах язучысы Саин Моратбековның «Кыргый алмалар» повестенда милли колоритны саклау буенча моңарчы күзгә бәрелмәгән уңышка ирешкән. Автор моңа бер яктан диалоглардагы үзенчәлекле казах сүзен татар теле текстында калдыру белән ирешсә, икенчедән, сүз тезмәләрен казахчадагы тәртибе белән саклау аркасында ирешә алган. «Ат җилкәсенә берегеп утыра» кебек тәгъбирләр — шуның мисалы. Соңгысы аеруча уңышлы, чөнки бу җөмләне уку белән күз алдына шундук атка атланган казахның кыяфәте күз алдына килеп баса. Әйтерсең, ат белән кешене бер бөтен сын итеп коеп куйганнар.

Моннан тыш Л. Хәмидуллин тәрҗемәсендәге милли колоритны бирә торган тагын бер отышлы алымны күрсәтеп узасы килә. Казах телендәге атамаларны тәрҗемәче парлы сүз итеп ала, ягъни казахча терминга аның татарчасын да китереп куша. Мәсәлән, куй-сарык, исән-аман, нукта-йөгән, табын-дастархан, болак-чишмә һ. б. Бу бик дөрес, табигый хәл, ник дигәндә, бездә савыт-саба инде күптән парлы сүз булып киткән. «Саба»ның үзен генә алып карасаң, ул бит безнең сүз түгел. Ул бит шул ук Урта Азиядән кергән сүз — бурдюкның казахчасы.

Боларга Л. Хәмидуллин казах халкы телен, тормыш-көнкүрешен яхшы белүе, культурасын өзлексез өйрәнүе аркасында ирешкән. Хәер, монысы журнал анкетасындагы икенче сорау. Аңа да юл уңаенда гына түгел, нык уйлап, җитди итеп, төпле җавап бирергә кирәк.

Әйе, тәрҗемәнең уңышлы килеп чыгуын тәрҗемәченең таланты да, осталыгы да, халыклар тарихын, культурасын, телен белүе дә хәл итә. Беренче карашка болар барысы бер төшенчә кебек, әмма уйлана башласаң, барысы бер үк төшенчә түгел икәне аңлашылыр. Беренче чиратта әдәби тәрҗемә эшенә тотынган кешенең талантлы булуы кирәк. Чөнки талантны талант кына тулысынча аңлый ала. Тукайны талантсыз тәрҗемәче русча ничек бирә алсын? Җәлил белән Кәримне дә, Такташ белән Туфанны да талантсыз тәрҗемәчеләр «коры сөяккә» калдыруы мөмкин. Үзәк нәшриятларда соңгы вакытта милли әдәбиятлар исәбенә туенып ятучы сәләтсез шигырьчеләр күбәйде. Алар теләсә кайчан, теләсә кайсы телдән, теләсәң күпме шигырь аударалар. Әйе, аударалар, тәрҗемә итмиләр, оригиналдагы зурлыкны аңларга теләмиләр. Менә монда инде телне белү, һич югы, халыкларның тормышын, культурасын белү ифрат та кирәк нәрсә. Телне белмәгән, халыкның күңелен белмәгән, аның мең еллык иҗат хәзинәсен өйрәнмәгән тәрҗемәче, гәрчә талантлы булса да, тулысынча уңышка ирешә алмый. Моның ачык мисалы — Такташ тәрҗемәләре. Һади Такташны русчага күренекле рус совет шагыйре, даны илгә таралган шагыйрь Леонид Мартынов тәрҗемә итте. Тик ул аны яртылаш кына бирә алды. Яртылаш дип шуңа әйтәм, Такташ русчада трибун, революция трибуны. Мартынов аны Маяковский кебегрәк итеп күз алдына китерә. Әмма Такташ бит татарчада, оригиналында, трибун гына түгел, лирик та, дөресрәге — Такташ революцион хисләрен, яңа җәмгыять идеяләрен җылы лирикага төреп бирә. Тәрҗемәче исә аның оригиналын белми, шул сәбәпле Такташ русчада бөтенләе белән үзе булып чыкмаган. Без, әлбәттә, Леонид Мартыновка эшләгән кадәрлесе өчен дә рәхмәтле. Такташны русчада яңгыратуга, классигыбызны пропагандалауга ул үзеннән җитди өлеш кертте, әмма үз вакы-

тында Такташның рухын, язу алымын аңа аңлатып бирүче булган булса, без хәзер Такташ русчада тулысынча яңгырый дип горурланып йөргән булыр идек.

Өченче сорау — тәрҗемә оригиналның бөтен байлыгын биреп бетерә аламы, тәрҗемә ителми торган шагыйрьләр яки аерым әсәрләр буламы? — беренче карашка бик ансат җавап биреп була торган сорау. Тәрҗемә беркайчан да оригиналның бөтен байлыгын биреп бетерә алмый. Юкса Көнчыгыш һәм Көнбатыш даһиларын бер гасыр эчендә генә дә унар мәртәбә тәрҗемә итмәсләр иде. Биредә вакыт факторы да бик мөһим. Чөнки заман сәнгать җәүһәрләренә үз таләпләрен куя, заман даһиларны үзенчә аңлый, тәрҗемә яңабаштан эшләнергә тиеш булып чыга. Классикларны бер читкә куеп торып, үз практикабыздагы гап-гади мисалга кайтып карыйк. Мисал өчен, Әхсән Баян прозасын. Ул безнең тормышыбыздагы кире якларны, үсүгә йөз тоткан кире тенденцияләрне сәнгатьчә шартлы алым белән камчылап бара, зур гомумиләштерүләргә китереп җиткерә. Бер дә яшерен-батырын түгел: аны тәнкыйтьчеләр арасында да, язучылар җәмәгатьчелегендә дә бик әллә ни хупламадылар. Илебездә кискен борылыш, илдә ныклы тәртип урнаштыру, хезмәт дисциплинасын ныгыту башлангач, әхлак-мораль мәсьәләләре һәркем өчен—министрдан башлап гади эшчегә, колхозчыга һәм хезмәткәргә кадәр — тигез итеп куелгач, Әхсән Баянның прозасы безгә калкурак булып күренә башлады. Димәк, аның моңарчы тәрҗемә ителгән прозасы (минем уемча, шактый ук дәрәҗәдә уртача тәрҗемә ителгән прозасы) яңабаштан каралырга, яңа таләпләр күзлегеннән каралырга, игътибар беләнрәк каралырга тиештер дип беләм.

Тәрҗемә итеп булмый торган шагыйрьләргә яки аерым әсәрләргә килгәндә, беренче нәүбәттә моның үрнәген Пушкинда күрергә кирәк. Шушы көнгә кадәр Пушкинны Европаның оригиналдагы дәрәҗәсендә укый алганы юк. Моны совет классиклары Фединнар, Фадеевлар, Твардовскийлар заманында әйтә килде. «Я помню чудное мгновенье»ны илебез халыклары теленә, шул исәптән татар теленә дә ничәмә-ничә мәртәбә тәрҗемә итеп карадылар, булмый. Җәүһәр тәрҗемәдә югала. Тукайның «Туган тел»ен дә мин шундый әсәрләр исәбенә кертер идем. «Әткәм-әнкәмнең теле» төшенчәләрендә, «И туган тел!» дип өзелеп әйтүләрдә моң бар, аһәң бар, газизлек бар, «отца-матери язык» дигән төшенчәдә моң да, аһәң дә юк. Туфан шигырьләренең күбесенә тәрҗемәчеләрнең теше үтми. Югала Туфан — ул 50 еллык титаник хезмәте белән ирешкән халыкчан моң, русча әйткәндә, сплав югала.

«Оригиналданмы, подстрочниктанмы тәрҗемә итү яхшырак» дигән мәсьәләгә мин болай карыйм. Әгәр дә оригиналны белүче талантлы да булса, оригиналдан тәрҗемә итү шәбрәк. Инде оригиналны белүченең өстенлеге бары тик оригиналны белүгә генә кайтып кала икән, талантлы тәрҗемәченең подстрочниктан тәрҗемә итүен кулайрак күрәм. Сибгат Хәкимне оригиналны белүчеләр дә тәрҗемә иттеләр, әмма Ярослав Смеляковның тәрҗемәләре аларныкыннан бер баш югарырак. Чөнки талантны талант аңлаган, рухына төшенгән, С. Хәкимнең хәтта татарчадагы моңын да саклый алган.

Подстрочник тәрҗемә ясаучылардан да талант таләп ителә. Юкса, Расул Гамзатов әйтмешли, сәнгатьчә ясалган кувшиннан чүлмәк ватыклары гына калырга мөмкин. Бездә проза буенча подстрочник ясаучылар арасында иң зур осталыкка ирешкәне Рәис Сабиров дип саныйм. Ул менә оригиналның барлык төсмерләрен подстрочникта аңлатып бирергә тырыша, ә тәҗрибәсез, яки сәләтсез подстрочникчылар турыдан гына ярып баралар, оригиналның рухын югалталар. Әйтик, прозада «башлы-күзле булды» дигән тәгъбир очрый икән, алар аны «женился» дигән сүз белән генә биреп китәләр. Бу әдәби әсәрне корытуга китерә. Ә бит «башлы-күзле булу» төшенчәсендә йортка баш булу да, күзәтү-барлау да, киңәшеп эшләү дә бар. Мондый очракта Р. Сабиров йөгертеп кенә узмый шул инде, җәя эчендә әлеге тәгъбирнең мәгънәсен иренмичә аңлатып бирә. Бәй, шулай булгач, подстрочник ясаучыга әле талантлан тыш эрудиция дә, тел төсмерләрен белү дә, халыкның культурасын үзләштергән булу да, намуслылык та кирәк икән.

Шагыйрьнең чын тәрҗемәчесе кем? Подстрочник ясаучы белән әдәби тәрҗемәче кулга-кул тотынып эшләгәндә генә чын тәрҗемә була ала. Шунлыктан хәзер Татарстан Язучылар союзы идарәсе Тукайның, Такташның, Җәлилнең, Туфанның, минем белүемчә, яңа подстрочникларын эшләтә. Бу инде гади подстрочник кына түгел, фәнни-филологик тәрҗемә. Ул бер генә дә түгел, өч вариантта эшләнә: әсәрнең эчтәлеге, формасы, ритмикасы бирелә. Андый тәрҗемәләрне Кавказда типографиядә бастырып, тугандаш республикаларга әдәби тәрҗемә өчен кулланма итеп тарату очраклары гел арта бара.

Бүгенге шагыйрьләребезнең русча чыккан китаплары турында нәрсә әйтә алам? Равил Фәйзуллин белән Ренат Харис үзләренә лаеклы тәрҗемәчеләрне таптылар. Русчада да яңгырыйлар. С. Хәкимнең Р. Моран, Н. Беляев, Н. Сидоренко, Я. Смеляков, Р. Бохараев тәрҗемәләре яхшы яңгырый, Р. Кутуй аны бераз үзгәртә, катлауландыра төшә, әмма поэзиясен югалтмый. Шулар янында С. Хәким рухына туры килеп җитмәгәннәре дә бар әле. Нури Арсланов русчада барып чыкмады, Гамил Аф-

заланың шушы көнгә тикле үз тәрҗемәчесен таба алганы юк. Зөлфәт белән Марат Акчуринның дуслыгын әйбәт хәл дип саныйм. Зөлфәтнең русчада күптән түгел басылып чыккан китабы зур өмет уята. Илдар Юзеев та, ниһаять, тәрҗемә ителә башлады, хәзергә үз дәрәҗәсенә җитеп бетә алмый. Хисам Камалов поэзиясе бик аз тәрҗемә ителгән. Шәүкәт Галиевне Казан шагыйрьләре үзенчәлеген саклап тәрҗемә итеп киләләр. Бездә тәрҗемә ителмәгән Нәкый Исәнбәт, Шәйхи Маннур, Әнвәр Давыдов, Роберт Әхмәтҗанов, Рәдиф Гатауллин, Мөдәррис Әгъләмов, Роберт Миңнуллиннар бар. Әхсән Баянның шигырьләре матур гына тәрҗемә ителә башлап, китабы үзәк матбугатта да уңай бәя алган иде, никтер тукталды. Әдип Маликовны Н. Старшинов әйбәт тәрҗемә итә иде — өзелде. Саҗидә Сөләйманованың танылган Мәскәү шагыйрәсе Людмила Щипахина ике китабын тәрҗемә итте, рухы сакланган. Әмма бүгенге шагыйрьләребезне тәрҗемә итү буенча да, миңа калса, эшлисе эш тау кадәр әле.

Бүгенге прозаикларның русча чыккан китаплары поэзиягә караганда сыйфатлырак диген фикердә торам. Мәсәлән, Шамил Бикчуринның ике романын да күренекле рус язучылары В. Чивилихин һәм Ю. Сбитнев тәрҗемә иттеләр. М. Хәбибуллин, М. Маликова үз тәрҗемәчеләрен таптылар. Озак кына азапланганнан соң Аяз Гыйләҗев та тәҗрибәле тәрҗемәче В. Сафоновка юлыкты. Шул ук тәрҗемәче Вакыйф Нуруллин китапларын русча яңгырата алды. В. Нуруллинның Р. Кутуй эшләгән тәрҗемәләре дә укучыда уңай фикер калдыра. Мәхмүт Хәсәнов начар тәрҗемәдә генә күренде әле. Әхәт Гаффар күп һәм яхшы тәрҗемә ителә. Заманында Рафаил Төхфәтуллинны В. Лукашевич бик яхшы тәрҗемә итә иде, ул үлгәннән соң Р. Төхфәтуллин русчада бөтенләй диярлек күренми башлады. Шамил Рәкыйповның хәрбипатриотик темага язылган повестьлары үз вакытында һәм яхшы тәрҗемә ителеп киләләр. Атилла Расих русчада да яхшы яңгырый.

Ләкин татар прозаикларын тәрҗемә итүдә кайбер уңышларыбыз булуга да карамастан, ирешәсе бик күп. Талантлы язучы, тарихи романнарга юл яручы Нурихан Фәттахны М. Зарипов русча Казанда чыгарды, Мәскәүдә аның беренче яшьлек романыннан башка әсәре басылганы юк. Гаять дәрәҗәдә үзенчәлекле, оригиналь язучы, тел остасы Хәсән Сарьян русча чыкмады әле. Әмирхан Еникине байтак тәрҗемәчеләр русчага әйләндереп карады, күбесенең теше үтмәде. А. Бадюгина аның иҗатына беркадәр якын килә алды, рухын төшенеп тәрҗемә итте. Хисам Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә» романын сугыш ветераны В. Мальцев эшләде, «Безне өйдә көтәләр» романын югарырак дәрәҗәле язучы тәрҗемә итсә, яхшы булыр иде, чөнки ул В. Быков әсәрләре белән ярыша алырдай роман. Мөхәммәт Мәһдиев русчага күп тәрҗемә ителде, «Без — кырык беренче ел балалары»н исәпкә алмаганда, үз югарылыгында тәрҗемәсе булмады.

Илебездә милли әдәбиятларны баету, үзара якынайту чарасы буларак, киләчәктә тәрҗемә эшен ничегрәк яхшыртырга мөмкин? Моның нинди чаралары бар?

Тәрҗемә эшен яхшырту, татар әдәбиятын республикаларда, ил күләмендә пропагандалауның мин бер юлын күрәм. Ул хакта инде байтак еллар буе әйтеп киләм, әле һаман да шул фикердән кире кайтканым юк. Татарстан китап нәшрияты каршында классикларыбызны русчага чыгару буенча безгә махсус редакция булдырырга кирәк. Андый редакция оештырылып, гамәлгә керсә, без Мәскәүнең иң яхшы тәрҗемәчеләрен үзебезгә тарта алабыз, алар белән договорлар төзи алабыз, аларны үзебезгә чакыра, республикабызның иң матур урыннарында, урманнарында, күл буйларында, Идел буе дачаларында урнаштыра алабыз. Безнең әдипләр алар белән аралаша, бергә утырып эшли ала, киңәшә, консультация бирә ала. Әлемтәләр ул чакта елдан-ел ныгый, киңәя һәм без үз теләгәнебезгә ирешәбез.

Әлбәттә, үзара якынаю, элемтәләр киңәюнең башка төрле юллары да бар, тик алары кечерәк юллар, сукмаклар, иң кирәге — безне үзенә тарта, оештыра торган, финанслар белән эш итә торган үзәкнең булуы. Шуннан башка, күпме генә матур сүз сөйләмик, без әдәби тәрҗемә эшен, әсәрләребезне, бигрәк тә классикларны, русчага, русча аркылы башка телләргә тәрҗемә итүне ил күләмендәге, дәүләт күләмендәге эш дәрәҗәсенә күтәрә алмыйбыз.

## Фәридә Каюмова:

Шәүкәт Галиевнең рус телендә чыккан «Волшебное зеркало» (Казан, 1984 ел) дигән китабыннан кайбер мисаллар китерик әле. Артык сайлап тормастан, «Беренче тамчы» дигән шигырьгә тукталыйк.

Иң беренче
Тамчы тамды —
Яз уянды!
Кушылырлар
Тиздән аңар
Зур елгалар!

Бик гадәти, җыйнак. Бары алты юл. Шигырьнең чынлыгы, кыйммәте дә фикер, хис зурлыгында һәм сурәт тыгызлыгында. Миңа шушы җанга нәрсәсе беләндер бик якын булган шигырьнең русчага тәрҗемә-

сен укыгач, кинәт тәнеңә салкын су сипкәндәй чирканып китәсең:

Капнула первая
капелька маленькая
и разбудила природу.
Скоро проснутся
бурные воды,
кораблики
и пароходы...

(Э. Блинова тәрҗемәсе)

Бу шигырьдә, күргәнебезчә, күпме төгәлсезлек. 1. «Капелька маленькая» дип әйтү дөрес түгел. «Капелька» дигән сүз үзе «совсем маленькая капля» (С. И. Ожегов. Словарь русского языка. 1953, с. 232.) дигән мәгънәне аңлата. 2. Беренче тамчы табигатьне уятмый, язны уята. Табигать — кешене чолгап алган органик һәм органик булмаган табигый материаль дөнья. Табигать (природа) сүзе тәрҗемәгә урынсыз, ялгыш килеп кергән. 3. Шигырьнең оригиналында «кораблльләр һәм пароходлар уяныр-лар» дигән сүзләр бөтенләй юк. Ә шигырьне тотып торган «кушылырлар тиздән аңар зур елгалар» дигән йомгаклау фикере бөтенләй төшереп калдырылган.

Тагын бер мисал. Ш. Галиевнең «Шаһидә бал җыя» дигән шигырен тәрҗемә иткәндә, тәрҗемәче Э. Блинова бөтенләй арттырып җибәрә. Хәтта шигырьнең исемен дә «Бал җыюның яңа ысулы»* дип атый. Шулай итеп шигырь тәмам шигырьлеген, әчтәлеген югалтып «Бал җыюның яңа ысулы» дигән технологик процесска әйләнеп кала.

Аның татарчасы болай:

Шаһидә тапкан шешә,
Шешәгә япкан шөпшә:
— Ул миңа бал җыя ди,
Монда күп бал сыя ди.
Тулып җиткәч баллары,
Чыгарам ди аннары.
Кузгалмыйбыз, карыйбыз,
Шөпшәдән күз алмыйбыз —
Шешә тиз тулыр микән,
Күпме бал булыр икән?

Ә русчага тәрҗемә менә ничек килеп чыккан:

Аниса
поймала в лесу
полосатую
злую осу,
в банку маленькую
посадила,
а заталкивая,
говорила:
— Пересажу ее
в банку новую,—
не в такую же —
в трехлитровую,
чтобы много
мне принесла
сладкого меда
моя пчела...

Күрәбез: шагыйрь шөпшә япкан иде, ә тәрҗемәче башта шөпшәне «усал шөпшәгә», аннан «бал корты»на әйләндерә. «Икенче яңа банкага күчереп утыртам,— шундыйга түгел,— өч литрлыга»,— дигән сүзләрне тәрҗемәче «иҗат» итә. Болар татарчада юк. Ә татарчадагы:

Кузгалмыйбыз, карыйбыз,
Шөпшәдән күз алмыйбыз —
Шешә тиз тулыр микән,
Күпме бал булыр икән? —

дигән юллар исә бөтенләй юкка чыгалар.

Тәрҗемәченең оригиналның авторы һәм укучылар алдында җаваплылыгы бик зур. Мин бу җаваплылыкны врач-хирург җаваплылыгына тиңләр идем. Хирург операциянең уңышлы үтүе өчен җаваплы булса, тәрҗемәче-шагыйрь художество әсәренең икенче телдәге яңгырашы, бөтенлеге өчен җаваплы.

Без мисал өчен ике шигырьне генә алдык. Кызганычка каршы, күпчелек шигырьләр белән дә шундый ук хәл. Без: «Дөнья әдәбиятына юл яхшы тәрҗемәләр аша»,— дибез. Әйе, хәзер шигырьнең юлы киң. Рус теленә тәрҗемә ителгән шигырь рус теленнән башка телләргә дә күчә. Тик менә «Беренче тамчы», «Шаһидә бал җыя» шигырьләрен рус теленнән башка телгә күчерелүен күз алдына китерсәк, күңел сискәнеп куя...

Минем уемча, һәрбер шагыйрь үзен шигырьләренең тәрҗемәләренә карата адвокат-яклаучы итеп эш итү белән бергә, аларга карата судья-хаким да булырга тиеш.

*Казан.*

библио графия

# ЭПОСНЫ ӨЙРӘНҮДӘ ЯҢА АДЫМ

Татар халык эпосы — зур әһәмияткә ия булган, инде күптәннән махсус өйрәнүне көтә торган катлаулы проблема. Дөрес, аның аерым жанрлары, аеруча бәетләр, байтактан бирле галимнәрнең игътибарын җәлеп итеп киләләр. Соңгыларына багышланган берничә махсус җыентык, төрле характердагы мәкаләләр, тикшеренүләр бар. Татар халык иҗатының бу үзенчәлекле жанрын өйрәнүгә Х. Бәдигый, Г. Рәхим, Г. Толымбай, Х. Ярми, И. Надировлар зур өлеш керттеләр. Соңгы елларда М. Бакиров белән Ф. Әхмәтованың бәетләргә багышланган җитди мәкаләләре дөнья күрде.

Табигый ки, еллар үткән саен, халык иҗатын өйрәнү тирәнәя һәм киңәя бара. Фольклор экспедицияләрендә яңадан-яңа фактик материаллар язып алына. Шушы җирлектә татар халык дастаннары мәсьәләсе дә зур актуальлек казанды. Бу юнәлештә беренче теоретик хезмәт — «Кузы-Күрпәч белән Баян-сылу» дастанының татарча версиясенә багышланган мәкалә Х. Ярми тарафыннан язылган иде. Соңгы елларда исә татар халык эпосының бу жанрын өйрәнү дә ярыйсы ук җанланып бара. Бәетләр белән бергә, дастаннарга багышланган махсус тикшеренүләр дә басылып тора. 1983—1984 елларда «Татар халык иҗаты» җыелмасының «Бәетләр» һәм «Дастаннар» томнары дөнья күрде.

Татар халык эпосының төрле жанрларын фәнни өйрәнүдә соңгы 20 ел дәвамында аеруча актив эшләгән галимнәрнең берсе Фатих Урманчиев «Советская тюркология», «Советская этнография», «Казан утлары» журналларында татар һәм, гомумән, төрки эпоска багышланган күп санлы мәкаләләр, «Халык авазы. Татар халык бәетләре тарихыннан очерклар» (1974 ел), «Татар халкының эпик дастаннары» (1980 ел) кебек җитди монографияләр бастырып чыгарды. Әнә шул ике дистә ел буена алып барылган фәнни эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, Татарстан китап нәшриятында Ф. Урманчиевның зур күләмле яңа хезмәте — «Татар халкының героик эпосы» дигән китабы дөнья күрде. Монографиянең беренче бүлегендә сүз халык эпосын өйрәнүнең методологик һәм фәнни-теоретик мәсьәләләре турында бара. Татар халык эпосы мәсьәләсенә автор яңача килә һәм татар халкының төрле этник төркемнәрендә таралган аерым жанрларга махсус тукталып үтә. Эпос әсәрләрен ул өч зур төркемгә бүлә: дастаннар, бәетләр, тарихи җырлар. Бу классификациядә аларның милли үзенчәлекләре һәм тарихи үсеш этаплары ярыйсы ук төгәл чагыла.

Татар халык эпосын өйрәнү һәм, гомумән, татар фольклор фәне тарихын автор киң планда алып яктырта. Элегрәк чыккан хезмәтләрдә, гадәттә, татар халык иҗатын өйрәнү тарихы XVIII, хәтта XIX йөздә башлана дип карала иде. Ф. Урманчиев исә бу тарих X йөздән — Ибне Фазланның «Иделгә сәяхәт» (922 ел) исемле мәгълүм язмасыннан башлана дип исәпли һәм беренче бүлектә татар халык иҗаты әсәрләрен җыю, бастырып чыгару, фәнни өйрәнүнең төп этапларын билгеләп үтә. Моны хезмәттәге игътибарга лаеклы моментларның берсе дип әйтәсе килә.

Китапның икенче — иң зур бүлеге татар халык дастаннарын өйрәнүгә багышланган. Автор дөрес күрсәтеп үткәнчә, биредәге материалларның күбесе татар фольклор фәне тарихында беренче тапкыр өйрәнелә. Бүлекнең гомуми эчтәлеге шактый бай һәм катлаулы. Билгеле булганча, әле 1984 елга кадәр татар халык дастаннарыннан торган махсус җыентык юк иде (ә Ф. Урманчиев китабы 1980 елда язылып беткән). Димәк, авторга күп төрле чыганакларга, җыентыкларга, гыйльми язмаларга мөрәҗәгать итәргә туры килгән. Конкрет материал күп төрле булу сәбәпле, автор дастаннарны да аерым төркемнәргә бүлә. Болар — борынгы героик дастаннар, батырлык дастаннары, лиро-эпик дастаннар һәм китаби дастаннар.

Аерым әсәрләрне өйрәнгәндә Ф. Урманчиев бүгенге совет фольклористикасында төп юнәлеш булып торган тарихи-чагыштыру ысулыннан файдалана. Ягъни, ул безнең халык телендә яки язма чыганакларда сакланган дастаннар белән генә чикләнми, ә казах, кыргыз, үзбәк, башкорт эпосы материалларына да еш мөрәҗәгать итә. Бу ысул татар халык дастаннарыннан «Түләк», «Ак Кубек», «Кузы-Күрпәч белән Баян-сылу» һ. б. күп кенә әсәрләрнең баш-

ка төрки халыклар эпосы ядкарьләре белән генетик һәм типологик бәйләнешләрен, әлеге дастаннарның милли версияләренә хас үзенчәлекләрне мөмкин кадәр төгәл билгеләргә ярдәм иткән.

Автор аерым эпик сюжетларның һәм мотивларның, образларның, төрле поэтик алымнарның килеп чыгышын һәм үсеш-үзгәреш этапларын ачыкларга омтыла. Бу ысулны эзлекле рәвештә куллану нәтиҗәсендә ул җитди фикерләр әйтә, кызыклы күзәтүләр ясый. Ф. Урманчиев халык дастаннарының идея-тематик эчтәлеген һәм образлар системасын шәрехләү белән генә чикләнми, ә төрле характердагы ярдәмче материалларга да зур игътибар белән карый, эпик әсәрләрдә халыкның тарихы һәм этнографиясе белән бәйле булган детальләргә киң туктала. Бу исә хезмәтнең фәнни-теоретик нигезен нык кына киңәйтә һәм тирәнәйтә.

Татар халык бәетләре турында Ф. Урманчиев әлеге монографиясенә кадәр дә күп кенә тикшеренүләр бастырган иде инде. Рецензияләнә торган хезмәттә дә бәетләргә киң урын бирелгән. Бәетләрне халык эпосы әсәрләре рәтеннән карау — инде фәндә урнашып киткән фикер дип булмый. Безгә калса, Ф. Урманчиевның бәетләрне татар халык эпосының башка төрләре белән бергә тикшерүе игътибарга лаеклы факт булып тора. Нигездә казан татарлары фольклорына хас булган бәетләрне автор типологик яктан украин халык эпосы әсәрләре думаларга, көньяк славяннар эпосының героик һәм лиро-эпик җыруларына, бигрәк тә славян халыклары балладаларына якын әсәрләр итеп саный.

Элегрәк дөнья күргән хезмәтләрдә бәетләрнең килеп чыгышы нигездә XVI йөзләргә карый дип языла килде. Ф. Урманчиев исә бәетләрнең килеп чыгышын XIII—XIV йөзләргә үк нисбәтли. Билгеле, бәетләр «буш урында» гына барлыкка килмәгән. Татар халык иҗаты бәетләргә кадәр озак тарихи юл үтеп, бай тәҗрибә туплый. Шуның белән бәйле рәвештә, бәетләрнең килеп чыгышы һәм формалашуы төрле иҗади традицияләргә нигезләнә. Автор бу традицияләр арасында аеруча әһәмиятле урын алып торганнарына туктала: борынгы төрки һәм болгар-татар язма культура чыганаклары; бәетләрдән элегрәк формалашкан халык эпосы әсәрләре; халык әкиятләре һәм борынгы җырлар. Бу фикерләрен автор күп санлы материаллар нигезендә эзлекле рәвештә дәлилләп барырга омтыла.

Китапның соңгы бүлеге тарихи җырларга багышланган. Бу мәсьәләне автор моннан шактый еллар элек «Казан утлары» журналында (1969, 3 сан) күтәреп, тарихи җырлар безнең фольклорда да бар дигән фикерне әйткән иде. Яңа монографиясендә ул бу төр җырларның барлыкка килү чорына, үсеш-үзгәреш этапларына туктала, тарихи җырларның бәетләргә һәм лирик җырларга мөнәсәбәтен тикшерә.

Әлбәттә, китапта эпоска бәйле барлык мәсьәләләр дә яктыртылыш тапкан дип булмый. Әйтик, автор татар халкы арасында киң таралган китаби дастаннар проблемасына киңрәк туктала алган булыр иде. Дөрес, үзе әйтеп үткәнчә, аның төп максаты — халыктан язып алынган эпик яки лиро-эпик әсәрләрне генә өйрәнү. Күрәсең шунлыктандыр, монографиядә китаби дастаннардан академик В. Радлов язып алган «Таһир белән Зөһрә» әсәре генә тикшерелә.

Шуның белән бергә, монографиянең исеме эчтәлегеннән таррак булуын да искәртеп үтәргә мөмкин. Китапта героик эпос әсәрләре генә түгел, лиро-эпик әсәрләр дә, бәетләр дә, тарихи җырлар да тикшерелә. Бу очракта автор совет фольклор фәненең электән килгән традицияләренә, аерым алганда, В. Жирмунский, Х. Зарифов кебек галимнәрнең элегрәк дөнья күргән хезмәтләренә таянган булса кирәк.

Йомгаклап әйткәндә, «Татар халкының героик эпосы» монографиясе — Ф. Урманчиевның зур фәнни әһәмияткә ия булган хезмәте. Ул халык иҗатының әлегә кадәр тиешенчә өйрәнелмәгән мәсьәләләрен күтәрә, татар фольклорының жанрлары составын тагын да киңрәк һәм баерак итеп күзалларга мөмкинлек бирә.

**Хуҗи МӘХМҮТОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ТОРМЫШНЫ ЯРАТУ

Г. Кариев, Г. Камаллар нигезләгән, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Т. Гыйззәтләр алга үстереп җибәргән, сәхнәсендә Х. Әбҗәлилов, Ф. Ильская, Ф. Халитов, Г. Шамуков кебек зур осталар уйнап киткән татар театрын җитмешенче-сиксәненче елларда «үз җилкәңә алу» өчен талантны саектырмый тотучы бер чыганак булырга тиештер? Җавапка мин көтмәгәндә юлыктым. Театр фойесында Т. Миңнуллин китапларыннан оештырылган күргәзмәне карап йөри торгач, авторның яфрак кадәрле генә беренче китапчыгына күзем төште. Тәүге битен ачтым да... елмаеп җибәрдем. Китапның кечкенәлеге елмайтмады мине. Беркем дә эшне калын томнар чыгарудан башламый. (Дистәләрчә еллар үтеп, бик күп китаплар бастыргач та, каләм әһелләре әнә шул беренче булып дөньяга килгән китапны кулга алу куанычын бүтән кичермәгәнлекләрен әйтәләр.) Мине китапның беренче битенә яшь авторның үз кулы белән шаяртып язып куелган автографы елмайтты. «Күптомлык сайланма әсәрләренең беренче китабы» дип язылган иде анда. «Оптимист»,— дип әйтеп куйганымны сизми дә калдым. Шулчак башымдагы уйларым кинәт яктырып китте. Таптым бит теге сүзне! Оптимизм икән бит! Чыннан да, аның күпчелек әсәрләрендә шушы төшенчә гәүдәләнеше ярылып ята икән. «Бәхетле кияү»дән алып «Әлдермештән Әлмәндәр»гә кадәр барысына да шушы сыйфат уртак икән.

Театр бүген «халыкка дәрсе гыйбрәттер» генә дә түгел, ул бүген иҗтимагый аң формалаштыруның бик әһәмиятле чарасы. Т. Миңнуллин, драматург буларак, менә шуны аңлап эш итә. Ул, иҗат иткәндә, бер үк вакытта укучыны да, тамашачыны да күздә тота. Укучы һәм тамашачы күңелен яулап алуның яңача ысулларын сынап карый. Пьесаларны укып, ләззәт алган кеше театрга тартыла, ә спектакльләрдән соң тамашачы кулына драма әсәрләрен алып укырга тели.

Бу юлларны язганда, алдыма драматургның барлык китапларын диярлек тезеп куйдым. Алар арасында өчесе тышкы яктан бербереңә нык охшаган: «Китәр юлың еракмы» (1978), «Кырларым-тугайларым» (1982), «Монда тудык, монда үстек» (1985). Өч китапны да рәссам Ю. Денисов бизәгән. Тышкы охшашлык шуннан килә булса кирәк. Ләкин китаплардагы пьесаларда, бәхеткә каршы, форма төрлелеге күренә. Аларда драманың да, комедиянең дә берничә төре бар, скетч, интермедияләр дә онытылмаган. Тагын да әһәмиятлесе — тормыш күренешләре төрлелеге.

Автор, шул китаплардан үзенә иң уңышлы тоелган әсәрләрен җыеп, 1985 елда «Советский писатель» нәшриятында аерым китап итеп бастырды. «У совести вариантов нет» исемле әлеге китапта «Моңлы бер җыр», «Үзебез сайлаган язмыш», «Әниләр һәм бәбиләр», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Монда тудык, монда үстек», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Дуслар җыелган җирдә» кебек әсәрләр бөтенсоюз укучысына тәкъдим ителә. Тәрҗемәчеләр А. Вольнов, О. Дзюбинская, Ал. Санин, Ю. Мочалов әсәрләрнең русча шактый төгәл яңгырашына ирешкәннәр.

Иң беренче күзгә ташланганы — китапның исеме: «У совести вариантов нет». «Моңлы бер җыр» публицистик драмасының исеме русча шулай бирелгән. Болай атау китапның тышына да чыккан. Чөнки әлеге пьеса биредәге әсәрләрнең тема ягыннан гына түгел, идея-эстетик эшләнеше буенча да иң әһәмиятлеләреннән. Ни өчен тәрҗемәдә әсәр исеме үзгәртелгән? Биредә, әлбәттә, русларда моң сүзенең булмавы гына сәбәп түгелдер. Болай исемләү әсәрнең идеясен шактый тулы ача шикелле. Яшь шагыйрь белән Муса арасындагы мондый диалогны искә төшерик.

Ш а г ы й р ь. Ул дәһшәтле елларда гомерегезне саклап калу өчен мөмкинлекләр бар иде. Гафу итегез, илне сату бәрабәренә димим. Сезгә фронтка китмичә тылда калырга мөмкин иде, фронтта да тынычрак урын таба ала идегез. Вариантлар бар иде.

М у с а. Вариант!.. Вөҗдан, намус бер генә бит ул, энекәем, вариантлар юк.

Бу диалогта совет кешесенең, коммунистның, шагыйрьнең сугышта үз урынының асыл мәгънәсен аңлавы никадәр тирән бирелгән! Муса бүтән юлдан китүне башына да китермәгән, җиңү хакына барысын да соң чиккәчә җиренә җиткереп башкарган. Димәк, әсәрнең исеме үк укучыны шушы югары хисләр,

фикерләр дулкынына көйли.

Китапны кулына алган кеше «Диләфрүзгә дүрт кияү» әсәре русчада ничек бирелгән икән дип кызыксыныр. Чөнки татар телендә бик матур, табигый яңгырый торган шаянчук яшьләр сөйләме, җыр-такмак күренешләрен башка телдә яңгырату җиңел эш түгел. Бәхеткә каршы, ярыйсы гына килеп чыккан. Шул ук вакытта кайбер урыннарда, сүзләр «чүмәләсе»ннән тиешлеләрен эзләп тормыйча, турыдан гына кистереп чыгу белән дә очрашасың. Бу бигрәк тә җыр текстларына карый. Диләфрүз, мәсәлән, сәхнәгә дәртле җыр белән килеп чыгарга тиеш. Тәрҗемәче Ал. Санин җырны бирүне кирәк тапмаган. Ә бит Диләфрүзнең уңганлыгы, матурлыгы, чаялыгы нәкъ менә шушы күренештә беренче мәртәбә күзгә ташлана. Тагын бер детальгә тукталыйк. Безнең карашка, ул тупас тоела. Галим атлы карт егеткә Диләфрүз мыскыл итеп болай җырлый:

> Сөям сине, сөям сине,
> Сөям сине үлгәнче.

Русчада ул менә ничек:

> Обожать тебя я буду
> До доски до гробовой.

«Головой» сүзенә рифма табам дип кенә «до доски до гробовой» дип булмый бит. Тәрҗемәчегә әсәр тукымасының бик нечкә тирбәлешләрен белеп эш итәргә кирәк. Шунсыз оригиналдан читкә китүеңне көт тә тор.

«Моңлы бер җыр» әсәрен исә автор тагы да камилләштерә төшкән. Муса, мәсәлән, үз гомерендә очраган иң яхшы кешеләрне исенә төшергәндә, русча вариантта аларны конкретлаштырып әйтә: «Кайда сез, минем дусларым?.. Кашшаф, Фәйзи, минем акыллы җитәкчем Александр Фадеев, Моабит мәхшәрләрен батырларча кичергән Андре Тиммерманс... Минем җанга якын дусларым!..» һәм шуннан соң дуслары турында шигырь укый.

Розенберг белән сөйләшкәндә, киләчәк шагыйре фашистларның вәхши йөзен фаш итүдә дәлил итеп М. Җәлилнең «Бүреләр» шигырен файдалана. Болар әсәрнең тукымасын баетуга китерәләр.

Халкыбызның милли һәм интернациональ якларын ачуга Т. Миңнуллин даими рәвештә көч сала. Әлмәндәр карт («Әлдермештән Әлмәндәр»), Гарифулла («Нигез ташлары»), Саттар («Монда тудык, монда үстек») һәм, ниһаять, Муса һәм аның көрәштәшләре («Моңлы бер җыр») — болар һәммәсе бер үк вакытта милли һәм интернациональ образлар. Яшәүгә дәрт, хезмәт ярату, бала җанлылык, уен-көлкегә маһирлек, халык бәхете өчен көрәштә батырлык, күңел көрлеге — Әлмәндәр картта гәүдәләнгән игелекле сыйфатларның кайберләре генә. Муса кебек үк, Әлмәндәр дә намусны вариантларга бүлеп карый алучылардан түгел. Әҗәл дә аның урынына башка кешеләрнең җанын алырга тәкъдим итә. Әмма карт кемдер исәбенә гомерен озайтучылардан түгел, мондый ахмак тәкъдим авыздан чыкмас борын ук кире кагыла.

Кеше гомере чикле. Ләкин чын шәхес дөньяны үз яшәеше белән генә чикләп карамый, балалары, оныклары, килер буыннар турында кайгырта, дөньяны аларга да матур килеш калдырырга тырыша. Кешеләрнең зур байлыгы — хәтер. Халык хәтерендә саклануга һәркем лаек булмаска мөмкин. Моның өчен мәгънәле яшәү таләп ителә. Ә мәгънәле яшәү үзе ничек була? Ул әлеге дә баягы Әлмәндәрләр, Мусалар кебек яшәү. «Нигез ташлары»ндагы Гарифулла да шулар рәтендә. Ул да тормыш саф әхлакый нигезгә корылырга тиеш дип инанган. Балалары да шулай дөрес яшиме? Соңгы вакытта аңа шул уй тынгылык бирми. Туган нигездән ара һәм вакыт ягыннан күбрәк аерылган саен, малайларында үзе канун итеп алган принципларның аерым очракларда йомшара баруын аңлый ул. Гарифулла картның йорты тузган. Йорт җиткерергә каршы түгел ул, әмма моны намуслы юл белән эшләргә кирәк. Колхоз председателенә министр урынбасары булып эшләүче малае кушып салдырган йортның түбәсен икенче улы урлаган калай белән ябарга аның күңеле тартмый. КПСС Үзәк Комитеты һәм хөкүмәтебезнең хезмәтсез керемнәргә каршы көрәшне көчәйтү чаралары турында игълан ителгән карарлары һәм законнары да менә шундый күңелсез күренешләргә каршы юнәлдерелгән. Т. Миңнуллин андыйларга карата кискен чаралар күрүнең зарурлыгын моннан берничә еллар элек үк аңлаган һәм йөрәк кайнарлыгы белән әлеге әсәрен язган.

Гомумән, Т. Миңнуллин — заман тормышын бик нечкәләп өйрәнә торган драматург. Мәсәлән, «Монда тудык, монда үстек» җыентыгына тупланган әсәрләр бары тик бүгенге көн проблемаларына гына багышланган. Алар күп төрле, күп бизәкле, шуның белән кызыклы да. Шулай да автор вакыт-вакыт кабатлана башлый, әйтик, зирәк картлар белән артыграк мавыга кебек. Әлмәндәр белән Гарифулла образлары кайчакта бер-берсенә охшап та китәләр. Саттар Биккинин да яшьләргә акыл өйрәтүче буларак күренә. Матур сыйфатларның өлкән буыннардан килүе табигый, аңа каршы килеп булмый, шулай да тормышны бүген төпкә җигелеп тартучылар арасындагы конфликт һәм ситуацияләрне язу зарурирак тоела. «Монда тудык, монда үстек» әсәрендә ул шулайрак булып чыккан да. Төп конфликт бертуган Илфат белән Надия арасында барлыкка килә. Туган җиргә, табигатькә карашта диаметраль капма-каршылыктагы коллизия әхлакый конфликтны хәзерли. Тик автор динамиканы ахырга кадәр югары накалда дәвам иттерми, аны гаилә кысалары белән чикләп куя. Илфат үсеш, эчке каршылыклар

аша дөрес юлга басуда ирләрчә ныклык күрсәтә алмый, ягъни вак даирәдә вакланып кала. Әсәрдәге барлык персонажларның төп кайгысы шушы сакаллы сабыйны дөрес юлга бастыру булып чыга. Күрәбез, биредә авторга гаилә кысаларында барлыкка килгән производство конфликтын киң колачлы итеп хәл итү бурычы буйсынып бетми.

Әдәбиятның рухлану чыганагы тормыш дибез икән, Т. Миңнуллинның «Без бит авыл малае» комедиясе нәкъ менә соңгы еллар чынбарлыгындагы уңай үзгәрешләр тәэсирендә язылган. Колхоз үзәгеннән еракта урнашкан авыллар язмышы, аларны бетерүгә йөз тоту күбебезне борчыды. Хәзер хәл үзгәрде, киресенчә, андый авылларны ныгыту чаралары күренә. Тик язучы иптәшләр колагына шуны әйтәсе килә: проблеманы хәл итеп башлагач түгел, бәлки авыр таш булып урынында ятканда күтәрү, җәмәгатьчелекнең игътибарын шуңа кыюрак юнәлтү күпкә файдалырак. Әдәбият вакыйгалардан алдарак барырга тиеш.

Кайбер яшьләрнең инфантильлеген ачып салган «Уйланыр чак», «Эш сөймәсне — ил сөймәс» дигән мәкальгә туры килүче ситуациягә корылган «Күрше кызы», әйләнә-тирәдәге хәл-әхвәлләргә битарафлыкның зарарын күрсәтеп биргән «Бәйләнчек» пьесалары һәм җыентыктагы башка әсәрләр Т. Миңнуллинга хас җорлык һәм үткен акыллылык белән язылганнар. Шулай да «Әниләр һәм бәбиләр» драматик хикәясе проблемасының тормыштан чумырып алынуы һәм бик тә актуальлеге белән җыентыктагы барлык әсәрләрдән аерылып тора.

Әгәр дә без киләчәккә өмет белән карыйбыз икән, димәк, яшь буынны тәрбияләүдән дә мөһим эш була алмый. Чөнки вакыты җиткәч, бу буыннар үз балаларын тәрбияләргә тиеш булачак. Безнең бу өлкәдәге эшчәнлегебез бүгенге яшь буынның әхлакый сыйфатларын формалаштыруга юнәлтелгән булса да, асылда без икенче, өченче һәм аннан соңгы алмашларны тәрбияләүне программалаштырабыз икән.

Әнә Римма исемле хатын үзенең Дилемма исемле кызын хиссез-кичерешсез «манекен» итеп үстергән. Хәзер исә бу егерме яшьлек хатын, дөньяга бала тудырырга яраса да, аны күкрәк сөтен имезеп, бишек җыры җырлап тирбәтергә әзер түгел. Ул әнисенә бала була да белмәгән, хәзер баласына ана да була алмый. Баш врач әйткәндәй, Римма ханым «кешеләр арасына бер имгәк үстереп җибәргән». Автор әсәрдә «Бишек җыры беләсезме?» дигән сорауны юкка гына бирми. Бишек җырыдай йомшак күңеллелекне, самимилекне, җылылыкны, нәфислекне югалтмыйсы, бу затлы сыйфатларны тагы да үстереп җибәрәсе иде бит. Менә нинди олы мәгънә салынган әсәр үзәгенә. Шундый таләпләргә җавап бирүче Гөлфинә образы әнә нинди матур! Аның сүзләре һәм ихласлылыгы тормыш тоткасы булган мәхәббәткә гимн булып яңгырый. Менә бу инде олы драматургларга хас булган киң колачлылык, заман белән бергә атлау, бүгенгене, аның кешеләрен яхшырту аркылы киләчәккә оптимизм белән карау. Әйе, Туфан Миңнуллин оптимист кеше, һәм аның иҗат үзенчәлеге дә шушы олы, күп мәгънә сыйдырышлы сүз белән билгеләнә.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

# Тукай-Кырлай, 1986 ел


Тукай-Кырлайда Габдулла Тукайның 100 еллыгына багышланган бәйрәм тантанасыннан күренешләр

Шагыйрьгә чәчәкләр >



Шагыйрь Н. Доризо чыгыш ясый.
V





Λ

Бәйрәм кунаклары М. Кәрим һәм Н. Җиһанов



Арча ягы үзешчәннәре чыгышы

V



Тукайның 100 еллыгына

## Бөркет Исхаков

# ТУКАЙ ҺӘМ КАЗАХ ӘДӘБИЯТЫ

Татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай исеме һәм иҗаты илдә яхшы билгеле. Чөнки ул үз милләтенең генә түгел, күпләгән шәрык халыкларының, бөтен Россия хезмәт ияләренең моң-зарын чагылдырды. Тукай әсәрләре XX гасыр башында Идел-Урал буйларында, Урта Азиядә, Кавказда һәм Кырымда иҗтимагый-политик фикер үсешенә, демократик карашлар тамыр җибәрүенә саллы өлеш кертте, дисталәгән милли әдәбиятларда якты эз калдырды. Шуңа күрә күп кенә шәрык халыклары, җөмләдән, казахлар да, аны «үз шагыйребез», «үз җырчыбыз» дип кабул итте.

Егерменче йөз башында кардәш төрки халыкларга иң көчле йогынты ясаган әдәбият — татар әдәбияты, иң күп җан азыгы биргән язучы — Г. Тукай иде. Чөнки татар халкы бу дәвердә экономик, иҗтимагый-политик үсеш ягыннан башка кардәшләреннән шактый алгарак киткән, социаль һәм милли азатлык көрәшләренә киңрәк, көчлерәк тартылган иде. Табигый ки, шул сәбәптән татар әдәбияты да халык тормышындагы әлеге прогрессив үзгәрешләрне үз вакытында чагылдыра башлады, демократик фикерләрне байрак итеп, укучыларны яңалыкка, көрәшкә канатландырды. Г. Тукай исә иҗтимагый эчтәлеге тирән, әдәби осталыгы югары реалистик иҗаты белән туган әдәбиятын яңа биеклекләргә күтәрде, татар мәдәнияты өчен генә түгел, бөтен дөнья классик әдәбияты өчен дә әһәмиятле әсәрләр язды һәм үзен талантлы шагыйрь, прозаик, публицист итеп танытты.

Габдулла Тукай. Аның исемен һәм иҗатын белмәгән кеше казах даласында, мөгаен, бөтенләй юктыр. Чөнки аның иҗаты гына түгел, тормышы да бик иртә казах җире, казах халкына бәйләнә. Булачак шагыйрь тугыз яшендә ерак Казан артыннан безнең Уральск шәһәренә күчеп килә. Әйтергә кирәк, бу күчү ятим малай язмышында зур роль уйный. Уральск шәһәрендә рус мәктәпләре генә түгел, татар мәдрәсәләре дә яшәп килә, үз көндәлек матбугаты да бар. Шәһәрнең эшчеләр катламы да шактый ук күзгә күренерлек була, алдынгы карашлы укымышлылары да очраштыргалый. Шәһәрдә үз халкыннан тыш, руслар, казахлар һәм бүтән милләт вәкилләре белән дә аралашу мөмкинлеге ачыла. Һәни Габдулла өчен монда тагын бер бик күңелле як та мөһим — хәлле җизнәсе Галиәсгар Госманов гаиләсендә ул, ниһаять, бер сыник икмәккә тилмерүдән котыла.

Уральск каласы Тукай тормышына чын мәгънәсендә якты борылыш урыны, үсү, җитлегү, кечкенә Апуштан зуп-зур Тукайга әверелү дәвере булып керер кала. Монда ул ун ел чамасы «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә, бер үк вакытта өч ел рус классында да укый, Иргали, Нургали исемле казах шәкертләре белән дуслаша, шәрыкның һәм гарепнең күп кенә шагыйрьләре, әдипләре, философлары иҗаты белән таныша, якындагы Җымпиты, Каратүбә дигән казах авылларын һәм җәйләүләрен

*ИСХАКОВ БӨРКЕТ ИБРАҺИМОВИЧ (1924) — СССР Язучылар союзы члены, шагыйрь һәм тәрҗемәче, филология фәннәре кандидаты, Казахстан Фәннәр академиясенең М. Әүэзов исемендәге Әдәбият һәм сәнгать институты өлкән фәнни хезмәткәре. Казах әдәбиятының халыкара бәйләнешләре, шул исәптән, казах-татар әдәби бәйләнешләрен өйрәнә. «Казах-татар әдәби бәйләнешләре» (1976) монографиясе һәм күп кенә әдәби җыентыклар авторы.*

барып күрә. Ул әдәбият дөньясына да беренче тапкыр шушында аяк баса.

Соңыннан язган истәлекләрендә Тукай казах җирендә үткән гомерен сагынып искә ала. Үзе искәртүенчә, ул монда татар әдәбияты, татар халык иҗаты белән генә түгел, казах үләңнәре (шигырьләре, җырлары) белән дә таныша, бигрәк тә сюжетлы казах җырларын ошата.

Мәгълүм булганча, Г. Тукай 1910 елның 15 апрелендә Казанның «Шәрык» клубында «Халык әдәбияты» дигән лекциясен сөйли. Ул монда кайбер китаби әсәрләрнең теле халыкның җанлы теленнән ерак икәнлеген борчылып билгеләп уза һәм, фикеренраслар өчен, «Таһир-Зөһрә»гә дә мөрәҗәгать итә.

> Сазың күп моң кылады, ишеткән таң калады;
> Гариб гашыйк, якын кил: исмеңез кем булады?

Шагыйрь шушы өзекне китерә дә: «Бу кем телендә? — дип сорый.— Кыргыз (казах — Б. И.) телендә. Бу кем китабы? Татар китабы. Бу — татарның искедән бирле укылып килгән әдәби китабы. Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер».

Тукай бу лекциясендә казах теле үзенчәлекләрен дә, казах һәм татар телләренең үзара якын һәм аңлаешлы булуын да бик яхшы белүен раслый. Алай гына да түгел, ул әле үзенең казах халык иҗаты белән яхшы таныш икәнлеген дә исбатлый.

«Кыргыз (казах — Б. И.) халкында булган кеби, бер-берсенә каршы җырлашу безнең халыкта әле һаман да бар. Ләкин кыргызлардагы кеби, шома вә яхшы чыкмый»,— дип дәвам итә ул лекциясен.

Г. Тукай 1912 елның маенда Троицк тирәсендәге бер казах җәйләвенә кымызга килә. Карабалык авылында үзе өчен тегелгән махсус кунак тирмәсендә ике ай ярым ял итә, балачагыннан үз күргән халыкның хәяте, гореф-гадәтләре, тормыш-көнкүреше белән тагын да якыннанрак таныша. Монда алган тәэсирләре мәшһүр шагыйрьнең берничә әсәренә илһам һәм этәргеч бирә.

«Бу — сахра. Бу — казакъ җире... Коры степь һавасы. Сөт, каймак — теләсәң көен, әле генә сауган саф кымыз. Бүген генә суйган ит. Бөтен нәрсә табигый, бөтен нәрсә алдаусыз»,— дип яза ул бу хакта «Мәкаләи махсуса» дигән юлъязмасында.

Шәһәр сөременнән, бозык һавадан, ыгы-зыгыдан, төрле бәрелешләрдән йончып, хәлдән таеп килгән шагыйрьгә дала табигате шифалы дәва була.

> Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
> Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!
> Ак күмәч берлән ашарлык саф һава;
> Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи!
> Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,
> Бер куныплык күкне сайлый, валлаһи! —

ди Тукай казах даласының табигатенә сокланып.

Тукай казах тормышын, казах халык иҗатын гына түгел, казах шигырь төзелешен дә әйбәт белгән. Ике кардәш халыкның әдәби багланышларын да күздән җуймаган. «Әле истән чыккан икән, тагы бер ярты казакъ, ярты татар Акмелла хәзрәтләре бар икән... Шигырьләреннән казакъ исе, күчмә халык исе чыгып торадыр»,— ди ул «Шигырьләребез» мәкаләсендә.

Тукай шунда ук казах шигърияте тәэсирен татып иҗат итүче бүтән татар шагыйрьләре дә булуын искәртә. «Әлгасрел-җәдит»нең 1907 елгы 2 февраль санында басылган «Шагыйрьгә» әсәре буенча без аның М. Гафури һәм Н. Думавины күздә тотуын чамалыйбыз. Бер үк вакытта, Тукай телнең дә, шигырь төзелешенең дә милли нигездә һәм халыкчан рухта булырга тиешлеген белдерергә онытмый.

Г. Тукай исеме әле үзе тере чакта ук казах иленә яхшы мәгълүм була. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укып йөргән бер казах шәкерте 1913 елда шагыйрь вафат булгач, түбәндәге шигырьне чыгара:

> Татарда акын үтте Тукай дигән,
> Ятим булып яшь көе калган чирдән...
> Һәр сүзе гәүһәр таштай ялтыраган,
> Гаҗәп-ай, акын иде уе тирән!

Менә шушы кечкенә күләмле әсәрдә дә казах халкының Тукайга мәхәббәте, аның иҗатына югары бәя бирүе бик ачык тасвирләнә. Башка милләт язучылары белән бергә, казах каләм әһелләре дә Тукай иҗатыннан илһам ала. Аларның егерменче елларда Тукай шигырьләрен укымаганын, шул шигырьләрдән өйрәнмәгәнен табу, гомумән, үтә кыен.

Иҗтимагый тормышка актив катнашу, заманының иң актуаль мәсьәләләрен күтәрү, аларны үткен һәм оста куя белү, һәрвакыт хезмәт ияләре мәнфәгатен яклау — кайсы гына яктан алсаң да, Г. Тукай казах акыннарына әйбәт үрнәк күрсәтә. Элек туган тел, милләт һәм милләтчеләр, казах хатын-кызлары турында әсәрләр безнең әдәбиятта юньләп күренмәсә, Тукай тәэсирендә бу темалар казах язучылары иҗатында торган саен киңрәк урын ала бара. Мәсәлән, С. Торайгыров туган тел, казах кызларының аң-белем ягыннан артта калулары турында Тукай үрнәгендә шигырьләр яза. С. Дөнәнтаевның «Милләтчеләргә» дигән шигыре дә иҗади бәйләнешкә мисал була ала. Тукайның остазлык роле С. Торайгыров, С. Дөнәнтаев, С. Күбиев, Б. Күлиевләр иҗатында аеруча калку чагыла.

Г. Тукай исеме һәм аның әсәрләре 1913 елдан («Айкап», 7 сан) башлап казах матбугаты битләрендә даими урын алып килә, аңа әледән-әле махсус мәкаләләр багышлана. Казах укучылары Тукай әсәрләрен элек асыл нөсхәсендә генә укый алса, хәзер инде алар белән туган телендә дә иркенләп танышу мөмкинлегенә ия. Совет дәверендә алар алты мәртәбә аерым китап итеп басылды. Шагыйрьнең йөз еллыгы уңае белән исә җиденче җыентыгы — «Күңел йолдызы» дөнья күрде. «Үрнәк тормыш» сериясендә И. Нуруллинның шагыйрь гомеренә һәм иҗатына багышланган «Тукай» документаль повесте басылып чыкты. Тукайның «Шүрәле» поэмасына нигезләнеп язылган Ф. Яруллин балеты Абай исемендәге Казах дәүләт опера-балет театры сәхнәсендә уйналды.

Тукай тормышы һәм иҗаты С. Мокaнов, Җ. Сыздыков, С. Машаков шикелле язучыларыбыз, Т. Нортазин, С. Талҗанов, С. Сәетов кебек галимнәребез тарафыннан даими яктыртылып килинә. Байтак шагыйрьләребез аңа багышлап шигырьләр, Эзтай Мамбетов исә «Тукай башланганда» дигән поэма иҗат итте.

Татар кызына өйләнеп гомер иткән, татар язучыларының китапларын, «Казан утлары» журналын өзлексез алдырып укып барган шагыйрь Җакан Сыздыков (1901—1978) исемен аерым телгә алу урынлы. Ул татар язучыларын, бигрәк тә Г. Тукай әсәрләрен тәрҗемә итүгә күп көч салды, аның тормышына һәм иҗатына багышлап мәкаләләр бастырды, чыгышлар ясады, татар остазы образын байтак шигырьләрендә гәүдәләндерде. Шагыйрьнең халык күңелендә яшәвен сурәтләп: «Олы остазым Габдулланың шигырьләреннән өлге аламын»,— дип белдерә автор. Җакан Сыздыков Татарстанга икенче мәртәбә килгәч, Тукайга бәйле барлык җирләрне яңадан күреп, күңелендәге тойгыларны яңарта һәм баета. Казах халкының кайнар мәхәббәт хисләрен шигырьләрендә дулкынланып бәян итә.

Э. Мамбетовның «Тукай башланганда» поэмасында, Т. Әлемколовның «Габдулла Тукайга», Г. Җомабаевның «Тукай җыйган хәрефләр» шигырьләрендә дә кардәш халыкның мәшһүр шагыйре образы, аның иҗатының гүзәллеге, игезәк милләтләрнең дуслыгын ныгытуда әһәмияте зур хөрмәт белән һәм сөеп гәүдәләндерелә.

Тукай иҗатын сокланып өйрәнүче, аңа югары бәя бирүчеләрнең берсе — Ленин һәм СССР Дәүләт премияләре лауреаты М. Әуэзов. Мәшһүр татар шагыйрен яшьли танып-белеп үскән казах язучысы үзенең бик күп фәнни тикшеренүләрендә Тукай исемен һәрвакыт Абай, Абовян, Ахундов, Чавчавадзелар сафына куя, аның шәрык һәм гареп классикларыннан бердәй өйрәнүен, әмма замандашлары ихтыяҗын тулырак канәгатьләндерү өчен, Европа әдәбиятлары, шул исәптән, демократик рус язучыларының реалистик иҗаты тәҗрибәсенә ныграк таянуын, шуңа күрә төрки халыклар тарафыннан аның әсәрләре бик тиз үз ителүен аңлата. Әуэзов 1949 елда язган «Пушкин һәм Совет Көнчыгыш кардәш әдәбиятлары» мәкаләсендә: «Татар әдәбияты тарихында Габдулла Тукай гаять әһәмиятле эш башкарды,— ди.— Ул үз иҗатында рус реализмы, рус революцион-демократик традицияләрен дәвам итте. Ислам фанатизмын һәм рухи торгынлыгын кискен хөкем итүче, үз халкының алдынгы җәмәгать эшлеклеләрен ышанычлы төстә рус культурасын үзләштерүгә баглаандыручы Тукайның горур шигърияте ирек сөюче Пушкин шигъриятенә якын иде. Тукайның Пушкин реализмын кабул итүе дә мөһим. Шушы нигездә ул үз дәвере

җәмгыятенең кимчелекләрен һәм тарихи каршылыкларын тирән ачуга иреште. Тукай чын халык шагыйре иде. Аның шигырьләренә тәшенке рух бөтенләй хас түгел. Аның иҗатында һәрвакыт якты, көяшлы, өметле башлангыч өстенлек итә. Пушкин шикелле, Тукай да җаны-тәне белән ватанының якын киләчәгенә ышана».

Казах совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе, атаклы шагыйрь Ильяс Җансүгеров (1894—1937) тормышы һәм иҗаты да татар халкы, аның әдәбияты белән тыгыз бәйләнгән. Ул татар язучылары әсәрләрен балачагыннан укып үсә. Моңа атасының татар китаплары да байтак булган шәхси китапханәсеннән файдалануы, Казан мәдрәсәләре үрнәгендә оештырылган Карагач мәктәбендә татар мөгаллимнәреннән укуы да этәргеч бирә. Алар казах шәкертләрен Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Гафури һәм башка татар язучылары әсәрләре белән киң таныштыра. Укучылар мәктәпкә алдырган Казан, Оренбург, Уфа татар көндәлек матбугатын да укып бара. Менә шундый мохитта үскән егет татар кызына өйләнә. Мәскәүдә укыганда да, Казахстан Язучылар союзы идарәсе председателе булып эшләгәндә дә гомер буе татар укымышлылары белән хезмәттәшлек итә, ике әдәбият дуслыгын ныгытуга теләп катнаша. Моңа аның Тукай әсәрләрен тәрҗемә итүе дә дәлил. Совет язучыларының беренче съездында Кави Нәҗми, Сәрвәр Әдһәмова һәм бүтән татар каләмдәшләре белән таныша, бергә фотога төшә, съезд трибунасыннан казах халкы яратып укый торган бөек язучылар исәбенә Г. Тукайны да кертеп сөйли.

Күренекле казах язучысы Сабит Мoканов (1900—1973) татар әдәбияты белән шулай ук бала чагыннан дуслаша. Тукай шигырьләрен укып әсәрләнә. Ул бу хакта «Гомер мәктәбе» трилогиясенең «Габдулла Тукай» бүлегендә ихлас күңелдән олылап яза. С. Мoканов Тукайның революциягә кадәр үк кулына төшкән татарча җыентыгын гомере буе кадерләп саклый, гомере буе кайта-кайта укый, казах матбугатында кардәш халыкның атаклы шагыйре хакында күп мәртәбәләр чыгыш ясый. Аның остазын югары бәяләгән «Мәңге яшәячәк шагыйрь» мәкаләсе Тукайның 75 еллыгы уңаеннан Алма-Атада «Казах әдәбияты» (1961, 14 июль) газетасында һәм Казанда «Совет әдәбияты»[1] (1963, 6 сан) журналында дөнья күрә. С. Мoкановның бу хезмәте — татар демократик мәдәниятен, аның иң зур вәкиле Г. Тукайны тәкъдир итү, төрки халыкларның иҗтимагый фикерен һәм әдәбиятын үстерүдә шагыйрьнең әһәмиятле ролен бәяләү ягыннан әлегә кадәр казах җәмәгать эшлеклесе һәм иҗатчысы язган иң дөрес, иң гадел мәкалә.

С. Мoкановның Тукай әсәрләреннән юаныч һәм илһам алуы башка татар язучылары иҗатына да игътибар итәргә, тормышында һәм эшендә тугандаш халык вәкилләре белән дуслашуга сәбәп булды. Соңра бу дуслык аның иҗатында да чагылды — «Бутакүз» романында һәм башка күп кенә әсәрләрендә татар халкы вәкилләренең сөйкемле һәм тормышчан образлары бирелгән.

С. Мoканов татар әдәбиятын, аерым алганда, Тукай иҗатын туган халкына таныту юлында һәрвакыт чын күңелдән бирелеп эшләде. Казанда шагыйрьнең сиксән еллыгын уздыруда катнашты, хезмәтләре өчен Татарстан АССР Верховный Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Г. Тукайның 90 еллыгы бөтен Казахстанда һәм аеруча шагыйрьнең яшьлеге узган Уральск өлкәсендә тантаналы төстә билгеләп узылды. Уральск шәһәрендә аның исемен мәңгеләштерү чаралары күрелде, татар һәм казах язучылары бергәләп үзләренең уртак остазларын хөрмәтләде, җәеклылар мәшһүр шагыйрьне онытмауларын, аның исеме белән горурлануларын тагын бер кат исбат иттеләр.

Татар халкының сөекле шагыйре Г. Тукайның йөз еллыгын да Казахстан җәмәгатьчелеге үз улы бәйрәмедәй билгеләп узды. Аның тормышы казах халкы тормышыннан, аның гаҗәп осталык белән язылган бай эчтәлекле әсәрләре казах әдәбиятыннан аерылгысыз икәнлеген тагын бер мәртәбә басым ясап күрсәттеләр. Чөнки Г. Тукай иҗаты, чыннан да, безнең рухи дөньябызны баетуга — социаль һәм милли аңыбызны уятуга, туган әдәбиятыбызны үстерүгә — аның яңа фикерләр, жанрлар һәм формалар белән тулылануына, сәнгатьчә маһирлыгы күтәрелүенә хезмәт итте. Менә шуңа күрә бөек татар шагыйре Г. Тукайның изге исеме, аның якты образы һәм гасырларга барачак ялкынлы иҗаты Казахстанда — безнең күңелләрдә, газиз Абаебыз шикелле, һәрвакыт якты йолдыз булып балкый.

# КЫМЫЗГА БАРУ ЮЛЫНДА

Әдәбият галиме, профессор И. Нуруллин «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә чыккан «Габдулла Тукай» (Казан, 1979, 270 б.) исемле китабында «шагыйрьнең Троицк чоры турында без бик аз беләбез», дип яза. Ш. Рахманкуловның 1983 елда «Казан утлары» журналының дүртенче санында басылган мәкаләсе дә шушы мәсьәләгә багышланган. Ул Г. Тукайның Троицк шәһәренә баруын һәм аны далада кымыз эчүгә урнаштыруны бары тик Габдрахман хәзрәт исеме белән генә бәйли. Тукайның хәзрәт белән элемтәсен аның муллалыгы «динем өчен түгел, көнем өчен» генә булуыннан чыгып аңлатырга тырыша. Ә менә безнең кулда булган материаллар бу эштә социал-демократия вәкилләренең дә катнашуын сөйли. Сүзне рәсми документка бирик.

### СПРАВКА[1]

По обмену мнениями с бывшими членами Троицкой организации РСДРП(б), я, Леонид Алексеевич Кулик, как бывший председатель этой организации, удостоверяю следующий факт: в 1906—1908 годах и раньше чайная в доме Викулова в гор. Троицке б. Оренбургской губ. служила местом распространения подпольной литературы. Крупное участие в распространении этой литературы принимал местный житель Багаутдин Шафигуллин, что и удостоверяю подписью. Кулик, 29 июля 1935 г.

Подпись руки Кулика Л. А. удостоверяет секретарь института (подпись).

Бу белешмәне бирүче турында бер-ике сүз. Зур Совет Энциклопедиясенең 24 томында (15 б.) аның турында түбәндәге мәгълүматлар теркәлгән: Леонид Алексеевич Кулик (1883—1942) — совет минералогы, метеоритларны өйрәнү буенча белгеч, совет метеоритикасына нигез салучыларның берсе. Бөек Ватан сугышы башлангач Л. А. Кулик үзе теләп халык ополчениесенә языла, яралана һәм әсирлектә һәлак була. Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр Л. А. Кулик Уралда политик сөргендә булган.

Инде мәсьәләнең асылына күчик. Югарыда китерелгән документта искә алынган Бәһаветдин Шәфигуллин Викуловлар йортында (Базарная һәм Гимназическая урамнары почмагында) чәйханә тоткан. Аны шәһәрдә «Чәйни Бәһави» дип йөрткәннәр. Чәйханә каршында уку залы булган, анда төрле газеталар һәм журналлар алынган. Бәһаветдин бабайның өч кызы һәм ике улы булган. Олы кызы Сәрвәр — минем хатыным Розаның әнисе. Ул мәрхүмә инде. Икенче кызы Мәймүнә укытучы булып эшләгән. Әтисенең яшерен эшләрендә ярдәмче булган. Мәймүнә апа да, бабайның ике улы да шулай ук мәрхүмнәр инде. Бәһаветдин бабайның кече кызы Хәдичә апа исән, хәзерге вакытта Чиләбе шәһәрендә олы кызы, РСФСРның атказанган укытучысы Роза Мәүлүтова белән тора. Аңа хәзер 84 яшь. Фикере ачык, хәтере яхшы. Тукай Троицкида булган елларда ул рус гимназиясендә укыган. Хәдичә апа Ш. Рахманкулов мәкаләсендә телгә алынган Г. Әхмәров кызларын да хәтерли.

Хәдичә апаның һәм Сәрвәр әниебезнең сөйләве буенча Тукайны Троицкида каршы алучы һәм далага озатучы Бәһаветдин бабай булган. Хәдичә апа Тукайның өйләренә килүен түбәндәгечә хәтерли: «Әти белән безгә яшь егет килеп керде, буе кечкенә, бик гади генә киенгән. Йөзе ак, авыруы сизелә. Әтигә без, балалар, сораулы күз белән карагач, ул килүченең бик талантлы шагыйрь Габдулла Тукай икәнлеген аңлатты».

Бәһаветдин бабай өендә Тукайга аерым бүлмә бирелгән. Анда бер кич кунганнан соң, Бәһаветдин бабай үз аты белән Г. Тукайны яхшы танышы казах Хәсән Имамбаев җәйләвенә илтеп куйган. Әлеге казахның атлары күп булган һәм кымызның сыйфаты да тирә-якта дан тоткан.

Сәрвәр әниебез җәйләүгә баруларын, Тукайны еш күрүләрен сөйли торган иде. Бәһаветдин бабайның төннәрен бик еш миллионер Яушев эшчеләре янына коралланып чыгып китүен, бер мәртәбә полиция куыйннан чак котылып калуын да Сәрвәр әниебез еш искә төшерә иде.

Бәһаветдин бабай Габдрахман хәзрәт белән таныш булган. Бабайның хатыны үлгәч, Габдрахман хәзрәт зиратта ясин укыган. Г. Тукайны кымыз эчәргә чакыру, аны каршы алу, урнаштыру турында аларның килешеп эшләүләре бик мөмкин.

**Фәрид ШӘҢГӘРӘЕВ,**
физика-математика фәннәре кандидаты,
Свердловск педагогия институты доценты.

---

[1] Бу белешмәнең Чиләбе шәһәр нотариаль конторасы тарафыннан 2359 нчы номер белән 1935 елның 23 сентябрендә расланган бер күчермә нөсхәсе автор кулында саклана. (Ред).

# САҖИДӘГӘ ХАТЛАР

I



Аның архивында укучыларыннан, редакцияләрдән һәм язучылардан килгән бик күп хатлар саклана. Язучыларныкы әле башкаларыннан күбрәк тә. Озак еллар буе районда, нефтьчеләр төбәгендә яшәгән Саҗидә, гомумән, хатлашып торырга ярата иде.

Бу язмада без күренекле каләм осталары — татар, башкорт һәм үзбәк язучыларыннан, шагыйрьләреннән Хәсән Туфан, Зөлфия, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Мостай Кәрим, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази һәм Нәҗәр Нәҗми хатларын файдаланырга булдык. Алар — шагыйрә иҗатына җылы караштагы, өлкәннәрчә кайгыртучанлык тойгысы белән язылган, истәлекле, әдәби кыйммәтле хатлар. Сөенү дә, соклану да, борчылу да, хәтта әрнү дә бар аларда...

Яшел кара белән «чигеп» язылган гыйбрәтле хаттан башлыйсы килә:

Кадерлебез Саҗидә!

Шигырьләрең турында кайбер фикерләремне сиңа Уфада очрашканда әйткән идем инде. Әйтү — җиңел, язу читен икән. Сиңа хат язарга дип утырам да, яңадан шигырьләреңне күздән кичерүгә күчәм. Әллә ничә шулай иттем инде.

Исеңдәдер, без синең әдәбиятка килүеңне сокланып, шатланып каршы алган идек. Татар поэзиясенең Анна Ахматовасы булачак бу дип сөенгән идек. Әле дә шулай уйлыйбыз.

Синең иҗади язмышың безнең өчен барыбер түгел. Битараф кына булып кала алмыйбыз. Кыскасы — мин сиңа ни генә әйтсәм дә, үз итеп, якын күреп әйтәм.

Нишлисең син, Саҗидә? Артык ашыгасың что ли? Нигә әйбәт әдәби исемеңнең кадерен белмисең? Синең гаҗәп гүзәл шигырьләреңә, чын мәгънәсендәге көчле шигырьләреңә урта кул әрсез шигырьләр тагылып киләләр. Бу хәл безне — синең чын иҗатны башкаларга да үрнәк итүчеләрне — уңайсыз хәлгә калдыра, кайгырырга мәҗбүр итә.

«Уйлар, юллар»ның (кулъязма хәлендәге җыентык. Ә. М. искәрмәсе.) урта кулдагы шигырьләрен һәм алар эчендәге кайбер бик әйбәт строфаларны укый-укый, «Серләремне сиңа сөйлим»гә килеп җиткәч: «Вот это да! Эчтәлеге гаҗәеп табигый, гади, ачык, җиңел тел белән, сокланырлык итеп әйтелгән» дип язып куйганмын шигыреңнең читенә. «Тынгысыз башкайларым»ны да, «Сине сагынып»ны да, «Юлларыңда юлдаш булыйм»ны да, «Асмалы күперләре»не дә һәм «Җир-су»ның байтак урыннарын шулай сөенеп укыдым. Ләкин җыентыкта синең типик, ап-ак шигъри күлмәгеңә башка төстәге кирәксез ямаулар гына булып торган шигырьләр дә байтак бит анда. Бу җыентыкны, шигырьләр читенә язып куелган фикерләр белән булышу өчен, үзеңә җибәрермен.

Менә минем әйтергә теләгән киңәшләрем шундыйрак, Саҗидә. Бер генә язсаң да, берәгәйле яз. Чын шагыйрь юлы иң катлаулы, иң авыр, ләкин иң гүзәл, олы, бай, бәхетле юл ул...

Абыйларча изге теләкләр белән Хәсән.

9.VII.68.

Талəпчəн аксакалыбыз Хəсəн Туфанның шагыйрəне тирəн ихтирам итеп, яратып, өзгəлəнеп язган, Сергей Есенин рəсеме төшерелгəн конвертка салып җибəргəн хатына аңлатма биреп торасы юк шикелле. Саҗидə бу хатны алгач, безнең белəн дə киңəшлəшеп, ул «эрсез» шигырьлəрне баштa безгə укымавына үкенеп, озак кына уйланып йөрде. Тəнкыйтькə очраган шигырьлəрнең бер өлешен нык кына эшлəде, ə кайберлəрен элеккечə, үзенчə калдырды. Аның Анна Ахматова да, башка берəү дə түгел, үзе булып каласы килə иде. Бу уңай белəн ул, берничə елдан соң укучыларга мəгълүм булган, җыентыкларына кергəн «Шагыйрə» дигəн шигырен язды. Аның соңгы юлы «Ахматова түгел мин, бүтəн» дип тəмамлана.

Хəсəн абыйның «Артык ашыгасың что ли?» дигəненə карата шуны əйтергə мөмкин. Саҗидə Сөлəйманова поэзия мəйданына 35 яшендə, унбиш еллап укыту стажы белəн килеп керде. Өчкə бүленеп яшəргə мəҗбүр булды ул: яраткан мəктəп коллективы да аны үзеннəн арттырмый, алда, күңелен җилкетеп, шигърият маягы да балкып дəшə һəм өйдə балалар итəктəн тота. Үткəнне кире кайтарып булмый, ə шигырь яше узып бара. Язып калырга ашыкты ул. Сан ягыннан куып түгел лəкин. Шигырьлəрен бик авырлык белəн, сызланып, газапланып язды Саҗидə. Яңасы тəгəллəнгəнче, өйдə рəтлəп сөйлəшми, үз эченə биклəнеп йөри, хəтта ябыгып кала.

Карыйсың, бер арада эш өстəлемдə пөхтə итеп күчерелгəн яңа шигырь пəйда була. Ə авторы дулкынланып, үзенə эш табып, башка бүлмəдə йөренə. Дəшеп алганны көтə. Уңай фикер ишетсə, башы күккə тиярдəй булып сөенə. Аннары дустыбыз Гамил Афзалга барып укый. Тəнкыйть фикерлəребез еш кына уртак була иде. Матур шигырь туган көнне өйдə бəйрəм.

Саҗидə Сөлəймановага иҗатта хəерле юл телəп, беренче фатиха биргəн олы шагыйрьлəр — Хəсəн Туфан белəн Сибгат Хəким булды. 1963 елда басылып чыккан «Кыр казлары» дигəн беренче шигырь җыентыгын, җəмəгать эше тəртибендə, С. Хəким редакциялəде. Гомере буе «Казан утлары» журналының редколлегия члены булгангамы, Саҗидəнең барлык шигырьлəре диярлек аның кулы аша узды. Заманында озак кына еллар журналның поэзия бүлеген җитəклəгəн тəҗрибəле шагыйрь Нури ага Арслан да авторларга бик игътибарлы иде. Бер юлы диярлек, икесеннəн дə хатлар килеп төшə Саҗидəгə. Уңышына сөенəлəр, кимчелеклəрен төзəттерү чарасын эзлилəр (башкалар иҗатына карата да шундый мөгамəлə булгандыр дип уйлыйм). Сибгат Хəкимнең бер хатына мөрəҗəгать итик:

Саҗидə!

...Шигырьлəрне укып чыктым. Ахырдагы шигырьдəн башлыйм. Иң җылысы шул кебек. Кыска, ачык, хислəр ышандыра. Шигырь шундый нəрсə инде ул, хиснең чынлыгы белəн алдыра. Бу кыска шигырьдə дə бер строфа артык. Баштан икенче строфа... «Көнлəшү» бик кыен җитə. «Табигать»,— матур:

Шəмəхə шəлнең чуклары
Алланып җиргə тамды...

Авылны бик тиз искə төшерде, образ күз алдына басты.

«Соңгы патрон...» Озынрак, сузынкырак. Сезнең кайчандыр əтиегез турында бик шəп шигырегез бар иде. Хислəр шунда кереп бетмəдеме икəн. Бусы да басыла торган шигырь, тегесендə хис күбрəк кебек иде, никтер шул шигырь хəтердə нык сакланып калган. Бөтен язган шигырьлəр дə əйбəт кенə булып бетсə... Пушкинны да, Лермонтов, Тукайларны да сайлап укыйлар. «Медный всадник», «Демон», «Белеет парус одинокий» яки «Өзелгəн өмет», «Печəн базары» дип...

Шигырьдə дə, прозада да Сез талантлы, тик үзеңне җуймаска кирəк. Сезнең үз лирик шигырьлəрегез, Сез генə сөйли торган лирик хислəрегез бар. Соңгы ике-өч елда алар бераз озыная төште, мудрить итү (татарча ничек?) күбəйде, описание күбəйде. Əллə мин ялгышам микəн. Мин шулай тоям. Минем укып, күзəтеп барган шагыйрьлəрем бар. Миндə шундый тойгы калды.

Хəрəкəт, йөрү-күрү кирəк. Бигрəк тə шагыйрьгə. Дөрес əйтəсез, хислəрне гел яңартып торсаң, җиңелрəк языла. Шул җитми кайчакта. Сезнең

иҗатта алай куркырлык нәрсә юк. Шигырь ял иткәндә — прозага, проза ял иткәндә — шигырьгә...

Саҗидә! Мин Чаллы тирәсендә әйләнә торгач, «Дәверләр капкасы» дигән бер нәрсә язып ташладым. 21 февральдә радиодан бирергә тиешләр. Тыңлап карагыз әле. Җитмешкә чыккач, шагыйрь ничек сукалый икән? Инде яңадан зур әйбергә тотынмам...

Барыгызга да күп сәлам белән, иҗатыгызда уңышлар теләп,

Сибгат Хәким. 8.1.74.

Шигырьләрне журналга тәкъдим итәм. С. Х.

Сибгат Хәким Саҗидәнең шигырьләрен рус дөньясына чыгару буенча да игелекле эш башкарды. 1973 елда Казанда басылып чыккан «Голубое эхо» исемле шигырьләр, поэмаларның тәрҗемәчесен (Львов шәһәреннән шагыйрь Григорий Глазов) ул табышып бирде, нәшриятта китапның хәрәкәте турында өзлексез кызыксынып торды.

Саҗидәнең поэзиясен күренекле прозаикларыбыз да сөенеп, игътибар белән күзәтеп бардылар (хәтта кайчакта шигырьдәге аерым сүзгә дә игътибар итеп.) Мирсәй Әмир, мәсәлән, «Укытучы» шигырендәге:

Далаларда йөри манаралар —
Нефтьчеләр,
җырлар, чатырлар...»

дигән юллардагы «йөри» сүзенә әһәмият бирә. Икенче бер урында ул сүз «мәшһүр» дип басылган булган икән. Хатында (22 май, 1976 ел) болай ди:

«Далаларда йөри манаралар» — гади юл гына түгел, грандиоз картина булды. «Далаларда мәшһүр манаралар» формасында чагында ул болай ук күзгә ташлана алмый иде. Менә бит уңышлы табылган бер сүз нишләтә шигырьне!.. Өстән генә караганда парадокс булган (ягъни «манара йөримени?»), ләкин фәнни логикага караганда, мең тапкыр хакыйкатькә якын шигъри логикага нигезләнгән әнә шундый образларны яратам. Мин андыйлардан тулы эстетик ләззәт алам. Бернинди склероз да онытрыра алмый аларны...»

Заманында «борыч телле» дигән «яманаты» чыккан, аерата таләпчән Ибраһим ага Гази дә Саҗидәнең иҗатын күздән ычкындырмады. Яңа шигырьләрен үзе сорап алды, әгәр җибәрсә, аңа рәхмәт әйтеп, киңәшләрен биреп хатлар язды:

Саҗидә, сәламәтмесез!

Карт кешене бөтенләй онытып ташламавыгыз өчен рәхмәт. Җибәргән шигырьләрегезне укып чыктым... Аңлый алуым ни дәрәҗәдәдер, мин шигырьләрнең бик күбесенә «әйбәт», «матур», «мәгънәле шигырь» дип язгалап куйдым. «Аңлашылып бетми, сизенеп кенә була» дип язганнарым да бар. «Иртән» дигән шигырьне «строфалар рассыпаются», «җилеме юк» дип язып куйганмын. «Фәридә» поэмасына «артык сузыла» дип резолюция салганмын.

«Бергә чакта каен утын яктык», «Этюд», «Күзләр якты быел», «Чишмә», «Ай кашы», «Уфа минем яшьлегем», «Улыма», аннары тагын берничә өч тәрткеле шигырьгә «матур» дип куйганмын.

Әгәр мине укып чыгып, шундый тамгалар салып чыксалар, мин бик куаныр идем.

Кыскасы, лирикага сездә осталык бар, интимрак лирикага дип тә өстәргә була.

Исәнлек-саулык теләп Ибраһим абыегыз.

...Миннән алып киткән гөлләргә сәлам. 5.V.70.

Саҗидә язучыларның Казан читендәге «Аккош күле» дачаларында булган саен, Хәсән Туфан, Ибраһим Гази, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким кебек өлкән абыйларының шигырь укырга әзер торуларына, аның иҗатына карата гаять игътибарлы булуларына сөенеп, һәркем үзләренең бакча түтәлләрендә ярыша-ярыша чәчәкләр, гөлләр үстерүләренә соклаиып кайта иде. Бер баруында Ибраһим Гази Саҗидәгә төбе белән пионнар бүләк итеп җибәрде. Хатында шул пион гөленә сәлам әйтүе...

Гөлләр турында сүз чыккач, менә бу хатны да искә алмыйча булмый:

Саҗидә, бәйрәм белән сине!

Синең алда кипкән чәчәк! 1944 елда безнең гаскәрләр Кырымга кергәч, мин бу чәчәкне Кара диңгез буеннан өзеп алган идем. Сугыш елларындагы блокнотымны актарганда килеп чыкты. Сиңа җибәрәм, чөнки 8 мартка җанлы чәчәк бирә алмыйм — син бик ерак.

Бакчагыздагы пионнар өшер дип куркасың икән. Өшемәскә тиеш, пион суыктан курыкмый.

Яратып, Ибраһим абыегыз. 2.III.68.

Монысы Әмирхан Еникидән килгән бәйрәм открыткасы:

Сәҗидә!

Мал иясенә охшый дигәндәй, синең үзең кебек тыйнак, сөйкемле, кешелекле шигырьләреңне мин чын күңелдән яратам һәм хөрмәт итәм.

Матур, шат яшә!

Таза, нык бул!

Әмирхан. 8.X.86.

Әмирхан абый Сәҗидәнең «Эс-сәлями, Суфият!» дигән сәфәр хикәятен, әле басылып чыкканчы, беренчеләрдән булып укыды һәм әсәрне камилләштерү буенча эшлекле киңәшләрен биреп хат язды...

Сәҗидәнең архивында Гомәр абый Бәшировтан килгән тирән эчтәлекле берничә хат саклана. Үзенең кайбер моң-зарларын, иҗат кичерешләрен яшермичә әйткәннән соң, бер хатын болай дәвам итә:

Сәҗидә!

Тирән хисләрне матур итеп, ифрат та үтемле һәм оста итеп әйтеп биргән һәйбәт шигырьләрең өчен чын күңелдән бик зур рәхмәт сиңа... Миңа синең шигырьләреңнең тирән эчтәлекле булуы, фикер уятуы, шуның белән бергә, «җырлап торуы» бик ошый. Гомумән, син, Сәҗидә ханым, ярыйсы ук җитди кеше булып чыктың. Байтак вакыт элек хикәяңне яратып укыган идем. Менә әле һәйбәт кенә сәяхәтнамә язып җибәргәнсең. Карале, мин малай чакта китаплардан укып сокланган, гаҗәпләнгән бәдәвиләрнең үзләрен күреп кайткансың бит! Безгә ул бәхет эләкми инде, табиблар ерак сәяхәтләрне рөхсәт итмиләр.

Шигырьләреңнән ялкынлы дәрт, эчке бер куәт бәреп тора, әйтелмәгән уйларың әйтелгәннәреннән дә күбрәк, баерак икәнлеге сизелеп тора. Димәк, бай, киеренке, омтылышлы рухи тормыш белән яшисең. Димәк, синнән яңа китаплар көтәбез!

Тагын бер бик зур рәхмәт, Сәҗидә. Зур уңышлар телим, сәламәтлек, иминлек телим...

Ихтирам белән: Г. Бәширов.

29.VI.1974 ел. Казан.

Хөрмәтле Сәҗидә сеңел!

Бая Союзда Әдипне күреп кайттым да сезгә хат язасым килеп китте. Менә бит язмыш. Кешеләр съездга җыела, Сезгә исә шифаханәдә ятып торырга туры килә икән. Съездга килергә ниятегез бар икән. Анысын ишетеп шатландым. Ләкин ул сәламәтлеккә зарар китерерлек булмаска тиешледер инде.

Күптән түгел генә бик яратып һәм тәмен татып дигәндәй яңа повестегызны укып чыктым. Укучы буларак, әсәрегезне бик ошатып, элеккечә әйткәндә, канәгать хасыйл кылдым, язучы буларак куандым. Менә бит, безнең әдәбиятка тагын бер талантлы проза язучы килеп кушылды. Дөрес, Сезнең элек язган чәчмә әсәрләрегез дә һәйбәт, шома тел белән язылган була иде. Әмма монысы, ягъни «Гөлбадран» тәмам өлгергән оста каләм җимеше булып чыккан дияр идем. Мине хәтта бу әсәрне журналның башыннан ук бирмичә, нигәдер туксан әллә ничәнче битләрдән генә башлаулары да җәберләде.

Иң башта бу әсәрне язучының миһербанлы, йомшак күңелле, кешегә хәерхаһ булган игелекле хатын-кыз икәнлеге сизелеп тора. Моны ирләр яза алмас, аларга шундый, Сезнең әсәрдәге шикелле мәрхәмәтле һәм ягымлы шәфкать туташының йомшак кулы җитмәс иде. Безнең хатын-кызларыбызга хас, кычкырып тормый торган тирән мәхәббәт тә, сабырлык та, нәзакәтлелек тә: бик күп авырлыкларны тешен кысып кына, һич тә чәбәләнмичә күтәрергә сәләтле булган чыдам рух ныклыгы да бар монда. Әнә Бибиса шундый.

Үзегез беләсез, прозага сурәт кирәк, кешенең холкы-фигыле кирәк. Сез бик

тә сөйкемле табиблар сурәтен иҗат итә алгансыз. Әнә Аллаяров шундый, Гыйлфанның да үз йөзе бар, Фәрханә язмышы да истә кала торган итеп язылган. Күп әсәрләрдә алар турында йөзәр битләп язсалар да истә калмый. Сез исә кечкенә генә мәйданда да аларны күренерлек, яратып калырлык итеп бирә алгансыз. Әсәрегезнең бу сыйфаты миңа аеруча ошады. Чөнки медицина хадимнәре халыкка, педагоглар кебек үк, бик якын торалар. аларның халыкка күрсәткән хезмәтләрен бик нечкәләп өйрәнгәнсез. Бу сыйфат та прозада бик кирәкле.

Проза осталарында гына очрый торган нечкәлекләр байтак кулланганcыз, алар әсәрегезнең кыйммәтен бигрәк тә күтәргән. Кайбер шундый урыннарны мин сокланып укыдым. Мәсәлән, «...бүтәннәр кулъяулыкларын күз тирәсенә тидергәләгәндә ул үзенең сөйкемле борынын җебетмәскә тырышып утырды». Шәп бу! Оста да, «йомырысы» да бар. Яисә менә бу урын: «...Хәер, икәүдән-икәү генә артык озак юанмаслар, икесен ике төбәктә юл чатына чыгып баскан язмышлар көтә...» Калганын үзең чамала, укучы иптәш.

Кыскасы, Сез бик һәйбәт шигъри әсәр язгансыз, безнең прозаны тагын да баеткансыз. Бик рәхмәт Сезгә. Шигырь белән бергә киләчәктә тагын шундый һәйбәт проза әсәрләре язарга насыйп булсын. Мин Сезгә озын гомер, сәламәтлек, зур иҗат уңышлары теләп калам.

Зур ихтирам белән: Г. Бәширов. 22 май, 1979 ел. Казан.

...1966 елда Әлмәт язучылары Уфада һәм Башкортстанның ике районында әдәбият атналыгында булдылар. Гаять матур узган онытылмас очрашуларның азагында Башкортстанның халык шагыйре, хәзер Социалистик Хезмәт Герое Мостай Кәрим безне өенә кунакка чакырып алды һәм һәрберебезгә сайланма әсәрләренең ике томлыгын бүләк итеп чыкты. Моңа иң нык куанганы Саҗидә булгандыр. Чөнки Мостай абыйның үзенә дә, иҗатына да ихтирамы бик зур иде аның. Үзе дә бурычлы булып калмаска тырышты, чыккан бер китабын Уфага салып җибәрә торган булды. Мостай Кәрим аларның берсенә дә игътибарсыз калмады. Менә арадан ике хат (беренчесе кыскартып бирелә):

... Саҗидә, бик зур рәхмәт!

Китабың һәйбәт, Саҗидә — дәртле дә, сагышлы да.

Елыйсы килгән чакларда
Җырласаң җиңел була.

Китапның җырлары елыйсы килгәндә җырланган төсле. Һәм бу йөрәк тетрәткеч көч! Моннан соң да шулай эчендәге тыщында булсын, шул чакта гына поэзиянең үзе була ала...

Хушыгыз.

Сезне сагынып Мостай. 23.X. 66.

Җырлы, моңлы, сагышлы Саҗидә!

Көн артыннан көн, ай артыннан ай үтә торды. «Кызыл каурыйлар» һаман минем өстәлем өстендә ята бирде. Көн дә булмаса да, еш кына укып, битләрен ача тордым. Менә бүген ул китап киштәсенә күчә, чөнки сиңа рәхмәт һәм соклану тулы хатымны язып утырам. Бәлки ул хатны язмый торырга иде, китапны күз алдымнан җибәрмәскә иде?!

Бик шатландым синең өчен, Саҗидә. Күңелне җилкендерә торган шигырьләр дә, уйландыра-моңландыра торганнары да бар. Бик әйбәтләре күп, тоныграклары очраштыра, ләкин бушка әйтелгән сүз юк, һәр сүзнең төбендә йөрәк, акыл ята.

Котлыйм! Кайсы чак бик матур сүзләр дә поэзиядә бушка әйтелә. Синең һәр юлыңда тойгы биографияң (эмоциональная биография), атылган бөркет канатыннан коелган кызыл каурыйлар шикелле, көннәрең, сәгатьләрең, минутларың ята.

Кулларыңны кысам, рәхмәт! Сәлам үзеңә, сине чолгап алган дөньяңа сәлам.

Мостай Кәрим. 3.X.76.

*P.S.* Шигырь юлын ноктадан соң гына зур хәрефтән яза торган модага күчкәнсең икән. Һәйбәт шигырьнең һәр юлы гына түгел, һәр сүзен дә баш хәрефтән язу тиешле.

Саҗидә Сөләйманова Үзбәкстанның халык шагыйрәсе, Неру премиясе лауреаты, хәзер Социалистик Хезмәт Герое Зөлфия белән Казанда, «Азат хатын» журналының 40 еллык юбилее көн-

нәрендә очрашты. Аларның шуннан башланган иҗади дуслыгы Саҗидәнең соңгы көннәренә кадәр дәвам итте. Үзара автографлар белән китаплар алышып, хатлашып тордылар. Зөлфия редакцияләгән үзбәк хатын-кызлары журналы «Саодат»та С. Сөләйманова шигырьләре тәрҗемә итеп бирелде... Хәзер хатларга сүз бирик:

Хөрмәтле Саҗидә ханым!

Мин сездән кадерле бүләк алдым — бу «Фал китабы». Бик шатландым, сезгә зур рәхмәт. Исеме матур!

Сезнең шигырьләрегез оригинал, һичберкем шигырьләренә охшамый. Аларда зур дөнья авазы. Табигать һәм җәмгыятьтәге һәммә вакыйгаларга, күренешләргә сизгер, үз күзе белән карап, үз йөрәге белән тойган нәфис, гаять тирән чынбарлык бар аларда.

Мин сезнең шигырьләрегезне үзәк матбугатта очратсам, шатланып укыйм. Китабыгыздагы берничә шигырьне «Саодат» журналында бастырырбыз. Безнең укучыларыбыз сезнең иҗатыгыз белән электән дә таныш.

Саҗидә ханым, безгә кунак булып килегез. Йөрешик. Без бит бик якын тугандашлар!

Сау булыгыз. Иҗатыгызда зур уңышлар теләп,

дустыгыз Зөлфия. 2.VIII.74.

Кадерле, сөйкемле Саҗидә ханым! Хәерле көн! Сезнең китабыгызны алу һәм сезнең нечкә хисле лирик кенә түгел, ә әйбәт прозаик икәнлегегезне дә белү минем өчен бик күңелле булды.

Юбилеегыз уңае белән, шагыйрь буларак, «Саодат» журналы укучыларына сезне янә тәкъдим итәргә җыенабыз. Гаҗәеп матур шигырьләрегез өчен зур рәхмәт. Чираттагы санда күренекле яхшы шагыйребез Әсгать Мохтар тәрҗемәсендә зур гына шигырьләр бәйләмегез басылачак.

Тантанагыз көннәрендә безнең «Саодат» та сезгә бәләкәй генә булса да шатлык китерер һәм безнең олы мәхәббәтебезне алып барыр дип ышанам.

Сәламәт булыгыз, яңа иҗат уңышлары телим сезгә.

Сезнең Зөлфиягез. 11.VI.76.

... Саҗидәнең каты авырый башлаганын ишеткәч, Зөлфия ханым бик нык борчылып, аны төрлечә юатып хатлар язды, сирәк очрый торган дарулар җибәреп торды.

«Бүген, авиабандероль белән, тормыш эликсиры (эликсир жизни — Ә. М.) салдым сезгә, — дип телеграмма сукты берсендә Зөлфия, — ул сезгә яңа матур шигырьләр тудырырга булышыр дип өметләнәм...»

Күренекле башкорт шагыйре, РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты Наҗар Нәҗми 1980 елның февралендә язган бер хатында болай дигән иде:

... Саҗидә!

Татар шагыйрьләре хакында «Дим буеннан ачык хатлар» дигән мәкалә-хатлар язган идем. Аларны үзебездә китапка кертәчәкмен. Менә шунда инде — хатта минем сиңа булган мәхәббәтем ачыла.

Бигрәк мужественный кеше син, Саҗидә! Иҗатта да, тормышта да, хатын-кыз мужественный булмаса, шагыйрә булалмый. Синең хакта язылган хатның төп фикерләреннән берсе — шул...

Наҗар Нәҗминең бу хатлары 1983 елда Уфада башкорт телендә, «Кем уйлаган» исемле китабында дөнья күрде. Олы поэзия турында тирән кичереп, дулкынланып, масштаблы итеп язылган бу әдәби тәнкыйть мәкаләләре җыентыгындагы «Әзләнү газаплары» дип аталган, Саҗидә Сөләйманова иҗатына багышланган хат 15 биттән тора. Зур булмаган бу язмада Наҗар Нәҗми хатыннан өзекләр бирү белән генә чикләнергә туры килә:

...Саҗидә!

Хатымның шушы урынына җиткәч, җан тетрәткеч хәбәр килде... Бу хәбәргә ышансаң да, ышанмасаң да чараң юк — ул хакыйкать иде: син вафат булдың... Башта ни эшләргә дә белмәдем. Үлгәннәр турында, гадәттә, истәлек язучаннар, миңа да шул юлга басаргамы? Юк, хатымны дәвам итәм, чөнки ул синең гомерең турында, иҗатың турында, димәк, син тереләрдән тере. Чын шагыйрьләр үлмиләр, аларның шигырьләре үзләренең тудыручыларын үлемсез итәләр.

Бу хатны башлаган чагымда, синең бик каты авыру икәнеңне, аннан соң бик авыр операция кичергәнеңне белдем. Операциядән соң бик озак реанимациядә ятканыңны да ишеттем. Шушы газаплардан соң да миңа дигән шигырьләр яздың — болар үзе генә дә искиткеч батырлык иде.

Батырлык дигәч, уйларым әлеге шул син тере чакта башлаган хат юлларына килеп бәйләнә. Ул хат «Ир-егеткә» дигән шигырьдә өзелеп калган иде. Бу шигырь, минемчә, ир-ат турында хатын-кыз гына, Саҗидә Сөләйманова гына яза алырлык шигырь. Анда хатын-кыз йөрәгенең нечкәлеге дә, өстә яткан тойгылар тирәнлеге дә, әрнүле мактау да, борчылулар аша горурлану да — һәммәсе дә бар:

... Вакланмаучы, акланмаучы җаннар,
Саклау, кадерләүгә сез лаек.
Никадәрле сездә ирлек булса,
Шул кадәрле башсыз малайлык.

Абайламый агу биргән дә сез,
Саранланмый ширбәт эчергән.
Шуңа да бит, без, хатыннар сезне
Мең кат каргап, мең кат кичергән.

... үлемнәрдән өстен ир-егетләр,
Сезнең белән көчле Ватаным.
Үзеннән дә алда киләчәккә
Яхшы аты бара атаның.

Белмим, тойгыларга, соклануларга бирелү аркасында, минем дә башсыз малайлыкка бирелүем бик мөмкин. Чөнки без дә, ир-егетләр, хатын-кыз алдында таш йөрәкле түгелбез, тиз эрибез. Әйбәт шигырь белән очрашудан да зур бәхет юктыр шикелле. Ә ул бәхет синең китабыңның битеннән битенә күчеп йөри.

... Хәсән Туфан миңа бервакыт: «Шигырьдә боль булырга тиеш, — диде... — Боль! Высокая боль!» — дип өстәп куйды. Безнең телдә аны күңел сызлануы, күңел әрнүе дип аңлатырга мөмкиндер. Шундый әрнүләрне мин Сибгат Хәкимдә күрәм... Шундый сызланулар, әрнүләр синдә, Мостай Кәримдәге шикелле, тирән яшеренгән.

... Саҗидә! Синең китабыңны укыгач, әлеге шул әрнүләр (высокая боль) турында уйлануларым юкка түгел. Күренүенчә, бу сыйфат синең һәрбер шигырендә дип әйтерлек чагылмый (киресенчә, синдә соклану күбрәк), аның шулай булуы табигый дә, югарыда әйткәнемчә, алар бик өстә ятмыйлар. Бу әрнү — мин аны якты әрнү дип тә әйтер идем — синең поэмаларыңда ярылып ята. Поэмаларыңда дигәндә «Җырланмаган җырлар»ны, «Җир-су»ны күз алдымда тотам. Фикерләрне исбатлар өчен мисаллар китерү кирәк, ләкин ул авыр хәл, чөнки поэмаларыңны аз-мазлап бөтенләе белән күчерергә туры килер иде.

Саҗидә! Хатымны син исән чагында язылган өлешендә мужественность турында сүз алып барган идем. Иҗаттагы бу сыйфат нинди җенестән икәнлеккә генә кайтып калмый. Бу сыйфат — шигырьдәге тослыгына (үткенлек. Ә. М.), аның аҗарлы, кыю, тирән булуына кайтып кала.

Алтын, диләр,
бик кирәгем чыкса, куштаннар.
Алтын булсам, бер сатылыр идем, —
Мин — Кеше.
Ярага — тоз, арага ут сала
дошманнар,
Корыч булсам да, бер эрер идем, —
Мин — Кеше.

Синең бөтен иҗатың дип әйтерлек менә шундый «ачкычка» язылган шигырьләрдән тора. Бу инде нииндидер шигъри челтәр бәйләү (рукоделие) түгел.

... Үлгәннәргә «Тыныч йокы!» — диләр. Чын шагыйрь мондый йокыдан мәхрүм. Әгәр дә сиңа, вафат булган кешегә, хат язып утырам икән, димәк, сиңа тынычлык юк дигән сүз. Чөнки чын шагыйрьгә үлгәч тә тынычлык юк. Гомергә шулай булсын.

...Башта әйткәнемчә, үзе исән чагында Саҗидәгә бик күп хатлар килде. Җавапсыз калдырмаска тырышты ул аларны. Беләсе иде аның ни язганнарын. Киткән хатлар, гадәттә, кире әйләнеп кайтмаса да, әдәбият хакына, моны эшләргә мөмкин булыр иде. Сүз биредә бер Саҗидә Сөләйманова турында гына да бармый. Укучыларында азмы язучыларның хатлары саклана! Очраштырасы иде шул илче хатларны, сөйләштерәсе иде кара-каршы матбугат битләрендә!

II

Болары — хатын-кызлардан. Шигырь, хәтта әкият белән башланганнары да бар. Мөлдерәмә хисләр. Аналарга, ир хатыннарына хас сабырлык һәм горурлык тойгысы да, моң-зарларын кушып, һәр күренешкә бераемтекләп бәя бирә белү осталыгы да... барысы да бар аларда. Мостай Кәрим әйтмешли, буш сүз юк ләкин. Тыгыз эш һәм тормыш мәшәкатьләре арасында язылган хатлар.

Бу язмада шуларның берничәсенә: РСФСРның атказанган артисткасы Евгения Лисецкая, Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая, язучылар Ләбибә Ихсанова, Кояш Тимбикова, Фәүзия Рәхимкулова, Мөкәрәмә Садыйкова һәм арада иң яшь автор — «КамАЗ» төзүчесе Сәлимә Шәрипова хатларына мөрәҗәгать итәбез. Соңгысыннан башлыйк әле:

... Бик зур рәхмәт Сезгә, Саҗидә апа!

Безнең шигырьләрне мактап телгә алуыгыз өчен генә түгел. Безнең күңелдә йөргән тойгыларны мәкаләгездә әйтеп бирүегез өчен рәхмәт. Ир-ат шагыйрьләрнең өзлексез бер-берен мактаган язмалары туйдырып бетергән иде инде. (Ә үзләре — хатын-кыз хезмәтеннән башка бер кашык аш та кабалмый торган «мескен җаннар»). Дөньяның күзгә күренмәгән бөтен мәшәкатьләре безнең җилкәдә. Семьяга без бөтен килеш кирәк. Хезмәткә дә, язарга теләгең бар икән, ансына да. Ярый әле безнең эше гадиләрне күрә белүче Сез бар, Саҗидә апа.

«Гөлбадран» повесте өчен дә рәхмәт, Саҗидә апа! Гади телдә, безнеңчә язылган. Авырып, больницада ятуларыгызның җимешләредер инде. Кичергән кыенлыкларыгыз да кешегә файда булып кайта. Йөрәгең, тәнең белән кичергәннәр генә кеше күңеленә барып җитә ала шул. Бөтенесе без белгән тормыштагыча.

... Шигырьләремә карата фикерләрегез өчен дә рәхмәт, Саҗидә апа. Җибәргән икесен «Азат хатын»да бассалар, бик әйбәт булыр әле.

Сезгә кайнар сәлам белән —

Сәлимә. Чаллы. 25.II.79.

Яклаучың итеп күргән иң якын кешеңә генә шулай язарга мөмкин. Ә ир-атларны яратып кына «мескен җаннар» дип тәнкыйтьләгән икән, ансына үпкәләмәбез.

Чаллыдагы «Ләйсән» әдәби берләшмәсе членнары Саҗидә Сөләйманова белән актив бәйләнештә яшәделәр. Алар, үзләрендә язучылар оешмасы ачылганчы ук, Саҗидәне шеф-консультантлары итеп таныдылар. Һәр ике якның ихлас теләкләре буенча эшләнде бу. Чаллы кызлары янына барам әле дип, Саҗидә берара юлга чыгып китәр иде. Әдәбиятчы егетләр шигырь кичәсе оештырып тора. Ә кичәгә кадәр әдәбият берләшмәсе утырышын үткәрәләр, кулъязмалар укыйлар, бәхәсләшәләр...

Редколлегия члены буларак, Саҗидә Сөләйманова «Азат хатын» редакциясе йөген дә җигелеп тартты. Эшнең нидән гыйбарәт икәнен белү өчен, шул чагында журналда бүлек редакторы булган язучы Кояш Тимбикованың бер хатына мөрәҗәгать итү дә җитә:

Саҗидә!

Борынгы әкияттә сөйләнгәнчә, «Бер көтү күгәрченнәр» җибәрәм. Хат кисәге салынган пакетны үзең белеп сайлап ал! Хәтереңдәме, әкияттәге бай, алдан килешкәнчә, тапкыр егеткә бердәнбер кызын бирергә тиеш булган, ди. Тагын бер кат сынау өчен, кызын күгәрченгә әверелдереп, кырык

кыз — күгәрчен белән буташтырган да егеткә әйткән: — Арадан сайлап ал! — дигән.
Мин сезнең тарафка ундүрт пакет җибәрдем. Берсенең эчендә — хат. Арадан сайлап ал! Алуың турында хәбәр ит, зинһар, яме?!
Ихтирам белән — Кояш. 31 август, 1973 ел.

Ә пакетларда — илебезнең төрле тарафларыннан килгән тезем-тезем шигырьләр. Андый пакетларны озак яткырмый иде Саҗидә. Кулъязма читенә үз билгеләрен куя-куя, бер-ике кичтә укып та чыга. Иң яхшы дигәннәре, әлбәттә, журналга тәкъдим ителә, бер өлеше «Шигырь күзәтү»дә файдаланыла. Ә бөтенләй булмастайлары белән бик вакланып та тормый. Чөнки андый авторны шигырь язарга кочәндерүдән әдәбиятыбызга бернинди файда тимәячәк.

Кояш Тимбикова Әлмәт тарафларына «күгәрченнәр очыру» белән генә чикләнмәде, әлбәттә. Ул, Саҗидәнең иҗатына үз мөнәсәбәтен белдереп, менә шундый хатлар да язган икән:

Саҗидә-күбәләккәем!
Әллә ничек, хат язарга тотына алмый йөри идем. Шигырь китабыңны алгач, бөтен эшне ташладым. Яңа җиңүең котлы булсын! Бик һәйбәт чыккан. Өсте килгән, асты да кеймәгән һәйбәт бәлеш кебек. Бик шатландым. Беренче тәэсирем шул — мөгаен, матбугат аша да әйтерлек сүзләрем чыгар. Дөрес, сиңа аның әллә ни кызыгы булмастыр. Абруе саллы кешеләр, аксакаллар тарафыннан язылган мәкаләләрне күрәсең киләдер. Миңа калса, сине, синең шигъриятне минем кебек тирәннән, матди дәрәҗәгә китереп тоючы, аңлаучы юк кебек. Син язганнар, бөек Тукай әйтмешли, «бигүк гали, бигүк нечкә»ләр. Аларны белү өчен сине белергә, сине тоярга кирәк. Мин синең язганнарыңда иҗатың белән шәхеснең тәңгәллеген тоям. Бу сыйфат, кызганычка каршы, барлык шагыйрьләргә дә хас түгел...
Хуш. Яратучы — Кояш. Казан, 25.I.80.

... Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис белән безнең дуслыгыбыз Бөек Ватан сугышыннан соң, Казанга кайткач башланды. Өйләнешеп алгач, бу дуслык хатыннарыбызга күчте. Әйтергә кирәк, ул тулылана, яңара һәм активлаша төште.

Араларны суытмыйча, Ләбибә Ихсанова белән Саҗидә арасында озак еллар буе канатлы хатлар йөреп торды:

Саҗидә!
Сездән кайткач та хат язармын дип уйлаган идем, мин җыенганчы, үзеңнән килеп төште. Ә юбилееың бик әйбәт узды. Биредә бик сорашалар. Без ничек булганын бәйнә-бәйнә сөйлибез...
... Һич арттыру түгел, ир-егетләрнең әйбәтләре белән янәшә торып иҗат итәсең. Тагын да шулай яшә, яз, тагын да күп китаплар чыгар. Тормышың тыныч, матур, таянычың — яныңда. Дөньяның ыгы-зыгысына кызыкма, бар да үтә торган нәрсәләр. Ә китап кала, әсәрләр кала. Сәламәтлегеңне сакла. Сездә утырган беренче көнне сокланып туя алмадым үзеңә. Өй обстановкасында бигрәк тә сөйкемле икәнсең бит син. Парлап өстәл янында утырасыз, һич күземне аласым килми. Инде, ходаем, шулай яшәгез.
Икегезгә дә зур рәхмәтләр белән — Ләбибә. 20.X.76.

Саҗидә Сөләйманова чыгышы белән Башкортстаннан иде («Чыгышым — Агыйделдән!»). Сугыштан соң Башкорт педагогия институтын тәмамлады. Студент еллары Уфа белән бәйле. Кыскасы, Казанны зурлап, Агыйдел буйларын сагынып яшәде ул. Башкорт язучылары, бигрәк тә хатын-кыз язучылар белән дуслыгы зур иде. Юл төшкәндә аралашып, ә күбрәк хатлашып торды алар белән. Минем алдымда шул хатларның берничәсе.

Саумысыз, Саҗидә апа!
Хатыгызны алып укыдым да: «Их, ул да Уфада яшәсә икән, никадәр иркенләп сөйләшер идек, бәхәсләшер һәм бер-беребезне баетыр идек», — дип уфтанып куйдым... Әле бер генә дә менә шундый нигезле фикер ишеткәнем юк иде повестем турында. Ләбибә апа да, Сез дә нинди тирән анализ ясап яздыгыз. Рәхмәт, Саҗидә апа!
Әлбәттә, әсәрне яхшырту ягыннан караганда, Сезнең хат әле дә соң түгел. Чөнки повесть 1975 ел планында китап булып чыгачак бит. Ә менә булдыра алырмынмы — хикмәт шунда гына. Тотып алган җитешсезлекләр бик дөрес күрсәтелгән югыйсә.

Мин Сезнең укырыгызга өмет тә итмәгән идем, күзләрегезнең авыртуы исемдә. Әгәр мөмкин булса, нәшриятка Сезнең хатны рецензия итеп тапшырыр идем дә, аның буенча эшләр идем. Безнең нәширләр тагын нинди таләп куярлар...

Да-а, «Современник»ка биргән шул кулъязмама бер уңай рецензия бар инде. Редактор: «Җиң сызганып эшләргә әзерләнегез!» — диде. Сезнең киңәшләрнең ул чакта да кирәк булуы ихтимал.

... Үз хәл-әхвәлләрегезне язмагансыз. Ә минем Сезнең белән иҗади мәсьәләләр буенча гына түгел, тормыш-көнкүреш, кием-салымнар хакында да сөйләшәсем килә. Әйткәндәй, нәрсәләр язып ятасыз үзегез? «Казан утлары»нда Әдип абыйның «Яшьлек утравы»н укыдым. Японнарны тәнәткәнче тукмап җибәрү хакындагы әсәр бик әһәмиятле. Югыйсә, бу тема Германияне җиңү фонында бөтенләй югалып, онытылып бара бит.

... Ярый, хәзергә хушыгыз. Сәлам белән,

Сезгә иң яхшы теләкләрдә калучы — Мөкәрәмә. 6.II. 74 ел».

Кем яратмый мактаганны. Мактау сүзенә Саҗидә дә эреп китә иде. Әмма масаюны белмәде. Башкорт язучысы Мөкәрәмә Садыйкованың икенче бер хатында болай дип язган иде:

... Фотоларыгызга караганда, Сез элеккегә караганда да сылурак күренәсез миңа. Күрәсең, шигырьләрегезнең матурлыгы йөзегезгә нур өсти торгандыр. Ни әйтсәң дә, Сез гаҗәп актив эшлисез, апа! Мин шигырьләрегезне укыйм да: «И, хода, моның иҗат капчыгы чишелде, күрәсең!» — дип куям сокланып. Кыскасы, молодец кеше Сез!

Бу юлларны укыгач, Саҗидәнең: «Бик үк молодец түгел шул, язасы иде әле, күбрәк язып каласы иде», — дип борчылу белдергәне хәтердә калган. Мактауга юлыкса — канатланып, тәнкыйтькә очраса — усалланып иҗат итте Саҗидә. Аларның берсен дә кире какмады.

Танылган балалар язучысы шагыйрә Фәүзия Рәхимкулова хатыннан:

Саумысыз, Саҗидә сеңлем!

«Аланнарда балан»ың өчен бик нык куандым. Әйтеп бетергесез олы рәхмәт! Шигырьләрең йөрәк төпкеленә барып җитте. Фикер тирәнлеге, тасвирлау һәм теле — гомумән, һәр яклап та бу синең яңа үргә очышың, яңа олы җиңүең! Мине син, Саҗидә, тагы да бер тапкыр таң калдырдың, ярсыттың, җилкендердең...

Безнең мөселман хатынының шул тиклем югарылыкка күтәрелүе, шул тиклем дөньяны аңлавы! Юк, мин гади сүзләр белән генә аңлата алмыйм үземнең дулкынлануымны.

Гайния белән Кәтибә Киньябулатовага сәламнәреңне тапшырдым. Мөкәрәмә үзенә багышлап язган шигыреңне укып куанды һәм кайнар сәлам, рәхмәтен тапшырырга кушты.

«Кызыл таң» синең бер шәлкем шәгырьләреңне бирергә әзерләнә. «Башкортстан кызы»нда шигырьләреңне май аенда бирәләр икән. Мин анда «Аланнарда балан» җыентыгы хакында да сүз әйтермен әле.

...Сине күрер өчен генә Әлмәткә барырга дип хыялланам.

«Казан утлары»ның 12 санын алгач, мин тагын да куандым, горурландым («К.У.» С. Сөләйманова, «Сабыр канатлары» исемле шигырьләр циклы. 1979 ел. Ә. М.) Журналны синең башлап җибәрүең гаҗәп әйбәт бит! Молодец, сеңлем, бөтенесе өчен дә!

Ак көннәр, хәерле сәгатьләр теләп — Фәүзия апаең.

Фәүзия Рәхимкулова хатында башкорт язучысы Мөкәрәмә Садыйковага багышланган шигырь турында сүз булды. Бу уңайдан әйтеп үтик: Саҗидәнең багышлау шигырьләре шактый зур урын ала иҗатында. Китапларына кергәннәрдән без Г. Тукай, М. Җәлил, Н. Исәнбәт, Х. Туфан, С. Хәким, А. Ахматова, М. Цветаева, Г. Афзал, Л. Ихсанова, Р. Харис, Р. Гатауллин, Ф. Гыйззәтуллина һәм башка язучыларга, шагыйрьләргә, Илһам Шакиров, Венера Шәрипова кебек мәшһүр җырчыларга, экономия фәннәре докторы, Әлмәттәге нефтьчеләр институты профессоры В. Козыревка, Әлмәт больницасының баш хирургы атказанган врач В. Поляковка, атаклы бораулау остасы Дамир Нурисламовка багышланган шигырьләрен беләбез. Алар һәркайсы зур гомумиләштерүгә, фикер тирәнлегенә ия. Моны ачыклау өчен бер строфаны китереп үтү дә җитә:

Ир кайгысын баса Ил шатлыгы,
Биләүләргә бирмә йөрәгең!
Изүеңне егетләрчә ачып,
Дөньябызны ваклыклардан арчып,
Арабызда, Туфан, йөр әле!
(«Хәсән Туфанга» шигыреннән. 1970.)

... Сәҗидә мәктәп елларында сәхнәне ярата иде. Кечә саен биетеләр аны, шигырь сөйләттеләр. Үзешчәннәр куйган спектакльләрдә ул төп рольләрне башкарды. Аның шул мавыгулары соңыннан сәхнә осталарына карата зур ихтирам чыганагына әйләнде. Әдәбият мәйданына килгәч, Сәҗидә Сөләйманова бик теләп, Әлмәт татар дәүләт драма театры артистларының иҗат портретларын язды, шәһәр һәм республика газеталарына спектакль премьералары турында анализлап язылган рецензияләр биреп барды. Татарстанның халык артисткасы Галия ханым Кайбицкая моны белеп, күреп барган, әлбәттә. Иң авыр кайгы кичергән көннәрендә, ул, үзенең изге үтенечен белдереп, Сәҗидәгә озын хат язды. Анда мондый юллар бар:



Хөрмәтле Сәҗидә ханым!

Татарстанның халык артисты, күренекле сәнгать остасы музыкант Ильяс Әүхәдиевнең кинәт үлеп китүе республикабыз җәмәгатьчелеге өчен авыр югалту булды. Әлмәттә 1965 елда ул оештырган районара симфоник оркестр җитәкчесез калды. Оркестр яшәвен дәвам итәргә тиеш дип саныйм.

Нефтьчеләрнең Техника йортында симфоник оркестрның беренче чыгышы әле дә күз алдымда: сәхнәдә һәммәсе яшь музыкантлар иде. Бөтен дәртләрен биреп, музыканың нечкәлеген аңлап, тирән хисләргә чумган хәлдә, онтылып, югалып уйнадылар. Залда утырган 600 кеше һәр башкарылган номер өчен гөрләтеп кул чапты. Дирижерлык иткән ирем — Ильяс Ваккасовичны кат-кат алкышладылар. Симфоник оркестрның уңышлары турында соңыннан республика һәм үзәк газеталарда язып чыктылар. Хәзер оркестрны Әлмәт музыка училищесы карамагына тапшыру турында сүз йөри. Училищеның, әлбәттә, моңа көче җитмәячәк.

...Сәҗидә бәгърем!

Балам күк күреп язам мин Сезгә бу хатны. Әлмәт шәһәрендә оешкан районара симфоник оркестр җиңел тумады. Ильяс Әүхәдиев гомеренең соңгы көннәрен шуңа багышлады. Ташланмасын, яшәп барсын иде ул оркестр. Бу бит безнең культурабыз тарихында зур вакыйга. Мин моны үземнең илле еллык сәхнә тәҗрибәмнән чыгып язам. Сөйләшегез әле, зинһар, шәһәр оешмалары белән, нефтьчеләр өлкә комитеты профсоюзы белән. Сез, язучы һәм культура фронтының алдынгы вәкиле буларак, моны эшли аласыз. Сезгә бар күңелем белән ышанам.

Уңышлар теләп, зур ихтирам белән — Галия Кайбицкая.

21.III.68. ел.

Сәҗидә бу зур үтенечне игътибарсыз калдырмады, аңа карата кайнар теләктәшлек белдерде. Ул партиянең Әлмәт шәһәр комитеты һәм нефтьчеләр профсоюзының өлкә комитеты җитәкчеләре белән элемтәгә керде, симфоник оркестрның язмышы турында борчылып, шәһәр активы җыелышында чыгыш ясады. Кыскасы, шактый вакытын шуңа багышлады. Нәтиҗәләре турында Галия ханым Кайбицкаяга хат аша хәбәр итте. Күренекле артисткадан шундый җавап хаты килде:

Хөрмәтле Сәҗидә ханым!

Сезгә биек таулар кадәр сәлам җибәрәм, чын кешелек йөзен күрсәтүегез өчен рәхмәт белдерәм.

Хатыгызны укыганда — «миңа хәтерегез калгандыр, озак җавап язмый тордым» дигән сүзләрегездән үк йөрәгемә җылылык бәрелде. Билгеле, минем мөрәҗәгать итеп язган хатым тиз генә җавап бирерлек түгел иде. Шулай да сездән җавап хаты алырга теләгем бик зур иде. Рәхмәт Сезгә! Бар үтенечемә тулы һәм эшлекле җавап язуыгыз — миңа зур ярдәм юлын ачты.

Тагын бер мәртәбә рәхмәт Сезгә, Сәҗидә бәгърем!

Сезгә зур уңышлар теләп, Әлмәттәге язучы дусларыбызга ихтирам сәламе белән — Галия Кайбицкая. 24/V-68 ел.

...Җан тетрәткеч менә бу хат Сәҗидә Сөләймановага исемләп язылмаган. Үзе юк иде инде. Шулай да мин аны «Сәҗидәгә хат-

лар» дигән папкада саклыйм. Чөнки ул аңа багышланган. Авторы — РСФСРның атказанган артисткасы Евгения Владимировна Лисецкая. Укучы аны Сәҗидәгә адресланган хат дип кабул итсен иде:

Хөрмәтле Әдип Маликович!

Һич көтмәгәндә мин Сездән гаҗәеп гүзәл бүләк — Сәҗидәнең шигырь китабын алдым. Миңа җан керде. Рәхмәт! Әйе, шулай. Коточкыч газаплы көннәр кичергәндә, язмыш миңа «Красные перья»не җибәрде...

Мин быел бердәнбер улымны югалттым. Бар булган тормышым, бәхетем, киләчәгем — Ул иде. Бу фаҗигале хәл Ленинградта булды. Улымны туксан яшьлек әтием белән күрештерергә дип барган идем. Башына кан сауды. Бер ай эчендә малаем юкка чыкты. Оныгын югалту кайгысыннан әтием йөрәге ярылып үлде. Соңыннан үзем белән ни булганын хәтерләмим. Аңымны җуйганмын. Хәсрәт утында янар өчендер, исән калдым. Шундый авыр чакларда ярый әле дусларым, иптәшләрем ярдәмгә килде. Эшләргә һәм яшәргә, әйе, яшәргә мәҗбүр иттеләр...

Нәкъ шул вакытларда радиодан Сәҗидә Сөләйманованың шигырьләрен укуымны сорадылар. Укыдым һәм алардан аерыла алмадым. Тапшыруны Сез тыңлагансыз икән. Тиз арада Сездән Сәҗидәнең «Красные перья» исемле русча шигырь китабы килеп төште. Аның буенча шунда ук радиокомпозиция төзергә тотындым.

... Сәҗидә Сөләйманова шигырьләре миңа яшәргә көч бирде, киләчәккә өмет уятты. Тирән кайгы базыннан чыгу өчен алар миңа таяныч булдылар. Аңымны, акылымны җуймас өчен, мин ул шигырьләрне күңелдән ятлап сөйләп йөрдем. Бәлки моңа кемнәрдер ышанмаслар да. Әмма бу шулай. Мине Сәҗидә коткарды. Мин хәзер кадерле улым һәм әтием торып калган шәһәргә күчәм. Бөтенләйгә Казан белән саубуллашам. Хәтеремне җуймас өчен барам анда. Алар турындагы газиз истәлекләр югалмаска тиеш. Аларны киләчәк өчен миннән башка кем саклар! Язарга тиешмен. Мине моңа Сәҗидә өйрәтте. Әйе, кәгазь битенә төшкән истәлекләр кала.

Сәҗидәнең шигырьләрен үзем белән алам. Аның юллары арасында гаҗәеп олы җаны, кешелекле йөрәге тибүен тоям. Ул, тере сыман, минем белән йөрәк серләрен уртаклаша. Шундый кадерле бүләк өчен тагын бер тапкыр рәхмәт Сезгә! Сәҗидәнең поэзиясе белән беренче мәртәбә таныштырган Эльза Гобәйдуллинага һәм радиотапшырулар режиссеры Әминәгә рәхмәт! Алар әле аның иҗатына торып-торып мөрәҗәгать итәрләр. Алар Сәҗидәне һәм аның поэзиясен яраталар.

Ихлас күңелдән, тирән ихтирам белән —

Ев. Лисецкая. 3/XII-80.

Күренекле артистка үзе төзегән һәм башкарган радиокомпозиция язмасы Татарстан радио фондында саклана. Озак еллар буена Качалов исемендәге Рус дәүләт Зур драма театрында эшләп, Казан тамашачыларының ихтирамын казанган Евгения Лисецкая хәзер Ленинградта — сәхнә ветераннары йортында яши. Хатлашып торабыз. Соңгы хатыннан юллар:

Сәҗидә Сөләйманованың шигырь китабын ачкан саен яңа фикерләр табам. Гаҗәеп олы җанлы бу хатын турында, шагыйрә һәм чын Кеше турында күңелемдә иң якты хатирә саклана. Ул барысын да-барысын да аңлый белә торган шагыйрә иде...

Хөрмәт белән —

Евгения Лисецкая.

Шушы язмага кергән хатларны раслап, миңа кул куярга гына кала инде, хөрмәтле укучылар.

**Әдип МАЛИКОВ.**

**РЕДАКЦИЯДӘН:** *Талантлы шагыйребез Сәҗидә Сөләйманованың үз чиратында язучыларга һәм укучыларына әдәби кыйммәте зур булган күп хатлар язганы билгеле. Редакция бу хатларның адресатларына аларны шагыйрьнең иҗат мирасы комиссиясе әгъзасы Әдип Маликовка түбәндәге адрес буенча җибәрүегезне үтенә: 423400 Әлмәт шәһәре, Ленин ур., 29-12.*

**Фирдәвес Әһлиуллина**

# ҖАНЛЫ УЧАК

## РСФСРның ХАЛЫК АРТИСТЫ, СССР ҺӘМ ТАССР ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕ ЛАУРЕАТЫ РИНАТ ТАҖЕТДИНОВ ТУРЫНДА ДОКУМЕНТАЛЬ ХИКӘЯ

Ринат, шактый гына вакыт йоклый алмыйча азапланып ятканнан соң, өйдәгеләрне уятмас өчен, сак кына урыныннан торды да, иңнәренә пинжәген салып, болдырга чыкты һәм бер мәлгә, күз алдында ачылып киткән матурлыктан сихерләнгәндәй, тып-тын калып карап торды. Нәкъ каршысында, тулган ай нурларында коенып, күкрәп үскән бодай башаклары дулкынланып тора иде. Менә талгын гына җил исеп куйды — тулышып җиткән эре башаклар, авыр башларын ия-ия, ни турындадыр серле итеп пышылдашып алдылар, ә аннары, тын җиһанны моңлы көмеш авазлар белән тутырып, әкрен генә чыңлый да башладылар төсле.

Тәмам онытылып тыңлады Ринат җанына якын булган бу аһәңнәрне. Шундый таныш, үтә газиз иде алар аның күңеленә. «Өлгергән инде икмәк, менә-менә коелырга тора,— дип уйлады ул зур кайгыртучанлык һәм җылылык белән.— Бер-ике көннән урып-җыюга да керешерләр инде».

Аның уйлары, иген дулкыннары сыман, берөзлексез агыла да агыла иде.

«Урак өсте... Игенчедән гаять зур тырышлык һәм фидакарьлек сорый торган вакыт. Табигатькә һәр ел саен килеп, даими рәвештә кабатланып торучы чор. Ә менә кешенең үз тормышында була микән шундыйрак чак? Ләкин ул бернечә елга, ә кайвакытта гомергә бер киләдер ахрысы.

Кеше һәрчак үзенең уй-фикерләренә, кылган эшләренә, үткән һәрбер көненә, күздән кичереп, нәтиҗә ясарга кунеккән. Чөнки үткәннәргә йомгак ясамыйча киләчәк көнеңне дә ачык итеп күзаллап булмый бит. Менә аның үзенең дә шундыйрак бер көне, дөресрәге, төне бугай. Чыннан да, инде ярты гасыр чамасы гомер яшәлгән, шуның яртысы, егерме биш елы, сәхнәдә иҗат итүгә багышланган. Күпме спектакльләр уйналган шушы вакыт арасында, күпме яңа образлар дөньяга тудырылган!..»

Ринатның күз алдыннан кайчандыр үзе сәхнәдә тудырган һәм хәзерге вакытта да яратып уйнап килгән образлары бер-бер артлы үтеп киткәндәй булды. Менә Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ында кайчандыр драматург үзе уйнаган Надыр-Мәхдүм роле... Менә Г. Фигерейдо әсәре буенча куелган спектакльдәге Эзоп. Әнә татар халкының язма әдәбиятына нигез салган беренче татар шагыйре Кол Гали... Менә Прометей, Мулланур Вахитов, Муса Җәлил... Аларның һәркайсы тере, җанлы булып күз алдында басып тора, артист күңеле түрендә изге бер урын тота. Аларның һәрберсенә дисталәгән йокысыз, газаплы төннәр, атналар, айлар багышланган. Тынгысыз эзләнүләр гәүдәләнеше булган әлеге геройларның берсе генә булмаса, аның шушы 25 еллык иҗат юлы тулы булмас төсле тоела: шулкадәр үз итә, якын итә ул аларны.

Иҗат юлына басканда Ринат үзе дә шушы кырларда язын шытып чыккан үсенте кебек кенә иде. Әмма тора-бара, талантлы драматурглар тудырган пьесалардан илһам алып, янәшәсендә эшләүче осталарның тәҗрибәсенә таянып, ул үзе дә үсте, көч җыя барды. Үсә барган саен тамырлары белән туган туфракка ныграк ябышты. Күңелендә берәр яңа образ

шытып килгән чакларда ул, гадәттә, бирегә кайтып, бодай башаклары арасында уйланып йөрергә ярата иде. Чөнки бодай җыры, җир моңы аңа образның кабатланмас үз моңын, үз төсен табарга ярдәм итә иде шикелле. Образ инде тәгәлләнеп, тамашачы тарафыннан алкышлап кабул ителгәч тә, кырларына кайтып, ул яңадан тагын бер тапкыр алар белән киңәшә иде. Спектакль инде йөзләрчә мәртәбәләр уйналгач та... Янәсе, күп мәртәбәләр кабатлаудан соң сүзләр төссезләнмәгәнме, хисләр сүрелмәгәнме, тузан кунмаганмы образның киемнәренә? Һәм Җир-ана аңа һәрвакыт иң дөрес, туры җавабын бирә торган иде.

Менә бу юлы да ул, яшь вакыттагы шикелле үк, сагынып, ашкынып кайтып керде туган авылына. Туган туфрак каршында инде чалара башлаган башын иде...

Ринат болдыр баскычларыннан түбән төште дә ашыкмый гына ихатаны кичте, капканы ачып, урамга чыкты, бер мәлгә тукталып, авыл авазларына колак салды. Тып-тын иде урам, хәтта этләр өргәне дә ишетелми, авылдашлары тыныч йокыга талган иде.

Урам буйлап түбән очка таба салмак кына атлап китте Ринат. Зур иде аларның авылы, матур иде. Йортларның капка-болдырлары, тәрәзә яңаклары әнә ничек итеп бизәлгән, төрле төсләр белән буялган, әйтерсең лә, елмаеп торалар. Элегрәк аларның авылында дүрт колхоз һәм дүрт председатель булган дип сөйлиләр Кече Чынлы аксакаллары. Һәм чыннан да, Ринат үзе дә кайвакыт аргы якта яшәүчеләрне белеп бетерми иде. Хәзер дә аның янына, Казанга, театр карарга килүчеләрнең кайберәүләрен күреп белми, әмма «Без Кече Чынлыдан» диюләре була, аның йорт ишеге шунда ук киң итеп, төбенә хәтле үк каерылып ачыла. Чөнки моннан да тылсымлырак сүз юк Ринат өчен.

«Авыл хәзер көннән-көн үсә, матурая бара. Шуңа күрә, яшьләрнең дә күбесе гомергә бирердә кала, китми авылдан. Әйтерсең лә, ниндидер күзгә күренми торган җепләр аларны туган туфракка бәйләгән. Шуңадыр да Җир-ананың һәр сулышын тоеп яши алар»,— дип уйлады Ринат бодай басуына якынлашкан чакта. Бодай башаклары чайкалып, баш иеп каршы алды аны, кул болгап, үзләре арасына дәште. Ул кыр аша салынган тар гына сукмакка аяк басты. Басу аша атлый-атлый, яңадан зарыктырган моң-җырны колак салып тыңлады, башакларның алтын башларын кулы белән сак кына сыйпап үтте.

Бәлки әле балачактан ук сәхнәдән җырларга хыялланып йөрүләре дә тикмәгә булмагандыр. Шушы бодайлар, җир моңының тәэсирендә тугандыр ул теләк. Хәер, тавышы да юк түгел иде төсле. Әле дә булса хәтерли: олы апалары күрше авылга кияүгә чыгып киткәч, аларга, гаиләдәге биш ир малайга, инештән чиратлашып су ташырга туры килә иде. Су юлы шактый озын, кайта-кайта зур чиләкләр тагы да авырая төшә иде. Әмма Ринат бу эшне бик яратып, теләп башкара, чөнки юл буе, кышынмы, җәенме, дөньясын онытып, җырлап бара, җырлап кайта торган иде. Аның шулкадәр бирелеп, тәэсирләнеп җырлаганын ишеткән кайбер хатын-кыз хәтта үзенә төртмәле сүзләр дә әйтә торган иде, ә үзләре малайның матур аһәңле, моңлы тавышына соклана.

Бәйрәм саен диярлек куелган концертларда да Ринатны еш кына җырлаталар, шигырь укытырлар иде. Алкышлап каршы алалар иде аны авылдашлары, алкышлап сәхнәдән озатып калалар иде. Шул алкышлар канат куйган булса кирәк яшь егеткә. Ә менә авылларына җырчы Рәшид Ваһапов килеп, танылган артист аңа төпле киңәш биргәч, егет инде тәгаен бер фикергә килде — унны бетерү белән үк Казанга бара, музыка училищесына укырга керә!

Һәм барды да. Әмма ул елны документларын бирергә инде соңга калган иде. Ә шулай да өметен өзмәде егет, киләсе елны яңадан килеп имтиханнар бирергә булды. Ләкин тормыш үзенчәрәк хәл итеп куйды шул Ринатның язмышын. 1956 елның җәй азаклары иде. Әтисе аның кулына бер газет китереп тоттырды. «Бер игълан бар анда, улым,— диде ата кеше серле итеп,— укып кара әле, бәлки тәвәккәлләрсең». Әрифҗан абзый, үзе бик үк укымышлы кеше булмаса да, уртанчы улының сәләтен күңеле белән сизеп тора, аның укып, зур кеше булуын тели иде.

Ринат газетаны укый башлады. «Татар дәүләт драма театры бер төркем талантлы яшьләрне җыеп, аларны СССРның Кече театры каршысындагы Щепкин исемендәге театр училищесына укырга җибәрәчәк...» диелгән иде анда.

Кеpмен дип уйламады да Ринат. Элегрәк хәл иткәнен дә, музыка училищесына уңышлы гына имтиханнарын биреп барды. Ата сүзен җиргә салып таптамас өчен генә, театр бинасында барган иҗади конкурсларга катнашты. Училищега керергә теләүчеләр бихисап иде: бер урынга егерме биш кеше. Өстәвенә, булачак шәкертләрне сайлап алу өчен Мәскәүдән махсус педагог җибәрелгән иде. Комиссия составында театрның баш режиссеры Ширияздан Сарымсаков, күренекле артистлар Хәлил Әбҗәлилов, Хөсәен Уразиков һәм башкалар.

Дулкынланмады да Ринат, керү турында да уйламады. Ул бөтен игътибарын алдан өйрәнеп килгән шигырь, мәсәл һәм проза өзекләренә, анда тудырылган образларга, идея эчтәлегенә юнәлтте, балаларча чын күңелдән бирелеп сөйләде. Шулай итеп, турларның өчесеннән дә җиңел генә узып китте Ринат һәм көтмәгәндә театр училищесы студенты булды да куйды.

Ринат инде кыр аша үтеп, елга буена чыккан иде. Бер мәлгә ул, текә яр өстендә тукталып, ай нурлары астында җемелдәп аккан Чынлы суына сокланып карап торды. «Күр әле, нинди киңлек, нинди матурлык!» — дип уйлады ул, тәэсирләнеп. Кай тарафка гына барма, туган ил юллары буйлап, алар сине һаман яңа биеклекләргә, яңа киңлекләргә илтә, алдыңда яңа мөмкинлекләр, мәйдан ача. Үзенең дә гомер юлы шулайрак булды. Татарстан читендә урнашкан туган авылыннан ул, Казанны да юньләп күрмәгән килеш, туп-туры башкаланың үзенә, Мәскәүгә килеп чыкты. Тормыш аны һәм аның курсташлары Туфан Миңнуллин, Равил Шәрәфиев, Нәҗибә Ихсанова, Гөлсем Исәнгулова, Наил Дунаев, Әзһәр Шакиров һәм башка талантлы татар яшьләрен, бөтереп диярлек, нәкъ үзегенә алып кереп китте. Художество җитәкчесе профессор Гладков ярый әле дөрес юнәлеш бирде. Югыйсә, шундый зур, бай культуралы шәһәрдә кинәттән башлары әйләнеп китү ихтимал иде бит. Тормышның һәм сәнгатьнең күп кенә серләренә төшенергә ярдәм итте, рухи хәзинәләргә юл күрсәтте, күп елларга, гомер буена җитәрлек белем, рухи байлыклар тупларга ярдәм итте остазлары.

Гомумән, Ринатның юлында гел гаҗәеп яхшы, изге күңелле кешеләр генә очрап торды. Шуларның берсе — СССРның халык артисты Хәлил ага Әбҗәлилов. Әле училищеда укып йөргән чакта ук ул даими рәвештә Мәскәүгә килеп йөри, аларның группаларын аталарча кайгыртучанлык белән күзәтә, булдыра алган кадәр ярдәм дә күрсәтә иде. Ә 1961 елда бер төркем яшь артистлар, училищены бетереп Казанга кайткач, Татар дәүләт драма театры коллективына көчле агым булып кереп киткәч, аның аларга карата булган игътибары тагы да арта төште кебек. Алай гына да түгел, Хәлил ага һәм аның сәхнә иптәшләре, өлкәннәр тәҗрибәсе белән яшьлек дәртенең бергә кушылуы өчен, барысын да эшләделәр. Ә инде шушы олы артистларның уенын күзәтү, аларның сәхнәгә чыгар алдыннан ничек итеп әзерләнүләрен күрү — үзенә бер бәхет, осталык мәктәбе иде. Ринатның әле бүгенгедәй күз алдында: Хәлил ага спектакль алдыннан гел иртәрәк килер иде. Грим бүлмәсендә костюмнарын киенер, грим салыр да, ярты сәгать чамасы күзләрен йомып, хәрәкәтсез утырып торыр, ә инде күзләрен ачып, урыныннан кузгалган чакта я Хуҗа Насретдингә, яки король Лирга әверелгән булыр. Ринат өчен могҗиза кебегрәк бер нәрсә иде бу. Артистның бөеклегенә соклана иде ул. Тик менә еллар үтеп, үзе байтак рольләрне уңышлы гына башкару бәхетенә ирешкәннән соң гына аңлый башлады: никадәрле зур рухи хезмәт, рухи эшчәнлек яткан икән бу тиңсез образларның нигезендә. Ринат гомере буе аның шул тырышлыгы, хезмәт сөючәнлегеннән үрнәк алып яшәргә тырышты һәм үзе дә, яңа роль өстендә эшләгән чакларында, бик күп укыды, эзләнде, уйланды. Менә, мәсәлән, Муса образы. Тиз генә, җиңел генә бирелмәде ул аңа. Артист аңа бик ерактан, еллар, юллар урап килде.

Әле Мәскәүдә укып йөргән чакларда ук алар, атна саен җыелышып, әдәби кичәләр үткәрәләр, анда татар шагыйрьләре әсәрләрен укып, халык көйләрен җырлый торганнар иде. Ринат аеруча Тукай һәм Җәлил шигырьләрен укырга ярата, аларны күңеленә якын күрә иде. Шундый кичәләрнең берсенә Әминә ханым Җәлил дә килгән иде. Ул Муса турында сөйләде, аның хатларын укыды, студентларның сорауларына җавап бирде. Әминә ханымның һәр сүзе, хәрәкәте Ринатның күңеленә нык уелып калган иде. Шул көннән алып ул матбугатта Җәлил турында басылып чыккан материаллар белән аеруча җитди кызыксына, аның шигърияте, шәхесе, батырлыгы турында даими рәвештә уйлана башлады. Ә инде Казанга кайтып,

театрда эшли башлагач, ул Муса образының сәхнәдәге гәүдәләнеше белән очрашты. Аны Нәкый Исәнбәтнең «Муса» исемле пьесасы буенча куелган спектакльдә театрның күренекле артисты Фуат Халитов башкара иде. Кабат-кабат карады Ринат бу спектакльне, артистның уенын аеруча җентекләп өйрәнде. Һәм бераздан бу өйрәнү аңа иҗат тормышында бик зур ярдәм итте, чөнки 1968 елны Муса ролен аның үзенә дә ышанып бирделәр. Таҗетдиновның уенын тамашачы да, спектакльне караган Әминә ханым да, язучылар Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур һәм Рафаэль Мостафин да җылы кабул иттеләр. Төсе-бите, кыяфәте, тавышы, йөрешенә кадәр Мусаныкына бик охшаганлыгын барысы да бертавыштан билгеләп үттеләр. Шулай, итеп спектакль өч-дүрт сезон буена уңышлы гына барды. Ләкин тормыш беркайчан да бер урында гына тормый бит. Вакыт узу белән, Муса турында да яңа фактлар, мәгълүматлар табыла торды, тора-бара аның образы үсә, зурая барды. Заман шагыйрь һәм герой Муса Җәлилнең образын философик яктан гомумиләштергән әсәрне көтте, һәм андый әсәр дөньяга озаклап мый туды. Ул драматург Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» дип исемләнгән публицистик драмасы булды. Театр коллективы, җиң сызганып, эшкә кереште...

Ринат ашыкмый гына ярдан төште һәм, кара туфрак өстеннән атлыйатлый, су буйлап китте. Әйтерсең лә, аны нәрсәдер алга өнди, бертуктаусыз дәшә иде. Менә ул ком өстендә җемелдәп яткан утлы күмер кисәкләрен күреп алды. Килеп караса — кемнеңдер сүнеп җитмәгән учагы. Янәшәдә яткан коры ботакларны шул күмер кисәкләре өстенә куеп, сулышы белән өреп караган иде — коры чыбыкларны шундук ут ялмап алды. Һәм сүнеп җитмәгән учак яңадан күңелле генә дөрли башлады.

Ялкын телләренә текәлеп карап торган чакта балачак учакларын исенә төшерде Ринат. Нәкъ шушында, менә шушы урында учак яга иде авылдан җыелып килгән бер төркем малай-шалай. Елгада балык тотып, уха пешерәләр, шулай итеп, бер телем икмәк күрергә зарыгып яшәгән авыр сугыш елларында бераз гына булса да туйдыралар иде ач тамакларын. Югыйсә, Ринатның әтисе икмәкне үз куллары белән тирә-юньдәге барлык кырларга чәчеп үстерә, җыеп ала иде бит. Кырлар тулы икмәк иде. Әтисе авылдан җиде чакрымнарда урнашкан МТСта сиксәнләп тракторга хуҗа итеп калдырылган бердәнбер механизатор иде. Күпме сорамасын, аны барыбер фронтка җибәрмәделәр, илгә икмәк кирәк, диделәр. Ә ничек үстерергә иде соң ул икмәкне, кемнәр белән? Әрифҗан абзыйның кул астында шул җимерек-ватык 80 трактор һәм гомерендә бер генә мәртәбә дә руль тотмаган дистәдән артык хатын-кыз иде. Ә шулай да үстерделәр. Кышын тракторларны бергәләп ремонтлап, язын хатын-кызларны аннан-моннан өйрәтеп, кырларга озата иде Әрифҗан абзый. Үзе дә көне-төне кырда булды. Сугыш елларында аның берничә мәртәбә генә өйгә кайтып кунганын хәтерли Ринат. Шул чакларда яман үзгәргән, ябыккан, йөзләре каралып беткән әтисен көч-хәл белән таный иде малай, әтисенең гаҗизлеген күреп, йөрәге сыза иде. Ә шулай да ялгыш кына булса да бер бөртек бодай да алып кайтмый иде ул өйләренә. Чөнки әтисе — коммунист, колхозлар төзешеп йөргән, шуның өчен исеме язылган пистолет белән дә бүләкләнгән кеше иде. Бандитлар үлем белән янаган чакта да бирешмәгәнне, ачлыкка гына бирешә идеме соң ул?! Балаларын да намуслы булырга, туры юлдан тайпылмаска, үзе турында гына түгел, ил элек иле турында уйларга өйрәтте ул...

Ринат бер таяк белән учактагы күмер кисәкләрен бутап алды, аннары утын өстәде. Ялкын телләре биеккә, күккә ургылып бии башлады.

«Ялкын, ялкын... Нинди бөек, могҗизалы көчкә ия син... — дип уйлады Ринат.— Бактың исә, Җир шарының үзәгендә дә ялкын икән бит. Ялкын — җимерүче көч түгел, ә бәлки тереклекне яшәтүче, яшәртүче көчтер ул. Уйлап карасаң, кешенең үзәгендә дә ялкынлы йөрәк тибә бит. Шул ялкынлы йөрәк кешегә тынычланырга ирек бирми, гаделлекне эзләргә, көрәшкә дәшә. Алай гына да түгел, борын-борын заманнарда гаделлекне эзләп көрәшкән ата-бабаларыбыз факел итеп күтәргән әлеге ялкын эстафета булып бер буыннан икенче буынга күчеп бара түгелме?! Прометейлардан Мулланур Вахитовлар кабул итеп алган факелны Мусалар күтәреп алды. Ә хәзер ул факел — безнең буын кулында. Безнең бурыч — әлеге факелны исән-имин киләчәк буыннарга тапшыру...»

Учак инде сүрелә башлаган иде. Әмма Ринат аңа бүтән утын өстәмәде. Чөнки шушы нәни учакның күккә очкан очкыннарыннан кабынган төсле, көнчыгыш якта алсуланып таң атып килә иде.

**Сорау:**

— КПССның XXVII съезды илебез тормышының һәр тармагында кискен борылыш ясау кирәклеген күрсәтте. Сезнеңчә, әдәбият бу процесста нинди роль уйнарга тиеш?

**Язучы, публицист Рахмай Хисмәтуллин:**

— Мин җыелып торган суларның ургылып агып китүен, яшенле һаваларның бушануын, язгы ташуларны, көчле җилләрне, аларның төрле яклардан исүен яратам.

Булып узган съезд, тизләнеш съезды, табигатемә туры килеп, мине яңартып, күптәнге уй-хыялларымны кузгатып җибәрде. Эш шунда ки, бу космик чордагы үсештә без кешенең гади акылы белән генә идарә итеп булмаслык тизләнеш дәверенә кердек. Бу тизләнешнең үзәге — автоматлар. Ә автоматларның үзәге — компьютерлар, компьютерларның үзәге — электрон хисаплау машиналары, ул машиналарның нигезендә математика һәм физика ята, гомумән, фән дөньясы ята. Ә фән дөньясының үзәге исә — көчле кешеләрнең акылы һәм психикасы.

Мин үзем, математик-программист буларак, моннан 20 ел элек яңа төзелеп яткан Түбән Кама шәһәренә төзелешне идарә итү буенча электрон хисаплау машиналары кертү хыялы белән килгән идем. Электрон хисаплау машиналары, компьютерлар — җәяүле — атлыны, машина — самолетны, гади счет төймәләре электрон хисаплау машиналарын узып китә алмауны исәпкә алганда — төзелешнең, аны тизләтүнең умыртка сөякләре булырга тиешләр иде. Ләкин безнең промышленность үсеше, җитәкчелек психологиясе ул вакытта андый югарылыкта булып чыкмады. Без, ничектер, ресурслар болай да җитәрлек, эш болай да бара бит дип, ирәебрәк яшәдек, шактый кыйммәтле вакытны кулдан ычкындырдык...

Язучыларга килгәндә, тизләнеш рухы иң беренче очерк жанрында тормышка ашырылырдыр. Күпләргә, бәлки, киң полотнолы әсәрләрен читкәрәк куеп торырга туры килер. Үземә килгәндә, мин шушы шәһәр төзелүнең төп сәбәпчесе булган «Нефтехим» берләшмәсенең атна саен була торган планеркасында съездан соң «компьютерлар, автомат идарә итү системалары» дигән сүзләрне еш ишетә башладым. Әле күптән түгел генә АКШтан компьютерлар кайтартылды. Шул ил белгечләре аны монтажлауга да керештеләр. Хәзер инде, яшьлегемдә өйрәнгән программист хыяллары күңелдә уянып, ул вакыттагы көндәлекләремне файдаланып, бүгенге компьютерларны үзләштерүчеләр турында очерк язып, шуны журнал укучыларына тәкъдим итәсем килә.

Икенчесе, бүгенге көндә хезмәт ияләренең көнкүрешен, ялын оештыру, халык иҗатын, язучылар иҗатын, гомумән, әдәбият-сәнгатьне пропагандалау беркайчан да булмаганча актуаль булып көн кадагына килеп басты. Бу уңайдан ВЦСПС председателе иптәш С. А. Шалаев «Правда» газетасының быелгы 14 январь санындагы «Иҗат бәйрәме» дигән мәкаләсендә язучыларны төрле массовый чараларның сценаристлары итеп тарту мәсьәләсен күтәреп чыкты. Без моны Түбән Камада күп еллар буе тормышка ашырып киләбез. Менә биш ел инде массовый чара булган «Җидегән чишмә» кичәләренең сценарийларын миннән яздыралар. Яңа шартларда аның әһәмияте тагын да арта төшәчәк, һәм моны мин иҗат эшемнең аерылгысыз бер өлеше итеп карыйм. «Җидегән чишмә»ләр дә Бөек Тизләнешкә хезмәт итәргә тиеш!

Тагын шунысы куанычлы: съезд документларында язучы эшенә көчле ихтыяҗ булуы нык чагылды. Димәк, язучы биргән продукция — аның әсәрләре дә халыкка мөмкин кадәр тизрәк барып ирешәчәк дигән сүз бит бу. Димәк, моннан соң китапларның чыгарылуы өч-дүрт елга сузылу анохронизм дип каралачак, нәшриятлар киңәячәк, аларның материаль базалары ныгыячак!

**Леонид Арсланов,**
филология фәннәре докторы

# КЕМНӘР АЛАР «ӘСТЕРХАН КАРАКАЛПАКЛАРЫ?»

Татар халкы һәм аның теленең килеп чыгышын өйрәнгәндә галимнәр тарихи, археологик, этнографик, фольклор һәм тел материалларына таянып эш итәләр. Әлбәттә, иң ышанычлы һәм мөһим чыганакларның берсе — татар халкының теле, бигрәк тә аның диалектлары һәм сөйләшләре. Бу өлкәдә татар тел гыйлеме шактый зур уңышларга иреште: татар теленең диалект һәм сөйләшләре монографик планда өйрәнелде, диалектологик сүзлек чыгарылды, һәм, ниһаять, татар теленең диалектологик атласын төзү тәмамланып килә.

Ләкин татар халкының зур булмаган кайбер этник төркемнәре моңа кадәр аз өйрәнелде. Ә бу этник төркемнәрнең тарихын, этнографиясен, фольклорын һәм телен өйрәнү этногенез мәсьәләләрен фәнни нигездә хәл итүдә өстәмә чыганак булып хезмәт итә алыр иде.

Галимнәр игътибарыннан читтә калып килгән аз санлы этник төркемнәрдән, мәсәлән, Әстерхан өлкәсенең Лиман районында яшәүче җидәле татарларын (русча — зензелинские татары), «Әстерхан һәм урал каракалпаклары»н күрсәтергә мөмкин. Болардан башка татар халкының кечкенә төркемнәре Ставрополь һәм Краснодар крайларында һәм Чечен-Ингушетия АССРда да бар.

Бу мәкаләбездә без укучыларны «әстерхан каракалпаклары» дип аталып йөртелгән этник төркем турында кайбер материаллар белән таныштырмакчы булабыз.

«Әстерхан каракалпаклары» хәзерге вакытта Волгоград өлкәсенең Палласовка һәм Старополтав районнарында, Казахстанның Урал өлкәсе Джаныбек районында һәм Палласовка, Гмелинка, Сайхын, Түбән Баскунчак станцияләрендә яшиләр.

«Әстерхан каракалпаклары» дигән этник төркем фәндә XIX гасырның икенче яртысында билгеле була. «Әстерхан каракалпаклары» турында беренче булып П. Небольсин үзенең «Очерки Волжского Низовья» дигән мәкаләсендә язып чыга[1]. Автор «каракалпакларның» тору урынын төгәл күрсәтми, бары тик Чернояр тирәсендә яшәүләрен генә яза. Ул, безнең уйлавыбызча, Баскунчак «каракалпакларын» күз алдында тота булса кирәк. П. Небольсин фикеренчә, «каракалпаклар» 1817 елда Түбән Идел далаларына килеп чыгалар һәм рәсми документларда 1827 елдан билгеле булып китәләр.

1827 елда Мөхәммәт Биктимеров дигән кыргыз (татар — Л. А.) дүрт гаилә исеменнән (барлыгы 61 җан) властьлар исеменә үзләрен «кундару татарлар» (хәзерге Әстерхан өлкәсе Краснояр һәм Харабали районнарында яшәүче карагачлар) итеп язуларын сорап үтенечнамә яза. Сүз, һичшиксез, Баскунчак күле тирәсендә яшәгән «каракалпаклар» (татарлар) турында бара, чөнки П. И. Небольсин язган заманда «каракалпаклар» Казахстанның Урал өлкәсендә дә яшиләр.

1847 елда «каракалпакларның» саны 68 ир, 66 хатын җенесе исәпләнә.

«Каракалпакларның» килеп чыгышына килгәндә, П. Небольсин антропологик яктан аларның казан татарларыннан аерылмавы турында яза. Ләкин татар икәнлекләрен кистереп әйтми; аларның теле турында да мәгълүмат китерми.

Шулай итеп, 1852 елдан башлап фәндә серле «әстерхан каракалпаклары», «урал каракалпаклары» яки «калпаклары» дигән атама кулланышка кереп китә.

«Әстерхан каракалпаклары» турындагы кайбер мәгълүматларны А. Терещенко

---

[1] «Әстерхан каракалпаклары» турында фәнни әдәбият безнең «Советская тюркология» журналының 4 санында (1981) басылып чыккан «О так называемых «астраханских каракалпаках» и их языке» дигән мәкаләдә бирелә.

үзенең «Следы Дешть кипчака и внутренняя киргиз-кайсацкая орда» дигән мәкаләсендә китерә. А. Терещенко аларны Баскунчак күле буена Россиянең төрле өлкәләреннән килгәннәр һәм бирсдә татар (?) белән кушылып, телләрен югалтканнар һәм мөселман динен кабул иткәннәр дип яза. Нинди телдә сөйләшүләре турында автор язмый.

А. П. Хорошхин исә Зур Үзән (Большая Узень) буйларында Җаек (Урал) казакъларына буйсынып торган 30 гаиләдән торган «каракалпаклар» турында яза. Болардан тыш А. П. Хорошхин казах арасында яшәүче «каракалпакларны» да искә ала. Автор аларның ярымкүчмә тормышта яшәүләре һәм тормыш-көнкүрешләре белән казахлардан аерылып торулары турында яза. (Сборник статей, касающихся Туркестанского края. СПб., 1876. 497 б.).

«Киргизы Букеевской орды» дигән мәкаләсендә А. Харузин «каракалпакларга» махсус бүлек багышлый. «Каракалпакларны» автор ике төркемгә: «чын каракалпак» һәм «исеме буенча гына каракалпак»ларга бүлә. Соңгыларын А. Харузин төрле тарафтан җыелган татарлар, бохарлыклар, хивалылар дип саный. Башка авторлардан аермалы буларак, күрсәтелгән автор «каракалпакларның» яшәү урыннарын да күрсәтә. Мәсәлән, ул «каракалпакларга» Җиһангир ханның җир бүлеп бирүе һәм бер төркеменең Әстерхан тирәсендәге Биштүбә авылына күчереп утыртылуы турында яза. 50 кибиткадан торган икенче төркем Сарбаста авылында кала, ә өченче төркем Урал өлкәсенең Сегир-Кудук авылына күчереп утыртыла.

А. Харузин китергән материаллар безнең тарафтан Әстерхан өлкәсе Нариман районының Биштүбә (Биштубиновка), Көлдермеш (Нов. Кучергановка) авылларында язып алынган материаллар белән дә раслана. Чыннан да, бу авылларда «каракалпак», «калпак» нәселләре әле дә бар. Ләкин алар чыгышлары буенча көнбатыш диалект вәкилләре — мишәрләр. Димәк, болары «исеме генә каракалпак»лар.

«Каракалпакларның» бер өлеше Әстерхан өлкәсе Лиман районының Җидәле (Зензели) авылына да күчереп утыртылалар.

Болардан башка А. Харузин «чын каракалпаклар» турында да яза һәм аларның 80 көймәле арбадан (кибиткадан) торганлыгын әйтә. Соңгылары Таргын һәм Таловка тирәсендә яшиләр, ди. А. Харузин әйтүенчә, кыргызлар (казахлар — Л. А.) аларны кыргыз дип танымыйлар, ә «калпак» дип атыйлар һәм аларны аерым халык дип саныйлар, ди. А. Харузин алар («каракалпаклар») татарларга тартым һәм кыргызлардан (казахлардан) кискен аерылып торалар, ди: «алар урта буйлы, аксыл җирән чәчле, күзләре соры»— дип яза.

«Каракалпаклар» турында кайбер мәгълүматларны И. Л. Щегловның «Трухмены и ногайцы Ставропольской губернии» (т. I, Ставрополь, 1911) дигән хезмәтендә табарга мөмкин. Автор 1790 елда Ставрополь төрекмәннәренә 80 гаилә кыргызларның («казакчиев род») килеп кушылуы турында сөйли. Автор фикеренчә, бу «казакчы ыруы» яңадан «казанлылар» дип аталган булса кирәк, ди. Бу «казакчы» ыруның кайберләре Ставрополь крае Камыш Борын авылына күчереп утыртыла.

Г. Н. Дроздов «каракалпакларны» кайчандыр Урал округында яшәгән һәм XVIII гасырның 40 елларында Россиягә буйсынып, һәм соңыннан, Сыр-Дарья һәм Аму-Дәрья елгаларының түбән агымына күченеп киткән күпсанлы халыкның (ягъни каракалпакларның — Л. А.) калдыгы дип саный, ягъни бу этник төркемнәрне каракалпакларга кайтарып калдыра. Ләкин үз фикерен бернинди фактлар белән дә дәлилләми. Г. Н. Дроздов «каракалпакларның» санын да күрсәтә. Урал округында — 845, Таловск районында — 597, Джаныбек районында 247 каракалпак яши, ягъни барлыгы 1687 кеше. «Каракалпакларның» нинди телдә сөйләшүләре турында автор язмый.

Күренекле тюрколог Н. А. Баскаков үзенең «Введение в изучение тюркских языков» хезмәтендә «әстерхан каракалпакларын» шулай ук каракалпак халкының локаль төркеме дип таный.

Каракалпак галиме Д. С. Насыров, П. Небольсин, А. Х. Хорошхин, А. Харузин, Г. Н. Дроздов, Н. А. Баскаков хезмәтләренә таянып «әстерхан һәм урал каракалпакларын» каракалпак халкының төньяк-көнбатыш локаль төркеме итеп таный һәм аларны казах һәм татар йогынтысына бирелгәннәр дип яза. Аларның телен исә автор казах теленең көнбатыш группасы составында карый.

Шулай итеп, кайбер галимнәрнең «әстерхан каракалпакларының» татарларга якын торулары турында язуларына карамастан, күпчелек галимнәр аларны каракалпак халкының локаль төркеме итеп карап килделәр. Тюркология фәнендә мондый ялгыш фикернең яшәп килүе әлеге «каракалпаклар»ның теле өйрәнелмәү белән аңлатыла.

1978 елда бу юлларны язучыга серле «каракалпаклар» да булырга насыйп булды, һәм аларның теле, фольклоры, этнографиясе буенча материал тупланды. Материал Волгоград өлкәсе Палласов районы «Кумыс» санаториясендә, Фурманов совхозының 3 номерлы фермасында һәм Палласовка станциясендә тупланды.

Без өйрәнгән «каракалпаклар» революциягә кадәр, җирле халыкның сөйләвенә караганда, Урал өлкәсенең Джаныбек районы Бурсы авылында һәм шул ук өлкәнең Казталов-

ский районы Карасу авылларында, Түбән Баскунчак тирәләрендә яшәгәннәр. Мәсәлән, Бурсыда Бүләкбай, Каугабаш, Абдрахман, Зөпәр, Баттал авыллары булып, һәр авыл 20 ләп өйдән торган.

Серле «каракалпакларның» килеп чыгышына килгәндә, җирле халыкның аңлатуынча, һәм без туплаган тел, фольклор, этнографик материал күрсәткәнчә, алар «каракалпак» түгел, ә чын казан татарлары. Хәзерге вакытта «каракалпакларның» «казах», «татар», «каракалпак» дип язылганнары да бар. Җирле казахлар аларны казах дип тынымыйлар, ә «калпаклар» дип йөртәләр.

Бүкәй урдасына (казах арасына) килеп чыгуларын «калпаклар» үзләре түбәндәгечә аңлаталар: аларның бабалары көчләп христианлаштыру һәм 25 еллык солдат хезмәтеннән качып, казах далаларына килеп чыгалар. Ләкин алар белән кушылмыйлар. Үзләре аерым төркем булып яши бирәләр, телләрен, гореф-гадәтләрен, материаль һәм рухи культураларын саклап киләләр. Ата-бабаларының туган иле итеп, Бөгелмә, Бәләбәй һәм Оренбург губернасының Бозаулык өязен саныйлар. Беренче булып килгән татарлар үзләренең килеп чыгышларын яшерә торган булганнар, еш кына фамилияләрен дә беркадәр үзгәртеп язганнар. Мәсәлән, Кошманов, Байдуллин, Җопаров һ. б. (Кошманов фамилиясе Апас районының Кошман авылына ишарә итә булса кирәк).

«Каракалпак» яки «калпак» исемен аларга казахлар биргән, чөнки татарлар үзләре баскан кара киез эшләпә киеп йөргәннәр (казахча эшләпәне «калпак» диләр).

Казах арасында шактый озак яшәүләренә карамастан, «калпак»ларда үзаң, татарларга хас материаль һәм рухи культура, татар теле сакланган. Җирле татарлар ике телле. Татарча да, казахча да иркен сөйләшәләр. Үзара татар телендә сөйләшәләр. Билгеле, икетеллелек аларның теленә йогынты ясамый калмаган. Бу бигрәк тә морфология һәм лексика өлкәсендә ачык күзәтелә. Алар фольклор үрнәкләрен дә шактый тулы саклаганнар. Мәсәлән, аларда «Сак-Сок бәете», «Җизнәкәй», «Баламишкин», «Карурман», «Зиләйлүк» көйләре киң таралган.

Серле «каракалпаклар» гаиләдә татар телендә сөйләшәләр, туган тел дип татар телен саныйлар һәм үзләрен татар — казан татары дип йөртәләр.

Җирле татарларның формалашуында урта диалект вәкилләреннән тыш Волгоград өлкәсенең Ленин һәм Старополтав районнарында яшәүче татарлар (мишәрләр) дә катнашкан. Тел ягыннан аларны урта диалектның аерым мөстәкыйль сөйләше итеп карарга була.

Түбәндә без җирле татарларның кайбер фольклор үрнәкләрен китерәбез.

## Мәзәк

Торба җаба гуй. Торба җапканда әйтә: «Йөз маниттан бер манит ким булса да алмас идем».— ди. Хуҗа Насретдин түбә җабып җата. Шол соң берәү ишетеп тора да уны: «Ни кылар микән, алар микән, алмас микән; мин туксан тугыз манит куйып, бер манит җиткерми куйыйн»— дип туксан тугыз манит акчаны әкилеп куя. «Менә минең кичәге теләгем булган икән гуй, туксан тугыз манит биргән ходай, тагын бер манит бирәр»,— дип Хуҗа калтасына акчаны салып ала. Туксан тугыз манит салган кеше килә гуй: «Минең акчаны бир, мин, ди, нарошно куйган идем»,— ди. Хуҗа: «җук ди, мин ходайдан сорадым ди, «бер манитын да бирәм» дип әйтте»,— ди. Туксан тугыз манит акчаны кесәсенә салып ала.

*Палласов районы Кумысолечебницада Нигъмәтов Давуҗдан 1978 елның маенда язып алынды.*

## Җизнәкәй

Иртән иртә китәм инде җизнәкәй, җизнәкәй?
Үзем тотып чыгарып салам, балдызым, җалгызым.

Өңкәл булып җазыламын, җизнәкәй, җизнәкәй?
Чүмеч булып сөзеп алам, балдызым, җалгызым.

Подувалда нигә җаттым җизнәкәй, җизнәкәй?
Сабын орлап сатканга, балдызым, җалгызым.

Кичә төштә кайда булдың, җизнәкәй, җизнәкәй?
Күршеләрдә утыра идем, балдызым, җалгызым.

Был айагың нидән йәзек, җизнәкәй, җизнәкәй?
Кыйшык итек кигәнгә, балдызым, җалгызым.

Был билләрең нидән йәзек, җизнәкәй, җизнәкәй?
Каеш билбау буганга, балдызым, җалгызым.

Был айагын нидән йәзек җизнәкәй, җизнәкәй?
Йазлый җәяү җөргәнгә, балдызым, җалгызым.

Был кулмәгең нидән керле, җизнәкәй, җизнәкәй?
Апаң салак булганга, балдызым, җалгызым.

Апам нидән салак булган җизнәкәй, җизнәкәй?
Ике катын тотканга, балдызым, җалгызым.

Сары (тары) булып чәчеләмен җизнәкәй, җизнәкәй?
Тавык булып чокып алам, балдызым, җалгызым.

Кара бөрек кимә дидем, җизнәкәй, җизнәкәй?
Кама бөрек табалмадым, балдызым, җалгызым.

*Волгоград өлкәсе Палласов районы «Фурманов» совхозының 3 номерлы бүлекчәсендә Дәүләтова Фәрига Хәнәфиевнадан (1929 елгы) 1978 елның маенда язып алынды.*

## Мәкальләр

1. Өйрәнгән җау сугышуга җакшы.
2. Алыстан чыккан җаудан качып котыларсың, өй эченнән чыккан җаудан нишләп котыларсың.
3. Сүз сүзне чыгара, җодрык күзне чыгара.
4. Үземнеке үзәгемдә.
5. Тешең барда ашап кал,
   Көчең барда эшләп кал.
6. Чикерткәдән курыксаң, иген икмә.
7. Әңгемә бозау имезә, бозау таяк җийгезә (ашата).

## Сары үзән

Сары үзәнкәй буйы ай бу тәкә,
Нигә ашамый да икән куй тәкә, куй тәкә.
Сары үзәнкәй буйы миңан тисә,
Бирер идем, бәгърем, куш таңкә, куш таңкә.
Сары үзәнкәй буйы киртләч, киртләч,
Киртләчләре китә кар киткәч, кар киткәч.
Сары үзәнкәй буе бик иләмле
Иләмнәре китәр без киткәч, без киткәч.
Анау өйгә бәгърем ай кем килгән,
Иярләнгән, бәгърем, ат тора, ат тора.
Аның җаный бәгърем шунысы бар,
Пичәтләгән бәгърем хат тора, хат тора.
Тугай гына, бәгърем, ай илебез,
Миңлебайда безнең өебез, өебез.
Җыеп дуслар арасында, бәгърем,
Җырлый торган безнең көебез, көебез.
Агыйделдән генә ай кичкәндә,
Җырлап кына ишкәк ишкәндә, ишкәндә.
Бер җырласаң бәгърем, бер җыларсың,
Үткән гомер искә төшкәндә, төшкәндә.

*Волгоград өлкәсе Палласовка районы «Фурманов» совхозының 3 номерлы бүлекчәсендә Мөхәммәтҗан ага Җаппаровтан (1902 елгы) 1978 елның маенда язып алынды. Бу җыр «Ишкәкче карт» көен хәтерләтә.*

# Әкият

Бер җегет була. Эшләмитен була. Аннан соң әтисе үлә кайгысыннан. Шуннан соң инде әнисе кала. Әнисен тыңламый бу. Тора бара акчаларны сандыгыннан күтәреп чыга башлый. Шулай җөрә, җөрә акча да бетә. Үзеннән үзе генә кала инде. Әнисе дә кайгыдан инде үлем хәленә килә. Шуннан соң әнисе әйтә: «Инде мин үләм, балам, ди, инде мине үтерәсең. Мин үлгән соң, син адәм булмассың. Калай да булса минем зиратыма килеп төнәп китәрсең»,— ди.

Ну, йарый, был шул әйткәнне күрә. Барын да күрәдер дә, был бала әнисенең зиратына бара. Төнни. Төнәгәннән соң, әнисе әйтә: «Я, балам,— ди,— минем әйткәннәрем булдыма»,— ди төшендә. Шуннан соң әйтә: «Минең зиратымның уң ягыннан, ди, җул чыгар, ди, шул җул мынан кит, ди. Барарсың бер илгә, ди, шул илдә сиган табылар хезмәт»— ди. Бара был илгә. Барса, илгә керә, Барса, бер адәм булмый инде. Бер зат та җук, балачага да җук, зат та җук. Җөрә, җөрә бер читеннән икенче читенә чыга. Утыра бер бабай. Бабайга киләдер дә сәлам бирә. Бабай әйтә: «Ну,— ди,— сәлам бирмәсәң, эчеп идем каныңны,— ди, алып идем җаныңны»,— ди, Шуннан соң был әйтә инде: «Сәламемне алмасаң, мин дә синең каныңны эчкән булыр идем,— ди, җаныңны алган булыр идем»,— ди. Шуннан соң инде был бабай әйтә: «Нишләп җөрәсең»— ди. Был әйтә: «Хезмәт эзлим»— ди. Бабай әйтә: «Хезмәт миндә була,— ди,— Миган мунча йагасың,— ди әвәле. Мунча төш, ди. Шуннан соң хезмәт бирәрмен»,— ди.

Ну был мунчага керә, мунчаны ягып ятканда каршында беркемне күрмәде. Инде моның артыннан берәү тарткандай була. Артына карай. Караса — бер кыз тора. Кыз әйтә: «Беләсеңме, син кайда килдең?» Был әйтә: «Кайда?». Кыз әйтә: «Шайтан өенә килдең,— ди,— был шайтан өе,— ди. Был карт шайтан сине үтерә, ди. Мунчага керсәң, эшең бетте, ди. Миган ышанмасаң, мунча артына чыгып бак, ди. Канча адәмнең сөйәге йата»,— ди.

Был төшенәдер дә, җакмый. «Нишлим?»— ди, кызга әйтә. Кыз әйтә: «Бар, ди, миган мунчаның кирәге йук, миган хезмәт кирәк дип әйт»,— ди.

«Ә инде сиган хезмәт ни зат? Минең конюшта айгырым бар, шуны өйрәтеп кил»,— дип әйтер»,— ди. Ә акчаны сиган күрсәтеп суга салар, ди, кодыкка биш тиен. Шул биш тиен акча суда калкып торат, ди, батмый. Ә инде кайвакытта ул качан җаны кыйнала ул картның, ул вакытта гына бата, ди, акча ди. Ул карт айгыр булып үзе торат конюшта, ди. Син өйрәткән вакытта башка бер зат да ясый алмыйсың, ди. Ул сине күккә дә алып очар, җиргә дә алып төшәр, только маңдаена кыйна, шуннан башка зат ясама»,— ди.

Шуннан килә, өйрәтә. Шуннан соң картка бара. «Бабай, ди, мин өйрәтеп килдем»,— ди. «Я, ни, ди, бир акча, өйрәнгән зат ул, өйрәнмәсә, бар, бак, ди. Шуннан соң бабай маңдаен бәйләгән, ята. Шуннан соң әйтә: «Минең срогым бәлки тулгандыр, акчаны карайык», ди. Нинди срок ул, ничә акча булган, ди. Барып карай, караса — акча йук. Баткан. Шуннан соң «Ни аласың» дигәндә, ди, сора, ди, кыз. «Мин зат та алмыйм, мин җабай батырдың өч көчеге менән күк атын сорыйм»,— ди. — Шуннан башка бер зат та сорамыйм, маган бер зат та кирәк имәс дип әйт, ди. Аны бирер ди, курыкканнан синнән ди. Шуннан соң монда торма ди, кит ди, үләсең ди, кыз әйтә.

Был, йахшы, барын выполнять итә. Далага барайтыргандa бер алма ята. (Безнең бит наданлыгыбыз көчле, барабыз да алабыз). Ул барган да алган. Алган да кесәсенә салган. Был бара, алма орлый бирә, орлый бирә. Шул соң, «бу алма булмас, башка зат булар»дип ташлый бирә. Ташлый биргәндә тора да кыз хасыйл була. Баягы кыз буладыр да әйтә: «Син, ди, мин әйткәннең бәрен ясадыңма»,— ди.

Йасадым.

— Котылдыңма?

— Котылдым.

«Ну инде улай булса җөр, ди, фәлән җирдә урман бар, ди. Күркәмлегемә кызыгып, сине берәү булмаса берәү үтерәр, ди. Гомер итәлмәсбез, ди. Шул урманга барып, шул урманда бер өй бар, шунда гомер итәрбез», ди. Шуннан киткәннәр урманга. Шул урманга барып, ничә бер җыллар гомер итеп торганнар. Аларның инде бала-чагасы булганмы, булмаганмы — белмәем.

*Волгоград өлкәсе Палласовка районы «Фурманов» совхозының 3 номерлы бүлекчәсендә Җаппаров Мөхәммәтҗаннан (1902 елгы) 1978 елның маенда язып алынды.*

# ГОМӘР БӘШИРОВНЫҢ «И ЯЗМЫШ, ЯЗМЫШ» ПОВЕСТЕ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘР

Исәнмесез, Гомәр ага!

Бүген яңа килгән санда Сезнең «И язмыш, язмыш...» повестен бер сулыштан йотылып укып чыктым да хат язарга утырмый түзә алмадым.

Әсәрне укыганда, бөтен барлыгымны соклану биләп алды. Сюжетның эчтәлек — чорына хас, гаять киеренкелеге дә, сөйләмнең чын халыкчан-тормышчанлыгы да, теленең искиткеч нәфислеге дә, Сезнең картаю белмәс иҗади дәрт-куәтегез дә — барысы да сокландырды. Повестьның һәр җөмләсе — чын татарча, халыкчан итеп, җырлап торган итеп әйтеп бирүнең гүзәл үрнәге. Әсәр бурыч-иман, анага тирән хөрмәт-мәхәббәт мәсьәләләренең, яшьлек мәхәббәтенең мәңге ачылып бетмәгән серләренә мөрәҗәгать итүе белән гаять заманча яңгырый.

Повестьны укып чыккач, ул биргән сәнгати ләззәт-хистән, ул уяткан уйлардан айный алмый утырдым. Шунда кинәт әсәрнең исеме «И язмыш, ялмыш...» дип түгел, нигәдер «И, әни, әни...» булып яңгырап китте. Нилектән бу? Әсәрнең герое әнә «ант» сүзенә дә «искелек калдыгы түгелме?..» дип шикләнеп карый. «Язмыш» сүзе исә халкыбызда борын-борыннан «язмыштан узмыш юк» дип, фанатик мәгънәдә йөри ич. (Хәзер генә ул «язмыштан узмыш бар!» дип укучыны ышандырырга тырышу китте). Димәк, әсәр герое үз хикәятен дә «искелек исе килә» дип алай атамас иде шикелле.

Ярый, монысы минем тик шәхси фикерем генә. Иң мөһиме — әсәр сокландыра, уйландыра.

Яңа иҗат уңышыгыз белән чын күңелдән тәбриклим, Гомәр ага!

Күп сәламнәр юллап, яңа иҗат уңышлары вә шатлыклары теләп:

**Рафаил ТӨХФӘТУЛЛИН**

Хөрмәтле Гомәр ага!

«И язмыш, язмыш»ны укыдым. Гадәттәгечә канәгать хасил иттем. «Ат аунаган җирдә төк кала» дип юкка гына әйтмәгәннәр шул. Сез әнә кайсы заманнарны уятып, сөйләп биргәнсез. Чыннан да, ипи тотып ант итүләр белән революция тәэсирендә туган өр-яңа кешенең кичерешләре гаҗәп гади һәм дөрес тасвир ителгән бит! Афәрин, Гомәр абзый! Иҗади уңышлар телим.

**Нури АРСЛАН**

Моннан берничә еллар элек «Казан утлары»нда Гомәр абый Бәшировның «Сарут» хикәясен укып мин таң калган идем. Менә быел хөрмәтле язучыбызның тагын бер әсәре — «И язмыш, язмыш» дип аталган повесте басылды. Повестьны мин бер тында укып чыктым. Яратып, исем китеп, сокланып укыдым. Әсәр һәр яктан камил. Сиксән биш яшьлек кешенең шундый тәэсирле итеп мәхәббәт хикәясе яза алуы үзе бер могҗиза. Әдәбиятта мондый хәл сирәк очрый.

Бер дә арттырмыйча әйтергә мөмкин: без Гомәр Бәшировның «Намус» романын укып, аннан өйрәнеп, аның белән рухланып үстек. Г. Бәширов безнең өчен һәрвакыт үрнәк булды. Бүген дә ул яшьләр өчен генә түгел, минем үзем өчен дә, минем кордашлар өчен дә буй җитмәслек талант иясе булып кала бирә. «И язмыш, язмыш» повесте моңа ышанычлы дәлил булып тора.

**Нурихан ФӘТТАХ**

Хөрмәтле якташ һәм кордаш Гомәр!

Әле генә «Казан утлары»ның 3 нче санында басылган «И язмыш, язмыш» дигән озын хикәягезне укып чыктым да, шуның хакында фикеремне язарга булдым.

«Иске байның келәтендә он бетте дигәч тә, өсәк төбен себерсәң, бер күәслек он чыга» дигән сүз бар бугай. Шуның шикелле, үзенең күп әсәрләрендә байтак яшь йөрәкләрне җилкендергән карт әдип хәзинәсендә әле хәтта картрак йөрәкләрне дә кытыкларлык татлы, образлы сүзләр калган икән. Бу әсәрне укыгач, яшь чаклар искә төшеп, күңелем кытыкланып алды. Их, бар иде безнең дә яшь чаклар...

Иң элек шул заман турында. Ие, кордаш, без гаять бай эчтәлекле, кызыклы да, авыр һәм бераз четерекле дә — һәртөрле вакыйгаларга гаять бай, гаҗәеп бер заманда яшәдек. Бездән элегрәк яшәп китеп барган буыннар да, киләчәк буын кешеләре дә көнләшерлек гаять бай эчтәлекле заман бу. Заман безне иркәләде дә, шелтәләде дә, маңгайга чирткән, муен тамырына кундырган чаклары да булды. Ай-һай, кешесенә карап булгалады андый чаклар да... Әмма моның өчен без үзебез яшәгән заманга үпкәләмибез. Чөнки ул — безнең заман, үзебезнеке! Ул безне чәчләребездән тартып үстерде. Үсәргә сәләтле кешеләрне тәхетләргә мендерде...

Әгәр үзебез яшәгән заман турында чын дөресне, ак кәгазь өстенә төшереп, киләчәк буын кешеләре — оныкларыбызга мирас итеп калдыра алсак, бу аларга дөнья бәясе бүләгебез булачак. Монда һич тә шик юк. Сез моны булдыра аласыз һәм Сезнең хезмәтегезнең шундый булуына ышаныч та зур. Озын гомер, какшамас сәламәтлек юлдашыгыз булсын!

Киләчәк буынга мирас калдыру теләге миндә дә булды, булмады түгел. Ләкин кешеләр барысы да бер үк микъдарда сәләтле булмаган кебек, «язмыш» аларга бүләк иткән мөмкинлекләр дә граммлап бүленмәгән...

Инде хикәянең кабыргаларын капшап карыйк.

Башта ук әйтеп куйыйм, хикәя миндә яхшы тәэсир калдырды. Гасыйм агайның бер ел чамасы вакыт эчендә кызын — атасы ризалыгыннан башка коммунистка кияүгә чыгарга җыенган үзсүзле кызын — алтын-көмешкә күмәрлек, ефәккә урарлык, шуның өстенә кызына шәһәрдә я фатир табып, яисә йорт алып бирерлек хәлле нэпманга әверелеп китүе дә гаҗәпләндермәде (элек сельпо рәисе булганлыктан, сәүдәнең нечкәлекләрен белгәндер). Әмма Зәйни уйландыра. Ул анасына зур хөрмәт белән караучы буларак бик уңай тәэсир калдыра. Шулай да Кызыл Армиядә хезмәт иткән, бер ел Мәскәүдә укып кайткан Зәйни нигездә бик үк шәп егет түгел булып чыга. Беренчедән (ничек кенә булмасын!), ул үзенең сөйгәнен, комсомолка кызны (әле аңа унҗиде яшь кенә) кыска сыйраклы бай малаена корбан итә, икенчедән, ул һаман хосусый милекче крестьян булып кала түгелме соң? Ул өйләнәсе иткәндә, беренче чиратта, әнисенә килен, йортка хуҗа хатын булдыруны максат итеп куя шикелле. Бу исә Хәмдүнәне тагын күпмедер вакыт шәһәрдәге ире турында уйланып саргайту булыр иде кебек. Менә шуңа күрә дә яшь комсомолка кыз чаяланып китеп, протест белдерә дә. Ә Зәйни аны язмыш кочагына ташлый да, анасының түй ризыкларына да артын куеп, дулап чыгып китә. Болай шәп түгел, минемчә. Зәйнине камилләшкәнрәк итеп күрәсе килә.

**Гасыйм ЛОТФИ**

## Маннур Саттаров

### Әлкәш Ибрай бәете

Сандугачның сайравына
Килә еласыларым.
Төшләремә дә кермәде
Әлкәш буласыларым.

Һавада йолдыз ничәдер,
Ничә баксам күчәдер.
Күзем йомсам, күз алдымда
Җем-җем иткән шешәдер.

Әлкәшләрнең закускасы
Кыяр белән кәбестә.
Әлкәш күргән михнәтләрне
Яза микән фәрештә?

Каз йөгерә, каз йөгерә
Боты озынга күрә.
Башым айныткычтан чыкмый,
Борным кызылга күрә...

Җаныкаем, Җамалым,
Белмисең хәл яманын.
Кибет ябык сәгатьләрдә
Ут эчендә янамын.

Кыйблалардин искән җилгә
Бөгелә талның нечкәсе.
Әнкәемнең биш улыннан
Булдым үкенечкәсе.

Телеграм баганасы
Олы юлга маяк ул.
— Абынасыңмы? — дип сорыйлар,
Абынмаган кая ул!

Уң кашым да тартадыр,
Сул кашым да тартадыр.
Ике кашым бергә тартса,
Баш ялангач кайтадыр.

Ике юлның арасы,
Без кайсыннан барасы?
Иртә торсам, гел бер кайгы:
Кемнән бер сум аласы?

Уфаларга барам дисең,
Барсаң, бәгърем, бара тор.
Бар нәчәлник эштән кугач,
Әлкәшне кем яратыр?

Агыйделдән агып килә
Аракы шешәләре.
Бер көн бакыр, биш көн такыр
Әлкәшнең кесәләре.

Алларым да бар минем,
Гөлләрем дә бар минем.
Чалбарымны сатып эчкән
Көннәрем дә бар минем.

Әнкәй, бәне ник таптың,
Ник таптың да ник бактың?
Минем бурычларны түләп,
Үзең бурычка баттың.

Һавадагы асыл кошны
Куа килә карчыга.
Эчмәм дигән көннәремдә
Дуслар чыга каршыга.

Сибелә сачем, сибелә сачем,
Сибелә, җилгә тарала.
Я утка сал, я суга сал,
Я дуслардин арала.

Тау астында киң дала,
Җиләк җыя бер бала.
Әлкәш булмас булса гына
Тусын икән ир бала.

Түтәлләрдә үсеп калды
Утырткан суганнарым.
Әлкәшләр йортына салды
Бәйләп үз туганнарым.

Таш кибеткә шәраб кайтса,
Барлык әлкәш җыелыр.
Алар булып, мин булмасам,
Бәгырьләре кыелыр.

Больницаның бакчасы,
Тимер биктә капкасы.
Бер шешәдән эчкән дуслар
Бәхил булсын барчасы.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫНДА

28 августта Татарстан язучыларының ачык партия җыелышы булып узды.

Җыелыш СССР Язучылар союзының «Дөнья язучыларына мөрәҗәгате»нә багышланган митинг белән башланып китте. Чыгыш ясаучы язучылар Р. Харис, С. Сабиров, Ә. Гадел, М. Әгъләмов әлеге мөрәҗәгатьтә әйтелгән дөньякүләм әһәмиятле фикерләрне яклаулары турында аны һәр язучы үз иҗаты белән исбатларга, тормышка ашыру өчен көрәшергә тиешлеге турында сөйләделәр.

Аннан соң Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мостафин «Иҗат эшендә үзгәртеп кору мәсьәләләре һәм һәр язучының шәхси җаваплылыгы» дигән темага доклад белән чыкты.

Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, язучылар А. Расих, Х. Госман, Ә. Еники, Л. Ихсанова, Г. Ахунов, Д. Вәлиев, Л. Хәмидуллин, Р. Мингалимов, Р. Низамиев һ. б. чыгыш ясады.

## ТУКАЙГА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

Киев шәһәрендә татар халык шагыйре Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган кичә уздырылды.

Әлеге чара Украина Художниклар союзы остаханәләренең берсендә оештырылган иде. Остаханә хуҗасы рәссам Рафаэль Мәсәгутов һәм аның иҗатташлары ярдәме һәм булышлыгы белән, өч өлештән торган күргәзмә әзерләнгән иде.

Беренче бүлеккә Г. Тукай әсәрләренә иллюстрацияләр һәм шагыйрь образы гәүдәләндерелгән портретлар тупланган.

Икенче бүлектә Г. Тукайның татар, рус, украин телләрендә чыккан китаплары урын алган.

Бөек шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында укытучылар Әсгать Кашапов һәм Таһир Абдуллин сөйләделәр.

Соңыннан Г. Тукай сүзләренә җырлана торган әсәрләр башкарылды.

## ТУКАЙ ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ

Казахстанның «Язучы» нәшрияты күптән түгел Габдулла Тукайның сайланма әсәрләрен бастырып чыгарды. «Күңел йолдызы» дип аталган бу җыентык сөекле шагыйребезнең казах телендә дөнья күргән җиденче китабы. Аңа кертелгән барлык шигырьләр, әкиятләр һәм поэмаларны галим һәм шагыйрь Түкән Әбдерахманов яңабаштан тәрҗемә иткән. Г. Тукайның йөз еллыгына багышлап нәшер ителгән бу китапта авторның портреты да бар.

Эстониянең «Сирп я вазар» («Урак һәм чүкеч») әдәби газетасы (1986, 11 июль) күренекле әдәбиятчы Оскар Кунингасның «Габдулла Тукай» дигән мәкаләсен игълан итте. Анда татар әдәбияты классигының тормышы һәм иҗаты яктыртыла. Мәкалә белән бергә Тукай һәйкәленең сурәте дә дөнья күргән. Эстон укучылары газетаның шушы ук санында классик язучыбызның «Шагыйрь» дигән әсәре белән дә таныштырыла. Аны Айн Каалеп турыдан-туры татарчадан тәрҗемә иткән.

Молдавиянең «Молдова сочиалистэ» («Социалистик Молдавия», 1986, 22 июль) газетасында гагауз язучысы Николай Бабуглының «Дуслык дулкынында» дигән мәкаләсе дөнья күрде. Анда Татарстан җәмәгатьчелегенең сөекле шагыйрен хөрмәтләве — Казанда Тукай музееН ачуы, тантаналы кичә уздыруы, Кырлайда шигырь бәйрәме үткәрүе, бу тантаналарда һәм фәнни конференциядә күп санлы кунакларның да катнашуы, Тукай иҗатының халыкара әһәмияте яктыртыла.

Н. Бабуглының «Дуслык бәйләнешләре» дигән күләмлерәк мәкаләсен молдаван әдәби газетасы «Литература ши арта» («Әдәбият һәм сәнгать», 1986, 31 июль) гагауз телендәге сәхифәсендә игълан итте.

## ШАГЫЙРЬЛӘР ИСЕМЕНДӘГЕ СТИПЕНДИЯЛӘР

РСФСР Министрлар Советы Муса Җәлил һәм Габдулла Тукай исемендәге махсус стипендияләр булдыру турында карар кабул итте. Җәлил исемендәге стипендия Казан дәүләт педагогия институтында иң яхшы билгеләренә генә укыган һәм шуның белән бергә фәнни эштә, җәмәгать эшләрендә актив катнашкан студентларга бирелачәк. Тукай стипендиясен шундый ук шартлар нигезендә Алабуга дәүләт педагогия институты студентлары алачак.

Халкыбызның бөек шагыйрьләре исемен йөрткән бу стипендияләр Г. Тукайның 100 еллык, М. Җәлилнең 80 еллык юбилейлары хөрмәтенә булдырылды.

## СВЯТОСЛАВ РИХТЕР КАЗАНДА

Святослав Рихтерның исеме бөтен дөньяга билгеле. Атаклы пианист август аенда Татарстан тамашачылары алдында чыгыш ясап, фортепьяно музыкасын яратучыларга гүзәл музыкаль мизгелләр бүләк итте. Консерваториянең Актлар залында биргән концертын С. Рихтер үзенең сабакташы һәм дусты Нияз Даутов истәлегенә багышлады.

## РЕДАКЦИЯДӘ ОЧРАШУ

13 августта «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре һәм редколлегия членнары

Украина ССРның атказанган рәссамы, Ленин комсомолы премиясе лауреаты яшьләрнең һәм студентларның XII Бөтендөнья фестивале эмблемасының авторы Рафаэль Мәсәгутов белән очраштылар.

— Мин Казанга буш кул белән кайтмадым,— диде рәссам.— Бүләгем — Муса Җәлилнең Киевта татар һәм украин телләрендә чыккан китабы. Бу җыентыкта мин эшләгән 120 ләп рәсем-иллюстрация бар. Украинада Муса Җәлил шигырьләрен яраталар, шундый олы шагыйрьне тудырган татар халкына хөрмәт белән карыйлар.

Сөекле Тукаебыз иҗатына иллюстрацияләр эшләдем, хәзерге көндә мәшһүр шагыйрьнең китабын чыгаруны юллап йөрим. Моннан тыш, Киевта украин телендә Кол Галинең үлемсез китабы «Кыйссаи Йосыф»ны әзерлибез.

Рәссам үзенең иҗат планнары белән уртаклашты һәм күп кенә сорауларга җавап бирде.

## ГАЛЕРЕЯГӘ БҮЛӘК

Әлмәт йорт төзү комбинаты администрациясе социаль-культура чаралары акчасына 2747 сумлык сынлы сәнгать әсәрләре сатып алды һәм шәһәрнең картиналар галереясына бүләк итте.

Алар арасында ТАССРның халык художнигы М. Усмановның «Әлмәт офыклары», «Буровойда кыш», республикабызның атказанган культура работнигы У. Абдуловның «Казан елга порты», Лениногорск рәссамнары О. Кульпинның «Ромашкино нефть промыселы», В. Кротовның «Тынлык» картинасы һәм башка әсәрләре бар.

Әлмәт картиналар галереясында хәзер 700 дән артык экспонат саклана.

## ГАРӘП ТЕЛЕНДӘ

Шагыйрь Равил Фәйзуллинның Сүрия башкаласы Дамаск шәһәренең «Әльбас» үзәк газетасында бер бәйләм шигыре авторның рәсеме белән һәм иллюстрацияләр белән басылып чыкты. Сүриянең күренекле шагыйре Айман Әбу Шаар тәрҗемә иткән шигырьләр ил радиосыннан да яңгырады. Әле күптән түгел генә Дамаскта басылып чыккан «Совет поэзисе антологиясе»нә дә башка шагыйрьләр белән бергә, Равил Фәйзуллинның шигырьләре кертелгән.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

18 августта Мәскәүдә яшәп иҗат итүче шагыйрь Гәрәй Рәхимнең Мәскәү метро төзүчеләре культура йортында иҗат кичәсе булып узды. Мәскәүдә яшәүче язучы Миргазыян Юныс Гәрәй Рәхим иҗаты турында сөйләде.

Культура сарае фойесында күргәзмә оештырылган иде. Анда Г. Рәхим иҗатына, тормышына бәйле булган афишалар, рәсемнәр, язучының рус һәм татар телләрендә басылган китаплары куелган.

Кичә Мәскәү метро төзелеше татар үзешчән сәнгатендә катнашучылар концерты белән тәмамланды.

## АРХЕОГРАФИК ТАБЫШЛАР

Быел июль аенда Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан дәүләт университетының Археографик экспедициясе тикшеренү эшләрен ике төркемгә бүленеп алып барды: тарих фәннәре докторы, профессор Миркасыйм Госманов җитәкчелегендәге зур төркем Горький өлкәсе Пилнә районы татар авылларында булды. Составында тарих фәннәре кандидаты Р. Ә. Шәйхиев һәм журналыбызның тәнкыйть һәм фән бүлеге өлкән редакторы Җ. С. Миңнуллин булган икенче төркем Ульяновск өлкәсе Иске Кулатка районында эшләде. Бу ике төркем алып барган археографик тикшеренүләр нәтиҗәсендә төрле эчтәлекле 100 ләп кулъязма тупланды. Иң кыйммәтле тарихи истәлекләр арасында халкыбызның атаклы мәгърифәтчесе Х. Фәезхановның туган авылы Сабачай тарихы, мәшһүр болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», шулай ук татар шагыйрьләре Г. Утыз-Имәни, М. Акмулла, Г. Кандалый әсәрләренең күчермәләре, XVII-XVIII гасырларда күчерелгән хикәя, башка кулъязма китаплар бар.

# КӨЗ МӘЛЕ

...Күктә көзге болытлар йөзә. Ничектер кулың белән кагылсаң, алардан кояш нурлары тамар шикелле. Җиргә алтынсу төс иңгән. Алтын көзнең тылсымлы җиле каен ябалдашларын да үзенчә «чалартып» узган. Яр астында алкын су күренеп тора. Елганың көзгесе шундый зәңгәрлек белән җемелди, мондый төсләр балкышы көзен генә буладыр...

РСФСРның атказанган рәссамы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әнәс Тумашевның «Көз мәле» исемле пейзажы шуны раслый: автор иксез-чиксез табигать манзарасыннан үзенең күңелендәге аһәңгә дәвам була алырлык халәт-мизгелне сәнгатьчә тотып алуга ирешкән. Нәкъ менә шушы күренеш сәнгать остасына үзенең күңел халәтен төсләр балкышы аша аңлатырга ярдәм иткән.

Көз мәле... Картинада табигать матурлыгының сулуы сурәтләнми. Юк. Рәссам үзенең әсәрендә көзге төсләрнең бәйрәмчә кабынып китүен бирергә омтылган. Һәрнәрсәдән затлылык сирпелә. Алтынсу төсләрдә уйчанланып калган Җирананың зирәклеге бөтен барлыгы белән чагыла төсле. Боларның барысы да рәссамның көзге баеш алды мизгелен нечкәләп тоюыннан киләдер.

Соңгы елларда пейзаж өлкәсендә аеруча нәтиҗәле эшләүче рәссам Ә. Тумашев «Көз мәле» әсәрендә үзенең уйчан иҗатчы икәнен шактый ачык итеп раслый. Әлеге картинасында ул композицион чишелешләр остасы булуын да, табигатьнең күзгә бәрелеп тормаган чалымнарын тотып ала белүен дә күрсәтә. Иң әһәмиятлесе: Туган илгә мәхәббәт белән сугарылган пейзажларда художник-гражданин төсмерләнә.

**Татьяна СЕДЫХ,**
Татарстан сынлы сәнгать
музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанда Габдулла Тукай музее.

Рөстәм **МАНСУРОВ** һәм Дмитрий **БУНТУКОВ** фотолары.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1987 ЕЛДА

Татар совет әдәбиятының күренекле әсәрләре укучыларга иң элек «Казан утлары» журналы аша барып ирешә.

Редакция портфелендә язучыларыбызның күләмле проза әсәрләре байтак. Менә аларның кайберләре:

Нурихан Фәттах. «Сызгыра торган уклар» романының икенче китабы.

Мәдинә Маликова. «Басып сайрар талы бар». Роман.

Гариф Ахунов. «Идел кызы» романының икенче китабы.

Нәби Дәүли. «Без дөньяга килдек» повестеның икенче китабы.

Рафаил Төхфәтуллин. «Чатта тукталу». Повесть.

Миргазиян Юныс. «Таңда Босфор аша». Повесть.

Вакыйф Нуруллин. «Җавап бир...» Повесть.

Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәхмүт Хәсәнов, Мәгъсүм Насыйбуллин һ. б. журнал өчен яңа әсәрләрен тәгәлләп киләләр.

«Казан утлары» поэзия һәм драматургия әсәрләренә, тугандаш халыклар әдипләренә, яшь язучылар иҗатына, бүгенге көн проблемаларын күтәргән очерклар һәм публицистик мәкаләләргә, әдәби хәрәкәт, тарих, сәнгать мәсьәләләренә киң урын бирә. Иҗат серләре турында яңа язмалар, әдәби мирас үрнәкләре, истәлекләр, хатлар укучыларыбызда шулай ук кызыксыну уятыр.

Журнал сәхифәләре сезгә киләсе елда да рухи канәгатьлек, яңа очрашулар шатлыгы алып килер дип уйлыйбыз.

«Казан утлары»ның Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 73210. Бер елга язылу хакы — 10 сум 80 тиен.

РЕДКОЛЛЕГИЯ.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)